
# КАЗАН УТЛАРЫ

10. 1994



## Равил Фәйзуллин

### Кайсын пигы итәгендә

Ватаныңа килеп, тауларыңда йөрим.
Үзең исән чакта соңладым.
Бер юаныч: исемең йөрткән пикны
үз күзләрем белән күралдым.

Монда булып киткән зур шагыйрьләр
данлап язсалар да тауларны,
таулар җанын йөрткән халык рухын
килгән-киткән сәях аңлармы?

Таулар матур. Әмма кырыс та алар.
Ташны тирең тишсә — син ашлы...
Әйтә идең: тауларымның минем
күләгәләре дә кояшлы!

Киртләч-киртләч икән тау очлары —
гүя кардиограмма сурәте!
Ничек түздең икән, йөрәгеңә
ишелгәндә халкың хәсрәте?

Синдәй ирләр барда, аз халык та
ишле, бөек булып танылa.
Әйтелгән сүз, күкрәү-яшен булып,
әверелә дөнья данына.

...«Ах! тау юклыклар...» дип язган идем
күптән инде — үсмер чагымда.
Гомер тавын төшеп кабатлыймын,
таулар юк! дип, тагын, тагын да.

Казаннарга килеп чыга идең,
күңелләргә шатлык өләшеп.
Егет булып калдың күңелләрдә,
бер символы булып көрәшнең.

Син бер ныклы тере күпере идең
Болгар иле белән Балкарның.
Җәрәхәтле таш та җанланадыр,
канат тисә — синдәй шонкарның!

...Кайсын пигы. Биек. Итәгендә
яшь бөркетләр канатланалар.
Таулар биеклекне югалталмый —
алар күккә кадакланганнар!

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**(864)**

**1994**

КАЗАН


## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ


Я. ЗӘНКИЕВ. Иртәш таңнары. *Роман* ......... 3

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. «Заман кемнең заманы?» *Яңа шигырьләр* ......... 52

Н. ӘХМӘДИЕВ. Бүләк. *Шигырьләр* ......... 62

С. САБИРОВ. Хәвефле сәфәр. *Повесть* ......... 66

Л. ШАГЫЙРЬҖАН. Багышлану. *Шигырьләр* 111

Р. ИДИЯТУЛЛИН. Шундый көннәр була. *Шигырьләр* ......... 117

М. МӘҺДИЕВ. Сагынам, дуслар, илкәйне. . 123


ПУБЛИЦИСТИКА


Р. ӘМИРХАН. Мәдәниятебез сагындагы Мәдинә ......... 145


ХАЛКЫБЫЗ ТАРИХЫНА


А. КАППЕЛЕР. Идел буе төркиләренең килеп чыгышы. ......... 155


МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА


Р. ХӘМИДУЛЛИНА. Гаяз Исхакый — хәлфә. ......... 162


СӘЙФИ КУДАШНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА


Хәсән Туфан һәм Сәйфи Кудаш хатлары .. 165


БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ


Т. ГАЛИУЛЛИН. Ул яшәсә, без бәхетле. *(Казан университетының татар бүлегенә 50 ел)* ......... 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ......... 190

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрваз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң а д р е с 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
хатлар — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, сәнгать,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

# В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: вторая книга романа Я. ЗАНКИЕВА «Зори Иртыша»; повесть «Опасное путешествие» С. САБИРОВА; воспоминания М. МАГДЕЕВА «Тоскую, друзья, по родине»; стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, Н. АХМАДЕЕВА, Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ, Р. ИДИАТУЛЛИНА.
«Публицистика»: Р. АМИРХАН рассказывает о деятельности М. Рахимкуловой в области культуры.
«К истории народа»: А. КАППЕЛЕР. «Происхождение Приволжских тюрков».
«К истории культуры»: статья Р. ХАМИДУЛЛИНОЙ «Гаяз Исхаки-учитель».
«К 100-летию С. Кудаша»: письма Х. Туфана и С. Кудаша.
«Наш календарь»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА посвящается к 50-летию отделения татарского языка и литературы Казанского госуниверситета.
Хроника культурной жизни.
«На наших обложках»: «Кайсын Кулиев» — картина художника Р. Имашева; известный поэт Зульфат.

# IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the second book of Ya.Zankiev's novel «The Irtish Daybreaks»; S. Sabirov's novel «The Dangerous Trip»; M. Magdiev's recollections «I Miss My Birthplace»; the verses of R. Phaizullin, N. Akhmadeev, L. Shakirzyaniva, R. Idiattullin.
«Publicism»: R. Amirkhan tells about cultural activities of M. Rakhimkulova.
«To the History of Nation»: A. Kappler «Descent of Volga Turki».
«To the History of Culture»: R. Khamidullina's article «Gayaz Iskhaki is a Teacher».
«To the 100 anniversary of S. Kudash»: the letters of Kh. Tuphan and S. Kudash.
The chronicle of cultural life.
In our corvers: R. Imashev's picture «Kaisin Kuliev»; the well-known poet Zulphat.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 5.09.94 ел. Басарга кул куелды 12.10.94 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 $^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 876. Заказ А-411. Бәясе 1100 сум.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1994 ел.

# Чәчмә әсәрләр



**Якуб Зәнкиев**

# ИРТЕШ ТАҢНАРЫ

РОМАННЫҢ ИКЕНЧЕ КИТАБЫ

## Сүз башым

**Үзем Тубыл ягы кешесе булсам да, ерак Өркет (Иркутск) каласында туганмын. Аңа кадәр исә...**

**Бабам Зәнки, җирсез сарт булуы аркасында, гомере буе иза чигеп ялчылыкта яшәгән. Чирек гасыр дәвамында Тубыл белән Иркутск арасында байлар товарын ташыган. Олаучылар Тубылдан кыйммәтле тире-пушнина, замш биләйләр алып китеп, Өркеттән кытай чәе, ефәк, мануфактура төяп кайтканнар. Кайчагында юлга бишәр йөз ат чыгып китә торган булган, сәфәрләре еллар буе дәвам иткән. Байкал күле тирәсендә тимер юл төзелә башлагач, бабам шунда биш ел таш каерган. Кулдан көч киткәч, Өркеттә, Метелев дигән купецта, ун ел дворник булып торган. Шул чагында улы Камалины, минем этине, үз янына алдырган һәм аны камыт тегүче итеп урнаштырган. Әнкәм Закирәбану Татарстанның Норлат районы Өрә авылы Вәлит мәзин кызы булган. Өркет ягына бәхет эзләп килеп чыккан, әти белән алар танышып кавышканнар. 1917 елның 6 апрелендә дөньяга мин килгәнмен. Нәселебезнең башында Зәнки шәех-хуҗа тора. Октябрь революциясе, ярлы-ябагай, нужа куучы кешеләрдә якты өметләр уятып, әтинең колагына «сартларга җир бирeләчәк!» дигән куанычлы хәбәр килеп ирешкән, ул озын-озак уйлап тормаган, гаиләсен алып туган якларга, Тубыл районының Хуҗайлан авылына әйләнеп кайткан... Балачагым, үсмер вакытым шул авылда үтте. Башта Тубылда ШКМны һәм татар педучилищесын бетердем, соңрак, 1940 елда, Төмәндә укытучылар институтының физика-математика бүлеген тәмамладым. Сугыш башланганчы Төмәндә урта мәктәптә физика-математиканы укыттым.**

**1942 елның маенда үз ирегем белән сугышка доброволец булып киттем, бик күп фронт юлларын үтеп, сугышны Прага шәһәрендә тәмамладым. Танкларга каршы сугышучы взвод командиры идем. Беренче һәм икенче дәрәҗә «Ватан сугышы», «Кызыл йолдыз» орденнары, күпсанлы медальләр белән бүләкләндем.**

**Сугыштан кайткач Төмән өлкәсе мәктәпләрендә завуч, директор, Тубыл район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләдем.**

**1957 елда «РСФСР мәктәпләренең атказанган укытучысы» дигән исем бирделәр. Бүгенге көндә пенсионер. Тубыл шәһәрендә яшәп ятам. Казан газета-**

**журналлары белән тыгыз бәйләнештә торам, җирле матбугатта да очеркларым, сугышчан хатирәләрем өзлексез басылып килә. Быел Төмәндә балалар өчен «Кайчыколак» дигән хикәяләр җыентыгым басылып чыкты.**

**Без яшәгән заманда, без гомер үткәргән җирләрдә укытучының роле ифрат зур иде. Шул үзем татыганнар, күргән-белгәннәр күңелемә тынгылык бирми башлаган чорда безнең төбәккә Казаннан бер төркем язучы килеп төште. Ф. Хөсни, Ш. Галиев, А. Гыйләҗевләр белән очрашу минем тормышымны яңартып, үзгәртеп җибәрде. Укытучыларга багышлап, себер татарларының тормышын, гореф-гадәтләрен, йолаларын сөйләп бирәсем килде. Әлеге фикер кырык ел буена миңа тынгы бирмәде, һәм, нәтиҗәдә, шушы әсәр туды...**

**Дөрес, мин әдәбиятның бөтен серләрен төшенеп җитә алмадым, үзебезнең якларда киңәш-табыш итәрлек белгечләр дә юк иде. Әмма бәхетемә күрә, талантлы, игътибарлы, ялкынлы язучы Аяз Гыйләҗев ярдәмгә килде, әдәби эшкәртүгә ул бик күп көч түкте, кадерле вакытын жәлләмәде. Аңа рәхмәтем чиксез зур. Икенче китапны басмага әзерләгәндә Аязның сәламәтлеге җитешеп бетмәгәнлектән, аның тормыш юлдашы Нәкыя ханым да зур ярдәм күрсәтте. Шул уңайдан аңа да тирән рәхмәтемне белдерәм. Эш дәверемдә, фольклор туплау, киңәш-табыш итүдә тормыш юлдашым Рәшидә олы ярдәм күрсәтте. Рәхмәт.**

**Аяз Гыйләҗев белән 29 ел таныш булуым, бертуктаусыз хатлашып һәм күрешеп сөйләшүләрем минем фикер агышымны да, дөньяга карашымны да үзгәртте. Мин үзем дөньяны гел алсу сыйфатларда гына күреп үскән кеше. Сугышта «За Родину, за Сталина!» дип атакага ташланучылар арасында мин дә бар идем. Кульязмамның беренче вариантын Казанга алып баргач, Аяз карап чыкты да беренче сабакны бирде: «Кызартма, кабартма, нәкъ тормыштагыча яз!»—диде. Мин шуннан соң үз тормыш юлыма, тирә-юньгә, җәмгыятебезнең төзелешенә, Сталинның кара эшләренә тәнкыйть күзлегеннән чыгып карый башладым. Үзебезнең себер татар авылларының тарихи үткәннәрен нигезләнрәк тикшердем һәм халкыбызның трагик үткәннәре белән очраштым. Чынбарлыкны үз төсендә күрә башладым. Минем дөньяга карашымда булган бу үзгәрешләрне икенче китабымны укучылар тоярлар һәм унай бәяләрләр дип өмет итәм.**

**Кадерле укучым!**

**Тубыл-Иртеш буйларында яшәүче милләттәшләремнең тормышлары турында Себер халкы тарихында беренче булып язылган шушы проза китабы аша чынбарлыкны житкерергә бик тырышкан Алла бәндәсен, әгәр сезгә ошамаган яклары булса, кичерүегезне үтенәм!**

**Якуб ЗӘНКИЕВ.**
**Тубыл шәһәре. 18 апрель, 1994 ел.**

## I

Сугыш башлангач, ил күген хәсрәт болытлары томалап, күз яшьләреннән ташулар акканда, уртак хәсрәт, уртак кайгылар моңарчы тылда яшәп яткан Мөхәммәт Уразаевка да тәэсир итми калмады, әлбәттә. Хатыны сугышта, улы Шамил утның иң кызган җирендә — алгы сызыкта, хатлар сирәк килә, анда да чамадан тыш озак йөри. Бу хәлләр берләшеп аның сынык күңелен көндез дә, төнлә дә биләп торалар, ул — үз күңеленә хуҗа булырга омтылган, читләр тәэсире белән яшәмәгән кеше, ихтыяр көченең әкеренләп кими барганын сизенә башлады. Сугышка мөнәсәбәте ифрат үзенчә иде аның. Кайгырды, куанган чаклары да булгалады. Әһә, диде ул эченнән генә, дөнья совет властенын көчен, өстенлеген һәм какшамас бердәмлеген күрсен әйдә! Моңарчы икеләнеп, шигәеп маташкан илләр дә дөрес, хак юлны аера алырлар! Ленин төзегән дәүләтне җиңәр көч юк, булмас та!

Сугыш башланды, туктаганы юк — бара. Мөхәммәт бөтен ил белән, менә-менә безнең гаскәрләр фашистларны үз җирендә тукмый башлар-

лар, дип көтә. Юк кына бит, киресенчә, фронт хәлләре көннән-көн хәтәрләнә, көн туды исә радиодан Левитанның канга тоз салучы тавышы гел бер үк сүзләрне тәкърарлый: «Каты сугышлардан соң безнең гаскәрләр фәлән-фәлән шәһәрләрне, фәлән-фәлән авылларны калдырдылар».

Левитан авызыннан чыкканда бу сүзләр җанны өшетеп узсалар, улы Шамилдән килгән хатларда «чигенәбез, чигендек» сүзләре йөрәкне телгәләп, шомлы җил булып таптап үтәләр. Чигенүчеләр арасында аның йөрәк парәсе — улы да бар. Саниясе, сугышка алынган врач буларак, алай ук ут астында йөрми торгандыр торуын... Дары исе иснәгән Мөхәммәт лазаретларның тылдарак, тынычтарак булуын белә иде. Туктаусыз чигенеп барган очракта госпитальләрнең дошман кулына төшү ихтималын да уйлагач, Мөхәммәтнең тәне эсселе-суыклы булып китә дә, төн йокыларыннан мәхрүм калып озак-озаклап түшәмгә карап ята. Йокылы-уяулы ята торгач, түшәм сугыш кырына әйләнә, әнә аның Шамиле мылтыгын кысып тотып, юк, алга түгел, артка йөгерә... Йөгерәләр, качалар, туган җирне немец фашистларына калдырып качалар. Әнә теге, түшәм тактасының чокырланып торган дәү ботак эзендә Саниясенең ак халаты күренеп-күренеп китә...

Соңгы атнада да Мөхәммәтнең борчылулары артты: ни Саниясеннән, ни улыннан хат-хәбәр юк. Ә радио һаман бер үк сүзләрне такылдый: «Фәлән-фәлән шәһәрләр калды... Дошман фәлән шәһәрләрне чолгады».

Өйдә чакта тәрәзәдән күзен алмаган Мөхәммәт хат ташучының болай таба килүен әллә каян күреп алды, аягына иске галуш элдереп, каударланып ук капка төбенә чыкты. Лыштыр-лыштыр килүче апаның сүрән чыраен, кулындагы сәер, юка гына хат букчасын күргәч коелып инде.

— Әллә?..

Хат якыннан, Тубыл шәһәреннән генә килгән икән. Мөхәммәт иңеннән җиргә төшкән кайры тунын иелеп алды да, шунда ук, капка төбендә, җил күзендә хат букчасын ачты. Хат бик кыска булса да көтелмәгән шикшөбһәләр алып килде. Мөхәммәтне иртәгәге көнгә, сәгать тугызга, НКВД начальнигы бүлмәсенә чакырганнар иде. Моңарчы бу дәһшәт оясына аны чакырып керткәннәре юк иде әле.

Колхозның егәрле, көр атларын берәм-берәм армиягә чүпләп торалар. Мөхәммәткә камыт суккан, ыңгырчак асты чиләнеп бозылган үшән алашаны җигеп чыгарга туры килде. «Вакытында барып житим, ул оешма адәмнәре соңга калганны бер дә өнәми!» — дип, юлга таңнан чыккан иде, чиләнде Мөхәммәт юлда! Аты ике атлый да бер туктый, кычкырып каулый башласаң, күзләрен алартып бер карый да тәртәгә үк тибәргә тотына. Арбадан төшеп, ат алдына чыгып, юлга дип алган бер бөтен икмәкне ваклап-ваклап каптыргалап, алдап кына эшне беразга җайлады Мөхәммәт. Шунда гына ул атның төне буе берни ашамавын, ач икәнлеген аңлады. Нишләмәк кирәк, кайда ипи иснәтеп, үр төшкәннәрдә чөмгереп куып шактый ара үттеләр. Бер иңкүлекне үткәндә ул аркалыкның бушайганын абайлады, төшеп ат башына таба килде. Аркалыкны тыгызлап бетергәч, читкәрәк китеп алашага җилкәсе белән борылып җиңел йомышын үти генә башлаган иде, урманны сискәндереп мылтык гөрселдәде. Соңыннан хәтеренә төшереп, кат-кат уйласа да өзеп кенә әйтә алмады Мөхәммәт: пуля колак яныннан гына сызгырып үтеп киттеме, әллә аңа шулай тоелды гынамы?..

Урманны чыккач, алаша холкын үзгәртте, күз тимәсен, арык бот мускулларын җыярга тырышып туктаусыз арбаны сөйрәде. Йончып, ачыгып таш коймалар арасына кысылган тимер капканы ачып эчкә керделәр, Мөхәммәт тәртә очына дилбегәсен ташлады да икенче катка йөгереп диярлек менде.

Сугыш башлангач, мондагы хезмәткәрләр дә алышынып беткән булып чыкты, аны капитан Лапиков янына керттеләр. Мөхәммәтнең кем

булуын белүгә, Лапиков урыныннан сикереп торды һәм бугазын киереп кычкыра ук башлады:

— Уразаев? Мөхәммәт?! Син ничәгә чакырылулы идең? Тугызгамы? Ә хәзер ничә? Әйт!.. Син мине эшсез утыра дип белдеңме? Юк-барга чакыра дип уйладыңмы? Мин, дәүләтнең иң җаваплы эше тапшырылган кеше, син йолкышны көтеп вакыт үткәрергә тиешме?..

Үз гомерендә мондый сүгенүне ишеткәне булмаган Мөхәммәтнең исе китте, сүзен әйтә алмас булды. Юлдагы хәлләр, атулар турында да әйтермен дип килгән иде, кая ул!

Лапиков самавыр сыман озак сүрелде, яңаклары тимгел-тимгел чуарланды, авызыннан чәчрәгән төкереге Мөхәммәтнең борын очына килеп сыланды. Мөхәммәт бар көчен, сабырлыгын җыеп:

— Ә мин хәзер туп-туры райкомга керәм! — диде.

Лапиковның күзләре акайды, бугаз төере төртеп чыкты, ул үз сүзләренә буылып, йодрыкларын йомарлап Уразаев өстенә килә башлады.

— Үземне мәсхәрәләргә ирек бирмәм,— диде Мөхәммәт агарынып.

— Мин сине!.. Нәсел-нәсәбеңне! Ата-бабаларыңны! Кулак калдыгы! Кучем хан иярчене!.. Нәрсә сөйләп маташкан була бит!..

Әллә капитанның ачуы чыгып бетте, әллә Уразаевның сабырлыгы аны тыйды, ул урындыгына барып утырды, алдындагы кәгазьләрне бер урыннан икенчесенә күчерде, «Казбек» пачкасын алып тәмәке кабызды.

— Якынрак кил! Бу хатларны күрәсеңме?

Мөхәммәтнең күзе дүрт булды: Лапиков өстәлендә хатыны Сания һәм улы Шамил кулы белән язылган ике хат ята иде.

— Ничек килеп кергәннәр алар сезгә? — дип сорады ул, сүзенең мәгънәсезлеген абайласа да. НКВДга хатларның нинди юл белән кергәнен белә ләбаса ул!

— Бу хатларның эчтәлеге хакында синнән алда райкомга мин хәбәр итәчәкмен! Анда аркаңнан сыйпамаслар! Менә күр, улың яза: «чигенәбез дә чигенәбез...» Хатының да шәп сайрый: «читен... авыр... яралылар бер өзлексез килеп тора... Сугышның очы-кырые күренми...» Йә, ничек? Аналы-уллы коткы тараталар! Паникерлар!

— Ялган сөйләмиләр ич! Дөресен язганнар.

— Ах, син дә шул коткыга кушыласың икән әле! Коммунист! Укытучы! Гаилә башы!

Мөхәммәт үзенә адресланган кәгазьләргә үрелгән иде, Лапиков сикереп торды да хатларны сул ягында кукыраеп утырган тимер сейфка бикләп тә куйды.

— Юк,— диде Мөхәммәт әзрәк кенә бер катлы булып күренергә тырышып,— сез миңа шуны аңлатыгыз! Нигә шулай чигенәбез без, нигә дошманга йомшаклыгыбызны күрсәтәбез? Кешеләр җитмиме? Коралмы? Тәртип юкмы?

— Син дошман! — дип бакырды Лапиков.— НКВД стенасы артында шундый провокацион сораулар бирәсең икән, халык арасында ниләр генә лыгырдамыйсыңдыр әле!

Һәм Мөхәммәт Уразаевны — Ялан авылының абруйлы мөгаллимен, сыналган коммунистын подвалга төшереп ябып та куйдылар.

Ул исәңгерәп, һушы китеп ярым караңгы подвалда шактый утырды. Тышта караңгы төшкәнне чамалап, ачыгып, усалланып тимер ишекне ике куллап төя башлады. Куллары аргач туктады, аркасын салкын стенага терәп йокымсырады. Бераздан сак, әмма ап-ачык пышылдаган тавышка сискәнеп ишеккә якын килде. Ишектәге дүрткел тишек ачылды, тишек яктылыгында кәҗә сакал, аннары кәҗә күзләре шәйләнде.

— Борчылма, атыңа печән салдым. Сугардым. Коры аранга керттем,— диде кәҗә сакал.

— Син кем?

— Кем дип... сиңа зыян салучы түгел. Хәтерләп кал. Кирәгем чыгар. Синең дә кирәк булып куюың бар.

— Ничек тә булса райкомга хәбәр ит. «Ялан авылыннан Мөхәммәт Уразаевны камадылар»,— диген. Кем туры килсә дә ярый. Ә ат өчен рәхмәт. Онытмам.

Инде бүген моннан чыгармасларына тәмам ышанып, өстендәге юка бишмәтен җәеп идәнгә йокыга яткач, Мөхәммәтнең арган аңын яшен яктысы кисеп үтте: тавышы таныш ич бу кәҗә сакалның!

Хәтер сүрүен ертып чыккан бу сәеррәк тавышның кемнеке икәнен тәгаен ачыклап бетерә алмаса да, тозакка төшкәч гадәттән тыш сагайган Мөхәммәт: «Канталыев түгелме соң бу! Шул ич, шул мөртәт!» — дип озак кына баш ватты.

Бераздан кәҗә сакал онытылды, тоткын чынбарлыкка — салкын һәм дымлы подвалга әйләнеп кайтты. Иң әүвәле: «Шамилемә бер-бер авырлык килмәсме? — дип изаланды.— Хатларны кайда тоткарладылар икән? Фронт тирәсендәме, әллә монда кайткач кынамы?» Чыбыкның бер очы Саниясенә дә тия калса... Ай-һай, улы да, Саниясе дә гел-гел дөреслекне сөйләп күнеккән, намуслы кешеләр шул. Үткән хатларының берсендә улы: «Чигенеп үтеп барганда авыл кешеләре, карт-корылар, гариплар, бала-чагалар бәргәләнә-бәргәләнә җылыйлар. Безне кемнәр кулына калдырып китәсез?!» дип сораганда, җир тишегенә кереп китәрдәй булам. Әти сез безгә гомер буе: «Сугыш була калса ул, әлбәттә, дошман җирендә барачак, безне җиңәр көч юк»,— дип тукып өйрәттегез. Бүген исә без туп-туры Мәскәүгә тәгәрибез. Арысландай егетләребез мылтык атарга да өлгермичә һәлак була. Унарлаган, йөзәрләгән әсирләр турында сүзләр йөри. Ни булды соң безгә?» — дип батырып язган иде. Шушы кискен сорау, ачы хакыйкать Мөхәммәтнең йөрәген таламаса, бүген, НКВД бинасына кереп, явызлыгы кыяфәтенә чыккан Лапиковка сораулар биреп ачылып китәр идемени? Башына тай типмәгән ич Мөхәммәтнең. Баш җитмәгән сорауларга җавап эзләп кенә маташа!

Ачыкканын, арганын, хәзерге сәгатьтә язмышының аяусызлыгын онытып Уразаевның колагында: «Үз җиребезнең бер карышын да дошманга бирмәбез!» — дигән буш сүзләр яңгырады. Кем әйткән иде соң бу купшы җөмләне Мөхәммәткә? Илгә, халыкка?! Әйткән кеше исенә төшкәч, моңарчы табынган иманы какшагандай булды. Аны курку басты. «Мондый килбәтсез уйларга чумып яши башласаң, бу подвалдан гомереңә чыгармаслар. Юк, юк,— диде ул уйларында үзе белән үзе көрәшеп,— илебез көчле, нык. Гражданнар сугышы елларында, утлы божра эчендә калсак та, күпме дошманны дөмбәсләдек! Көлләрен күккә очырдык!» Уразаев бер хакыйкатькә генә ышана: фашизм җиңеләчәк, тар-мар ителәчәк. Хаклык, гаделлек безнең якта. Читләр җиренә без басып кермәдек, сугышны без башламадык.

Күңеленә батыр, чая уйлар килгәч, Уразаев үзен сугышчан сафта дип хис итеп, нык-нык басып арлы-бирле йөри башлаган иде, маңгае белән шап каты бер нәрсәгә! Дивардан сизгәк сыерның очлы мөгезе булып, тимер чөй тырпаеп тора икән. Шуңа бәрелгән Уразаев. Кан тибеп чыккан ярык маңгаен кулъяулыгы белән кысуга күңеленә тагын да дәһшәтлерәк уй иңде: безнең шанлы гаскәр башлыкларыбыз калмаганмы әллә? Блюхер, Тухачевский, Якир, Егоровлар тезелешеп эзсез югалдылар, китаплардан, дәфтәр тышларыннан аларның рәсемнәрен үзе җыеп йөргән иде ләбаса!

Ике дөньяның олуг бәрелеше алдыннан гына аларның гаип булуы үзенә күрә бер шик тудырды. Ул Блюхерны күреп тә белә иде ич! 51-нче Блюхер дивизиясе Колчакны Себердән, Тубыл шәһәреннән себереп куганда үзе дә сугышларда катнашты. Совет властен урнаштырыр өчен күпме көч, егәр куйган маршаллар нигә дип Аңа каршы чыктылар икән? Әллә юктан бәла тагып юк иттеләрме аларны? Монда мантыйк юк ич! Кайда, кем тарафыннан бозылды бу мантыйк?

Шуңа охшашлы җавапсыз уйлар Мөхәммәтнең уйлап туймас башына элегрәк тә килеп киткәли иде. Менә монда, чекистларның йорты астына поскан подвалда, уйлар тагын да аяусызланып җанны талкыйлар.

Басымчаклыкка өйрәтелгән акыл, ничәмә-ничә еллар Мәскәү коткысына ияреп күнеккән зиһен барыбер өстенлек алды. «Хәзер кемнән дә булса гаеп-кыек эзләп, көчләрне таркатып утыра торган заман түгел! Җиңеп чыккач кайда хата, ник чигенгәнбез, боларга ничек-ничек юл куелган икәнлеген тарих тикшерер! Саниягә дә, Шамилгә дә бу хакта ныгытып язарга кирәк әле, колакларына шул иманны гына элсеннәр. Тарих һәркайсыбызны үз урынына куяр».

Кичен Уразаевны дөбер-шатыр китереп Лапиков үзе ябып куйган иде, иртәнчәк таң яралып бераз вакыт узгач, аны теге кәҗә сакал ачып чыгарды. «Тундыңмы?» — диде ул, үзенең Уразаевка теләктәш икәнен белдереп. Мөхәммәт көнгә чыккач аңа текәлеп-текәлеп карады. «Исемең ничек синең, кардәш, фамилияң?» — дип сорады. «Нигә сиңа минем исем?» — диде тегесе.

Болай җиңел генә подвалдан котылгач, Уразаев мәсьәләнең уңай якка борылганын сизенде һәм кереп, Лапиковтан Саниясенең һәм Шамиленең хатларын алмакчы булды. Капитан килмәгән иде әле. Кәҗә сакал кулы белән тәрәзәгә күрсәтеп: «Көтеп торма син аны. Кайчан килә әле ул!.. Килмәве дә бар. Һаваны кара! Атың арык, юлың ерак, үзең ач. Юнь барында юлда була тор»,— диде.

Тәрәзәгә караса, Мөхәммәт имәнеп китте: тышта бурый-бурый яңгыр катыш кар ява иде. Өстенә иске бер чүпрәк ябылган алаша туңыпкалтырап болдыр баганасын кимереп аны көтә. Чыннан да, юлда булуың хәерлерәк!..

Кәҗә сакал капканы ачты, кыяфәте өлкән кешенеке булса да, хәрәкәтләре шактый җитез иде әле бу серле адәмнең!

Ниһаять, Саниясеннән өзелеп көткән хат килеп төште. Ул үз дивизияләренең Дон елгасы буенда чолганышта калып каты сугышлар алып баруын, әлерәк кенә зур югалтулар, мең төрле җәфаларны җиңеп дошман боҗрасыннан котылуларын язган иде. Әнисен, Фаягөлен, Мөхәммәтен өзелеп сагынуын кат-кат әйткән. Йөзләгән сугышчыларга операция ясап аларны аякка бастыруын да яшереп тормаган. Дошманның мәкерле, явыз һәм көчле булуын искәртергә дә сүзләр тапкан! Мөхәммәт җанашының җылы кулы белән язылган, «цензурой проверено» дигән зәңгәр мөһер басылган хатны укып чыккач шаккатты. Ничек үткәргәннәр бу хатны?! Әгәр Лапиков кызып-кызып аңа тозак әзерләп маташканда хәвефле хәбәрләргә шактый бай хат аның кулына килеп эләксә... Нихәл итәсең, Саниясен бер бүген генә үзгәртеп, җанын алыштырып куя алмыйсың. Гадел яшәде, әллә нинди сугышларың булса да ул үз иманына хыянәт итә торган икейөзле, ике сүзле зат түгел!

## 2

Шушы төндә ул үз тормыш юлын мәрҗән сыман итеп бер җепкә тезеп чыкты, йокламады. Баксаң, бу мәрҗән, язмыш дисбесе гел гәүһәр-якутлардан гына тормый икән. Ул шактый чуар булып чыкты. Уйлана торгач, аның кайбер буынтыкларына кап-кара ямьсез ташлар да кысылган иде... Әллә подвалда үткәргән шомлы төн, әллә Саниясе, улы исемен катыштырып Лапиковның куркытулары, янаулары аяусызрак булырга мәҗбүр иттеме аны? Бүтән чакта үз хаталарын акларга яраткан, хөкемен тирәнгә үк җибәрмәгән Мөхәммәт Уразаев бүген үз-үзенә хөкемдар булып аяусыз приговорлар да чыгарды.

Менә аның бер тамырсыз калгач, муенына капчык асып, йорттан-йортка теләнеп йөргән чаклары. Ырсытдиннең мәрхәмәте аркасында

кеше булуы, белем алуы, дөнья тануы... Йомабикә байбичәнең кайнар куенын исенә төшергәч, Мөхәммәтнең маңгаена тир бәреп чыкты! Яхшылыкка яманлык кылды түгелме ул? Мәрҗәннең киләчәк буынтыкларында Шамил... Тиңсез сылу кызы Мәүлия... Тормышын ал таң итеп бизәгән, шау чәчәккә төргән, хәсрәтләрен оныттырып, кайгыларын киметеп язмышының иң татлы мизгелләрен бүләк иткән Саниясе. Бәхетле таңда дөньяга аваз биреп туган, мәңгегә күңел түренә кереп утырган Фаягөле... Болары гадәти тормыш агышлары, Мөхәммәтнең җанын җылытып яшәткән изге хатирәләр.

Шуннан башланды, шуннан китте, Уразаевның язмышы язгы ташу төшкәч Иртеш елгасы кебек убылып-актарылып, өйрәтелмәгән тай кебек анда-монда сугылып агарга тотынды! Колхозлар төзи башлагач, шактый зур, ямьсез адымнар ясалган түгелме? Утызынчы елда, бөтен авыл халкын җыеп, Сәмукъ ише хөрәсәннәр белән бер булып: «Калхуз гына аз безгә, даваегыз коммуна төзибез!» — дип акырганда ул да авызын бәлшәйтеп, ризалашып кул күтәрмәдемени? Шул ук ялкау Сәмукълар, мөртәт Чырык Абдрахманнар, үшән Тимерҗаннар авылга баш булып, урта хәллеләрне талап, куркытып йөргәндә нигә бер сүз дә әйтмәде икән?

Торадан килгән вәкилләр җыен юньсез, ярлы-ябагай эшлексезләргә таянып, тырышларны, урта хәллеләрне кычкыртып талаганда күләгәдә калучыларның берсе ул үзе — Мөхәммәт Уразаев түгел идеме?

Хәтерендә, талаган мал-мөлкәтне Бүре Рәхмәтулланың бушап калган дәү амбарына ташып өйделәр. Төнлә-төнлә затлырак әйберләрнең кая таба «аякланганын» Уразаев күрмәдеме? Күзе сукырайган идеме аның, «коммуна, коммунизмнар» белән саташып аңы томаланган идеме? Чаяланган, әрсезләнгән Чырык Абдрахман шул төннәрнең берсендә, сөргенгә озатуларын көтеп коты алынган Гафур хәзрәт ихатасына аяк басты. «Яман адәмнәр дөньяны басты, хәзрәт, сакалың аклыгына карап тормаслар, ил имамы икәнеңне саннамаслар, байлык-муллыгың этләргә ризык булмасын. Әйдә, ару кием-салымнарыңны, алтын-көмешеңне алып китеп яшерим. Сорап килерсең — бөртеге дә югалмас!» — дип алдап-юлдап, болай да зиһене таралган ил агасының бар малын җыештырып алып чыгып киткәне икенче көнне үк ил арасында таралды. Ах, авыл халкын җыеп, оятсыз хәйләкәр төлкенең йөзен ертып көнгә чыгарган булса!.. Мөхәммәт бүген алай ук иманы белән тарткалашып ятмас та иде!

Хәзрәтнең көмеш кашыклары, абыстайдан абыстайга күчә килгән борыңгы алтын беләзекләре, алкалары бикле тимер сандыкка күчеп Чырык Абдрахманга ияреп киттеләр. Абдрахман шактый мул хәзинәне «ышанычлы» урынга яшереп кайтты. Иртәгесен Гафур хәзрәтне илдән куарга авыл активлары керде. Сәмукъ, аның әрсез алабайлары, алтын-көмеш таптырып хәзрәтнең сакалын йолкып бетерделәр, таба алмагач, бар булган ризыкларын бөртегенә чаклы себереп алып чыктылар. Ризыклар да әллә кая китмәде, иплән кенә Сәмукъ чоланына кереп баттылар. Мулла гаиләсе белән ачыга башлады, шешенеп бетте. Бәхетләренә күрә, Өркеттән кунакка кайткан ерак кардәшләре Камил абзый, авыл советы рәисенә йөз таңкәне сеңдереп, белешмә юнәтеп «ярлы-ябагай — ходай колы Гафурны» үзе белән алып китте.

Ике-өч ел үткәч, Өркеттән Гафур хәзрәтнең өлкән улы Әхмәт кайтып төште. Туп-туры Чырыкларга барып керде. Чырык Әхмәтне күреп өнсез калса да, теле берөзлексез тегермән тартты.

— И балам, балакаем! Сез киткәч, кемдер НКВДга барып чаккан. Илдә эт-кош бетәмени?! Безгә тентү керде. Инде тапмадылар, инде котылдык кына дигәндә, денсез Сәмукъ, ике дөньяның берсендә дә рәхәт күрмәсен мәлгунь! — ындыр башына күмелгән тимер сандыкны казып чыгарды. Эт тә эт, Сәмукъ та искә җитез алабай икән.

Мәхдүм Әхмәт телгә йомшак, холкы ипле егет иде. Карышып сүз катмады, явызланмады. Алай иткәндә дә комсыз Чырык егетне НКВД

белән өркетеп куйды. Әхмәтнең кире кайтырлык юл акчасы да юк икән, Чырыктан чыгып, бик ерак кардәшләре Шәмсеруй апаларга керде, сөтле чәй эчеп, майлы ипи ашап тамагын ялгады. Шәмсеруй карчык — сорашырга тотынса, тозны төбенә салмыйча тыела алмас җитез карчык — егетнең хәлен аңлап, «әткәң әрвахлар рухына дога кылсын» дип, егетнең хәлен җиңеләйтте, юллык акча бирде.

Мөхәммәтнең бер юлда адашып йөреп, икенче юл-сукмакларга барып-бәреп кергән уйлары тагын колхозлашкан көннәргә борылып кайтты. Үлчәүнең ниндиенә салып карасаң да, кешелек тарихында Уразаевны ныклап иләртеп киткән, дөнья гамәлләренә баш-аягын катнаштырган ике генә вакыйга булып үткән ләбаса! Беренчесе — гражданнар сугышы булса, икенчесе авылда колхоз төзү иде бит. Сугышка яшьли килеш тартып алдылар аны, ә колхоз төзешкәндә исәйгән, күзе ачылган адәм иде инде ул. Алай да ничаклы хаталар ясалган, күпме үкенечләр калган.

Җиде көн, җиде төн тарткалашты Ялан халкы, телләр аргач арага йодырыклар килеп керде, бер-берсенең җилкәсен төйделәр, күлмәк якаларын аердылар. Белмәгәннәр белгән булып кыланды, аңгыралар акылга өйрәтеп авылны ду китерделәр. Нәтиҗәдә, колхоз түгел, коммуна төзелде. Атларны гына түгел, сыер-сарыкларны, кош-кортны берләштерү башланды. Авыл куштаннары, коммунистлар азынды, ә халык кан җылады. Коммунага каршы сыңар сүз ычкындырдыңмы, сине подкулачник ясадылар. Ә утызынчы еллар башында ягылган кара мәңгегә юылмады, нәсел-нәсәбеңнең тамырын корытты. Подкулачникларны, кулаклар җырына кушылган дип санап, авылдан сөрелергә тиешлеләр исемлегенә керттеләр. Моңарчы аяк терәп карышып, нык торганнар ахыр чиктә шул кара исемлеккә теркәлгәннәр, ике көн рәттән самогон сөременә чолганып өнсез-хәтерсез яшәделәр дә, «коммунага алыгыз», дигән гаризаларын тотып, ава-түнә, совет йортына килә башладылар. Чүлмәкчедән күрмәкче, бүтәннәр дә аларга иярделәр. Шул көннәрдә Бүре Рахматулланың бәрәңге бакчасына җыелган сыерлар, бер көн сөзешеп, ике көн коерыкларын чәнчеп бакча тирәли чабышып йөрделәр дә, атна дигәндә коймаларны ватып-аударып Ялан авылын өметсез мөгерәүләренә күмеп үз йортларына таба чаптылар. Ошбу бәхетсез мәхлукъларның ачлыктан хәлләре киткән, өйләренә көч-хәл белән кайтып егылдылар. Йосыфларның сыеры кайтып кергәч, Гыйззәтбану түти йокысызлыктан үтереп кычыткан күзләрен ышкый-ышкый сөтбикәсен чабып барып кочаклады.

Икенче көнне Эссәт әкә «коммунар сыерларны» замат арасында җыеп алырга боерды. Мөгезләренә бау салынган тоткын малларны көчләп коммуна абзарына илтә башлагач, тагын мәхшәр купты, сыерлар аякларын җиргә терәп чөрәшәләр, күзләре тонган, кайбер акыллыраклары җиргә үк сузылып ята. Алдан малны ирләр тарта, арттан сыер коерыгына ябышкан хатыннар чәрелди. Сыер малы булмаган ярлы-ябагай бот чабып көлә-көлә капка төпләренә басып бу хәйран тамашаны күзәтеп тора.

Сәгъдетдин абзый: «Керәбез!» — ди, Гыйззәтбану түти: «Юк, мәңге юк!» — ди. Аның кебекләр ачуланышып, ызгышып айлар буенча салкын түшәкләрдә аерым йокладылар. Ярәшелеп, куллар сугышкан, көтеп торган туйлар таралды, күрше-күршегә гомерлек кара дошман булып беттеләр. Әллә кайчангы, хан заманыннан килеп онытылган ызгыш-талашлар терелеп арага керде.

Сәгъдетдин әкәнең ике атын коммун абзарына алдылар. Абзарга кереп улак башы кимерергә дә өлгермәде, бичара кырыкмышны авыл активисты Сәмукъ атланып йөрергә өйрәтергә керешге. Самогон исенә тынчыган Сәмукъны кырыкмыш якын да җибәрмәде, башын һавага чөеп үргә сикерде, кушаяклап тибәргә маташты, авызлык тимерләре сафьян иреннәрен канатып бетерде. Явыз Сәмукъ кулындагы тай аюга әверелде. Сәмукъ тайны сигездән үргән каеш чыбыркы-елан белән чарларга тотын-

гач, курка-өркә коммунага керергә чабышкан Ялан кешеләренә мисал буларак, тиз генә баш бирмәде, рәнжеде, үз сыртына беренче кем менеп утырганын аңлады да Сәмукъ мәлгуньне чөеп ыргытты. Сәмукъ тун итәкләрен җилфердәтеп өч тәртә буе еракка чәнчелеп барып төште, тай биек койма аша сикереп авыл арьягына чапты. Анда сыеныр урын тапмагач, борылып кире кайтты, чыбыркысын айкап, бүредәй улап, йөзе-бите шешенеп ямьсезләнгән Сәмукъны күргәч уңга сикерде һәм корсагы белән очлы казыкка кадалды...

И ул көннәр, ул көннәр! Көн туса әллә кайлардан ят, яңа хәбәрләр килеп ирешә. Авыл эче төрледән-төрле вакыйгалар белән тулган иде. Тик торганда авылның мәшһүр сарнаучысы-җырчысы Сабира әбине бер такмак әйткәне өчен көпә-көндез милиционер алып китте. Әби хатын-кыз җыелган җирдә каяндыр ишетеп калган такмагын, гадәтенчә, кычкырып әйткән икән. Йөзе кара берәү каян аны НКВДга илтеп җиткергән диген!

Әйе, бәлтерәгән, авылның юанычы вә куанычы булган Сабира әбине чанага утыртып алып киттеләр. Ишле нәбәрә-оныклары өннәләренең иске бишмәт итәгенә ябышып: «Тимәгез безнең өннәбезгә! Алып китмәгез әбиебезне!» — дип үкерешеп, җир тырнап, күз яшьләре коеп, кар өстендә — кайсы яланаяк, кайсы яланбаш аунап ятып калдылар. И заманалар! Ә Мөхәммәт, Мөхәммәт!.. Чанада бөкшәеп утырган, орчык башы хәтле генә корткага карап: «Сабира әби, даһи Атабызга ничекләр итеп тел тидерә алдың?!» — дип шелтәләп калды түгелме?!

Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе турында ишеткәч, Ялан хатыннары буран булып куптылар, ачлыктан эчләре тактага әйләнгән, коерыклары букка каткан сыерлары янына чаптылар. Мылтык тотып, һавага ата-ата каршыларына чыккан Сәмукъны очыртып җибәрделәр, таптап үттеләр. Булды ул чакта ирмәкләр! Мөхәммәт яши башлаган көненнән алып коммунаның ялгыш адым, пүчтәк нәрсә икәнен сизде, әмма бүтәннәр белән бергә тел яшерде. Алай да җыелышта: «Тотар һәм ашатыр абзарлар булмый торып сыерларны туплау, җыю зур хата иде», — дип бер генә җөмлә ычкындырды. Сәмукълар, Тимерҗаннар колакларын үрә торгыздылар. Ни сөйли бу бәндә, кая чакыра?

Иртәгесен «Мөхәммәт Уразаев дошман җырын җырлаучы» дигән хәбәр райкомга барып керде.

Улы Шамилне сөннәткә әллә кайчан утырткannар иде инде. Заманында бу хәбәрне берәү дә авызга алмады. Хәзер, Мөхәммәтне егарга җай көтеп торган агач активистлар шул гадәти вакыйганы купайтып, арттырып, чокып чыгардылар. Райкомга кереп тулган урыслар «аһ!» диделәр. Җәһәт кенә бюро җыелды, сүзләр эсселе-салкынлы булды, «череп таркалган милләтче» Уразаевны партиядән тимер себерке белән себереп үк түккәндә, өлгер РОНО урыслары аны эшеннән дә куып чыгардылар.

Уразаев тәмам эреп төште. Өч көн дигәндә исенә килеп, юллык акча юнәтеп, бурычка батып Мәскәүгә — Крупская янына юл алды. Атна чамасы Мәскәү вокзаллары идәнендә аунагач, чиргә сабышып беттем дигәндә, Надежда Константиновна аны чакырып алды. Крупская ашыктырмады, иплән кенә Уразаевның дәлилләрен тыңлады, бөртекләп сорашты. Уразаевның сүзе бер булды: «Әни карчык, күрше-тирә мөселманнары «әгәр Шамилне сөннәткә утыртмасагыз, аны бакмыйбыз да, карамыйбыз да!» — дип кистереп куйгач, бу мөселман дөньясында күмәк кабул ителгән йоланы үтәмичә булдыра алмадым. Сөннәт — христианнарның нәниләрне чукындыруы белән бер дәрәҗәдә», — дип аңлатты. Гражданнар сугышына катнашкан, большевиклар идеясенә һәрчак тугры булган бу кешене, беренче ялгышы өчен язмышын кырт өзәргә Крупская базмады шикелле, алай да, мөселман милли комиссариатына шалтыратып кат-кат сорашты һәм «Уразаевны партиядә вә эшендә калдырырга!» дигән язу тоттырып, ашханәдә тамагын туйдырып кайтарып җибәрде. Шулай тинтала булып йөргән арада Ялanда коммуна төзелеп куелды.

Әгәр подвалда төн үткәреп кайтмаса, Мөхәммәт Уразаевның хәтере, инде еллар тузаны астында калып онытыла башлаган бик күп вакыйгаларга әйләнеп кайтыр идеме икән? Тагын бер җайсызлыгы бар Мөхәммәтнең, бүгенге көндә ул япа-ялгыз калды. Иң якын дусты Әссәт әкәне вакытсыз югалтты ул. Менә кем аңа акыл да бирер, кирәк чагында аяп алып та калыр иде! Уйлар Әссәт әкә яныннан көчкә-көчкә аерылып Төнтек Мәхмүтҗанга барып ялганды. Ул адәмнең тәүге көннәрдәге кыланышлары күз алдына килгәч, көлемсерәп куйды Мөхәммәт һәм сул ягына борылып ятты.

Мәхмүтҗан гомере буе көтү көтте, тамагын җәен-кышын, авыл өстендә үткәрде. Морҗасы кыеш, капкасы авыш, коймалары чалыш иде бичараның. Бер өйләнде, ике, биштән арткач, Ялан киленнәренең санын оныттылар. Хатыннарның атна торучылары булды, ә берәвесе, аның койты ихатасын, әстәгъфирулла белән генә басып торган җил капкасын күргәч, «йомышым бар!» дип җимерек абзар артына кергән дә ындыр аша килгән җиренә элдергән. Комбедка рәис сайларга дигәндә... активларның исенә Мәхмүтҗан төшә. «Иң ярлы бездә кем? Мәхмүтҗан. Нигә ярлы? Аңа яшәргә, тормыш рәтләргә патша хөкүмәте ирек бирмәгән. Димәк, ул бүтәннәрдән бер башка өстен!»

Рәис булып алгач, чүпрәккә уралган мөһер Мәхмүтҗанның кат-кат ямалган кесә төбенә төшеп яткач, егет тагын бер тапкыр халыкны шаккатырды. Үзе көтү көткәндә менеп йөри торган әшнәсе сары биягә атланып, баскыч такталарын дөбер-шатыр китереп идарәгә килеп керде. Аттан төшеп сары бияне янына ук тартып бәйләп куйды, үзе Гафур хәзрәт йортыннан «аякланып килгән» тирән көрсигә кереп чумды. Рәиснең җәлпәк чөгендердәй шәмәхә томшыгы гына күренеп калды. Ходавәндәм, бүтән чакта авыз ачып берәүгә бер юньле сүз әйтә алмаган шушы апара корсакны хатын-кызлар кай җире өчен яраттылар икән?! Кай авылга барса да хатын ияртеп кайта иде бит, мәлгунь!

Авыл башы булып алгач, ниләр күрсәтер бу адәм тәганәсе?!

Хәтерли Мөхәммәт, онытканы юк. Рәиснең беренче боерыгы шул булды: колхоз амбарыннан ике пот бодай алып самогон кайнатырга! Яраннары кайнаганны көтәргә риза түгел иде, шул кичне үк бодайны (өч пот итеп алып!) бер чиләк ачыткыга алмаштырып та килделәр. Төркемләшеп таңгача, күкле-яшелле тавышлар белән «Зиләйлүк»не суздылар. Чиләккә чиләк ялганды, башлар түнде, мәҗлестәшләр сынсыз калып как идәнгә тәгәрәделәр. Арган, ачыккан, сусаган сары бия чинап Төнтекне йокысыннан уятты. «Ә, синең дә эчәсең киләмени!?» дип рәис биягә чиләк төбендә калган самогонны эчертте. «Дустым! Ялангa хәзер без баш! Теләсәк нимә кылабыз! Эчәбез дә типтерәбез, типтерәбез дә сиптерәбез! Иртәгә үк торага кыз алырга барабыз. Дөнья безнеке!» Ул арада бия арт аякларын ерды, өтек коерыгын чак-чак күтәрде һәм чыжлатып хуҗасына һәм идәнгә тәгәрәгән совет активистларына су чәчрәтә башлады. Лычма су булсалар да, исерек куштаннар аны-моны сизмәде, авыз тирәләренә чәчрәгән әче бәвелне ялый-ялый куанышып мөгерәштеләр. «Вәт безнең Мәхмүтҗан егет ул, егылсаң да өлешсез калдырмый!» — дип мыгырдап берәвесе борылып ятты.

Шул көннән китте эчеш, бер мәҗлес икенчесен алыштырды, икенчесенә өченчесе ялганды. Келәтләр бушады, язгы чәчү килеп җиткәнен беркем искәрмәде. Атлар аркыланды, күпләре аякка басып тора алмады, аларны арканнар белән абзар өрлекләренә астылар. Авылда ачлык башланды... Аннан-моннан җир тырмаштырып, чәчкәндәй итеп маташтылар, печәнгә төшкәндә җир хуҗалары, катырак җил искәндә урам киртәләренә тотынып йөри башлаганнар иде инде.

Шул чакта рәискә багышланган җыр чыкты. Имеш, ачлыктан теш казналары череп канаган Миңлекалыш абыстай болай дигән: «И замана-

лар. Сабира карчык юк... Әрәм иттеләр бахырны! Исән булса, бу җыруны ул әйтер иде:

Төнтек безнең башыбыз.
Шырчай безнең ашыбыз.
Иртеш буе печәнлектә
Көлтерәйде башыбыз!»

Җыр яшен тизлеге белән таралды авылда, атлар-атламас кына йөргән Минлекалыш кортканың яшен тизлеге белән авылдан очканын күрми дә калдылар. Суга төшкән таш булды әбекәй, югалды. Тагын сөйләделәр, карчык югалганын ишеткәч, салмыш Төнтек әбинең йортына кереп, улын, киленен «юатып йөргән» ди: «Кайгырмагыз, бер тамак кимеде, дип, сәвиткә рәхмәт укыгыз!»

Бу тамашаларга Мөхәммәт тә шаһит иде бит, һәммәсен белеп яшәде. Берни кыла алмады!

Кыска гына араларда Ялан авылында булды инде ирмәкләр!

Ә утыз җиденче еллардагы тоташ фаҗигаләр? Һәммәсе дә әле җаны теп-тере, көчле Мөхәммәтнең күз алдында булмадымыни?

Нигәдер күңеле бик күтәренке, чәк кенә шешә төбен каккан Азиз клубка барып керә. Түрдә юлбашчыбыз Сталин портреты. Азизга Сталин ничектер кыеш-мыеш, чалыш-чолыш эленгән булып күренгән. Сурәтне турыларга теләгән Азиз, урындыкны якынрак тартып китергән һәм Сталин бабасына үрелгән. Баскан урындыгы шулчак авып китмәсенме! Азиз сурәтнең бер почмагына тотынган һәм, гөнаһ шомлыгы, почмак умырылып та чыккан. Һәр урында уяулык күрсәтергә остарып килгән агач активлар моны да НКВДга җиткергәннәр. Өченче көн дигәндә һич гаепсез яшь егетне кара машина килеп алып та китте. Шул китүеннән Азиз да хәбәрсез югалды. Курка-курка гына: «Колымага алып киткәннәр икән»,— дип сүз кыстыручылар булды. Дию парисенә һәр даим җылы кан кирәк, адәм каны, Азиз артыннан ук авылның иң уңган, иң эшлекле өч кешесен алып киттеләр. Сәгыйть әкә чыгып барышлый карчыгына әйткән ди: «Һич гаебем булмагач, минем белән анда нишләсеннәр? Сөреп бетерәсе җирем калды, чәчәргә кирәк, бодай ул соңарганны бер дә яратмый. Бу бер аңлашылмау килеп чыккандыр. Барып аңлатыйм да кайтырмын. Базарга кагылып сиңа яңа галушлар апкайтырмын. Мин кайтышка син мунча яга тор, утын-суыңны җәлләмә! Яме!»

Һәм вәссәләм, шул китүдән җир упты. Диюгә ризык булды Сәгыйть әкә. Бераз торгач кына, язны җәй, җәйне көз алыштыргач кына: «Тубыл төрмәсендә атканнар икән!» — дигән шомлы хәбәре очып кайтты. Асыл ирләрнең берсе дип белә иде аны Уразаев, ударник, хөр күңелле, эшчән, нык беләкле кеше иде. «Немецларга хәбәрләр җиткереп яткан, имеш. Империализмның ялчысы булган!»

Инде кыш азакларында, Сәгыйтьнең карчыгын аулакта очраткач, Уразаев як-ягын каранып кына сорау куйды:

— Ирецне ни өчен алып киттеләр?

— Белмим, мөгаллим.— Кортканың тавышы тонык, сүрән.— Өебез тимер белән ябылган, күршеләребез «андай йорт бәхетсез була»,— дип юрыйлар. Юкса, картым бик ирсемәк кеше иде. Таңнан таңга кадәр эшләде, ударник булды, намусын бозмады — ач яшәсәк тә, бер уч иген иярте кайтмады. Нахак бәлаләр яктылар башына,— дип әби ярсып елап та җибәрде.

Хәзер шуларны уйлый да Мөхәммәтнең җаны әрни. Мендәрдә култык астына башын тыгып Фаягөл йоклый, йомшак чәче болыт булып таралган. Кайчакта көлеп тә куя нарасый. Мөгаен төшендә әнкәсен күрә торгандыр. Сагына, нык юксына бала.

## 3

Гомернең күпмесе үтте икән? Мөхәммәтнең гомере Иртеш суына кушылып акты, эзсез югалды. Бу тарихта синең урының кайда, Мөхәммәт!? Адәм баласының урынын үзе түгел, ул яшәгән чорның борылышлары билгели икән. Гражданнар сугышында ул әле яктылыкка ышанган, гомерен чиксез озын дип уйлап куйган гап-гади, беркатлы авыл мокыты булган икән. Утызынчы елларның әче җилләре аның беркатлы ышануларын чәчеп-таратып бетерде. Хәзер кем булды Мөхәммәт?.. Хәзер аның аңында алмашу чоры бара, фикер белән фикер талаша, талаштан үтеп китеп сугышып та алалар уй-фикерләр. Хәзер сугыш бара, канлы бәрелеш. Бу сугыш һаман җәелә, яңадан-яңа корбаннар сорый, бу сугыш бер Мөхәммәт Уразаевның язмышына гына түгел, җир шарындагы һәрбер җан иясенең тормышына кагылып узачак...

Ул, мамыгы бер почмакка җыелып кантарланган мендәреннән чуен башын калкытып караганда авыр, ямансу таң яралган иде инде.

Гадәттә, таң аңа җиңеллек китерә иде, бүген киресенчә булды, ул тагын хатирәләр, ямьсез истәлекләр упкынына чумды...

Уразаев моңа кадәр ике тапкыр гариза биреп, үзен фронтка җибәрүләрен үтенеп сораган иде инде. «Сабыр итегез, кирәге чыккач үзебез чакыртырбыз»,— дип җавап бирделәр. Сугыш чыккан мәлләрдә ачуярсуы ташып чыккач Мөхәммәт бер минут та илдә калырга теләмәгән иде, хәзер күңеле тыйлыкты. «Бер гаиләдән икәү фронтта, өченчесе монда калса да гөнаһ булмас, әбисе белән Фаягөлне мин китсәм кем карар?» — дип әчтән генә уйлап алган чаклары да булгалады.

Инде тынычланып кына килгәндә аны райкомга чакырып алдылар. Кочкорович үзе кабул итте. «Иптәш Уразаев, көчегезне куяр урын табылды. Сугыш заемына язылу үткәрегез. Сезнең авылга кырык биш мең сум! Теләсә ничек һәм бик тиз шул сумманы урнаштырыгыз. Арттырып үтәсәгез дан һәм мактау булыр!»

Кырык биш төтенле Ялан авылы өчен бу коточкыч зур сумма иде. Ел дәвамында тир түгеп, бер тиен хак алмаган колхозчылардан мондый коточкыч зур акчаны ничек җыймак кирәк? Уразаевның икеләнгәнен Кочкорович күреп торды һәм авыр йодырыгы белән кызыл җәймә ябылган өстәлне төйде. «Әгәр бу мактаулы кампанияне өзсәгез, партбилетыгыздан колак кагасыз!»

Мөхәммәт белән бер вәкил ияреп кайтты. Кайтуга ук активларны җыйдылар, вәкил тәкъдиме буенча кырык бишкә тагын ике меңне өстәп, һәрбер йортка кырык җиде меңне бүлеп чыктылар.

Вәкил мондый эшләрдә чыныккан, хәйләкәр, хәйләгә маһир кеше булып чыкты. Планны сызыгын сызыкка тәгаенләп әзерләделәр. «Мин бу заемга чын йөрәгем белән шатланып язылам!» — дип әйтергә Мөхәммәтдәмин дигән бер байгышны әзерләп куйдылар. Вәкил авызыннан сүз, тәкъдим чыккан саен шаулатып кул чабарга ике җиңгәчәйне ризалаттылар. Заемга шәп кенә язылгач, аларга берәр кило он бирергә булдылар. Ә вәкил, тегенең колагына пышылдады: «Ә синең меңеңнең ике нулен азакта сызып ыргытырбыз!»

Сугышның әче сулышыннан үшәнгән арык хатын-кыз, бөкерәйгән җилкәләрен күрсәтмәскә тырышып артка, почмакларга поскан карт-коры мәктәп бинасына кереп тулды. Бер-берсе белән баш кагып кына сәламләштеләр. Сирәк сүз кагып хәл-әхвәл белештеләр һәм тын калып көтә башладылар. Берәү дә авыз тутырып: «Шөкер, аман яшибез!» — дип авыз тутырып әйтмәде. Ходай сакласын, «шәплеген, аманлыгын» вәкил ишетә күрмәсен, җиде кат чишендерер! Җыелганнар буш җиңен бил каешына кыстырган вәкилгә, кәгазь кисәгенә кадалып каткан Уразаевка карап каттылар. Вәкилнең баш очына халыклар атасы Сталинның бик үк зур булмаган сурәтен элеп куйганнар, аска «Барысы да фронт өчен, барысы

да жиңү өчен!» дип язып элгәннәр. Сүз бирелгәч вәкил житез генә аякка басты.

— Кадерле иптәшләр! — Вәкил тавышыннан лампа эчендәге сүрән утлар атылып куйды. — Мәкерле дошман безнең басу-кырларны таптый. Безнең шанлы Кызыл Армия геройларча көрәш алып бара. Фашистларның чучка танавыннан кан агыза. Бөек полководецыбыз иптәш Сталин житәкчелегендә халкыбыз дошманны тар-мар итәчәк. Кайда Сталин — анда жиңү! Яшәсен бөек Сталин!

Он вәгъдәсен алган хатыннар шашып-шашып кул чабарга тотынды, бүтәннәр кыяр-кыймас кына аларга иярде.

Шаулатып озак кына кул чаптылар. Аннары вәкил даhи атабызны берүк сүзләрне кабатлый-кабатлый бик озак мактады һәм заем таратуга китереп терәде. Залдагылар алкышларның, кул чабуларның чамасыз озакка сузылыуын теләп утыралар, күзләр идәнгә текәлде. Тынлык шактый дәвам итте. Гыйззәтбану түти үз янында гырлап йокыга киткән Мөхәммәтдәминнең кабыргасына төрткәләп уятты, теге, уянып шап-шоп кул чаба башлады. Көлмәделәр, тагын да ныграк сагайдылар. Сүз Уразаевка бирелде.

Ул бернәрсә дә сөйләп тормады, кемгә күпме акча салынуы турында исемлекне укырга кереште. Кайчагында, язу танымаган адәм сыман абынып-сөртенеп ала, кирәкмәгәндә йөткерә, тамак кыра, ахырга барып чыкканчы мөгаллимнең тәмам хәле китте. Ул соңгы фамилияне укып бетерүне чак чыдап көтеп утырган халык, дәррәү урыннан купты, күтәрелде, зал явыз тычкан кергән умарта эче сыман бызлый башлыд. Арадан: «Ул чаклы акчаны каян алыек?» — дигән ярсулы сүзләр, кискен тавышлар аерылып чыккалады. Уразаев нишләргә белмичә як-ягына каранды. Ул арада вәкил шау-шуга йокысыннан уянган Мөхәммәтдәмингә ым какты. Аягүрә басып, өстәлгә куш йодырыгын сугып-төеп, шау-шу басылгач, аңа сүз бирде. Мөхәммәтдәмин, «минә күрәсезме абзагызны?» дигән сыман калкынды, бүтәкәсе бүлтәйгән каздай алгарак чыгып басты, бер колакчыны өзелеп төшкән куян бүреген учында аймап сүзне бөердән алып сөйли башлады:

— Шулай, товарищлар, хөкемәтебезгә ярдәм кирәк, ягъни пумыш. Мин әйтелгән сигез йөз урынына мең тәңкәгә язылам. Сезне булышовикларча суривнаваниега чакырам. Без иптәш Сталин белән бергәләп бәдбәхет дошманны, hичшиксез, жиңәчәкбез, кәнишне. Ур-ра!

Шулай дип уң кулын югары чөйгәндә ертык тун жиңе салынып төште һәм нәп-нәзек беләге шәп-шәрә булып сөрәеп чыкты. Тун астында күлмәге дә юк икән бичараның. Алда утырган ике хатын һәм өстәл тирәли сарган куштаннар кул чапты. Ә авылдашлары: «Әллә ычкынган инде, бичара?» — дип, бер-берсенә шигәеп караштылар. Гомер-гомергә тез тишегеннән тәне күренеп торган, хужалыгында мал-туар асрамагач, мәңге ачлы-туклы яшәгән бу байгыш ул меңне бетен сатып түләр микән дип, телен тешләп сүзсез калды... Ни уйлаганыңны әйтергә ярамый икәнен авыл халкы чамалый иде инде, кемнәрнеңдер теле кычытса да, авыз ачарга базмадылар. Гыйззәтбану түти, он вәгъдә ителгәнен онытып: «Заемга язылу ирекле дидегез, язгыз мине алайса... бер илле сумга! — диде. — Хет асыгыз, хет кисегез, мөгаллим, син исемлектә укыган мең тәңкә миндә юк!»

Вәкилнең сыңар кулы уңга-сулга очып һаваны телгәли башлады. «Сез нәрсә, ханым? Илле сум! без сәдака теләнеп килдекме әллә? Партия карарларыннан көләсезме? Райкомны мыскыллыйсызмы?»

Моңарчы иягеп учына салып, президиумда мыштым гына утырган Дәүләтша әкәнең дә монсу тавышы ишетелеп калды: «Йәгез, жәмәгать, кемгә сүз бирәбез?» — диде ул.

— Өннә апаның нindидер сүзе бар кебек. Баядан бирле кыптырдый, — диде арадан берәү. Битләре тимгел-тимгел чабырып чыккан

хатын, аркасына таш төялгән кәрҗин күтәргән сыман, авыр гына калкынды.

— Фронтка ярдәм кирәк икәнен барыбыз да беләбез. Шуңа күрә һич карышусыз көне-төне эшлибез. Ач дип тормыйбыз. Менә мин дәүләткә 500 литр сөт, 50 кило ит, 100 йомырка, сарык малым булмаса да йон, тире тапшырам. Сыерым җәй буе чирләде, мантымады, сөте кәҗәнеке хәтле генә. Сөт заданием тулмагач, кызымның бердәнбер шәлен, башыннан салдырып алып Хәпчә әбигә кертеп 50 литр сөткә алмаштырдым. Аны хөкүмәткә тапшырдым. Бүтән сатар нәрсәм дә, алмаштырып алырлык малым да юк. Өем шып-шыр. Баш белән уйлап карагыз әле, мең сумны каян алыйм? Бер дәүләт ич ул — мең тәңкә! Боларын, мөгаллим, син үзең дә бик шәп беләсең. Нигә белгән килеш шундый тузга язмаган исемлек яздың?!

Уразаев каты ярмадан шунда авызында ботка пешерде:

— Тырышып карарга кирәк булыр инде,— диде ул. Залдагылар сүзсез генә мөгерәп алдылар. Вәкил заемга язылуның ялгыш юлга кереп китүен чамалап тагын сикереп торды.

— Сез, ханым, ни тугылыйсыз? Нинди ният белән халыкны бутарга маташасыз?! Сезнең сүзләр миндә шик тудыра. Әйе, шик. Әгәр ил буенча уңышлы баручы сәяси кампанияне өзсәгез, башыгыздан сыйпамаслар. Шуны аңлагыз!

— Нишләп өзим? Чукрак булмасагыз, ишеткәнсездер: акчам юк, дим.

— Күрәм, бик ачык күрәм: сез советка каршы эшегезне астыртын алымнар белән алып барырга ниятлисез икән. Кем сезне котыртты?

— Әстәгефирулла тәүбә, йә ходам! Мин нинди контр булыйм, ул ни дигән сүз?! Яз әйдә, мөгаллим, туй йөзегем исән — аны сатармын, бердәнбер ахак кашлы алкам бар, әйдә, китсен ул да! Бозавымны сатармын, итлеккә дип асрый идем. Бәрәңге белән дә үлмәм әле!

Тик тормаган күттә бәла бар, дигән халкыбыз. Өннә апа да үзен эчтән каргый-каргый кушылган суммага язылды да күз яшьләрен авылдашларына күрсәтмәскә тырышып чыгып та китте. Яхшы чакта итәкне җыю хәерле. Сатулаша-сатулаша тагын берничә кешене күндерделәр. Төн уртасы җитте, күрше йортта таң әтәчләре кычкырды.

Истә, бүгенгедәй истә: Уразаев теләсә-теләмәсә сыңар куллы вәкил кубызына биеде, аның җырын җырлады. Арткы рәтләрдән шыпан-шыпан чыгып тайганнарны парлы пүнәтәйләр җибәреп, жылынырга өлгермәгән түшәкләреннән дөбердәтеп торгызып, сак астында дигәндәй, кире мәктәпкә алып килделәр. Әле юмалап, әле бакырып сөйләшкән вәкилнең күз төпләренә эре-эре эрен кунды, чырае ямьсезләнде, тамагы карлыкты, ул ике сүзнең берендә: «фашист тегерменәнә су коясың», «халык дошманы, немец шпионы» дигән янаулы куркыныч сүзләр ычкындырды. «Шпион» дигәндә коты алынган Ялан кешеләре күнсә күнде, күнмәсә дә кул тамгасын салып, сыңар кулдан котылырга, тизрәк өйгә шылырга тырыштылар. Мескен солдаткаларның фронттагы ирләрен сагынып-җирсеп күз яшьләре коелып бетмәгән икән әле, башларын өстәлгә бәрәбәрә, яулык читләреннән әче яшьләрен сыга-сыга, кәкере-бөкере хәрефләр белән имзаларын сырладылар.

Язылдылар заемга...

Сәгъдетдин абзыйның бу көннәрдә күзгә күренмәвен Уразаев баштан ук абайлаган иде, «чирләп киттеме әллә?» дип уйлады да, уен тышка чыгармады. Икенче көнне вәкил (ул фатирга Дәүләтша әкәләргә төшкән иде) күзен ертып: «Теге... төрмәдән кайткан... Сәгъдетдинме әле? Нигә күренми ул?» — дип сорап куймасынмы. Совет йортына кешеләр килеп керде, Мөхәммәт туры җавaптан котылып калды. Инде исемлекнең соңгысы төзелеп, имзалар белән беркетелеп, ялanлылар берән-сәрән акча да китерә башлагач, вәкил тагын Сәгъдетдин хакында сорап куйды: «Кайда ул?» Иртәнге вак-төяк эшләрне карагач, вәкил Уразаевның ай-

ваена карамастан, тагын бер пүнәтәй ияртеп Сәгъдетдин абзыйларга юл тоттылар. Керделәр. Сәлам бирделәр. Шыр ялангач өйдә үле тынлык. Ары-бире каранып, такыр сәкедә ял итеп утырганда мич артыннан кыштырдаган тавыш ишетелеп калды. Уразаев барып караса... Сәгъдетдин, балаларча бөкшәеп, башын тезенә терәп гөлбәчтә качып утыра икән! Сакалы дер-дер селкенә, үзе бизгәк тоткандай калтырый. Беломорканалдан кайткан бичара бит! Сукыр бер тиен акчасы юк, карышып авыз ачарга ярамый, кайткан юлыннан момент җибәрәчәкләр. Вәкил килгәннән бирле ил күзенә чыгарга куркып шунда утыра икән. Кергән дә кысылган, нуры коелган күзләре чак-чак кына елтырый. Мич арасы Уразаевның күләгәсе белән тулгач, аның куркуы тагын да көчәйде, хәленнән килсә идән ярыгыннан базга, базга гына түгел җәһәннәмгә төшеп олагыр иде. Бу арадагы бәхетсезлек хәлләрен күреп, күз яшьләренә коенып җаны ургый-ургый кайнаган Уразаев Сәгъдетдинне шулчаклы кызганды, юкарган сирәк чәченнән кат-кат сыйпады.

— Чык, Сәгъдетдин абзый, дөнья мәшәкатьләреннән качып котылмак юк, өлешеңне үзем түләрмен. Җаен тапсаң, берәр заман кайтарырсың, кайтара алмасаң да... бәхил!

Сәгъдетдингә җан керде. Заманында үз гаиләсендә Мөхәммәтнең улы Шамилне тәрбияләгән мәрхәмәтле зат бит! Уразаев моны оныта ала диме?! Сәгъдетдиннең имзасын алып, якын көннәрдә акча китерәчәгенә килешенеп, «Ялан авылында заемга язылуны арттырып үтәдек!» — телефон аша рапорт та биреп куйдылар.

Заем Ялан авылын кышкы йокысыннан уятты, кем ат җигеп күршетирәдәге хәллерәк авылларга, байрак кардәшләренә чыгып китте, күпчелек ата-бабадан калган йөзек-беләзекләрне, балдакларны базарга илтте. Рәхәтләнде кала маржалары! Нәселдән нәселгә күчеп килгән, аерым бер тантаналарда, туйларда гына көнгә чыга торган затлы әйберләрне ярты бәясенә сөзеп алдылар...

Атна буе ике ут арасында өзелгән Уразаев җиңел сулап куярга да өлгермәде, иртә-таңнан таралган хәбәр аны тәмам акылыннан шаштырды. Халыктан җыелган акчаны совет йортында, Дәүләтшә әкә утыра торган бүлмә шкафына нәни генә ачкыч белән бикләп калдырганнар иде. Иртән, акчаны торага илтәбез дип җыенсалар, шкаф ачык, йозагы ватылган, акча юк. Бу хәбәр кара козгын булып йорттан-йортка очып кереп йөрде. Болай да күкрәк читлегендә чак сыеп торган йөрәкләр өзелеп төште. Сәгате-минуты белән Тубылдан әлеге дә баягы вәкил килеп житте. Кашавай чанага ике ат җиккәннәр, вәкил янында ак тун кигән, кызыл чырайлы, сары салам чәчле милиционер да утырган. «Лапиков та килеп җитәчәк. Әле дезертирлар ауларга китте. «Мондагы хәлләрне ашык-пошык сорашкач, әле барып тотынырлык бер дәлил дә юклыгын белгәч... «Авылда ят адәмнәр күренмәгән, Яланнан беркем, беркая чыгып китмәгән, димәк, карак та, акча да авылда булырга тиеш!» Вәкилнең хөкем карары каты булды: «Лапиков килгәнче без акчаны да, каракны да табарга тиеш!»

Идарә йортында тынлык. Мондый тынлыкны бозарга берәүнең дә йөрәге җитми. Авызыңны ачасың икән — төпле бер сүз әйт! Әйтерең юк икән — тыңла. Вәкилнең сыңар кулы өстәлдә, ул җыелганнарның теңкәсенә тиеп барабан кага. Шактый озак утырдылар. Дәүләтша әкә торыптөрып ишек катыннан әйләнгәләп тә килә. Уразаев озын аякларын идәнгә аерып сузып, калын аркасы белән бүрәнә диварга терәлгән, кымшанмый да, селкенми дә, күзгә күренмәс дәү кадаклар белән кадаклаганнармыни мөгаллимне!.. Вәкилнең сыңар кулы тик тормый, тук-тук итә, бу тукылдау арган, йокламаган яланлыларның чигәсен кага, куркыта. «Таптым!» — дип кычкырып җибәрде берзаман вәкил. Бүтәннәр сикереп торып өстәл тирәсенә җыйналдылар. «Мөгаен Сәгъдетдин эше бу! — дип ашыгып сүз кушты вәкил, — бер дә бүтән түгел! Гомере буе

совет властена каршы булган! Беломорканалга гаепсезләр эләкмәде анда! Әйдәгез, хәзер үк кулга алабыз Сәгъдетдинне». Вәкилнең хөкем сүзе шулкадәр кискен иде ки, бер мәлгә җыелганнар аптырап калдылар. Моңа кадәр мич артындагы сулы чиләк яныннан китмәгән, кичен чөмергән самогоннан авызы кибеп интеккән милиционер салам чәчен бармаклары белән бер якка аралап салды да: «Кая барырга? Күрсәтегез?» — диде. Уразаев Сәгъдетдин абзыйның нинди бәлагә тарыганын аңлап, тегенең юлына аркылы төште. «Иптәшләр, иптәшләр!» — диде ул кабаланып.— Ашыкмыйк әле. Бер гаебе булмаган кеше катына барып хата ясамыйк». Вәкил күзен алартып аңа карады. «Акча бар идеме? Бар иде. Нинди акча? Патриотлардан җыйналган заем акчасы. Авыл тора түгел, монда һәр бәндә күз алдында. Авылда кемнең кулы уйный ала? Мин моны «метод исключения» исәпләп чыгардым. Бердәнбер шикле кеше кем? Сәгъдетдин мөртәт!»

Йә, каршы төшеп ни әйтәсең инде бу бәндәгә? Сәгъдетдинне ничек аяп алып каласың... «Туктагыз әле. Лапиков килер, «шаһитыгыз бармы, дәлилләрегез?» дип сораса, ни диярбез. «Факты булса, акты табылыр»,— диде милиционер тагын йотлыгып су эчә-эчә. Вәкил икеләнә калды, шуннан файдаланып Мөхәммәт болай диде: «Ашыкмыйк, сабыр гына уйлашыйк әле». «Нинди сабырлык тагын?» — диде кинәт ярылып,— сүз монда гади акча турында барса икән! Заем акчасын үзләштерергә бары тик дошманның гына кулы бара ала! Яланда дошманнар күпме? Ничәү? Моны исәпләп чыгару өчен гади арифметика да җитә!» Бүтәннәрнең аны ашыгып хупламаулары вәкилне әз генә шиккә төшерде, ул маңгаена шап иттереп сукты да. «Таптым!» — дип кычкырды.— Хәзер үк минем янга теге... кем әле? Заемга беренче булып язылган?» «Мөхәммәтдәмин», диде Дәүләтша әкә төкселәнеп. «Шул инде шул. Тиз йөрегез!» Бу юлы Мөхәммәтдәминне чакырырга Дәүләтша әкә үзе чыгып китте, аның бу чишелмәс төеннәр чәбәләнгән урыннан, тәмәке сөременнән котылып торасы килде. Озакламый мышнап, өзек-өзек тын алып Мөхәммәтдәмин дә килеп җитте. Вәкил кушуы буенча бүтәннәр чыгып торды, совет йортында алар икесе утырып калды. Вәкил беренче сүзеннән үк Мөхәммәтдәминнең бугазыннан эләктереп алды. «Болай дисең... Төнлә, әллә таң алды ук булдымы икән, буаз сарыгыбызның хәлен белергә дип, ишегалдына чыксам, ни күрәм: совет йорты ягыннан бик ашыгып Сәгъдетдин абзый кайтып бара. Кабалана үзе, абынып та егылды. Як-ягына карана... Ишетсен колагың: шушы сүзләрне кем сораса да әйтәсең, бутамасыннар, онытма! Бүтән берни дә белмим, диген... Безгә Сәгъдетдиннең төн уртасында яки таң алдыннан совет йорты ягыннан кайтуын күргән булу кирәк». «Кайтканмы соң ул?» «Кайткан, кайткан. Кайтмаса, сиңа сүз әйттерер идек мени?» «Минем сарыгым юк шул, буазы да юк, кысыры да.» «Ай, алла колы! Җилгә чыккан идем, сияргә диярсең.» «Төнлә чыгып та йөрмим мин...», дип Мөхәммәтдәмин нидер әйтә башлаган иде, кая ул, вәкил элеп алды тегене, селкеп салды! Тәки ризалатты мәхлукны... Хәзер тимерне кызуында сугарга кирәк иде. Мөхәммәтдәминне совет йортында, чираттагы кизү карамагында калдырдылар, калганнар төркем булып халык дошманы, карак, хыянәтче Сәгъдетдинне тотып кайтырга киттеләр.

Җәяүле буран, әллә кайлардан кузгатып алып килгән кар бөртекләрен өерли, ә дигәнче эзләрне күмә... Акча югалган төндә дә шулай иде, ишек-шкаф ачык, ә эзләр юк. Эзләрне буран яшергән. Хәзер шушы шомлы төенне, шушы элмәкне Сәгъдетдингә сыларга дип бер-берсен уза-уза урам уртасыннан баралар. Төркемне кем күрсә дә шундук кача, йә өйгә кереп китә, йә лапас асты ышыгына күмелә...

Мөхәммәт Уразаев та бара. Бер-бер сәбәп табып аның да бу хәтәр ямьсез шөгыльдән ычкынасы килә. Авылның абруйлы кешесе, ил агасы булып килгән мөгаллим юк эш артыннан йөри. Гаепсез кешене чокырга

этеп төшерергә булыша. Кыен килгәндә аның улын, Шамилен карап торган изге җанны пычратырга бара. Ул беренче тапкыр үзенең җаны кабул итмәгән эшкә дучар булуын ап-ачык итеп, шунда җирдән себергән ак буран уртасыннан барган чакта аңлады. «Йә, нишли аласың! Вәкилгә карышып кара. Аның артында партия, закон, тагын әллә нинди көчләр тора. Син әнә шул аяк астында очып тәгәрәгән кар бөртеге... Өрделәр исә, эрисең, югаласың...»

Шул ук юлдан, югалган эзләренә баса-баса алар совет йортына Сәгъдетдинне алып кайттылар. Иң алдан сыңар кулын киң селки-селки вәкил атлый, танау эченнән генә җыр да шыңшый бугай. Аның кәеф күтәренке, ул шат, заем акчасын урлаучыны тиз үк тотып алу, бу сиңа бәрән төчкерүе түгел. Батырлык дип атала бу!

Совет йортына кайтып керсәләр... юк Мөхәммәтдәмин! «Йортка чыгып керимче, кысталдым» дип чыгып китте дә борылып кермәде,— ди, күз керфекләрен тотен кисеп бетергән кортка. Йортка чабып чыктылар, юк Мөхәммәтдәмин. Өенә барып керделәр, юк кына теге юньсез! Юклыбарлы ихатадан эзләп тә интекмәделәр, адәмне качырып торырлык эт оясы да юк иде Мөхәммәтдәмин нигезендә.

Әй котырынды вәкил, әй шаулады, әдәп саклап, сүз сайлап тормады, урысчасы шәп икән, ата-анасының гүр такталарын бәрә генә бу, беркемнән читенсенеп тормый...

Вәкил ни әтәчләнсә дә, Мөхәммәтдәминне эзләп таба алмадылар. Иртәгесен, караңгылы-яктылыда хәл беркадәр ачыкланды. Таңга кадәр кайда посып утыргандыр, таңда, әле йолдызлар яктысы сүнмәгәндә Мөхәммәтдәминне Ялан авылына торадан килешли Лапиков алып кайтты. Заем акчасы югалганны белә, кабаланып килеп ятканда, каршысына килеп чыккан адәмнән шигәеп сораша башлаганнар, куркудан йөрәге алынган Мөхәммәтдәминнең өзә-төтә җавапларыннан соң дөбердәтеп авылга алып кайтканнар. Вәкил йодырыкларын йомарлап Мөхәммәтдәмингә ташланса да, Сәгъдетдин бичараны күпме талкыса да, алар бүген үз сүзләрендә тордылар, берсе: «Совет йортына якын да бармадым, аллам сакласын»,— дип чәрәшеп катты, Мөхәммәтдәмин авызыннан «күрмәдем, белмәдем, ишетмәдем» дигән сүзләр генә чыкты.

Лапиков вәкил Сидоренконың үз урынына кыҗрап йөргәнен белә иде инде. Сидоренконың НКВД начальнигын егарга тырышып вак-төяк уйдырмалар таратуын да ишеткәли иде. Алар байтак вакыттан бер-берсен күрә алмыйча астыртын дошманлашып яшиләр иде. Бу дошманлыкның файдасы яланлыларга ярап куйды, вәкилнең сүзен сүз итмәс өчен генә Лапиков аның дәлилләрен кире какты, уен какшатты һәм Сәгъдетдин дә, Мөхәммәтдәмин дә рәхмәтләр әйтеп өйләренә кайтып киттеләр. Мич арасында төтеннән яшьле күзләрен сөртеп ярым акыллы кизү карчык кына: «Ник ирмәкне тиз бетердегез? Сез чәкәләшкәндә мәзәк иде лә!» — дип сукранып калды.

Мөхәммәт өенә кайтып кергәч, ишегалдында тугарылган атны күреп гаҗәпләнде. Өенә кереп, түрендә пешенә-пешенә чәй эчеп утырган кешене танып егылып китә язды. Бу... теге вакытта аның атын, үзен аяп алып калган НКВДның ат караучысы һәм йомышчысы... ул Канталыев дип уйлаган бәндә бит! Каян, ничек бу якка килеп чыккан, башы миңгерәүләнгән Мөхәммәт Уразаев аңардан ул хакта җентекләп сораша да алмады. Тубылдагы ярдәме-игътибары өчен ул аңа бурычлы иде, шуңа күрә артыгын төпченмәде, бәйләнмәде, чәй белән сыйлады. Кыстаса да юлаучы куна калмады, исемен дә әйтмәде. «Алла бәндәсе инде мин»,— дип көлде дә атын җикте.

Килеп чыгуына исе китмәгән иде Уразаевның, юлаучының китәр алдыннан җитдиләнүе, тел яшерүе, кабалана-кабалана, ишле кар яуганда, дөм караңгыда юлга ашыгуы аны бераз сәерсендерде дә, шиккә дә төшерде. Мөхәммәт кайтканчы сәер юлаучы үзен «мөгаллимнең

ахирәте» дип белдергән һәм авыл хәлләрен бөртекләп сорашып та утырган.

Ни әйтсен карчык, ни әйтә алсын? Заем акчасы эзсез югалды, вәкил тагын әйләнеп килде, салам чәчле милиционер да аннан калмаган иде. Алар атна эчендә кан елатып, кешеләрне чиргә сабыштырып тагын бер кат, дөрес бераз киметеп, акча җыйдылар, авылны талап чыктылар. Болай да бетәшкән Ялан авылы җан саклап кына язга чыкты.

## 4

Мөхәммәт Уразаев «фронтка бару» түгел, «фронтка качу» турында хыяллана башлады һәм хәрби комиссариатка өченче гаризасын илтеп тапшырды. Җавапны аңа военкоматтан түгел, райкомнан ирештерделәр. Беренче секретарь Кочкорович аны ашыгыч чакыртып алды да, кай җирең кечи, сөйли генә! Сөйләми — сүгенә, сүгенү генәме соң — нәгърә ора, пыр туздыра! Коммунистларның атасы саналган, игътибарлы дип йөртелгән Кочкоровичның мондый зәһәр тавышка ия икәнен белми иде моңарчы Мөхәммәт. Ә үз тавышы? Үз тавышы үзгәрмәгән мени Уразаевның? Кочкорович: «Авылыгызда ничә коммунист калганын беләсеңме?» Алары да... һәм секретарь аты-юлы белән зәһәр итеп сүгенде. Баш очына Сталин сурәте эленгән, ян диварларда коммунизмның аталары Маркс, Энгельслар карап, тыңланып торалар. Һәм Уразаев Яланда ничә коммунист барлыгын онытты, һич исенә төшерә генә алмый бит. Аксак... Яшьтән үк күрә карау... Тагын кем соң әле? Исемнәре дә хәтердән чыгып китте, каһәр!

Кочкорович җавап көтеп тормады, Уразаевның янында икәнен дә онытып телефонга ябышты. Кемнедер чакырды, кемгәдер янады, сикереп торып: «Мин сине төрмәдә чертәм»,— дип, «ямьле киләчәген» билгеләп куйды. Райком бинасыннан чыкканда Мөхәммәтнең: «Барыбер китәм, барыбер! — дигән уе ныгый төшкән иде. Үзенең шул уй белән килеп кереп, Кочкорович алдында чарасыз утырганын юлда кайтканда гына абайлады. Кочкоровичка аңа рәхәт, ул Уразаевны пыр туздырып сүгә дә җанын тынычландыра. Ә Мөхәммәт?.. Ачлыктан тилмергән, авыр хезмәттән йончыган, туя ашамаган, өс-башлары теткәләнгән солдатҡалар белән сатулашып, юк акчаларын даулап утыру егет кеше эшеме?! «Юк, булмый мондый эш!» — дип кат-кат кычкырып кабатлады ул. Арык алаша: «Миңа эндәшәме әллә бу?» — дип, ялт борылып карый да, дилбегә тоткан хуҗасының күңеле булсын дигәндәй лырт-лырт юраткан була. «Урыным — фронтта!» дигән уен беркетә-беркетә кайтты Уразаев. Авыл якынайган саен аның һич бушый алмаган күңелен яңадан-яңа уй-фикерләр тыгызладылар. «Сугыш ерак ерагын, андагы хәлләр турындагы хәбәрләр Ялангa көчкә-көчкә килеп җитә, әмма һәр тармакның, шул җөмләдән кырык биш йортның бар яшәеше, хәл-әхвәлләре әнә шул, әлегә бик еракта, әллә кайларда бара торган аяусыз сугышка барып тоташа. Әле кырык икенче ел гына, немецлар бөтен фронтларда алга баралар. Димәк, алар көчле, сугышка тиешенчә әзерләнгәннәр. Чын хәбәрләр бик сирәк килеп җитә. Сания белән Шамилдән хәзер үтә кыска, кысыр сүзләр генә килеп ирешә. Аларны да чакырып алып кисәтteләрме? Ярый әле, хат аларның исән-сау яшәүләренең шаһиты. Әзгә дә куана хәзер Мөхәммәт, әзгә дә риза булып яши.

Үз хатлары да кыскарды хәзер. Ни язарга белмәссең, ни язсаң да йөрәккә кан сава. Сугыш вакытының тыныч урыннарында да фаҗигаләр була һәм гел кабатланып тора икән! Язга чыгып, кыр эшләре башлангач, Ялан авылы өстенә килгән бәла-казаларны санап бетерерлек түгел иде. Ачлы-туклы кышлаган сыерлар бозау салды. Берәмтекләп санап торган атлар бер-бер артлы үлде. Сарыкларга ябышкан чирләрнең серен ача

алмадылар, сарык башларын кисеп торага озаттылар. Үләт базына илтеп ташлаган сарык гәүдәләрен төнлә-төнлә алып кайтып, кат-кат кайнатып пешереп бала-чагаларны ач үлемнән саклап калдылар. Авыл халкы элегрәк елларда кыш буена җитәрлек итеп балыгын тота, урманнан капчык-капчык чикләвек ташый иде. Ир-ат булмагач балык та тоттырмый икән, коерыгын күрсәтә дә төпкә чума. Эзләп тап син аны! Ә якын-тирә урманнарда качкыннар, сугыштан качып калган дезертирлар күренгәләгәч, урманга бала-чага гына түгел, хатын-кызлар да керергә курка башлады.

Калдык-постык көч белән, үпкәләре бугазга килсә дә зарланмыйча язгы чәчүне төгәлләделәр, җәйне үлән ашап, карлыган, шомырт җыеп җан асрап көч-хәл белән үткәрделәр. Уракка төшкәч... язын җылынган өметләрне дә боз сукты. Суккан бер икмәкне хөкүмәт амбарларына ташыдылар. Инде Иртеш аръягындагы басуда гына әз-мәз бодай калды. Сугышка кадәр ул басудан иген кайтарулар олы бер бәйрәмгә әйләнә иде. Атлар, кешеләр очлы борынлы, озынча көймәләрдә аръякка чыгалар да, иген-таруны җыеп, сугып, бәйрәм ясап, гармун уйнатып, җырлар җырлап Иртешнең дулкыннарын кисеп бу якка ташыйлар иде. Күпме җырлар җырланмагандыр Иртешне кичкән чакларда!

Кырык икедә бу эш тагын шул ук арык хатыннар, ныгымаган үсмерләр җилкәсенә төште...

Илдә тавыш-гауга барганда, хәвеф-хәтәр килгәндә яки сугыш чыкканда адәм балаларының күңеле сагая, сиземләү көче бермә-бер арта. Сугыш елларында күрәзәләрнең, багучыларның ишәюе бер дә хорафәтләргә табыну түгел, ул адәмнәрнең үз арасыннан кемнәрнедер сайлап алып алга чыгаруы. Багучылар, күрәзәләр билгесезлек диңгезендә бата башлаган сыңар канатлы солдаткаларга канат куючы, җәрәхәтләрен төзәтүчеләр дә түгел идемени?.. Саниянең әнкәсе ике көн рәттән, таң белән, уянуга Мөхәмматкә йөзен ачып күрсәтмичә генә авыр көннәр юрады. «Кияү,— диде ул,— саграк бул, зинһар, төшләрнең бик ямьсезе керде. Ике төн рәттән бер үк төш күрдем, аруга түгел бу, ходай сакласын»,— диде.

Инде соңгы көн, Иртеш аръягындагы иген урылган, сугылган, капчыкларга тутырылган. Бүген шул капчыклар авылга кайта. Авыл халкына өлеш шулардан чыкса гына, юк икән! Сакал сыпырып озын-озак кышка керәсе була. Калсаң каласың, калмасаң тәпи сузасың. Бакча бәрәңгесе уңды уңуын, мәгәр аның белән йөз төрле налог түлисе бар, мал-туар асрасаң да бердәнбер өмет бәрәңгедә, бәрәңге синең җаныңны саклап алып калырга тиеш. Шулай ук олы кодрәткә, чамасыз зур егәргә иямени гап-гади бәрәңге?

Уянып чыккач та Уразаев бәрәңге бакчасына күз сала торган иде, бүген карашы офыкларны басып торган иләмсез кара болытларга, игътибары өй кыекларына кунып җыламсыраган нәзек җилгә төште. Ай-һай, ямьсез көн! Иртеш үзәнендә ниләр кыландырмыйдыр бу көтелмәгән әрсез җил, мөгаен генә бүген бодайны бу якка ташып булмас. Ул салкын су сибеп, аннан-моннан гына бит-күзен юыштырды да, эре-эре атлап идарәгә төшеп китте. Дәүләтша әкәнең дә йокысын качырган икән җил, ул да килеп җиткән, нидер әйтергә теләпме, нидер көтепме телефон трубкасына карап каткан. Ияк кагып кына исәнләштеләр, күзләр тышка, сәгате сукса да һаман якты ра алмаган көнгә текәлде. Ул ара да булмады, идарә каршына яхшы ук көр, тимеркүк айгыр килеп туктады һәм таныш гәүдә трантастан сикереп төште. Әйе, бу ул, былтыр заем белән Ялан халкының җилкәсен кимергән вәкил — Петр Сидоренко иде. Бу Рязань урысы каян, ничек бу якларга килеп чыккандыр, нәсел-нәсәбе кем, бераү дә белми. Җитез һәм шома кеше булып чыкты Рязань урысы! Хәзерендә Кочкоровичны Төмәнгә олырак эшкә алалар, урынына шушы сыңар кулны калдыралар икән, дигән хәбәрләр йомык яшәп

яткан Ялан авылына да килеп җиткән иде. Район башлыгын алыштыру — патша төшереп, яңа патша кую белән бер дәрәҗәдә йөри. Монда — тайга, Мәскәү ерак. Райком секретаре — алла да, мулла да, үзе үк җәза бирүче палач та...

Кулсыз керде, сыңар кулын киң чайкап кәнсәләрдәгеләргә сәлам бирде һәм телефонга төртеп күрсәтеп: «Шалтыраттымы?» — дип сорады. Мөхәммәт белән Дәүләтшә әкә сорамасалар да кем шалтыратырга тиешлеген чамалыйлар иде, икесе бер авыздан: «Ю-юк»,— дип суздылар. «Шалтыратыр! — диде ниндидер тантана белән кулсыз,— бүген без аръяктан икмәкне чыгарып, дәүләткә тапшырып бетерергә тиеш! Бүген! Теләсәгез минем атны да алыгыз. Мин эш беткәнче монда булам». Бу аның: «Фатир ягын карагыз һәм хәзер үк тамак ягын кайгыртыгыз!» — дигән сүзе иде. Бүтән вакыт булса Дәүләтшә әкә күтәрелер дә, аякларының сызлавын сүгә-сүгә, ишеккә атлар, җәһәт кенә үзенә ияргән район вәкилен иртәнге чәйгә алып китәр иде. Бүген ашыкмады Дәүләтшә әкә, муенын борып тәрәзәгә карады һәм шул халәтендә озакка калды. «Көн бозылырга тора, ай-һай, бүген Иртеш тирәсенә якын барырлык булырмы?» дип сүзенә куәт эзләгәндәй Уразаевка карап алды. Уразаев сүз кушарга өлгермәде, вәкил, йөзенә төчелек чыгарып: «Кочкорович көтә! Бүген кичкә ул Төмәнгә отчет бирәчәк. Ул кушканны үтәмәү — җинаять!»

Вәкил белән сүз көрәштерүнең һичкайчан яхшыга илтмәслеген каткат сынап авызканаткан Дәүләтшә әкә дә, Уразаев та авызларына су кабып утыра бирделәр. «Әйдәгез әле,— дип калкынды вәкил,— барыйк, карыйк. Тик алдан ук кисәтәм, җил-яңгыр дип икмәк тапшыруны өзмисез! Таш яуса да, ут атса да план үтәлгән булырга тиеш.»

Каршыга искән җилне җиңә-җиңә яр буена барып бассалар... аста мәхшәр, өермә, акбашлы текә дулкыннар бер-берсен таптап узарга теләгәндәй ярсып куышалар, яр балчыгын ишеп чупылдыйлар, яр асларында аклы-сарылы күбек түтәлләре».

Болытлар тагын да куерып, якты көнне каралтып агачларның башларына тияр-тимәс кенә актылар. Ярда бәхәс кызды, вәкил рәисне төрле түбән сүзләр белән коендырды, Дәүләтшә әкә дә саклык кирәклеген онытып, аңа әче-әче җаваплар кайтаргалады. Әлегә битарафлык саклаган Уразаев әз-мәз җайлы сүзләр табып ике якны да сабырлыкка чакырды. Яр буенда, алардан йөз метр өстәрәк, юан-юан казыкларга борыннан да, ян-яктан да тартылып бәйләнгән көймәләр, бер-берсен ышкып ашый-ашый җил иркендә чайкалалар иде. Вәкил шуларның берсенә, иң зурысына сикереп төшкәч рәис тә, Уразаев та бирелделәр. Тракторчы Рәшидәне йөгерттертеп алып килдерделәр, аны ишкәккә утырттылар. Рәшидә белән шыпырт кына сөйләшкән Дәүләтшә әкә нинди сүзләр белән аны ризалаштыргандыр, нинди сүзләр табып җайлагандыр, Рәшидә ишкәкләрен күтәреп килде дә аяк йөзеннән суга керде һәм: «Мин әзер», диде. Вәкил, Дәүләтшә белән Уразаевның ава-түнә кергәннәрен карап торды да: «Мин монда калам. Секретарьга кирәгем чыгуы бар. Телефон тирәсендә булырмын»,— дип китеп тә барды. Ходайның кодрәте, фәрештәләрнең ярдәме булмаса, ай-һай, көймә аръякка чыгып җитә алыр идеме икән?..

Көймәгә унбиш капчык бодай тутырдылар. Рәшидәне ишкәккә утырттылар. Дәүләтшә әкә аръякта калып торырга булды, чөнки Шәмсеруй карчыкның йөрәк өянәге башланган да, хәлсез әбине ике ягыннан тотып ике үсмер кыз капчыклар тирәсенә чүмәште. Коерык калагын Эссәткә тоттырдылар. «Шәт-иншалла, чыгып котылырсыз,— диде Дәүләтшә әкә озатканда.— Монда чыкканда яман җил каршыга бәрә иде, хәзер арттан этәчәк. Ходага тапшырдык».

Болытлар чынлап торып укмаша алмадылар, әрсез җил аларны йөртте-йөртте дә бер читкәрәк куып таратты. Куркак, җитез болытлар арасыннан кояш нурлары да ялтырап күренеп калды. Җил көймәне дә болыт

дип белде, ахрысы, ярдан чак кына ерагаюга бөтереп алып китте. Оча гына, унбиш капчык бодай белән эреле-ваклы алты кешене төягән көймә оча! Әле ярый, көймә шактый озын, бортлары биек. Рәшидә ишми, ул җил ирегенә бирелгән авыр көймәне туры тотарга тырыша, әле калкына, әле утырып аякларын көймә төбенә тери. Унике яшьлек, каурый кебек җиңел үсмер Эссәт-малай агарынган, тешләре кысылган.

Бара көймә, җил аны куа, менә елганың уртасына җиттеләр шикелле, яр, ярда әрле-бирле йөренгән вәкил ап-ачык күренә. Инде җитәбез, инде ярга барып бәреләбез дигәндә явыз җил егет-малай Эссәт кулыннан коерык ишкәген бәреп төшерде, көймә чайкалды һәм ярга яны белән борылды. Борылган көймә буена биек, акбашлы, саллы су тавы китереп бәрде һәм тыелгысыз су көймә эченә ыргылды. Бәләкәй Эссәт җан ачуы белән: «Уң якка тотыныгыз, тотын тизрәк!» — дип чәрелдәде. Рәшидә бер ишкәккә, Уразаев икенчесенә тотынып көймәне баягы сыман борыны белән ярга борырга тырыштылар. Ул арада ач дулкын улап тагын көймә кырына китереп бәрде, тагын су ташкыны эчкә кереп тулды, көймә чайкала һәм һаман бортлары аша сикергән су ташкынын үзенә җыя иде. Әле ярга өч-дүрт сажин бар. Тагын бер дулкын бәрсә...

Чыннан да, моңарчы котырынган дулкыннардан да хәтәррәк тагын берсе көймәгә китереп тә бәрде, ишкәкләре белән су каерган Рәшидә белән Уразаев суга чалкан барып та төштеләр. Киемнәре суланып авырайган Уразаев авыр гәүдәсен күтәреп өскә калыкканда дулкыннар арасында Эссәт белән Рәшидәдән бүтән кеше юк, көймә үзе дә күренми, баткан иде. Иртеш уртасына җитәрәк йөрәге тоткан Шәмсеруй карчык төпкә киткән, үзләре дә юньләп йөзә белмәгән, алай да бичара карчыкны кулларыннан ычкындырмаган чибәр кызлар Айсылу белән Мәликә дә дулкын кочагында югалганнар иде.

Фаҗига булган урынга бөтен авыл җыелды, олысы-кечесе тәмам шашынып, бәргәләнә-бәргәләнә җылыйлар иде. Бигрәк тә Шәмсеруй карчыкны кызгандылар. Аның аръякка чыгып, ашлык сугып, бодай җилгәреп йөрер чаклары мы соң?! Кыз булып житеп килгән Айсылу белән Мәликәнең әниләре тораташ булып һушсыз егылганнар иде. Әз-мәз баш-күз алгач Айсылуның әнисе күкрәген төя-төя ыңгырашты. «Әтисе кайткач мин аңа ни диярмен? Әткәсенең күзенә ничек карармын? Ни җаваплар бирермен?!» — дип кабатлады.

Уразаев йөзәргә оста малайларны оештырып елым белән Иртешне аркылы-торкылы айкап чыкты. Елга Шәмсеруй әбине әллә кая алып китмәгән иде, аны тиз таптылар. Җиңел-курач кызлар, Айсылу белән Мәликә, ерак-еракларга китеп, тал тамырлары арасына эләгеп, икесе янәшә диярлек яталар иде. Ялан гына түгел, якын-тирә авыллар да кайгыга батты.

Вәкил булып килгән Петр Сидоренко көймәнең авып суга батуын күргәч, тиз-тиз атын җиккән дә: «Ашыгыч эшләрем бар!» — дип авылдан чыгып югалган иде.

Чырык Абдрахман яраннары тарафыннан чамасыз нык мыскыллангән Сәрвәрнең әле чынлап торып аякка басканы юк иде, әнкәсенең шулай ямьсез вафат булуы аны тагын урынга салды, егылды кыз, әнисен югалтуын ифрат авыр кичерде. Мөхәммәт Уразаев армиягә китә калсам, мәктәпкә хуҗа итеп Сәрвәрне калдырам, дип уйлап йөри иде, бу яктан аның планнары сүтелде.

Мәрхүмнәрнең өчесен уздыргач кына Иртеш йоткан унбиш капчык бодайны су төбеннән чыгару хәстәренә керештеләр. Чумарга һәвәс дүрт малайга йөкләделәр бу гадәттән тыш авыр эшне. Чумалар үсмерләр, тегеләй эзләп карыйлар, болай таба киләләр, юк кына бит капчыклар! Ә бодайны калдырырга ярамый! Малайлар зәңгәрләнеп, күгәреп беттеләр. «Малайларны бетерәбез бит», — диде Уразаев Дәүләтшә әкәгә. Чумучыларга берәр тустаган самогон йоттыргач кына аларга әз-мәз җан керде.

Ниһаять, шактый иза чиккәч кенә, бодайлы капчыкларны берәм-берәм су төбеннән тартып чыгардылар. Ул көннәрдә Петр Сидоренконы телефонга бәйләп куйганнар диярсең, иртә таңнан кичкә кадәр өзмәс шалтыратып торды. Җитмәсә, шул монафыйк: «Шул давылда-җилдә игенне бу якка чыгарырга ашыкмаска кушкан идем, Уразаев белән Дәүләтшә рәис мине тыңламадылар»,— дип йөргән. Чүп өстенә чүмәлә — давылның күләгәсе мөгаллим Уразаев өстенә төште һәм бик озакка ягылып калды. Җыелыш саен, пленум саен аның исемен тугыладылар.

Су төбендә ятып бүрткән, тәс җуйган бодайны хезмәт көне исәбенә колхозчыларга тараттылар. Дәүләтшә әкә, Мөхәммәт Уразаев киңәшен тотып, «бодай дәүләткә тапшырырга яраксыз», дип акт төзетте һәм шушы хәлдән файдаланып, сер сыя торган колхозчыларга әз-мәз «су коенмаган» ашлыкны да шудырды. Алда озын-озак кыш, өметсез зәһәр суыклар, алар артыннан ук ашыгып-кабаланып яз киләчәк. Язга кадәр эш тотарлык адәмнәрне сакларга да кирәк иде. Дәүләт планы тулмаган килеш иген-таруны тарату үтә хәвефле, куркыныч эш иде, әгәр белә калсалар Уразаевның да, рәиснең дә башы очып кына төшәчәк иде. Әле дә, инде эзләр суынды дигәндә дә, Ялан авылына тикшерү килеп төште. Шикаятьне, мөгаен, Мөхәммәтдәмин язгандыр дип уйладылар. Казындылар, авыл халкының котын алып чокчындылар да моңарчы ындыр бригадиры булып эшләгән Хафиз әкәнең бронен алып, «иген тапшыруда сүлпәнлек күрсәткәне өчен», дип эшеннән кудылар, Урал шахталарына стройбатка озаттылар.

Язгы-җәйге мәшәкатьләр, кабатланып-өелеп бер-бер артлы килгән кайгы хәсрәтләр Уразаевны мәктәп тормышыннан нык ук ерагайткан иде. Каеп яфракларына беренче сары сарып, урман-болыннарга тут йөгергәч, бәрәңге сабаклары пәжеп ызаннарга егыла башлагач ул кинәт кенә мәктәбен исенә төшерде. Уку елы килеп җиткән ләбаса! Башка елларны сентябрь башы Уразаев өчен зур бәйрәм була торган иде. Быел исә уйлады да кара кайгыга чумды. Яланлылар яңа мәктәп салырга җыенганнар иде. Мәктәп проектын Төмәнгә барып Уразаев үзе эзләп, сайлап алып, бик шәбен — кәттәсен алып кайткан иде. Аннан-моннан корыштырган иске мәктәпләреннән шактый җык күргәннән соң туган иде мондый якты уйлар! Яңа мәктәпләре биек тә, якты да, җылы булачак иде. Сугыш аларның бу планнарын да бозып ташлады. Иркен урында күтәрелгән бура бүрәнәләре яңгырда-карда дымланып муртаеп утыралар әнә. Яңа мәктәп турында авыз ача да алмыйсың, инде әз-мәз ремонт ясарлык акча бирсәләр, төзү материаллары табарга булышсалар... Уйлаган-кискән, Уразаев иртәләрнең берсендә, җәй узып та күрәймәгән үшән атын җигеп торага китте. Укытучылар җәһәтеннән дә киңәшсе булыр, ир-атлар калмады, өлкәннәр кинәт картаеп-муртаеп беттеләр. Гомумән, сугыш елларының кешелеккә, аерым адәмнәргә тискәре тәэсир ясавын Уразаев аңлый башлаган иде инде. Шушы Ялан-Тубыл юлында ялгыз гына трантаста барганда чакрым саен яңа ачышлар ясады ул. Әле сугыш башланганга алай әлләни күп вакыт та үтмәде, сугыш ерак, аның авазы монда килеп җитәчәк тә түгел, мәгәр ил, халык биреште. Ел дигәндә авыл үзгәрде дә куйды. Нужа бөтен халык өстенә ятса уртак рух сүнә, сүрелә икән. Рух сыну — халык өчен иң куркынычлы, җимерүче афәт икән. Рух сына — урман пожары кебек гел сикерә, берәүләрдән бүтәннәргә күчә, рух сынуга беркем дә каршы тора алмый...

Уйлар илләрне, чикләрне үтеп сугыш кырларына барып керә дә, Саниясен, Шамилен хәтерләп бер урында кайнап алгач, тагын Иртеш якларына борылып кайта, анда-монда адашып-саташып йөри дә мәктәп ноктасына кайтып туктала.

Үзе армиягә китсә, урынына Сәрвәрне калдырам дип уйлап йөри иде директор Уразаев, ул хакта читләтеп кенә Дәүләтшә әкә белән дә киңәшкәләп алган иде. Бердән, кыз булдыклы, зиһенле. Икенчедән, чиреннән

арынып кына килгәндә, ике кулына тапшырылган олы эш аны вак-төяк хәсрәтләрдән, чагып-тешләп торган уй-хатирәләрдән коткарып торачак. Һәр хәсрәтне бары тик эш белән генә җиңеп буласын инде Уразаев нык үзләштергән иде. Шәмсеруй карчыкның дөнья йөзеннән китүе Сәрвәрнең терелүен авырайтса да, аңа бердәнбер юл — мәктәп. Бүген укытучы, иртәгә — директор, Ялан авылы балаларының өмете, тәрбиячесе... Җимерелеп барган мәктәп, әле бер ягарлык утыны булмаган мәктәп, ишек-тәрәзә яңаклары калҗайган мәктәп... Алда салкын Себер кышы... Ай-һай, боларның бөтенесен бичара Сәрвәр иненә салып куярга ярар микән?.. Сәрвәр янына тагын бер, көчлерәк, баш бирмәсрәк хатын-кыз табып булмасмы? Ир затлары хакында уйламый Мөхәммәт, сугыш дигән җиде башлы дию ир-атларның үсkәнен, калкынганын күзәтеп кенә тора, комсызланып йота бара аларны...

Күз-күргән, очрашкан-белешкән, яратып-ошатып йөргән хатын-кыз педагогларны хәтереннән берәм-берәм, кабаланмыйча гына үткәрде Мөхәммәт. Үшән ат, аның тирән уйларын түгеп-чәчеп бетермәс өчен дигән кебек, салмак кына атлап бара, үр төшкәннәрдә артын сикертеп лырт-лырт юртып та куя. Уйлар трантас тәгәрмәчләренә уралып тәгәриләр. Тормышы, көн-күреше тиз авырлашкан Ялан авылына яңа укытучы килерме? Килсә ни-нәрсәләргә ышанып килер?

Бу хакта өзеп кенә уйларга курка иде Уразаев.

Менә шәһәр урамнары башланды. Авылдан шәһәргә килгән кешенең күзе үткенәя, хәерчеләрнең артканын күрде Уразаев, яңа култык таякларына өйрәнеп җитмәгән, авып-түнеп баручы курач солдатлар очрады аңа, мансиларның табак битләре күренеп калды, унар бала иярткән, киң итәкләре белән урам ташларын себереп баручы чегән хатыннарын күзгә ияртеп алды. Ниһаять, ул үзе эзләгән, үзенә бүген бик тансык кешене күреп алды һәм трантасыннан сикереп төшеп: «Миңнурый!» дип кычкырып җибәрде...

## 5

Миңнурыйның беркемне дә күрәсе, беркемгә дә күренәсе килмәгән чагы иде. Сугыш елларының кагыйдәсе бер: адәм балаларын урыннарыннан кузгатып бары тик нужа гына йөртә. Ике нужа очрашып бергә әйләнгәндә ул тагын да әрсезләнә, күңелнең иң тирән чоңгылларын болгатып-туздырып көтелмәгән хәсрәт-кайгыларны өскә күтәрә. Берәү дә ят очрашулардан шәфкать-мәрхәмәт көтми. Очрашуга сүз сугыш билгеләгән усал эздән бара: кем югалган да кемнең үлү хәбәре килгән, кем тайгада адашкан да, кем Иртеш дулкыннарына батып үлгән?! Миңнурый торага бу юлы ярдәм-киңәш эзләп килгән иде. Аның ачык максаты да, билгеләгән кешесе дә юк, әмма ул бу көннәрдә өендә, үз авылында кала алмады. Ачы хәсрәт аны юлга куды, таң яралганда авылыннан чыгып киткән кыз хәзер башын кая куярга белмичә, зар-интизар булып, бер максатсыз тора урамында арлы-бирле йөреп тора иде. Кемнедер эзли, берүк вакытта үзен танытасы да килми, ары бара, бире килә, чуар яулыгын тартыбырак куя, битен каплый. Була бит җанның шулай талпынган, бәргәләнгән чагы: кемнедер эзләп зарыгасың да, йөзең яшереп адәм улларыннан качасың да! Инде өметсезлеккә төшкән, инде барыр юлы тоташтан бикләнгән сизгер җаннар гына мондый хисне кичерәләр...

Ничек танып, белеп алгандыр аны Мөхәммәт абыйсы?

Язмыш байгышларны очраштыра. Миңнурый исә гомере буе нужа, кимсетүләр, мыскыллаулар белән көрәшкән сагышлы-моңлы татар кызы иде. Язмыш аңа белә-белгәннән бирле мәрхәмәтсез булды. Дәһшәтле мең тугыз йөз егерме тугызынчы елны аларны бөтен гаиләләре белән

Чиләбе каласыннан Төмән-Тубыл якларына, тайга уртасына кереп поскан Ростошь исемле урынга кудылар. Әти-әнисе бай булганга да түгел, Миңнурыйның сөекле бабасы — ачык йөзле, озынча, төз буйлы Сөләймән мәчетнең мәэзине иде. Активлар, коммунистлар җыелалар да шундый карарга киләләр: «дин-әфьюн, халык өчен агу, аны юк итәргә кирәк!» Манарасын кисәргә ниятләп мәчет тирәсенә кызыл авызлар туплана. Сөләймән мәэзин бу хәбәрне ишетүгә ау мылтыгын корып мәчет эченә кереп бикләнә һәм манарадан торып таза тавышы белән сала: «Изге урынны мәсхәрә итәргә беркемгә дә ирек бирмим, якын килсәгез, атам да үтерәм!» Шулай дип кычкыра да сүзенең уен түгеллеген белдереп мылтыгыннан бер гөрселдәтә. Көн утыра мәчеттә бикләнеп Сөләймән мәэзин, төн утыра, өч көн үтә, ул арада Чиләбедән кораллы кызыл отряд килеп төшә. Мәэзиннең һәм аның улы Минһаҗның кулларына богау салып типкәли-типкәли шәһәргә алып китәләр. Суд була. Бабасын, әткәсен, бөтен гаиләләрен Себергә сөрәләр. Җитеп килгән Миңнурый да Себер «сәяхәтенә» чыга. Ят юллар, ят җирләр, ят кешеләр шыплап тәялгән Себер юлы. Гади юл түгел, газаплар, кимсетүләр юлы. Кайнар ризык пешерергә, чәй кайнатырга рөхсәт юк. Юл озын, төннәр чиксез, көннәр санаусыз. Конвойлар арасында усал сүзле, ямьсез күзле хәтәр маржалар байтак. Сәфәрчеләр арасында күрше авыл мулласы, халыкның ничек-ничек интеккәнен, бала-чагаларның ашсыз, сусыз тилмереп чиргә сабышканын күреп: «Кызым-балам, без мөселманнар, кайнар чәйсез яши алмыйбыз. Су да кирәк. Динебез пакьлек ярата. Тукталган араларда юынып, чәйләп алсак иде»,— дип, йомшак, җылы тавышы белән биле вә муены бер юанлыкта булган конвой-марҗага эндәшкән икән, марҗа күзен агартып көлгән дә, ике дә уйлап тормаган, шунда, күз алдында хәзрәтне атып үтергән. Вагон «аһ» иткән. Алдагы тукталышта сакчылар мәетне вагон ишегеннән җиргә ташлаганнар да ашык-пошык карга күмеп киткәннәр.

Чиләбе тирәсендәге татар авылларыннан җыелган мөселманнарны Төмән карурманнарының берсенә китереп ыргытканнар. Салкын кыш, куерып ябалак кар ява, күз бәйләнеп килә. Тирә-якта сүзсез тайга. Дәү-дәү юан кедр агачлары арасында җылыныррлык йорт та, ышыкланырлык киртә-корта да юк. Кайчандыр эшләргә маташкан такта яру заводыннан гайре бер ихата, бер корылма-бина юк икән. Заводны сала башлаганнар да контракт белән килгән эшчеләр таралганнар. Картлар ыңгыраша, балалар җылаша.

Агачларның аскы салынкы ботакларын кисеп, куышлар ясап, кар көрәп төнгә кергәннәр. Уртага балаларны алганнар, ян-якларга ир-атлар тезелешеп яткан. Урман ят кунакларны тамаша итеп төне буе ыңгырашкан. Боларга башлык буласы кеше икенче көнне генә килеп төшкән. «Агач егасыз, такта ярасыз, йортлар саласыз. Кем дә кем рөхсәтсез китә икән — төрмә. Бөтенләй качарга җыенганнарга — үлем». Иң әүвәл, бөтен көчләрен җыеп әнә шул җирән мыеклы, чалыш күзле явыз адәмгә өй салып биргәннәр. Аннан соң гына үзләренә барак салырга тотынганнар. Тәбәнәк, озынча баракны иске-москы чаршаулар белән телгәләп-бүлеп ышыкка кереп урнашканнар. Шунда ерак та түгел зират җире бүлеп алганнар, Чиләбе татарлары, динле вә иманлы мөселманнар, тайганың шытырдап каткан җирдән уелган ләхетләренә кереп мәңгелеккә юл алганнар.

Миңнурыйның бабасы үз илендә танылган оста булып, ул талчыбыктан күз явын алырлык кәрҗиннәр, бала бишекләре, каз оялары үрә торган иде. Авылларыннан куганда да әйбер-караларын дүрт почмаклы, капкачлы кызыл кәрҗингә тутырып алганнар иде. Кәрҗин исән-имин хәлдә тайга уртасына да килеп җиткән иде. Көн саен казынып, тикшеренеп йөргән комендантның күзе шул кәрҗинне күреп кызган бит. Бер көнне сорап куйды: «Каян алдың?» «Үзем үрдем». «Хәзер дә үрә аласын-

мы?» «Чыбыгы булса нигә үрмәскә?» Комендант Миңнурыйның әтисе Минһаҗны атына утыртып якындагы күл ярына алып бара. Һи-и, андагы талларны күргәч, Минһаҗ телсез кала! Миңнурый тал кабыкларын кырып төшереп тора, әтисе көн яктысы сүрелгәнче сыгылмалы чыбыклардан кәрҗин үрә. Башта комендантка сандык, өч-дүрт кәрҗин аның бичәсенә, аннан туганнарына... Беркөн кәрҗиннәр артып кала һәм Минһаҗ оста аларны, комендант рөхсәте белән, иң якындагы базарга күтәреп китә. Бер бара — кәрҗиннәрне суырып кына алалар, ике бара — товар җитми! Заказлар мең! Тапкан акчага Минһаҗ азык-төлек, ит, он, ярма сатып алып кайта. Авылда бәйрәм. Талы бар икән — күле дә бар дигән сүз. Минһаҗ төрле фасонда мурдалар үреп балык тотарга керешә. Баракка мич чыгаралар, саулар сөенә, чирлеләр терелә.

Көннәрдән бер көнне Минһаҗ базардан кызыл кикрикле, урак койрыклы, зәһәр тавышлы чуар әтәч алып кайта. Адәмнәрдән кала беренче җан иясен тамаша кылырга бөтен халык җыйнала. Әтәч тә хәтәр, үзенең игътибар уртасында икәнен сизеп дөнья яңгыратып «кикрикүк!» дип кычкырып та җибәрә. Җыелган халык таң кала: «Минһаҗ Камалов сәгать алып кайткан!» дип әй куанышалар, әй куаналар!

Берзаман заводның түгәрәк пычкылары зыңгылдап әйләнә, электр килә. Куылганнарга җан керә. Халык арта, этап белән дә куып китерәләр, дөнья нужасыннан котылырга теләп байгышлар да төрле өлкәләрдән монда килеп сыеналар. Авыл киңәя, үсә, урамнар арта. Рәсәй мәмләкәтенә гомергә хас яман, кара гадәтләр дә кереп тула. Чиләбе төбәгенең мәчетле, иманлы авылыннан килгән шактый сандагы татар гаиләләре дә шушы чуар, усал төркем арасында эреп югалалар. Берәүләр чыдый алмыйча качып китеп төрмәгә эләгәләр, икенчеләр урыс исерекләренә баш иреп иманнарын җуялар, җыен эшлексез, җыен бушбугазлар авыл адәмнәрен буйсындырып, куркытып, малларын талап гомер уздыралар. Моңарчы гел-гел күз алдында йөргән комендант хәзер өеннән чыкмый диярлек, чыкса аракыдан шешенгән күзләрен ача да алмыйча акырып-җикереп урам уртасыннан бер уза да тагын атна буе качып эчеп ята. Адәмнәр һаман өстәлә тора, һәр яңа дулкын элеккеләргә караганда явызрак, ярлырак, әрсезрәк була бара. Кәрҗин үрергә дип тозлы суга салган талчыбыклар әллә кая югала. Елга-күлләрдә мурдалар төн дә чыга алмый — урлап бетерәләр. Кибәргә элгән җирдән елымнар аяклана. Кетәкләрдә әтәч-тавыклар, абзарларда сыер малын тота алмыйсың...

Утызынчы еллар башында хәл тәмам мөшкелләнә, адәм балалары явызлыкның чигенә чыккан чүл бүреләренә әвереләләр.

Миңнурый үсте, зифа буйлы, озын толымнарын җилләрдә уйнатып йөрүче сылу кызга әйләнде. Аңа күз атмаган, ямьсез тәкъдим ясамаган ир-ат әз калгандыр урман авылында. Ләкин ул горур, кыю иде, беркемгә дә баш бирмәде, усал тәкъдимнәр ясаганнарга нәфрәт белән карап үзенчә яши бирде. Аның терәге — гаиләсе, ата-бабасы иде. Ул бабасының ныклыгына, чисталыгына, сүзен сүз итеп яши алуына сабый вакытыннан сокланып үсте. Мәчет капкасы төбендә, кулындагы мылтыгын кысып тотып Чиләбедән килгән усаллар отряды каршысында бер башы басып торган бөркет бит ул! Монда да ни кыенлыклар күрмәделәр, «ачтан үләбез, инде беттек!» дигән вакытлар килде, карт мөәзиннең теш арасыннан зар сүзе чыкмады. Яшәү сүтелеп бетә дигәндә дә Аллага таянды, бер чакта да биш вакыт намазын калдырмады, өс-башын мөселманча пөхтә йөртте, яткан-торган урыны да пакь, чиста булды. Эштән бушаган чакларында кураен алып ишегалдына чыгар иде дә моңлы татар-башкорт көйләрен уйнап дөньяны үзенә каратыр иде.

Төрле халык арасында татарлар югалып калгандай булдылар, ә Миңнурыйның бабасы үзгәрмәде, урыс гадәтләренә, урыс ризыкларына, урысча яшәү шартларына иярләшә алмады. Ни ачыккан чакларда да гөмбә, помидор ише нәрсәләрне ашамады, дуңгыз итен күргәндә җирәнеп косар дәрәҗәгә җитте.

Утызынчы еллар уртасында тайга авылыннан берәм-берәм кешеләр югала башлады. Берәм-берәм дә алып киткәләделәр, төнлә килеп, байтак башларны җыеп машинага төяп тә алып киттеләр. Дөнья аларны йотты, эзләренә үлән үсте. Ил белән өметсезлек килде. Шул хәлләрдә дә бабасы Миңнурыйны укытырга тырышты. Бабасы ярдәме белән ул Тубыл педучилищесына укырга керде, аны тәмамлады. Ул торада укыган елларда бабасы ачтан үлде. Миңнурый бабасының үз авызыннан өзеп аңа, студентка нәбәрәсенә бар тапканын ташып торганын соңрак, үсә төшкәч кенә аңлады.

Бабасыннан соң әтисе дә озак яшәмәде, олау белән барган җиреннән туңып, эченә суык төшеп кайтты да, атна да чирләмәде, кан төкереп вафат булды. Соңгы сүзе шул иде: «И кызым, балам! Тома ятим каласың. Ничекләр яшәрсең бу караңгы дөньяда?»

Педучилищены тәмамлаган Миңнурыйны ата-бабасы җәфаланып үлгән тайга авылына җибәрергә теләгәннәр иде, кыз аяк терәп, черәшеп каршы торды. «Теләсә кая барам, әмма ләкин авылыма кайтмыйм!» — диде ул. Куркытып та карадылар кызны, үгетләделәр дә, әмма кызга бабасының ныклыгы, үҗәтлеге һәм үз сүзендә тора алу гайрәте күчкән икән. Аны Тубыл районына кергән, торадан унбиш чакрымдагы Бишнә авылына җибәрделәр. Миңнурый ялгыз-ялпы яшәп яткан Җәмилә карчыкта фатирда яши башлады. Җәмилә әби дә Казан арты авылларының берсендә яшәгән, ике ат, ике сыер тотканнар. «Байгуралар!» дип аларны да читкә сөргәннәр, мал-туарларын, йорт-җирләрен талап алганнар. Җәмилә әби Миңнурыйны сөенә-сөенә кертте, сөенә-сөенә эшенә озатты, көлә-көлә каршылады. Миңнурыйның колагы тынып, җаны рәхәттә калды. Тирә-юньдә ят кешеләр, күбесе илдән куылган бичаралар булса да, монда күпчелек татарлар булганга, яшәү җиңелрәк иде...

Шулай җайлашып, Җәмилә кортка белән чөкердәшеп, күрше-каршылар белән йомышка йөрешеп, тату гына яшәп ятканда бәла көтелмәгән яктан килде. Нindидер уңай белән авылга вәкил җибәрделәр. Сыңар куллы, чандыр, озынча буйлы Ибраһим Миңнуллин дигән бәндә иде бу. Килгән шәпкә үк ул мәктәпкә кагылып чыкты һәм шунда Миңнурыйны очратты. Кызның чәчәк атып, тулып, дөнья күзен кызыктырырлык дәрәҗәгә житкән чагы иде. Ибраһим, комсыз күзләре белән кызның бөтен яшерен җирләрен капшап: «Кичен клубта очрашабыз», — диде. Кызның тәненә салкын су сиптеләрмени, чирканып китте һәм тыйнак кына: «Клубта ремонт», — диде. «Барыбер ачтырабыз аны!» — диде Ибраһим. Кичен, клуб мөдире, авызыннан гелән суган исе аңкыган карсак гәүдәле, кыргый мыеклы Әхәт килеп: «Вәкил сине чакырта. Бүген клубта уен!» — дигәч кенә, Ибраһимның зәһәр карашын хәтерләп куркытып китте. Алай да бармады. Әхәт бер килде, ике, өченчесендә Ибраһим үзе дә килеп җитте. «Кызый... чамала! Язмышың минем кулда!» — дип, һаман бер сүзне кабатлады. Бармады Миңнурый, куркытсалар да курыкмады, үзенең кыю татар мәэзине нәбәрәсе икәнен тагын бер кат шул төндә исбатлады. Вәкилнең янавын тыңлап яткан Җәмилә әби, аяк эзләре тынгач, фатирчысының янына килеп утырды, кытыршы, рәхәт бармаклары белән Миңнурыйның маңгаен сыйпады. «Кызым, балам! Яман бәндәнең күзе төшкән сиңа. Ничекләр котылырсың икән?!» — диде.

Төн ката йокы эленмәде Миңнурыйның моңлы күзләренә. Һәм шул кичтән аның язмышы кискен борылыш ясый, явыз вәкил, сыңар куллы иблис Ибраһим аның күләгәсенә әйләнә. Хәзер Миңнурый элекке кебек кыю, тәвәккәл, туры сүзле була алмый: артта бер гөнаһсыз әүлияләр җәһәннәмгә тап булган юллар тора. Бабасы, әткәсе «сөрген сандугачы», халык дошманы. Өстенә шундый авыр, иләмсез ташлар явып торганда бәхет турында уйлый, өметләнә аласыңмыни?..

Менә быел да, яңа уку елына керәбез дигәндә, авылга кара козгын-вәкил Ибраһим килеп чыкты... Янады, куркытты, өркетте, сүзләрнең ин-ин әчеләрен түкте. Һәм, башын кая куярга белмәгән Миңнурый, йөрәге ярсуына түзә алмыйча торага чыгып китте. Кемгә барып эндәшергә, кая барып таянырга белми торган чагы иде сылу татар кызының. Һәркем кара багана булып күренә, һәр күз — аның өчен мылтык көпшәсе тишеге... Кош сайравы да өметсез матәм булып ишетелә. Шулай ярым адашып, ярым саташып тора урамнарын аркылы-торкылы гизгәндә Мөхәммәт абыйсы Уразаевны очратты. Уразаевның кыяфәте дә моңсу, сагышлы күренде. Кайчандыр әтисенең якыны диярлек булган бу дәү абзыкайны Миңнурый белә-белгәннән якын итә иде. Монда да әүлия бабасының йогынтысы, тәэсире булмый калмагандыр. Бабасы: «Уразай ул... кеше! Коммунистлыкка язылса да иманын югалтмаган зат. Себер сөргеннәрендә, бер-берсен ашарга, таптарга җибәрелгән адәмнәр арасында кеше булып калу ай-һай җиңел түгел!» — дия иде бабасы.

Танныдылар, күрештеләр, хәсрәтләрне бүлешергә күп сүз кирәкмени? Миңнурыйның хәлен ярты сүздән аңлады Мөхәммәт һәм үзен көтеп торырга кушты: «Вак-төяк йомышларымны гына йомышлыйм», — дип, РОНОга кереп китте. РОНОның хуҗалык эшләрен башкаручы җаваплы кешесе Уразаевны ярты сүздән бүлде: «Аңладым, аңладым... Ләкин, Ходам шаһит, бер дә генә ярдәм күрсәтә алмыйм. Әйдәле, ышанмасаң үзең кара». Ул Ялан мәктәбе директорын буш, салкынча складка алып керде, почмактан калай банка тартып чыгарды. «Бу — кызыл буяу. Бөтен байлыгым шул. Алсаң — бирәм. Башкасына өметләнмә», — дип кистерде. Уразаев ярым җимерек мичләрен, су тамып торган иске түшәм такталарын, җил сызгырып кереп торган тәрәзә борысларын күз алдына китерде дә, тирән итеп көрсенде һәм бер банка кызыл буяу күтәреп үзен көтеп зарыга башлаган Миңнурый янына чыкты.

Уразаевның җимерек уйларының бер йомгагы булды: «Миңнурый, тот та безнең мәктәпкә кил! Үзебездә фатир торырсың. «Миңнурыйның карашы бер мәлгә җылынып, нурланып алды да сүнде: «Ай, Мөхәммәт абый! Кем мине җибәрсен. РОНО ризалашса да теге козгын, Ибраһим вәкилне әйтәм, мине ычкындырмас. Йотам дигәндә авызыннан татлы калҗаны тартып алырга ирек бирә торган бәндәме ул! Мин Яланга, сезнең янга, рәхәтләнеп барыр идем дә...»

Теле кычытса да Мөхәммәт актыккы сүзен әйтмәде, «мин тиздән сугышка китәргә ниятләп торам» дигән уен белдермәде.

Соң гына, күз бәйләнгәч кенә Яланга кайтып җиттеләр. Фаягөл әткәсенең кочагына атылды, кече якта, чуар пәрдә артында Мөхлисә әбинең буыла-буыла ютәлләгәне ишетелде. Бу ютәл Уразаевның: «Әйе, Миңнурыйны ничек тә булса әби белән бала катында калдырырга!» — дигән уен ныгытты гына.

Миңнурыйга урынны Мөхлисә әби яткан бүлмәгә җәйделәр. Әби белән кунак кызы шактый озак сөйләшеп, гәпләшеп яттылар һәм бер-берсен яратышып та өлгерделәр. Миңнурыйның шушы җылы өйдә җаны тынычлык тапкандай булды.

Иртән Миңнурыйны ияртеп Уразаев мәктәпкә китте, икәүләшеп мәктәпне бер урадылар, ике... Директор күргән-курешкәннәргә кызны «безнең яңа укытучы» дип таныштырды. Әйләнеп-тулганып йөргәч, кызыл буяуга да урын табылды: бик тырышып, тигез төшереп тышкы ишекне кызылга буяп куйдылар. Ремонт шуның белән тәмамланды. «Вәкил килә калса, кызыл ишекне күреп куаначак!» — диде, мәктәп белән танышып йөргәндә тәүге тапкыр елмайган Миңнурый.

Җәберләнгән кызның язмышын тиз арада хәл итәргә кирәк булса да, Уразаев атна узганчы торага җыенып чыга алмады. Мәктәпкә утын китерәсе, бер очтан үз хуҗалыгына да ягулык ташып куясы бар иде. Хәлсез карчык белән көчсез кызны утынсыз-нисез Себер кышына кертеп

җибәрсәң... Алла каргар! Райбашкармага кат-кат шалтыратып, аннан бер, моннан ике ат юнәтеп атна эчендә шактый утын ташып та куйдылар. Дәүләтшә әкә миһербанлык күрсәтте, мәктәп директоры ихатасына да утын ташытып куйды.

Түземсезләнеп көткән көн килеп җитте. «Яшь укытучы Миңнурыйны Ялан мәктәбенә эшкә җибәрегез» дигән гариза белән Уразаев РОНОга барды. Мөдир өйдә юк иде. Уразаев РОНОдагы күз күргән кешеләр белән иплəп кенә сөйләште, кадрлар бүлегенә кереп тиргә батканчы утырды. Сөйләшү авыр барды, инде хәл ителде дигәндә генә мөдир кайтып керде һәм эшнең асылын аңлауга җаны-тәне белән каршы төште. Уразаев суынып, кара сөмсеренә батып Ялангa кайтты. Күз яшен күрсәтмәсә дә, Миңнурыйга аның ни уйлавын белү кыен түгел иде. Үз авылыннан Яланны үтеп киткән юлаучы Ибраһим Миңнуллинның пыр тузып аны эзләтү хәбәрен җиткергән иде. Тагын ике көн үтте. Мөхәммәт белән Миңнурый утын кисеп, аны Мөхлисә әбинең лапас астына ташып өйделәр. Шунда, эш арасында Миңнурый Мөхәммәт абзасына өр-яңа вә бик сәер фикерен әйтте. «Мөхәммәт абый,— дип йомшак тавышы белән башлап китте сылу кыз. Мин чишә алмаслык табышмакка тап булдым. Сизәм, моннан ансат кына котылмак юк. Каядыр еракка китеп олагыр идем, җибәрмәсләр, мин һаман учетта. Паспортым юк. Авылга кайтасым килми. Ибраһимның төнлә-төнлә килүен күргәләделәр. Исеме-чабы чыккан мөгаллимнең ни абруе булсын? Ялан миңа бик ошый. Тын да, аулак та. Сездә килмешәкләр юк әлегә. Сез РОНОда: «Мин Миңнурыйга өйләнәм, аны Яланга алып кайтам»,— диегез. Шикләнмәгез, муеныгызга асылынырга да, кылган языгымны да качырырга җыенмыйм. Мин саф кыз. Үз өлешемә язган егет очраганчы шулай булып калырмын да».

Мөхәммәт бер агарды, бер күгәрде, кызның чая уеннан тәмам аңгыраеп калды. Исенә килгәч, җайлап кына кызның тәкъдимен кире какты. Хәбәр сәгате белән Саниясенә барып ирешәчәк, ил-көн алдында көлкегә калачак, хата эшләп адәм рисвае булачакбыз, диде. Әмма кыз һәр ягын уйлап куйган булып чыкты. «Сания апа кайтыр, һәммәсен җайлап аңлатырбыз. Сез фронтка чыгып китсәгез кешe, Мөхлисә әби белән Фаягөлне үзем карап торырмын. Җәберләмәм, хәзерге бәла-казалардан бергәләп котылсак кына инде...»

РОНОга яңа тәкъдим белән барды Уразаев, бер үк вакытта военкоматка кереп гариза да калдырып чыкты. Ул көннәрдә нәкъ аңа кирәкле хәрби часть — Түмән коммунистик дивизиясе оеша башлаган иде. Уразаев шунда җибәрүләрен үтенде. РОНОда элекке укучылары Сәрвәр белән Нурияне дә сугышка алынган укытучылар урынына билгеләтте. Мәүлия биология өстенә немец телен дә укытырга булды. А, кызның бәхете: Миңнурыйны «кияүгә чыгу» уңаеннан Ялан мәктәбенә күчереп куйдылар.

Ахыр чиктә иң кыены нәни Фаягөле белән аның әбисен калдырып китү иде. Берсе бала, икенчесе зәгыйфь карчык. Әгәр Миңнурый, яннарында җитез һәм кече күңелле Миңнурый була алса, Мөхәммәтнең хафа богавында торган күңеле тынычрак булыр иде.

Мөхлисә әби ил язмышы хәл ителгәндә Мөхәммәт кебек ир-егетнең авылда ятуы мөмкин түгеллеген яхшы аңлый иде.

— Гитлер мәлгуньнең муенын сындырып, Саниям белән бергәләп тиз әйләнеп кайтыгыз,— диде ул, күз яшьләрен тыярга һәм яшерергә тырышып.— Шамил улым да сау-сәламәт йөрсен. Илдә чыпчык үлми. Хак язганы булыр, безнең өчен кайгырма. Фаягөл наныемны күз нурым итеп карармын. Хәерле юл, кияү.

Мөхәммәт Уразаев Мөхлисә карчыктан Миңнурый хакында берәр җылы сүз, фикер көткән иде, әмма карчык өйдәш булып каласы кыз турында аны-моны әйтмәде. Эчтән нык сыкрап булса да киявенә хәерфатихасын бирде.

— Рәхмәт сезгә, олы җанлы әнкәебез! — диде күңеле нечкәргән кияү. Аннан Мөхәммәт үз әткә-әнкәсе белән саубуллашырга Фаягөлен ияртеп зиратка чыгып китте. Миңнурый да аларга ияргергә теләгән иде, тыелды, аның көпә-көндез Мөхәммәт абыйсы белән янәшә басып ил-күз алдыннан үтеп китәсе килмәде.

Аталы-кызлы шәрәләнгән каеннар, кояш нурларын эзләп күккә үрелгән мәһабәт кедрлар, куппы яшел чыршылар арасыннан боргаланып барган сукмактан тын гына бардылар. Уңда күрер күзгә якын һәйкәл күренде. Мөхәммәт туктап аңа башын иде.

— Бу ни, әтием?

— Монда Сәрвәр апаңның әткәсе Эссәт әкә ята. Аны явыз бандитлар үтерде.

— Калбәй әкәне үтергән фашистлар да бандитмы?

— Болары тагын да әшәкерәк, кызым.

Фаягөл фашистларның һәм бандитларның кем булуларын бик яхшы аңлагандай: «Й-й, — дип сузып куйды. Уразаев янәшә яткан әти-әнисе янына килеп баскач, шактый вакыт уйга батып торды. Аннары чүгәләде, каберләр өстеннән бармаклары белән аралап бер уч туфрак алды, аны сулышы белән учында җылытты, күлмәк астыннан муенына эленгән ефәк янчыкка салды. Әткә-әнкәсе янындагы буш урынга карап көрсенде дә кызын җитәкләп, аска, бик күп эзләр сеңгән сукмакка карап кайтып китте. Фаягөл әтисеннән күзен алмады, әмма ләкин әтисенең күңелендә кайнаган уйларны аңламады. Сабый шул әле. Әти-әнисе белән генә түгел, үзенә дип багышлап куйган буш урын белән дә саубуллашты Мөхәммәт Уразаев. Үзенең асыл сөякләре ата-ана кабере янында булуын, туган төягендә таралып ятуын тели иде мөгаллим, хәзер әнә куркынычлы юлга чыга. Тагын кайтып күрерме ул туган якларын, ямьле Иртеш буйларын?..

Күңелендәге ният ныгыган иде Мөхәммәтнең, хәзер һичбер икеләнүләргә урын юк, бүгенге авыр, хәвефле шартларда ул Саниясе, Шамиле янында булырга тиеш.

Кайтып керүгә аларны ишегалдында Миңнурый каршылады, ваемсыз Фаягөл үзләренең дөньяның иң моңсу почмагыннан кайтуларын онытып ягымлы йөзле апасының кочагына атылды. «Кемнең күңеле ничек икәнне балалар сизә!» — дип уйлап куйды Мөхәммәт һәм икесен тынта калдырып өйгә керде. Юлга чыгар алдыннан кайбер нәрсәләрне җыештырып, барлап куярга кирәк иде. Авыл арасында җыелган җырлар дүрт дәфтәр булган икән. Бәетләр дә бар. Әмма аерата кирәкле, күз карасыдай сакланырга тиешле кәгазьләр сандык төбендә яталар иде. Өлкәннәрдән җыйган истәлекләр, гәҗит-журналлардан кисеп алынган тарихи белешмәләр-фактлар Уразаевның аерым бер мактанычы иде. Ул Себер татарлары тарихына багышланган, күзенә чалынган байтак документларны, ишеткәннәрен, күргән-белгәннәрен пөхтә итеп калын бер папкага туплаган иде. Моңарчы кәгазьләрне берәүнең дә күргәне юк. Уразаев аларны якыннарына да белдермичә, Саниясенә дә ачылып китмичәрәк, шыпырт кына туплый барды. Аллам сакласын, авылның авызы тишек, Тубыл тирәсенә барып ишетелсә... Авыл мөгаллиме, коммунистның хан заманнары белән мавыгуын белеп калсалар... Бетте баш, калды муен сераеп булыр!

Ул ясканып, нык кызыксынып, беренче тапкыр күргәндәй комарланып кайсылары искергән, чит-читләре кителгән кәгазьләргә йотылды. Әбисенең: «Кияү, әллә чәйләп алыйкмы, балага йокларга вакыт!» — дигән йомшак сүзләрен ике-өч тапкыр әйткәч кенә ишетте. Чәй эчтеләр, гаилә белән эчкән кичке чәй һәрчак тәмле була, чәй янында Сания белән Шамилне сагынып телгә алалар, җаннары җылынып китә. Кече якта урыннар җәелде, яшьләрне ияртеп әби шул якка чыгып китте. Мөхәммәт лампа филтәсен бераз калкытып кәгазьләре өстенә иелде. Шул чакта

сискәндереп тәрәзә шакыдылар. Уразаев ялт кына күтәрелеп карады да таралып яткан кәгазьләрне тиз-тиз катыргы тартма эченә тутырып куйды, тартманы күренмәслек итеп ястык астына яшереп кертте. Шуннан соң гына сак атлап ояддына чыкты, тышкы ишекнең келәсен күтәрде. Каршысындагы адәмне танымады, аның шактый өшәнгән карт булуын һәм нык ук аксавын гына абайлады. Яктыга кереп хуҗага йөзе борылгач кына ул ят кешенең кем икәнен аерды: әйе, бу ул ич, Тубыл НКВДсының подвалына ябылгач аңа көтелмәгән теләктәшлек күрсәткән, ничектер ярарга тырышкан ягымлы бәндә иде. Ягымлы дип, әгәр аның берсе өскә менгән, икенчесе аска җимерелеп төшкән сирәк кашларын, яңагындагы куе зәңгәр яра эзен, чалыш авызын күрмәсәң, ягымлы санарга да була иде. Беренче күргәндә каян алып бу гарип-горәбәне Канталыев дип уйлады соң? Шулай уйларга ни сәбәп булды? Канталыев зифа һәм купшы офицер иде ләбаса! Ә бу...

Керүче түргә узмады, картузын салып тезенә сугып какты, кайчандыр солдат иңендә йөргән, хәзер төймә тишекләре ашалган, җиң очлары кыршылган плащын җилбәгәй җибәреп, бераз тыңланды да кече якка башын кыйгайтып: «Өйдәләрме?» — дип сорады. «Йоклыйлар»,— диде Уразаев, үзе эченнән: «Миннурый йокламаган булса ярар иде!» — дип уйлады. Керүче өзмәс көлемсерәп торса да, аның белән йортка ниндидер шом, хәвеф керде. Менә ул тәрәзәгә килде, пәрдәне күтәреп тышка карады. Шуннан соң гына өстәл янына килеп утырды. Уразаев аңа каршы яктан урын алды. Бер-берсенә карашып шактый вакыт утырдылар шикелле. Килүче тагы да ягымлырак елмайгандай итте, әмма сагайган Уразаев аның тирән утырган күз почмакларында яшеренгән явызлык, тәвәккәллек утын абайлады. «Мөхәммәт Уразаев! — дип башлады юлаучы, тавышын сүндереп кенә,— карыйсыз, баш ватасыз инде, иеме? Үткән танышларыгыз арасыннан эзләп-аптырап кемлегемне белергә тырышасыз. «Шулай»,— диде Мөхәммәт туры карап,— төсмерлим дә сыман, тик менә, кем булуыгызны өзеп әйтә алмыйм». Кеше, тырнаклары яргаланган, буынтык-буынтык бармаклары белән өстәлдә барабан какты да тагын да сүрәнрәк, шыпырт тавыш белән сүз башлады. «Интекмәгез. Бүтәннәр өчен мин алла бәндәсе! Ә сезнең өчен күптәнге танышыгыз Канталыев булырмын. Шикләнмәгез, мин ерак түгел, теге дөньядан да кайтмадым. Документларым тәртиптә, совет законнарын бер чакта да бозмаган, урта хәлле крестьян баласы. Эшләгән урынымны беләсез... Киткән кошлар бер әйләнеп кайта икән ул, Мөхәммәт Уразаев. Нигә кайттым дигәндә... миңа сез гомер буе бөртекләп җыйган кәгазьләр кирәк. Бөтенесен беләм! Синең һаман-һаман эзләнүләрең дә мәгълүм, чөнки мин һәм минем кешеләрем бер сукмактан диярлек йөргәнбез. Ләкин син мондагы кеше, табышларың күбрәк. Синдә булган мәгълүматлар миндә булса, мин әллә кайчан Күчем хан хәзинәләренә ия булып, дөньяның кендегенә әйләнә идем. Сез иртәгә сугышка чыгып китәсез. Күреп торасыз, мин сезнең хакта сез уйлаганга караганда күбрәк беләм! Әйләнеп кайтасызмы, юкмы, анысы Алла кулында. Шикләнмим, хан хәзинәсен мин сез белгәннәрдән башка да табам. Ие, табам! Мәгәр сездәге фактларга таянып тизрәк табам мин аларны! Миңа ашыгырга вакыт!»

Канталыев һаван пышылдап диярлек сөйләшсә дә тавышы торган саен ныгыды, соңрак үткер чалгы чыңлавына әйләнде. Белеп, Мөхәммәтне аяк астына салып таптарына ышанып сөйли иде юлаучы. Хәзер Уразаевка мөмкин кадәр тыныч, сабыр һәм акыллы булырга кирәк иде. Йөрәге калтыравын, күкрәге өстенә авыр таш төшеп ятканын һич тә сиздермәскә иде! Ул тирән итеп көрсенде дә:

— Хаталанасыз, господин-әфәнде,— диде ул, сүзләре арасына тыныш ясап.— Әйе, яшьрәк чакта тиле-тәүкәл булып казна эзләп чапкан чаклар булды. Ләкин шуны әйтәм: сездән өлгер кешеләр дә яши дөньяда! Документларның мин җыйган кадәресен быел яз ук алып киттеләр.

Канталыев сикереп торды, кыска аягы ягына чайкалды һәм саклык кирәклеген дә онытып: «Кем ул? Кайда яши ул хайван?» — дип кычкырып җибәрде. Уразаев та турайды, тәрәзәгә карады, пәрдә ачыгыннан берәүнең чәбәләнгән озын сакалы күренеп китте. Димәк, тагын да саграк булу кирәк аңарга! Канталыевның утлы күмергә баскандай сикергәләвенә эченнән генә сөенеп, ул баягыдан да тынычрак тавыш белән: «НКВД абзаң алып китте аны, НКВД абзаң. Ертык кәгазь почмагын да калдырмадылар!» — диде. Канталыевның чытырдап йомылган йодырыгы яшен булып аның күзләре турында уйнады. «Алдыйсың, мөгаллим, хәйлә корасың. Онытма! Теге чакта, урман кичкәндә дуган түбәсеннән утлы ук сызгырып үттеме? Бу — кисәтү иде. Сине ни көткәнен белдерү иде. Онытма, шул ук юлдан иртәгә үтәсең бар. Кача алмыйсың, маташсаң, пуля сине момент эзләп табачак.»

Уразаев көчләп елмайды һәм НКВДның документларны кайчан алып китүен сәгате-минуты белән аңлатып бирде. Озак сатулашты Канталыев: янады, куркытты, караңгы тәрәзәгә карап нидер ишарәләде. «Яхшы,— диде ул ахыр чиктә,— НКВД алганмы кәгазьләрне, юкмы, ачыкларбыз! Син китсәң, монда кызың кала. Документ урынына ул да ярап торыр.» Бу сүзләрне көтә иде Уразаев, Канталыевның соңгы дәлиле шул буласын чамалый да иде. Анда да бирешмәде Уразаев, сынмады, ниһаять, аның ныклыгын күреп Канталыев икеләнде шикелле, яңа хәвеф-хәтәрләр вәгъдә итеп янады-янады да чайкала-чайкала чыгып китте.

Канталыев үчегүе, янавы белән түгел, үзенең оятсызланып кемлеген ачып салуы белән Уразаевның йокысын алып китте. Күрче син аны, юньсезне! Кемлеген әйтте дә бирде, тычкан-мәче уены уйнап тормады. Шулай иркен ачыла ала икән — кемгәдер таяна дигән сүз. Дөньяның агышына аркалана дияр идең, дөньяны кем белеп бетергән? Бүген бер төсле ул, иртәгә меңгә төрләнә. Бер нәрсә шиксез: Канталыев Уразаевның НКВДга барып үзен чагып йөрмәячәген тәгаен белә. Саниянең әнкәсе белән кызчыгы Фаягөлнең Ялан авылында ятим-ялпы калачакларын истә тотып ачыла Канталыев. Ялгыз түгел, кемнәредер бар. Максатлары ачык...

Әкрен генә урталай чатнаган башыннан төрле якка йөгерешкән фикерләрен җыеп, бергә тупларга дип утырган арада, кече як ишеге ачылды, аннан иңенә ак яулык салган Миңнурый килеп чыкты. Уразаев сораулы күзләрен куркынган кызга күтәреп карады. «Мөхәммәт абый,— диде Миңнурый, бармакларын бармаклары белән аралап.— Кичерегез, мин һәммәсен дә ишетеп яттым. Бәйләнә башласа дип чыра пычагын да янproblematic алган идем... Бәндәнең үзен күрмәсәм дә беләм: сезгә куркыныч яный. Болай итик: ул кәгазьләрне миңа бирегез, мин аларны иплəп кенә Җәмилә әби катына шудырырмын».

Шулай килештеләр. Уразаев китеп аяк эзләре тынгач, торага ишле кешеләр барган бер очракта Миңнурый аларга ияреп Яланнан китә дә, Җәмилә әбисе янына кайтып, киңәш-табыш итеп, карчыкны кисәтеп кәгазьләрне шунда калдыра. «Безнең Җәмилә әби дөньяның һәр сызыгын аңлый торган әүлия карчык!» — диде Миңнурый, өметле нурлар балкыган күзләрен Мөхәммәт абыйсына тутырып карап.

## 6

Камалышта калган Бишик-Тура йортларын өч көн сугышып та ала алмагач, шымчылары китергән хәбәргә Ермак та ышанды: бу йортларда хатын-кыз бәһасен бик шәп белгән Күчем ханның гүзәл бичәләренең берсе булырга тиеш! Татарларның шундый үҗәтлек, ныклык белән каршы торуын Ермак беренче тапкыр күрде. Инде генә бетте татарлар, канга тузып теге дөньяга күченделәр дип уйлыйсың, тагын

калкындылар алар, җир япыкларыннан чыгып ук яудырдылар, сөңгеләр, пычаклар тотып һөҗүм итүче урыслар арасына ерып керделәр. Өч көн тоташтан орыш барды! Ермак яраннары канлы бармакларын бөгә-бөгә корбаннарын санадылар. Татарлар тынмады, алар яу кырыннан үз корбаннарын, урыс кулыннан үткән яугирләрен ташыдылар. Кая куялардыр шәһит яугирләрен, белерлек түгел, әллә алдан әзерләнгән яшерен чокырларга, саклык базларына илтәләр инде? Күчемнең байтак көчләре Бишик-Турага тупланган, дигән хәбәрләр дә раска чыга, ахрысы. Кырыс Ермак тар маңгаен җыерып авыр уйлардан газап чигә.

Күзгә төртсәң күренмәслек салкын октябрь төне ябырылды. Андасанда посып кына янган юаш учак утларын җил аудара. Урыслар бар булган көчләрен җыеп, явызланып, татарларга ләгънәт яудыра-яудыра тагын бер тапкыр күтәрелделәр. Дружина солдатлары кимегән саен Ермак кырыслана бара, алда ханлыкның мәркәзе Искер, татарларны аннан куып җибәрер өчен шактый көч кирәк буласын ул хәзер аңлый. Элегрәк алар татар җирен җиңел генә яулап алыр кебек тоелган иде. Менә бүгенге бәрелеш ни күрсәтер!..

Урыслар күтәрелде, татарлар аларга каршы ташланды, кылычлар чыңлады, яралы атлар ыңгырашты, канга тузган яугирләр үлем ачысы белән тартышып җан бирделәр. Таң алдыннан сугыш тынган кебек булды, инде көн тәмам яктырып, сугыш кыры ап-ачык күренә башлагач урыслар гаҗәпкә калдылар: татар гаскәре эреп югалган, күзгә күренмәс булган. Урыслар чукынып бер-берсен тынычландырдылар: «Аларның шулай кача торган җир асты мәгарәләре бар!»

Акыллы Күчем хан ханлыкның язмышы Искер өчен сугышларда хәл ителәчәген белә иде, шуңа күрә ул Бишик-Туран ташлап китеп, бар булган көчне мәркәзе тирәсенә тупларга карар кылды...

Үз көченә, җиңелмәслегенә ышанган тәкәббер вә горур хан, кайчан исә бер Искер дошман кулына төшәр дип уйлап та карамый иде. Тәкәбберлек һәм горурлык ханнан яу башларына, гади яугирләргә дә күчеп, ханлыкта ваемсызлык чире дә йоктырган иде. Ермак килеп чыгып, һич көтелмәгән тарафта хан урдасының таралып китүенә дә әнә шул чир сәбәп булды. Себер ханы, ил агалары, руханилар, гаскәр башлыклары: «Аллаһе Тәгалә һәм Мөхәммәт пәйгамбәр кодрәте белән нигез салынган ханлык гомергомергә, ахырзаманга кадәр исән-имин яшәячәк!» — дигән ялгыш уй белән харап булдылар. Әле бу хакта ил белми, татарлар урысларны тар-мар итәргә ханның көче вә хәйләсе җитәчәк, дип ышанып торала. Хан үзе бүтәнчәрәк уйлый, бүтәнчә хөкем йөртә. Бирмәс иде ул күңеленең кәгъбәсе булган Искерне явыз урысларга, аяк та бастырмас иде!

Кырык ел дәвамында ханлык кылган Күчем Искерне данлы-шанлы мәркәз итеп төзегән иде. Дөньяның дүрт ягыннан, төрле төбәкләрдә төрле телләрдә сөйләшүче халыклар, Искернең данын ишетеп шул төбәккә агылдылар. Сәүдә кешеләре, руханилар, байлык артыннан куучылар, малтабарлар, маклерлар Искергә иркен үтеп кереп шунда урнаштылар, яшәп калдылар. Себер шәһәре һәркемне юмарт кабул итте. Биш-ун кешесен ияркткән Ермак та хан башкаласына иркен кереп, күзәтеп, үзенә кирәк урыннарда иснәнеп йөрде. Ханның байлыгы, аның алтын-көмеш, энҗе-мәрҗәннәре саклана торган җир асты сандыклары хакында Ермак күп риваятьләрне шул чакта ишетте. Риваятьләрне Азия-Аурупа илләренә тасма телләр, комсыз куллар ишәйтеп таратты. Шул хәбәрләр чакырды урыс гаскәрен татар җиренә! Комсыз Ермакка шул хәбәрләр көч-гайрәт өстәде!

Ханлыкның ахыр чиктә тар-мар ителәчәген, татарларга Иртеш буйларын йә ташлап китәргә, йә урыс явызларына кол булып изелеп яшәргә туры киләчәген бүген Күчем хан аермачык белә иде. Искернең көннәре санаулы, ул илбасар Ермак кулына төшәчәк. Урысны җиңә торган көч юк, дәүләт диңгезләрдән диңгезләргә җәелгән. Урыс канында дөньяны басып алу ярсуы яна.

Ермак гаскәренең беркемне дә, бернәрсәне дә аяп тормаслыгын да белә Күчем хан. Иң әүвәл карт-корыны, бала-чаганы, хатын-кызларны дошманга бирмәскә кирәк. Көтү-көтү елкы, бүтән мал-туарны да урыска калдырырга ярамый. Тагын бер-ике тәүлек кенә урысларны Искергә үткәрмәскә иде. Йа Хода, ярдәмче бул!

Кырык ел күз карасыдай җыелган, берәмтекләп тупланган хан казнасын нишләтергә? Күчем хан ил хәлен бик яхшы аңлый, әгәр казнаны урыныннан кузгатып күчерә башласаң, илдә шом таралачак. Яугирләрнең хәлен алачак. Урыс баскыннарының явызлыгы, кылган аяусыз җинаятьләре хакындагы хәбәрләр Иртеш дулкыннарына ияреп бөтен төбәкләргә җиткән, карурман эчләрендә, сазлык урталарында утырган ерак йортларга да кара шом барып ирешкән. Күчем ханның казнасы турындагы имеш-мимешләр урыс гаскәрләре арасында да нык таралган. Яу башлыклары гына түгел, гап-гади укчылар да хан казнасына азау тешләрен батыру турында хыялланалар. Нишләргә? Казнаны кая, ничек итеп күздән югалтырга?..

Төннәрнең иң караңгысын, иң шомлысын сайлап, хан станыннан бер алай атлылар юртып чыкты. Тик аларның кая нинди максат белән юл тотканын ханның үзеннән башка, иң ышанычлы тән сакчылардан һәм ике-өч руханидан гайре берәү дә белми иде. Хан сәфәрне шулай итеп оештырды, әллә аның кешеләре хан казнасын яшерелгән җирдән алып кайтырга ниятлиме, әллә киресенчә дошман күзеннән ераккарак качырырга тырышамы,— татар арасына кереп кысылган урыс шымчылары да моны белми калды. Атлылар алаеның Алтын Мөгез утравына таба юл тотканын гына абайлап калдылар. Көз, салкыннар еш-еш кабатланса да сазлыклар әле туңмаган, атлар кормаклары җиргә тигәнче баталар... Киткәннәр арасыннан бик әзләре генә хан ягасына әйләнеп кайтты.

Мәгәр алар үз бурычларын төгәл үтәделәр: хан казнасы турындагы имеш-мимешләр тагын да ныграк чуалды.

Урыс илбасарлары Искерне алгач, күзләренә кырып салырлык кына хәзинә өлешен күз күрерлек урыннарда калдырырга да кирәк иде. Ачкакларга бер сөяк!

Төн. Себер ханлыгының соңгы төне. Татарларны, аларның гайрәтле ханын алда ни көткәнен әле беркем дә белми. Гайрәте кимемәгән хан төн уртасында чыгып, тән сакчыларының казнадан иң кадерле, иң кыйммәтле нәрсәләрне төяп китүләрен күзәтеп торды да дошман ягына каратып ук атты. Тыгыз җәяне тиз һәм житез тартты ул. Ходага шөкер, Ходай ханнан көчне җәлләмәгән. Әле берзаман әйләнеп кайтыр ул, кайтыр! Шул чагында аңа казна кирәк булачак! Дәүләтнең, дәүләтчелекнең нигезе — казна!

Тора тирәсенә тупланган мал-туарны өер-өер кудылар, аяклы малны саклап калырга өметләнмәде акыллы хан, ул мал-байлыкның урыслар кулында калуын гына теләмәде. Шул көнне Себер сазлыклары, аждаһа булып елкыларны, сыер-үгезләрне йотты. Мал-туарның тавышы да, эзе дә калмады...

Күчем хан да Аксак Тимер кебек дошманнарыннан качып, соңгы көннәренә кадәр мәетләр аймагында гомерен тәмамлармы?.. Юк, юк, киңлекне сөйгән, рухы бары тик киңлеккә омтылган Күчем хан, шакшы күсе сыман, җир астына кереп посачак түгел! Ул иркен Ишим далаларына чыгып югалырга ниятләде. Тик аның бу планын берәү дә белми. Ханның үзе дә беразга югалырга тиеш!

Һәм даңлы-шанлы Себер ханы Искерын ташлап чыкканда, таң күге сыек кына агарып, чыгып килгән кояшның кылыч нурлары гөмбәзне телгәләгәндә Күчем хан җан ачысы белән күкләргә эндәште:

— Йә Тәңрем! Күрәсең, үз ирегем белән Себерне бирмәдем, аны миннән урыс явызы Ермак алды!..

Ил шөһрәтен саклап, Себер татарларының ил агасы булып яшәгән, атлы-тунлы, йортлы-җирле хан «дала дуңгәләгенә» әйләнә, бер кавымга Ишим якларына чыгып югала. Ермак илбасарлары Искерны талыйлар,

хан казнасыннан калган алтын-көмешләрне, бизәнү әйберләрен, кеш туннарны, кыйммәтле тиреләрне чинаша-чинаша бүлешәләр, сугышып бетәләр...

Искер бирелде, хан югалды, ә казнасы кайда?

Акыллы вә хәйләкәр Күчем хан алай посып яту белән генә ризалашмый. Үзен күрмәсәләр дә, аның эзләре гел суынмый, кинәт ясаган һөҗүмнәре белән ул урысларны өзмәс борчып тора. Аның коралллы алайлары дала өермәсе булып урыс йортына бәреп керәләр дә җилдән җитез кыланып күздән югалалар.

Күчем хан мәркәзен ташлап чыкканга сигез ел үткәч, Себер воеводасы Кольцов-Мосальский шактый гаскәр туплап Күчемне эзәрлекли башлый. Алар Ишим елгасы тамагында очрашалар. Бу канлы орышта Күчем ханның ике кызы һәм улы урысларга әсир төшә. Хан үзе исән кала һәм Ишим далалары түрендә тагын эреп югала. Һаман-һаман дәвам иткән, искәрмәс һөҗүмнәрдә күп сугышчыларын югалткан урыс патшасы Федор Иванович тота да күчемгә хат юллый. «Син татардан казакка әйләндең, ялгыз башың, кая барсаң да син куылган зат. Әҗәлең артыннан ияреп йөри. Мин үзем Себергә барып чыгарга риза, теләсәң, элеккеге йортларыңны, дәрәҗәңне кайтарып бирә алам — тик буйсын гына, бирел!» — дип яза патша. Әмма Күчем хан — Себер татарларының горур һәм гайрәтле хуҗасы — мондый тәкъдимнәрне, түбәнлеккә чакыруларны кабул итми, кире кага.

Нәрсәгә өметләнә ул, кемнәргә таяна? Кызганыч, тарихта моңа җавап бирерлек дәлилләр юк, урыслар узган җирдә тарих эзләре таптала, аста, бик тирәндә күмелеп кала.

Ишим тамагындагы каты бәрелештән соң тагын җиде ел үтә. Инде бетте, иксез-чиксез сазламыкларда Күчем хан сеңде, дип кенә уйлыйсың: юк, бетмәгән икән! Кадерле мәркәзе Искер тирәсендә хан тагын пәйда була. Нинди кодрәт, нинди өннәр чакырып кайтара аны? Без моны берчакта да белә алмабыз. Әгәр хан үз казнасын юллап кына йөргән дисәләр дә, моңа ышану кыен. Дөрес, катлы-катлы сугышларда йончыган, бар малын сугыш-бәрелешләргә тоткан ханның тормышы, көнкүрмеше әлләкем булмый, алтын-көмеш хәзинәләр бик тә ярап куйган булыр иде аңа! Малга кызыгып кына кайттымы икән горур хан?

1598 елда ялланган хыянәтче татарлар белән көчәйтелгән вә ишәйтелгән урыс гаскәрләре Андрей Воевиков җитәкчелегендә, Обь елгасының уңъяк кушылдыгы тамагында, Ирмән каласы тирәсендә Күчем станына һөҗүм итәләр. Мондый аяусыз орышның Себер якларында тиңе булдымы икән? Сугыш өч көн, өч төн дәвам итә. Ханның иң гайрәтле, иң ышанычлы яугирләреннән йөз илле баһадир шушы дәһшәтле орышта һәлак була, йөздән артыгы су төбенә китә. Воевода мактанып патшасына хат яза: «Күчем ханны, ниһаять дөмектердем, хатыннарын, балаларын әсир иттем. Обь елгасын аркылы-торкылы кичтем, урманнарны актардым, дәрьяларның барысын да тикшердем — Күчем ханның үзен беркайдан да таба алмадым». Мәскәүдә чиркәү чаңнары атна буе улый, татарлардан талап алынган алтын-көмешләр белән бизәлгән чапаннар ябынган кәрәк сакаллы руханилар аллага һәм ак патшага дан җырлап атна дәвамында бәйрәм иткәннәр.

Шул көннәрдә Күчем ханның эзе өзелә...

* * *

Җимерелгән ханлыкның мал-мөлкәтен эзләү гасырлар буена дәвам итсә дә, аның төп казнасы табылмый, ач күзләрне буыннан-буынга котыртып килә. Халык хәтере кайчагында сак: казнасы булмаса, аның даны гасырлардан гасырларга күчә килер идемени? «Эз-

ләгән — табар!» Әле аннан, әле моннан хан казнасына күзләрен кыздырып, ансат кына баерга теләүче сукбайлар килеп чыга, зур-зур калаларда фәнни экспедицияләр оеша, аларны күбрәк авантюристлар җитәкли. Эзләнүләр гел-гел нәтиҗәсез дә булмый, төрле урыннарда алтын-көмеш акчалар, беләзекләр, затлы чүлмәк ватыклары килеп чыга. Адәм сөякләре тулган чокырларга да юлыгалар эзләнүче ач күзләр...

Дөнья белән нык мавыккан мөгаллим Мөхәммәт Уразаев Сорокин белән Канталыев барын онытып та җибәргән иде инде. Нишлисең, аяусыз дөнья шулай корылган: яхшылар яманнар барын онытып та җибәрәләр, әмма усаллар яхшылар барлыгын һич кайчан да хәтердән чыгармыйлар. Кәкере куллар, яман ниятлеләр җирдәге көндәшләре — яхшы адәмнәрдән һәрвакыт, һәрдаим көнләшеп, кызыгып яшиләр. Сорокин да шундый җаннарның берсе иде. «Иң бәхетле адәм!» — дип бер чакта да авыз тутырып әйтә алмаган, язмышы тарафыннан нык ук кыерсытылган бу адәм, Себер урманнарында шактыйдан качып йөри иде инде. Сугыш башлангач та ул үтә нык сөенде, Совет властен тар-мар итәрлек, дөньяны башка — ул теләгән юлга кертеп җибәрә алырлык көч бары тик Гитлерда гына дип исәпли иде Сорокин. Сугыш чыгып, немецлар дулкыны Рәсәй өлкәләрен берәм-берәм кабып йота башлагач, ул үз тирәсендә җим тапкан берән-сәрән кешеләргә белдермичә генә Көнбатышка — немецларны каршыларга әзерләнә дә башлаган иде инде. Истә-оста югында Тубыл төбәгенә Урта Азиядән Канталыев кайтып төште. Канталыев урман серләрен белә, озакламый Сорокинны эзләп тапты. Очраштылар. Сорокин элгәре Канталыев белән очрашкалаган да иде, хәзер исә кешеләрне хәтерләүгә искиткеч нык хәтерле адәм — аны танымады. Шымчы, НКВД җибәргән мөртәт дип уйлап, чак кына теге дөньяга җибәрмәде. Канталыев көлде генә: «Әгәр танырлык булсам, мин монда кайтып йөри идемме?..»

Канталыев олыгая төшсә дә һаман да хатын-кызга хирыс затсыз вә алама адәм булып калды. Урта Азиядә яшь кенә үзбәк хатынына кул салып, бу даны үзбәк арасында фаш булды. Башка милләт хатын-кызларын кыерларга яраткан үзбәкләр үз кызларына кул салганны бер чакта да кичермәделәр. Төннәрнең берендә, Канталыевның каяндыр кайтып килгәнен сагалап, башта тимер таяклар белән аркылы-торкылы ярдылар, соңра буй-буй дәү капчыкка салып сулы арыкка ыргыттылар. Шунда тончыгып, мәңгегә онытыла иде Канталыев, ул барып төшүгә арыкта су кимеде, тора-бара агудан бөтенләй туктады. Эт җан иде Канталыев, тәне корыч, йөрәге тимерче күреге иде, тешләрен каната-каната капчыкны тиште, башта кулын тыкты, кул сыйган ерыкка гәүдәсе үк кереп китте. Ярты ел чамасы шифаханәдә ятып чыкты. Докторлар аны ямадылар, тектеләр, йөзе-бите танымаслыкка әйләнсә дә, гәүдәсе исән хәлдә көнгә чыкты. Ул арада сугыш башланды. Канталыев моны Ходаның аңа күрсәткән беренче мәрхәмәте дип кабул итте. Онытмыйк, угрылар, мөртәләр, явызлар да кыен чакларда Аллаһе Тәгаләне искә ала!.. Немецларның Урал аръягына, Рәсәйнең киң далаларына чыгып йөземлекавынлы Ташкент тирәләренә килеп җитә алмаслыгын чамалый иде күпне күргән мөртәт. Элегрәк ишеткән бер анекдот хәтеренә төште. Революциядән соң караңгы авыл клубында каладан килгән бер адәм лекция укый икән. «Менә, мадьярларда революция җиңде... Германия кузгала! Һиндстанда да революция көтелә...» — дип санап киткән бу. Алдагы рәтләрдә утырып сасы тәмәкесен авызыннан чыгармаган берәү, башын чайкап аңа каршы төшкән. «Не, не будет этого», — дигән. Лектор зәңгәр күзләрен маңгаена менгереп: «Ник алай дисез?» дип сораган. «Жидов не хватит», — дигән мужик. Монда да шул, Рәсәйне басып алып бетерергә немецлар җитмәячәк. Урал аларны туктатачак. Димәк, аларны көтеп ятмаска, немецларны каршы алырга кирәк!

Бу хакта күп уйлады Канталыев, озак баш ватты һәм шул чакта Күчем ханның әкияти хәзинәсе аның исенә төште. Немецларны каршылап, аларга ничек ярыйсың да, нинди сүз әйтәсең? Төсең-кыяфәтең өтек, кесәң буп-буш, документларда син совет хөкүмәтенең ышанычлысы, гомере буе мәктәптә эшләгән адәм. Әйдә, немецлар урыс илен турый торсын, коммунистларны кырсыннар, Канталыев алар каршысына Күчем хан токымыннан, совет тарафыннан рәнҗетелгән, төрмәләрдә кыйналган, имгәтелгән берәү булып барып чыгачак...

«Бабайлардан калган мал» белән ул һәркемнең ышанычын казаначак.

Сорокин әңгәмәдәшенең кемлегенә ышангач, ике як та алдагы планнарын һич яшермичә ачып салгач, Канталыевның тавышы үзгәрде: «Юк, юк, хәерче хәлендә герман вәкилләре арасына барып катнашу — шыр тилелек. Башта мал юнәтәбез, хәзинәне табабыз!» — диде. Тәки ышандырды Сорокинны. Сүзләрдән бигрәк, тәҗрибәле Сорокинны Канталыев җыйган кәгазьләр, язмалар, хәтирәләр кызыктырды. Ул да шул казнага юлыгыр өчен күпме гомерен сарыф итте, әмма Канталыев юнәткән документлар әлегә анда юк иде. Кулында булмаса да барлыгына хәбәрдар иде Сорокин. Ул үз җәһәтеннән аңа Чырык Абдрахманнан ишеткән хәбәрләрне җиткерде. «Ялан мөгаллимендә кәгазьләр бар, танавы ис сизә аның, кәгазьләрдә юкка казынмагандыр»,— диде.

Ул төнне Сорокин арбада утырып калды, Канталыев мөгаллимне каз йолкыган кебек йолкырга керде. Әмма Уразаевның ныклыгы, каушамавы аны икеләндерде. Чырыкның энәне дөя, чаянны көя итеп күрсәтә алуын да белә иде. Алар, хан казнасына юл эзләп килеп, тишек чиләк тотып кайтып киттеләр. Шунысы җәл: Уразаев иртәгә сугышка чыгып китә. Бүген үк аның башын кыярга, яисә иң биек кедр агачына асып куярга да була иде, Канталыев шулай да итәр иде, Сорокин тыйды: «Бүре ни ач булса да үзенең даими биләмәләрендә ризык җыймас. Уразаев төбәктә билгеле кеше, аның үлеме шау-шу кузгатыр. Болай да бу араларда безгә төрле яктан тозак салалар. Безгә казна табылганчы шыпырт яшәргә кирәк. Кесәң буш, тамагың ач икән — дәшмә. «Казна эзләүчеләрне бер йодрыкка төйнәп, һәммәсенә хуҗа булырга омтылган Канталыев тешен кысып, инде атылып чыгарга әзерләнгән сүзләрен йотты. Чыннан да, ул мал кулга төшкәнче үзара талашырга да, аерылырга да ярамый иде.

## 7

Сания — Мөхлисә карчыкның иманлы, инсафлы, хыянәтсез, тормышка әзерләнгән кызы. Аның күңеле якты, шәфкатьле, яраланган немец солдатлары ул хезмәт күрсәткән лазаретка эләккәндә, ул аларны да чиксез кызгана. Өлкән яралыга карап гел бер төрле уйлый: «И, бичара, бала-чагасы каладыр бу немецның!» — дип куя. Күңеленә тагын кызы Фаягөл килә. Канга тузып, ыңгырашып, чит телдә саташып яткан яшь-җилкенчеккә карап Яланда калган әнкәсен хәтеренә ала: «И ходаем, бу немец та ата баласы бит... Кайдадыр аны да көтәләрдер!» Уйларын яшерергә өйрәнмәгән Сания янәшәсендәге иптәшләре белән чәкәләшеп тә ала. Юкса кайберәүләр: «Дару, вакыт әрәм итеп ятканчы, һәммәсен чокырларга тутырырга да кырып салырга!» — дип кычкыралар.

Сания солдат хезмәтенә эләгеп, фронт юлларында байтак гыйбрәтләр күреп үзгәрергә, яңача яши башларга тиеш булса да, аның әнкәсе тәрбиясеннән ычкынып китә алганы юк. Китмәс тә!

Дивизиягә килеп төшүгә, аны полк командирларыннан берәвесе «эзләп тапты». Килгән сылу хатыннарны чүплэп кенә торырга яраткан бу әрмән подполковнигына кемдер хәбәр җиткергән: «Чибәр бер татарочка килеп төште. Бер кашык су белән йотып җибәрерлек! Подполковник

Саниянең «иңен-буен үлчәргә» үзе килеп житте. Саниянең сафлыгы, тыйнаклыгы, үз кадерен үзе белүе чыраена, буй-сынына чыккан иде. Подполковник турыдан бәрдерде: «Озын-озак сөйләшә торган заман түгел, без бүген бар, ә иртәгә суалчаннарга азык булачакбыз. Миңа сылу юлдаш кирәк. Әгәр мине тыңласаң (әрсез әрмән Саниянең тулышып торган нык күкрәкләренә кул аркасын тидереп алды), янымда калдырам. Көчем житә. Тыңламыйсың икән (сизгерлеген арттырган Сания бу юлы әрсезнең кулын сугып җибәрде), җәһәннәм суырып алыр сине.» Подполковник майлы күзләрен уйнатып, мыек очларын мәзәк кенә кыймылдатып «татарочканы» кабып йотарга теләп кочагын җәйде. Ә Сания лач итеп тегенең битенә төкерде. Әрмән агарды, күгәрде, нәгъръә орды...

Санияне сугышның иң хәтәр кызган җиренә — алгы сызыкка кыр лазаретына җибәрделәр. Сугышларда яраланган, миңгерәүләнгән солдат-офицерлар әүвәл башлап алар кулына килеп керә иде. Көн юк, төн юк, ал-ял турында уйларга да вакыт калмый. Азык-төлек тә үз вакытында килеп җитә алмый. Килгән тәкъдирдә дә аны яралылар белән бүлешергә туры килә. Бүген лазаретта кырык кеше булса, иртәгә йөз илле солдат килеп керә! Иң кыены шул иде, дивизия һаман чигенә, инде чигенү тукталды, урнаштык бугай дип уйлап та өлгермисең, тагын төксе командa колакларны кисә: «Күченергә!» Ай, ул төнге чигенүләр, карлы-яңгырлы көннәрдә качып китүләр. Яралыларның әрнүле ыңгырашулары! Шундый язмышка дучар итүләре өчен яралыларның кемнәрнедер каргаулары. Ул җан биреп ятучыларның соңгы тырпылдаулары!

Авыр һәм хурлыклы чигенүләрдән соң, Сания военврач булып хезмәт иткән дивизия Дон елгасы буенда оборона алды. Озаккамы? Командирлар бер-берсен һәм үзләрен ышандырып: «Озакка!» — диделәр. Ыжгырып куып килгән фашистлардан вакыт-вакыт котылып торсалар да, аяусыз дошманнар совет солдатларына икенче яктан һөҗүм башладылар. Боларыннан һич котылмак юк иде! Бөтен дивизияне бет басты. Дивизия буйлап каты боерык таралды: «Тиф белән чирләүчеләр күренә башлады! Уяу булырга! Аерата эвакогоспитальләрдә, лазаретларда нәтиҗәле һәм ашыгыч чаралар күрергә!»

Солдатларның шытыр-шытыр кашынганын Сания байтактан күреп, борчылып килә иде. Тифы булмаса да, бете бар. Кайгы төште Сания башына, тик нык борчылсаң да, нишли аласың?! Шулкадәр тиз һәм ашыгыч чигенгән атналар булды, авыл мунчалары моңаеп карап калдылар. Хатын-кызларның хәле бигрәк тә мөшкел иде.

Госпиталь тирәсенә кемнәр генә сыенмады, дошман чолганышыннан котылып чыга алган батырлар да бар арада, авыллардан үткәндә чигенүчеләргә ияргән аксак-туксаклар да, ватык-потык машиналарда калтырап кил-килә миләре түнгән яралылар да, тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр. «Армия түгел... чегән таборы!» — дип сукрана иде доктор Фирсман...

Чигенә-чигенә госпиталь аулак, бик тын бер авылга килеп туктады. Элегрәк бик каты бомба гарасаты авылны кат-кат теткәләгән шикелле, сугыш эзләрен шактый калын кар каплап киткән, җан ияләре күренми. «Мунча», — диде Сания ахылдап. Кызганычка күрә, мунчаларның төзеге табылмады, алай да иң кирәге булды: исән калган йортлар арасыннан бик кирәкле нәмәстәкәйне табып кайттылар. Әллә ферма булган монда, әллә ял итү урыны, агач биналар янып беткән, кисәү-бүрәнәләр күмергә калган нигезләр арасында дәү бер чуен шаң аунап ята иде. Ишеге исән, тыгыз ябыла, кемдер: «Бет кыздырырга ярый ич бу!» — дип кычкырып салган.

Кабыл-тибел брезент палаткалар кордылар. Буш мичкәләрне авылдан табылган савытларны гөлдердәп агып яткан инештән су ташып тутырдылар. Тирә-яктан таш, кирпеч кисәкләрен җыеп, алар астына дөрләтеп учак яктылар. Кызып кызарган ташларны сулы савытларга

кертеп салалар да чаж-чож итеп пар сикертәләр, тәки су жылына! Ир-атлар палаткалар алдында чишенәләр дә яланаяк кар өстеннән сикерә-сикерә бетле кием-салымнарын тимер шаңга тутыралар. Терәлеп торган дәү учактан ялкын телләре шаңны кыздыра.

Өзлексез кашудан җәрәхәтләнеп беткән, купшакланган тәнгә сабынлы җылымса су тигәч, солдатлар ах-ух килеп уына башладылар.

Ферсман, таза бәдәнле, биек маңгайлы, җирән чәчле яһүдә маржасы: «Сонечка, син кереп карап чык, хәлсезләнеп ятучылар булмасын!» — дип ике мәртәбә кисәтте. Сания бурлаттай кызарып, йомык тавыш белән генә баш врачына каршы төште. «Бездә... мөселман хатын-кызларында андый гадәт юк»,— диде. Ферсман гаҗәпләнеп: «Син хәзер мөселман хатын-кызы түгел, син сугышчы, табибә!» — дип кат-кат кисәтсә дә, Сания аны тыңламады.

Ул арада әллә ни булды, янәшәдә генә туңган җирне актарып, йокымсырап утырган агачларны чәрдәкләп аударып миналар ярыла башлады, шартлаган саен кар фонтаннары атып җир тетрәде. Брезент палаткалардан шәрәтән гәүдәләр чабып чыкты, Пожаркадан кочак-кочак кайнар киемнәрне чыгарып чөйделәр. Китте киемнәрне эзләү, буталыш, ызгыш-талаш. Юынып өлгерә алмаганнар сабынлы тәннәренә эссе киемнәрен кигәндә, кызган төймәләр арык тәннәрне көйдереп-пешереп алды. Яралы-җәрәхәтле урыннарын әрнетеп яндырды. «Немец танклары моннан биш-алты чакрымда гына икән!» — дигән хәбәр килеп ирешкәч, госпиталь бер кавымга тынсыз калды. Мичемә әз-мәз җылы йөгерә башлаган йорт идәненә тезелеп яткан авыр яралылар да бу хәбәрне тиз ишеттеләр. Аннан да, моннан да: «Сестра, сестра!» — дип кычкырган авазлар, сүгенү, каргау тавышлары дөньяны ярды. Аларны тизрәк моннан күчерергә кирәк иде...

Кул-аягы һәм зиһене исән кешегә сугышның иң авыр мизгеле — чигенү. Чигенү — билгесезлек ул, дошман кай яктан һәм ничек килеп чыгар да син җир шарының кайсы ярыгында җаныңны саклап кала алырсың?! Як-ягында ут, өстән дә ява ул, ян-яктан да, җир үкерә, ыңгыраша, сине тотып чөя, ә син чигенүче, коты очкан бөҗәккә әйләнүеңне сизми дә каласың.

Ләкин солдат чигенүеннән дә хәтәррәк нәрсә бар: ул — язмыш синең кулыңа тапшырган яралылар белән чигенү. Солдат үзе һәм коралы өчен генә җавап бирә. Ә госпиталь-лазарет чигенеше... Бигрәк тә шундый чакта, онытылып мунча кереп маташканда... Команда яңгырый: «Дошман кулында әсир каласыгыз килмәсә, ятрәк кыланыгыз!» Команда яңгырый, команда иясе шундук юк була, җиңел машинасына утырып каядыр сыза. Монда исә... бар булган атлар ашык-пошык җигелә, иң авыр яралыларны шунда чыгарып төйиләр. Алгы пыяласын пулялар тишкәләгән, канатларын ут дулкыны каерып ыргыткан бердәнбер полуторка дер-дер калтырый башлый. Аңа бәйләү материалларын, даруларны, актыккы азык-төлекне төйиләр. Такталар, төенчекләр арасына авыр гәүдәсен көчкә сыйдырып Ферсман менеп утыра. Кемнең әз генә хәле, егәре бар, алар иреннәрен канатып тешләп, яралыларны эвакуациягә әзерлиләр.

Машина югалды, инде ат дугалары да күренмәс булды, кем җәяүләп, кем шуышып бу хәтәр урыннан китеп югалдылар. Миче сүнеп суынган йортта иң авыр, иң хәтәр яралы биш-алты кеше калды. Алар үзләрен ташлап китүчеләр артыннан нәләт сүзләре озатып ятканда, ишектә шинель өстеннән ак халатын кигән Сания күренде. Аны күргәннәр сүгенүдән туктадылар, нинди дә булса өметле хәбәр көтеп аңа текәлделәр. Йөзтүбән яткан ике солдат кына күз яшьләре аша язмышларын каргыйлар, алласын, фәрештәсен, Гитлерны бер очтан эттән алып эткә салалар иде. Мондый хәлдә Сания нишли ала?

Ул бер мәлгә генә югалып, аптырашта калып торды, ниһаять табигый көче, зирәклеге җиңде, ул яралылар укмашып яткан почмакка килеп яннарына тезләнде. «Зинһар, каушамагыз, курыкмагыз! — диде, — хәзер машина борылып кайтачак. Бергәләп госпитальне куып җитәчәкбез. Сабыр гына ятыгыз, туганнар.»

Ыңгырашулар бер мәлгә тынган кебек булды, әллә атыш-шартлау тавышлары ыңгырашларны капладымы? Секунд саен хәлнең мөшкелләнгән аңлаган Сания чарасыз иде: нишләргә? Яралыларның күзе аңарда, яралыларның өмете табибта. Монда озак юанырга һич тә ярамый иде. Китә дә алмый Сания, калырга да ярамый. Ул арада шартлау тавышлары тынды, төчкереп-зарланып машиналар үтте, чыелдап машина туктады, ят телдә ирләр сөйләшкән сүзләр колакка эленде һәм яралылар яткан йортка дүрт немец килеп керде. Күнекмәгән күз аларның офицермы, солдатмы икәнен аермады, иллә мәгәр керүчеләр ачулы һәм үтә кырыс иде. Автоматлар белән юл салып алар әкрен генә яралыларга якынайдылар һәм Саниядән башкаларның хәле чамалы икәнен шундук абайладылар... Тәҗрибәле күзләр яралыларны капшады, тәҗрибәле куллардагы автоматлар бер тынга тырылдады да, яралы солдатлар эһ итәргә дә өлгермәделәр...

Немецларның озынырагы сул кулын сузып, изәп Саниягә алга барырга боерды, «шнель, шнель» дип каулады.

Чыкса! Дөнья актарылган, солдатлар анда да, монда да канга, карга күмелеп төрле рәвешләргә кереп җан биргәннәр. Юл уртасында дәү әрҗәле немец машинасы пуфылдап утыра, анда бөкшәйгән, төс җуйган, кайсы яланбаш, күбесе яланкул кызылармеецлар утыра. «Әсирләр!» — дип уйлап өлгерде Сания, озын немец аның җилкәсенә китереп төртте һәм үткер соры күзе белән аңар машинага менәргә кушты. Сания әрҗә читенә ябышты, өстән кемдер аңа кул бирде һәм ул шушы өшәнгән бичара ирләр арасына менеп урнашты. «Әсирләр! Дошман кулына төшкән бичаралар!» — диде ул үз-үзенә. Әле ул чакта үз хәлен, алданиләр күрәчәген уйлый алмый иде Сания. Бу ниндидер ялгышлык, хата, уен гынадыр, менә-менә кемдер килеп чыгар да аны да, як-яктагы мәхбүс мескеннәрне дә йолып алыр кебек тоела иде.

## 8

Ялан белән, нәни кызчыгы Фаягөл белән хушлашу үтә авыр булды Мөхәммәткә. Саубуллашу, аерылышу җанга шушы кадәр тәэсир итә дип һич уйламаган иде. Ир-ат югыйсә, җылады. Мөхлисә әби дә өзмәс балавыз сыкты, яулык очлары күз яшенә чыланып бетте. Бер Миңнурый гына сабырлыгын саклады, мичкә арты белән сөялде дә иреннәрен тешләп Мөхлисә карчыкка да, Мөхәммәт абыйсына да карамаска тырышты. Әби белән баланы карарга, Мөхәммәттән калган кәгазьләрне югалтмыйча сакларга вәгъдәләр бирде...

«Төшләргә кереп йөдәтер инде туган-үскән яклар!» — дип уйлаган иде Мөхәммәт, кая ул, төшләр күрерлек йокы эләгәме урыс солдатына?.. Аны бертуктаусыз куалар, чак кына кыек атласаң да җәзалыйлар, төн юк, көн юк, сугыш уеннары уйнаталар. Ашау такы-токы. Юл, юл, юл! Ике атналык кыска курсларда чакта шактый иләделәр Мөхәммәтне, гәүдәсе юкаланып, буе тураеп калды егетнең...

Күптәннән партия әгъзасы, гражданнар сугышының да кыйпылчыгын күргән, «сибиряк» дигән данлы исеме булган Уразаевны замполит иттеләр.

Юлда ике тапкыр бомбалар яңгыры астында калып, байтак юлдашларын югалтып, алгы сызык дигәненә якынлаштылар. Формировкада чагында ук Мөхәммәт Уразаевлар полкын туплар һәм снарядлар белән

тәэмин итә алмыйча интектеләр. Фронт әнә якында гына, ә тупларны тартып йөртер өчен атлар да, машиналар да җитми иде. Шуңа күрә алгы сызыкка күчкәндә полкны икегә бүлделәр. Мөхәммәтнең уттанерактарак буласы килгән иде дә, беренче нәүбәткә эләкте. Замполит Уразаев беренче нәүбәттәгеләр белән Сосновка авылына килеп төште. Күз-баш алырга да өлгермәделәр, машиналар теркәлгән тупларын калдырып, полкның икенче өлешен һәм азык-төлекне алырга киттеләр. Бу бик куркынычлы хәл тудырды.

Машиналар бата-чума чак-чак кына үткән юллардан туплар тагылгын атлар кайчан килеп җитәр?.. Мөхәммәт мәшәкатьләргә баш бирмәскә, үз күңелен күтәреп, сөмсерләре коелган тупчыларга дәрт өстәргә тиеш иде дә, юк кына, уен үзгәртә алмаган йөзеннән аптырау галәмәтләре китми. Тәҗрибәле солдатлардан берәвесе, чал мыеклы сибиряк Пахомов аның тирәсендә чуала. «Килеп капмадык микән без, командир?» — дип кабатлый. Сугыш хәлләрен дөрес чамалый Пахомов. Полкның икенче яртысын тылсым белән тыртып китерер иде дә Мөхәммәт, сугышта тылсымның гайрәте юк! Алар дүрт күз белән көткән арада хәбәр алынды: «Дошман танклары якынаеп килә!» «Ничәү?» — дип сорады Мөхәммәт. «Җитәрлек! диделәр аңа.— Утыз-кырыктан ким булмас!»

Расчетлар рәтләп урнашып өлгермәгән, элемтә чыбыклары сузылмаган, иртә таңнан юл килгән солдатлар ач. Ач солдатның ачуы яман!

Уразаев бердән бербәйләнеш чыганагы радио аша бригада командирын эзләп тапты. Сосновкада Уразаевтан югары дәрәҗәле командирлардан берәү дә юк икән! Хәзер барлык җаваплылык аның өстендә калды.

Уразаевның каны кайнады, тик аны берәүгә дә күрсәтергә ярамый иде. Комбригның кыска вә кырыс «Ну?» дигән соравын ишетүгә, Уразаев хәлне яшереп, шомартып тормады. Эш шомартудан узган иде. Ул ачык текст белән командирына хәл-әхвәлне төшендереп бирде. «Немец танклары авылга һөҗүм итә, иптәш командир. Безнең снарядлар аз. Ашыгыч ярдәм сорыйбыз.» Рация бераз тынып торды да аннан комбриг әче боерыкларын яудыра башлады... «Миңа боерык түгел, снарядлар кирәк!» — дигән сүз чак кына Уразаевның теленнән ычкынмады. «Бар булганы белән дошманга отпор бирегез! «Бер адым да чигенмәскә!» Бу минем сүз түгел, главнокомандующий иптәш Сталин боерыгы!»

Карлы урам-тыкрыклары белән тын гына утырган Сосновка авылында мәхшәр купты. Беренче, икенче батареяларны урнаштырып бетерделәр генә, авылдан ерак та түгел калкулыкта дошман танклары күренде. Гөрселдәтеп ата-ата каршыңа дошман танклары килгәндә җаның үкчәгә төшеп китсә дә ни әйтмәк кирәк? Танклар килә, ниһаять, ашыгып-кабаланып бу яктагы туплар да төчкереп куйды. Ике яктан да атыш башланды. Бар икән, тупчылар арасында осталар да, җебеп төшмәгәннәр дә бар икән. Менә бер танкны чәнчелдерделәр, икенчесе кара төтенсөремгә уралып туктады. Өч!.. «Снарядлар бетте! Снарядлар!» — дигән тавышлар Уразаевка төрле яктан килеп ирешкәч, ул тагын рациягә тотынды. «Иптәш комбриг! Дошман безнең оборонаны өзде. Ярдәм кирәк, ярдәм!» дип кабатлады. Комбриг аты-юлы белән әче итеп сүгенде, немецларны сүктеме, әллә үзебезнең солдатларнымы, аңлашылмады. Баягыдан да яманрак итеп: «Бер адым да чигенмәскә! Гранаталар, ягулык шешәләре белән дошманны үткәрмәскә!» — дип кабатлады. «Якындагы нарат урманына чигенергә рөхсәт итегез. Шунда торып полкның калган өлешен каршыларбыз!» — дип ялварды Уразаев. Рация: «Уразаев! Сез паникер, маңка! Күзгә күренүгә, мин сезне атачакмын! Сталин приказын оныттыгызмы? Нык торыгыз! Туплар дошман кулына төшә күрмәсен и все!»

Комбриг үз приказы белән Уразаевның аягын-кулын бәйләп куйды. Әле ярый, танклары яна башлаган немецларның һөҗүме бер мәлгә

сөрлекте, алар, Кызыл Армиянең зур көчләре белән очраштык, дип фараз кылдылармы, туктап чигенә башладылар. Уразаев батареяларының бер атарлык та снарядлары калмаганын белсәләрме алар!..

Туктап тору, чигенгәндәй итү гап-гади маневр булган икән, дошман танклары Сосновканы уртада калдырып ике флангка таралдылар һәм авылны чолгап ала башладылар. Уразаев ягыннан хәрәкәт юклыгын абайлап авылга бәреп керделәр, тупларны изеп-сытып үтеп тә киттеләр. Расчетлар бер карышусыз һәлак булды. Уразаевның сизгерлеге меңгә артты, ул калган кешеләрне божраның тоташып житмәгән урыныннан алып чыгарга мөмкинлек барын абайлады. Тик тупларны нишләтергә? Уйлап торырга вакыт бик әз калган иде, замполит: «Чигенәбез!» — дигән карарга килде.

Рация эшләми, Сосновка төбәгендәге сугыш хәлләрен беркем белми, белә дә алмый, бер нәрсә шиксез: әзгә генә кичексәләр дә, немецлар әлегә исән калганнарны изеп бетерәчәкләр. Һәр тарафта атыш тавышлары, туплар гөрселди, минометлар алмаш-тилмәш тавыш сала. Әллә үзебезнекеләр, әллә дошманнар?

Исән калган тупларны сөйрәп, шашынып, дөньяның дүрт ягын каһәрләп, Уразаев кушканча чигенәләр. Каян, ничек аларның артларына төшкәннәр немецлар, алар үтеп китәргә җыенган авыл очы чигенүчеләрне ут ташкыны белән каршылады. Күп йортларны ялкын чорнап алды, ялкын күңелләргә шом, өметсезлек өстәп сугыш хәлләрен тагын да кыздырды. Кар өстендә уннарча кара һәм соры киемле мәетләр аунап ята. Ул да булмады, Сосновка күгендә «Юнкерс»ларның гөрелдесе ишетелде. Алар янып утырган йортларның тетмәсен теттеләр.

Уразаев үзләренең чигенә баручы пехота батальоннары белән кушылып китүләрен соңыннан гына аңлады. Немец солдатлары шул батальоннарны эзәрлекли калганнар икән...

Тупларны коткарырга җай калмады, хәлдән тайган тупчылар коралларын сай гына карлы чокыр төбендә калдырып чабыша башладылар. Ни эшләсен, алар артыннан Уразаев та чапты. Егылды — торды, торды — егылды...

Каен урманы Сосновкадан ике чакрымда гына булса да чигенүчеләргә җәһәннәм газаплары китергән карлы юл озын, чиксез озын булып тоелды. Пехотачылар белән тупчылар аралашканнар, аларның да командирлары үлеп беткән, карлы урман ышыгына барып кереп, әз-мәз хәл алгач, карлыккан тавышлы, таза бәдәнле старшина кычкырып-кычкырып үзенекеләрне җыештыра башлады. Тупчыларның исән калганнары, табигый рәвештә, Уразаев янына тартылдылар. Арада шактый каты яра алганнары да бар иде.

Уразаев белән старшина кыска-кыска гына сөйләшеп, киңәшеп алдылар. Әлерәк кенә: «Бер адым да чигенмәскә!» — дип кискен командалар биреп торган комбриг та һәлак булган икән. «Тылдан торып акыру-бакыру җиңел дә ул!» — дип эченнән генә командиры исеменә ләгънәт укыган Уразаевка читен булып китте. Бу хәбәрне аңа старшина житкерде. Чигенүчеләрнең хәле беразга җиңеләйгән кебек булса да урман авызында озак юанырга һич ярамый иде. Мөмкинлек барында немецлардан ерагаерга кирәк иде. Старшина да шул фикердә. Пехотачылар сиксәнләп кеше булса, тупчылар нибарысы кырык ике кеше җыела алдылар.

Кулда житәрлек корал барында әле дошманга каршы торырга да булыр иде, корал юк! Ашыгып-кабаланып коралларны исәпкә алып чыктылар. Нәтиҗә бер: тизрәк-тизрәк дошман ягыннан ычкынырга кирәк! Коралсыз килеш камалышта калсаң — беттең.

Себердә партизан отрядында йөргәндә Уразаев тирән карга ерып кереп хәрәкәт итү ысулларын яхшы ук өйрәнгән иде. Төн урталары житкәч отряд карга чумып кереп китте. Озак бара алмадылар, разведкага киткән пехотачыларны куып җиттеләр. Баксаң, алда немец траншеялары

сузылган, чигенүчеләр камалышта калганнар икән инде. Әлерәк өстәлгән хәвеф-казалар, иптәшләре өчен җаваплылык тою хисе Мөхәммәт Уразаевка хәл кертеп җибәргәндәй булды, старшина аны отрядтан җибәрмәскә теләсә дә, немецлар позициясе белән танышырга Уразаев үзе китте. Сак һәм тугры Пахомов аңа иярде.

Траншеялар кардан гына казылган булып чыкты, якында гына мыдыр-мыдыр нидер сөйләшеп ике немец йөренеп торалар иде. Борынга тәмле тәмәке исе килеп бәрелде. «Җиңү исереклеге белән саклыкны онытып җибәргән болар!» — дип уйлады Уразаев. Уң кул якта, кар басып бетергән өч-дүрт шактый зур йортлар шәйләнде. Мөгаен, болары урман хуҗалыгы биләмәләре иде. Немецларның бүтәннәре җылыга кереп йоклаган булырга охшый. Әгәр теге сакчыларны тавышсыз тынсыз йомдырсак...

Борылып кайтканда Уразаевның карары ныгып күңеленә береккән иде. Кыю старшина да аны хуплады, отрядны җыеп ике сүздә бурычны аңлаттылар. Старшина җитәкләгән биш кеше часовойларга ташланды һәм алар хәвеф-хәтәрсез генә отрядка юл ачтылар. Алдан иң хәлле яшьрәк солдатлар кузгалды, алар салган эзгә басарга тырышып бүтәннәр атлый, казлар кебек тезелеп үткән сукмактан, дәү северке итеп бәйләнгән ботакларга салып яралылырны, хәлдән тайганнарны сөйрәделәр. Дүрт-биш чакрым үттеләр бугай. Күк болытлы, кар яктысына һәм старшинаның чамалавына гына ышанып бардылар. Бераздан җил күтәрелде, агач башлары тоташтан ыңгыраша, сөйләшә башлады. Җил болытларны таратты, күк йөзе ачылды, хәлсез сугышчылар йолдызларны бер-берсенә күрсәтеп юнәлешне ачыкларга тырыштылар. Йолдызларга карап юл сайларга туктагач кына үзләренең чамадан тыш арулары сизенделәр. Өч-дүрт кеше карга авып йокыга да китте. Ничә сәгатьләр кар ерып килгән, өс-башлары лычма су булган солдатлар хәзер катып үләчәкләр иде. Егылганнарның шинельләре бозлы кабыкка әйләнде. Яту түгел, карга утырсаң да, ярдәмсез урыннан кубып та булмый иде. Отряд уртасында Уразаевның кискен боерыгы яңгырады: «Карга утырмаска һәм ятмаска! Каеннарны кочаклап баскан килеш ял итәргә!»

Авызларына ике тәүлек буена ипи валчыгы да эләкмәгән, тәртипсез, буталчык сугышларда йончыган, өметләре өзелә язган солдатлар аякларында чак кына басып торалар, кайберәүләр онытылып китеп тел өсләренә кар салалар. Авызга кергән карның телдәге соңгы җылыны куып чыгарачагын аңлаучылар, әйтеп-әйтеп карасалар да күпчелекне тыя алмадылар. Аяклар тоташ дымланган киез итекләренә ябышып катты. Мондый чакта адәм улларын йокысызлык бик нык интектерә. Туп көпшәсе юанлыгы каеннарны баскан килеш кочаклаган сугышчылар алай да әз-мәз хәл алдылар. Каеннардан читкә китмичә генә аякларын тыпырдата, кыймылдый башладылар. Өлкәнрәк бер солдатның каенны кочагыннан ычкындырмыйча гына җиргә иңүен күреп алган Уразаев аның янына барып җитте. Солдат таш булып каткан иде, күзе йомык, битенә үлем сарысы яткан. Иң олы яшьтәге бу солдатны старшина да күзәткәләп тора икән, ул да килеп җитте, куен кесәсеннән фляга чыгарып тегенең авызына биш-алты тамчы спирт тамызды. Җаны бар икән бичараның, тереклек тәмен сизеп иреннәрен мүкелдәтә башлады. «Актыккысы!» — диде старшина, буш фляга төбен кагып.

Таң атар вакыт җитте, ахрысы, каеннарны тагын да агартып, сыек кына яктылык иңде. Уразаев шул чакта гына онытылып, йоклап китте. Шушы кыска гына арада да аңа төш керде. Саниясе мич тирәсендә бавырсак пешереп йөри икән... Өстендә күз явын алырлык зәп-зәңгәр күлмәк икән. Кәпәчтәй эре, сап-сары себер бавырсагын инде кабам дигәндә Уразаев чайкалып китте һәм баш очындагы ботакка ябышты. Аяк буыннары тәмам бушап калган иде. Ул уянып җитә алмыйча шак-

тый вакыт исәңгерәп торды. Күзен ачты, каеннарга сөлек булып ябышкан солдатлар уяна башлаганнар иде.

Уразаев тәмам уянып, бияләен салып, авырайган күз кабакларын уды. Әйе, менә бу егетләрнең язмышы Уразаев кулында диярлек. Ул аларның өметләрен аклый алырмы, көче җитәрме? Ничек бу авыр хәлдән котылырга? Дошманның бер боҗрасын үтеп чыга алдылар. Аллаһе Тәгалә ярдәм итте. Моннан ары эшләр кая таба борылыр?

Солдатларның берсе каен тузы кубарып алып учак кабызып җибәргән иде, старшина шундук аның янына барып җитте. «Борын астында дошман... Фашист хәзер тотенне күреп алыр. Кышкы урманда каен тузының исе дә еракка тарала. Сүндер!» — диде.

«Үләбез бит, эчкә суык төште»,— диде солдат. Ул корык-корык ютәлләвеннән тыела алмыйча аптырады. Аннан соң солдат ныклап кабынып та өлгермәгән учагына уч-уч кар ташлады. Учак чаж-чож килеп иренеп кенә сүнде. Кузгалырдан элек разведка җибәреп, барыр якны әз булса да тикшерергә кирәк иде. Уразаев: «Пахомов! Син бар! Иптәшне үзең сайла!» — дигән иде, арадан Жук фамилияле солдат атылып чыкты: «Мин барам, үзем!» Моңарчы замполитның күзенә чалынмыйчарак, гел читтә-читтә йөрергә тырышкан Жукка Уразаевның ныгытып караганы да юк иде. Таза бәдәнле, имән кискәдәй егет, бит алмалары кып-кызыл, янып тора. «Булдырыр бу!» — дип Уразаев уйлап та өлгермәде, бая учак тергезергә маташкан солдат ютәлли-ютәлли: «Жукны җибәрмә, командир!» — дип кычкырды. Шактый каты яраланган, муенын канлы чүпрәкләргә ураган, төсе китеп барган солдат сүзен әйтеп тә бетермәде, аткан тавыш яңгырады. Атучы Жук иде, ул атты да янындагыларны читкә каерып сукмакка, отряд килгән юлга ташланды. Егетләр шуны гына көткәннәр диярсең, аны ике ягыннан каерып тоттылар, аяк чалып җиргә ектылар. «Тентергә, мөртәтне!» Уразаевның тавышы бу юлы шактый көр чыкты. Старшина белән берничә солдат Жукның юл капчыгын актарып ташладылар. «Карагыз!» — диде старшина кар арасыннан җемелдәгән нәрсә-караларны күрсәтеп. Кемдер Жукка китереп типте. Ул, яткан җиреннән: «Мин гаепсез! Мылтыгым үзе атылып китте. Ә бу капчыкны урамнан таптым!» — дип чинады. Капчыктан бер бөтен ипи, ике дәү генә кисәк ак май, ярты литр самогон һәм алтын беләзек, бер балдак килеп чыкты. Беләзекне кулдан-кулга йөртеп карадылар. Жукның барлык патроннары да исән иде. Димәк, дошманга атмаган явыз! Бер мөһим нәрсә Уразаевны шиккә төшерде. «Качарга җай барында, нигә дошман ягына чыкмаган Жук? Яралы солдат ник моңарчы шиген белдермәгән? Әллә бер-бер задание алып, отрядны озата киләме бу мөртәт Жук?» Сугыш әлифбасын әлерәк кенә өйрәнә башлаган замполит та, дары исенә күнегеп бетмәгән старшина да аптырашта калдылар. Пахомов кына: «Юк итәргә кирәк явызны... Тикшереп-нитеп торырга ара юк!» — диде. «Кичә шикләндем мин аңардан. Якасы белән яңагын каплап нидер күшии иде!» — диде солдатлардан берәвесе. Жукның бүтән гаепләрен дә күргәннәр икән, бәлтерәгән карчыктан самогон таптыруын да, өлкән яшьтәге хатынны көчләп, икмәк урлап чыгуын да абайлаганнар. «Нинди карарга киләбез?» — диде кашларын җыерып Уразаев. «Атарга кирәк аны! Барыбызны да сатып бетергәнче юк итәргә кирәк!», «Хыянәтчене, кеше үтерүчене, көчләүчене җәлләү юк, үлсен!»

Сугыш шушы кыска гына арада үзенең бар дәһшәтен күрсәтеп өлгерә шикелле: рөхсәтсез-нисез ут позицияләрен ташлап киттеләр, беркетелгән коралларын калдырып качтылар... Хәзер приговорсыз-нисез хәлдә сугышчыларның берсен үлем җәзасына хөкем итәргәме? Язып беркетергә, тавышка куярга ара да, мөмкинлек тә юк! Исән калдырырга да ярамый: Жукны ким дигәндә икәү саклап барырга тиеш. Ул үгездәй таза, яшь, көчле. Ризыктан өзелмәгән мөртәт. Кем саклый алыр? Уразаев үзен урап алган, тездән, тубыктан карда басып торып, төрле якка кыйгайган, житү

сакаллы, ачулы күз читләре эренләп каткан отрядына күз йөгертеп чыкты. Ул солдатларның берсенә төртеп күрсәтте дә: «По изменнику родины пли!» — дип команда бирде. Жук ату тавышыннан да элгәрәк карга капланды, аны шул яткан килеш аттылар. Хыянәтче бер-ике тартышты да тынып калды. Бер агач төбендә кардан кабер казыдылар һәм Жукны шунда төшереп өстән тигезләделәр. Бу вакыйгадан соң бераз киеренке тынлык булып алды. Старшина Жуктан чыккан азык-төлекне яралыларга таратты. Хәзер разведкага китәргә тиешле ике сугышчыга майлы ипи кыерчыклары эләкте...

Уразаев, бер карарга килеп, старшинага эндәште: «Болай торып булмас, кузгалыйк, разведчикларны каршылыйк»,— диде. Шулай иттеләр. Ярый әле көн җилсез, аяз туып маташа, разведчикларның эзләре алга чакырып каен араларында ярылып ята. Шылт иткән тавыш юк. Көн яктыра дигәндә урман өстенә шомлы тавышлар коеп самолетлар очып үтте, солдатлар самолет күзенә күренмәскә тырышып куак асларына сибелделәр. Тагын кар, дымлы киемнәр аны йотып кына ала, тагын өс-баш авырлаша. Чакрым үттеләрме икән, алда бар көчләренә ашыгып килүче разведчиклар шәйләнде. Аларны тыйнак кына хуплап каршыладылар, сүз көтеп тегеләрнең тирән күз чокырларына текәлделәр. «Авыл бар,— диделәр алар бер-берсен бүлдереп.— Берәр чакрым ара булыр. Авылда немец обозы тора. Авыл тирәсендә олы юллар юк. Обоз нәрсә көтәдер, аңлап булмый. Ике олау атлар тугарылган. Чаналарда йөк, тартмалар, капчыклар. Солдатлар күренми, йоклыйлардыр, ахрысы.» Уразаев иптәшләренә карады. «Бәрәбез дә керәбез,— диде кызып старшина.— Ризыксыз, коралсыз без болай бетәчәкбез! Ачлык белән салкын тәмам бетергәнче яшәп калыйк!» Уразаев үзе дә шулай уйлый иде.

Дөнья яктыра, ачыла. Гадәттә, укылган китапларда, каралган кинофильмнарда авылда сеңеп йоклаган дошманнарны төн карасы эчендә бәреп кереп тар-мар итә торганнар иде. Уразаев алып барган йончыган солдатлар белән кичне көтәргәме? Аңа кадәр обозлар китеп барса? Яки мондагыларга өстәмә көчләр килеп кушылса? Гадәттән тыш бу һөҗүмне гадәти булмаган, һич көтелмәгән бер вакытта башкарып чыгасы иде! Беркем уйламаганда, яктыда шау-шусыз гына бәреп керәсең дә...

Соңгы патроннар, җиде граната, пычаклар, штыклар белән корыллангән унҗиде солдат авылга барып кергәндә ындыр артлары тын, урамнар буш иде. Кышлакта, калку җирдә утырган авыл тирәсендә кар әзрәк иде, яуганы берен җилләр алып китеп торганнар. Ындыр артлатып ике яктан урамга үтеп чыксалар, малахаен иягеннән үк кысып бәйләгән, алама тунын җилбәгәй җибәргән карсак кына бер мужик очрады. Сыңар күзле икән. Уразаевка сыңар күз дә бик житә, бик ярап куясы, куркып ыштанын буямасын да, күргән-белгәннәрен сөйләп кенә бирсен. Тиз арада белештеләр. Немецлар күп түгел, корал, азык-төлек китергәннәр дә кемнәрнеңдер килүен көтәләр. Өченче көн авыл аша немец сакчылары әсирләрне куып узганнар. Бүтәнчә гаскәриләрнең күзгә чалынганы юк. Староста да, полицайлар да юк.

Биш чәршәмбенең бер җомгасы була, диләр. Моңарчы бөтен уйлаганнары кыекка китеп торганда бу юлы Уразаевларга күн төшә түгелме? Ике йортта нибарысы җиде солдат!..

Сыңар күз географияне дә шактый шәп белә икән, ходаның рәхмәте төшсен, ике-өч сүз белән ул олы юлның кай тирәдәнрәк үткәнен дә, урын юлларның җайлыракларын бармаган бөгә-бөгә санап чыкты. Азактан кыенсынып кына: «Сез кайсы якка юл тотасыз соң?» — дип сорады. Уразаев белән старшина йөзләрен, чытып, бер-берсенә караштылар. «Әлегә көнчыгышка», диде старшина. Сыңар күз район үзәгенең кай тарафларда булуын, өч-дүрт көн шул якка өзлексез гаскәр агылуын әйтеп бирде дә кинәт юкка чыкты. Ул ара булмады, кайдадыр ишек шыгырдады, бала җылаганы ишетелде, Уразаев немецлар кереп йоклаган берен-

че йортка атылды, кызган, ярсыган солдатларның икенче төркеме ишеккә бәреп кергән старшина артыннан иярделәр. Уразаев кулындагы гранатасын ыргытмады, өй хуҗаларын һәлак итәсе килмәде аның, ишектән бәреп тә керде: «Партизаны!» — дип акырып та җибәрде. Күнитекләрен, кыска туннарын салып, чишенеп яткан немец солдатлары кайсы кайдан идәнгә тәгәрәделәр, ых итәргә дә өлгермәделәр...

Старшина солдатлары барып керәсе йортта хәл икенчерәк булды, иртә уянган ефрейтор, чалбар төймәсен каптыра-каптыра өялдына чыгып җиткән икән, ул өялды ишегендә совет солдатлары күренүгә ялт итеп артына борылып өлгерде, ишек келәсен элде һәм иптәшләрен уятып автоматына тотынды. Ләкин шашынган старшинаны туктатыр көч булмый, ул ишекнең күгәннәрен суырып чыгара, иңбашын ике пуля тишеп узса да ефрейторны сугып ега, бугазына пычагын сала. Бүтәннәрне аның иптәшләре теге дөньяга озата...

Газиз укучым! Сүзем дәвамында беренче тапкыр мин сиңа атап эндәшәм! Ялан укытучысы Мөхәммәт Уразаевның төнге маҗараларын сөйләвем озаккарак та китте шикелле. Гафу ит! Уразаевның тәҗрибәсе күбрәк булса, ул шушы дәһшәтле көнгә сугыш фәнен үзе катнашкан бәрелешләрдән чыгып өйрәнсә, тәүлектән артык вакыт эчендә ул бүтәнчәрәк хәрәкәт итәр иде! Телсез каен урманында ул кадәр солдатларын күмеп тә калдырмас, бер-бер нәтиҗәле чарасын тапкан булыр иде! Алай булмады шул, ул тәүге сугышына барып керде, беренче тапкыр явыз дошман белән бил алышты, җиңелде дә, җиңде дә. Һәм аның беренче сугыш соңгысы да булды... Отряды белән дошманның тагын бер божрасын өзү насыйп булды аңа. Әйе, ике олауга төялгән мылтык-гранаталар, туклыклы ризыклар ярдәмгә килмәсә, алар шунда, карлы-бозлы юлларда ятып калырлар иде. Инде котылабыз, үзебезнекеләр ягына чыгып җитәбез дигәндә, төнге сугышта Уразаев каты яраланды. Кырда, карда саташып, канга тузып озак интекмәде, тугры Пахомов аны җилкәсенә салып алга атлады...

Ике тәүлек ятканнан соң ул аңына килде, күзге сорап алды һәм карагач үзен танымады. Күзгедән аңа текәлеп сурайган озынча йөзле, җыерчыклы маңгайлы, чәчләренә нык ук әрсез чал йөгергән кырыс, сүзсез кеше карап ята иде. Госпиталь хезмәткәрләре арасында Сания исемле доктор юкмы дигән соравы икенче булды. Аның соравына каршы шәфкать туташлары баш кына селкеделәр. Авыр тән яраларыннан да ныграк булып, аның Сания исеме мәңгегә кереп урнашкан йөрәге сызлый иде.

## 9

Фашистлар Мәскәүгә ыжгырып килгән көннәрдә Кара Елгада Бүре Рәхмәтулладан бушаган алачыкка Колгасар Сорокин белән унике дезертир кереп ояладылар. Ялан тирәләрен, Ялан тирәсе юлларын өйрәнеп һәм күнегеп өлгергән Сорокин авылга «сәяхәтләрен» ешайтты. Моның үзенә күрә җитди генә сәбәпләре дә бар иде.

Унике тамакка шактый ризык кирәк, бу — «урман отряды»ның әлегә төп шөгыле, амбар-келәт басалар, сарык-бозау урлап кайталар. Дөрес, сирәк кенә кулга төшкән самогон шешәләрен бушатып күзләре калайланган Сорокин үз гамәлләренә «сәяси» төс бирергә бик тырыша иде. Эчкәч тагын да усалланa торган «командир Сорокин» үзен дошми-тынмый да тыңлаган дезертирларына ышанып бетми, аларның «командирларына» ышанмавын да сизеп-белеп тора. Әлегә аңа каршы чыккан, ачыктан-ачык сүзен кире каккан кеше юк. Ул — офицер, ул төрмә-лагерьларны үткән, советларның җәзасын татыган булып исәпләнә, тирә-якны аның кебек шәп белүче юк, Сорокинның тәҗрибәсе зур, ә тәҗрибә качкыннар арасында абруй ул, монда командирга буйсынмыйча ярамый.

Сорокинның өмет зурдан иде! Немецлар Мәскәү капкасын кага башлауга, ул Себер урманнарына совет заманы белән ризалашмаган аңлы, акыллы кешеләр агылыр, дип көткән иде. Себергә сөрелгәннәр дә фронттан качып калырга тиеш ләбаса, Себернең үзендә яшәп совет хөкүмәтеннән кыен ашаган урыс-татарның балалары, якыннары да Сталин өчен кан коярга китеп бармаслар ич инде! Алай булып чыкмады. Сугыш башлангач та аның өтек отрядына килеп сыенган кайберәүләр, сугыш кызган саен, гитлерчылар Рәсәйне калҗаларга бүлгәләгән саен алар бүтәнчә уйладылар. Бер-ике көн сөмсерләре коелып, хәлсезләнеп йөрделәр дә, кая баруларын беркемгә дә тишмичә мыштым гына кедр урманнарыннан авыл якларына китеп бардылар. Китүчеләрнең берәвесен тотып алып, каен ботагына асып куеп та карады Сорокин. Ул юлдашларының кашлары җыерылуын, тавышларының үзгәрүен күреп сагайды, китүчеләргә бүтән хөкем чыгарырга ашыкмады. Китәләр икән, китсеннәр! Сорокин үз юлыннан тайпылучы кеше түгел. Болар бит авыл мужиклары, ә Сорокин — офицер!

Янында калдырырга тырышу түгел, кайберәүләрнең отрядтан китүен дә тели иде командир. Аның янына беренчеләрдән килгәннәр арасында Ялан авылының тәкъвә кешесе Чырык Абдрахман да бар иде. Хәйләкәр, көндез йокымсырап кына йөрсә дә, төннәрен Абдрахман үзгәрә, тавыкларны кетәктән урларга дигәндә аннан да оста кеше юк!

Баштарак бик мәзәк булды, Чырыкка караган саен шаркылдап көләсе килә иде Сорокинның. Урманда беренче очрашканда кыяфәте үләр дәрәҗәдә көлке иде Чырыкның! Чәче генә түгел, кашы, сакал-мыеклары шомартып кырылган, ирлек кыяфәтен җуйган иде тәкъвә абзыкай. Коты очкан, нәни генә ботак шытырдаса да көл төсенә кереп, иреннәрен калтыратып догаларын укырга тотына иде. Алай да Абдрахман Сорокинга бик ярап куйды, тирә-якны белә, урман-юл сукмаклары аңа таныш, хәйләкәр, куркак булса да кушканны үти. Үтәмичә кая барасың? Ялanga борылып кайтыр җае калмаган, авылы белән арасын кырт өзгән ышанычлы юлдаш иде...

Сорокинның иманы еш чатный, баштарак ул шушы якның карурманнарында зур, кораллы банда төзеп совет властена каршы сугыш игълан итәргә җыенып йөргән иде. Бу планнары яңарак килгәннәрне дә, элегрәк килгән качкыннарны да җылытып килде. «Японнар тик кенә көтеп ята торган халык түгел. Японнар совет властенең кан дошманнары. Күреп торыгыз, немецлар Мәскәү-Ленинградны басып алуга, океан дулкыны булып японнар күтәреләчәк. Рәсәй ике фронтка да көч житкерә алмаячак, аның эше хөрти, инде без дә оешып аның тылын таркатсак, тимер юлларын шартлатып, бозып бетерсәк, японнар Себер киңлекләрен җырлый-җырлый узачак!» — диде ул ике сүзнең берендә. Бу сүзләре тора-бара кимеде, Мәскәү тирәсендәге каты сугышларда немецларның коерыгы бозга каткач, Сорокин вәгазьләренең юнәлешен үзгәртте. «Көчем ханнан калган казнаны гына табабыз да... немецлар ягына авышабыз», — дия башлады. «Хан казнасы!» дигәнне Чырык электән ишетеп белә, ә яңалардан байтагысының колагы үрә торды. Качкын отряд Алтын Мөгез тирәсенә баргалап йөрде, казындылар, чокчындылар, юанырлык әйберләр табылмаса да, алданырлык вак-төяк ияртеп кайттылар. Кышкы салкыннарда, зәһәр суыкта да катмый торган, мәгәр алдавыч кар катламы астына кереп күренмәс булган төпсез сазлыклар эзләү эшләрен туктатты. Язны көтәргә кирәк иде. Язга кадәр күп нәрсә ачыкланачак. Алырлармы немецлар Ленинград, Мәскәүләрне! Җайлы чакны көтеп яткан Квантун армиясе көнчыгыштан бәреп керерме?..

Чырык кышка кергәннән бирле саулыкка туймый башлады, гел зарлана, еламсырый, йокысы юк диярлек. Мондый җайсыз кеше качкыннар арасында җәфа, аннан ничек тә котылырга кирәк була. Чырык та үзенең артык кашык икәнлеген чамалый, тәҗрибәсе бар, артык кашыкның яз-

мыш азагы ни белән беткәнен дә белә. Атачаклар аны, гәүдәсен урман киекләре кимерсен өчен чокырга ташлаячаклар. Ләкин Сорокин моңарчы Абдрахманны жәлләде. Картның соңгы атналарда диненә, алласына бирелеп китүе күңелен йомшартты, ахрысы. Яшьтән үк үтә гади гаиләдә тәрбия алган, үзе диненнән әллә кайчан җәяүләп качкан офицер аллага ныклап табынган кешеләрне әз-мәз хөрмәт итә иде. Аларның каргышы төшәр дип шикләнә иде ул. Аннары, ул Чырыкны авылга кайтарып җибәрмәскә тырышуының тагын бер мөһим сәбәбе бар иде. Чырыкның теле тотанаксыз, мактанырга бик ярата. Телен бер чишсәме, бетте, һич туктатырмын димә! Күзләрен елтыратып, ияген атындырып буш тегермәнне әйләндерә дә әйләндерә.

Юк әле, аны отрядтан ычкындырырга ярамый. Дөнья хәлләре ачыкланганга кадәр Сорокинның тылы тыныч һәм хәвефсез булырга тиеш. Ә Чырык таң туды исә сыктый, сыкрый: «Кайтарып җибәр син мине, улым!» Сорокинның «улым!» дип эндәшкәнне яратуын хәйләкәр Чырык белә. Аңа бик күптәннән беркемнең дә «улым!» дип зурлап эндәшкәне юк...

Чырыкның үзе генә белгән яшерен сере дә бар. Сорокин ике иптәше белән «ризык юнәтергә» шактый ерак авылларның берсенә сәфәр чыгып киткәч, песием-песием генә булып әйләнгәләп йөрде дә, киек җәнлекләр салган эздән олы юлга таба чыгып йөгерде. Ул Тубыл белән Яланны тоташтыра торган юлга барып житте. Өмете: шул юлдан үтүче бер-бер авылдашын очрату иде. Карлы юлдан үрәчәле нәни чана тарткан Нәсимә җиңгине күргәч, чыдамады карт, җылап җибәрде. Авыл хәлләрен сорашты, «Хода хакына мине күрүеңне әйтмә, үзем дә әҗерен бер кайтарырмын»,— дип иелә-иелә күп вәгъдәләр бирде. Нәсимә — Чырыкның бик ерак кына кардәше, зарсыз-моңсыз куркак кына карчык, торага кодагыйларына утырмага бара икән. Ике-өч сүз белән авыл хәлләрен сөйләде. Кем сугышка чыгып киткән дә, кемнең үлү хәбәре килгән. Сугыш еллары авызына шул сүзләр генә сыя иде бит. Карчыгы Гөлҗамалның чирләп урынга егылуын Чырык Нәсимә карчыктан ишетте. Озаклап, бөртекләп сорашырга иде исәбе, вакыты чамалы икәнен хәтерләп, килгән сукмагыннан кире йөгерде. Сорокиннар кайтып житә күрмәсен. Ризык эзләп киткәннәре соң гына, эт булып арып-талып, буш кул белән кайтып кërделәр. Андый чакта Сорокинга сүз ката күрмә!

Чырык кырык ямаулы корама юрганына төренеп төне буе йокысыз ятты. Ул үз гөнаһларын кичерерлек, хаталарын акларлык дәлилләр табарга тырышты. «Минем ни гаебем бар? Әйтик, кызның ризалыгыннан башка, шәригать кануннарын бозып, никах укыганмын икән, Тәңрем андый гына гөнаһны гафу иткәндер инде. Күргән җәбер-җәфаларым, ач бүре көненә төшеп монда интегүләрем, тәүбәгә килү булмадымыни? Авылдашларга килгәндә, аларга ни зыян-зарар салганым бар? Адәм җанын кыймадым, кулымны канга буямадым, урлашмадым. Вак-төяк гөнаһлар бардыр-барын, йә кемдә юк алар? Ә күпме яхшылык кылдым? Үлем-җитем булганда җиренә җиткереп, шәригать кушканча, соңгы юлына озаттым. Хәзер авылда шәригать законнарын белеп кулланырлык кем калды? Мәет юарлык, кәфен тегеп, җеназа укырлык адәм дә калмады ич Яланда! Әйе, әйе, Ходаның хәере белән кайтыйм да китим авылга!»

Уе шушы җылы урынга җиткәч, йөрәге кысылып, Чырык куырылып куйды. «Ә колга? — диде ул караңгы авыз эчен ялап. — Аннан ничек котылырга? Аның тозагыннан ансат кына ычкынырмын димә! Һәр сукмакка капкыннарын салган ул! Татарчаны да белә бугай ул явыз... Билем авырта, йөрәгем туктаусыз кага, дип алдына егылып ялынсам, әллә җибәрерме?!»

Тегеләй борыла Чырык, болайга әйләнеп ята, йокы алмый. Йокы Ялан якларына ук, Гөлҗамал карчык янына ук качкан.

Икенче көнне кайнар чәй белән корсакларын алдап, күңелне әз-мәз жылыткач, күзләрен читкә яшереп кенә Чырык Сорокинга эндәште. «Сорокин корша,— диде ул мескен тавыш белән,— үзем сырхау, үзем карт. Бүген карчыгым түшемә килеп керде. Кайларда тилмереп йөрисең син, карт, ди. Мин, ди, жан бирә алмыйча ятам, ә син, ди, әллә кайларда йөрисең, ди. Әйе, әйе, әжәл килгән мөселманны мәңгелеккә озатыр кеше дә калмады ич авылда.» Сорокин кырыс көлемсерәде: «Авылда буып атачаклар ич сине!» «Бумаслар!» — диде өметенең аяк астына төшеп изелгәнен күреп Чырык. «Моңарчы кайда качып яттың,— дип бугазыңнан элеп алсалар?» «Нигә качып ятыйм ди? Салехардта минем туганнарым, абзам яши. Шуларда торып тордым, диярмен». «Ышанырлармы?» «Моңарчы ышаналар иде әле!» Сорокин озак уйлап торды да сорап куйды: «Сатмассыңмы безне?» Чырык сикереп торды: «Менә, икмәк өсте, сезнең хакта сыңар сүз ычкындырсам, ходай орсын». «Мин бу кешегә ышанмыйм! Ул безне сатарга жыена,— диде дезертирларның берсе. Аның муенын монда Кара Елгада гына кыярга кирәк. Әгәр сездән боерык булса, мин хәзер үк аның кара жанын жәһәннәмгә олактырам.» Сүзенең рас икәнен күрсәтергә теләп, дезертир билендәге пычакның кара күн тышын сыйпап алды. Чырык калтыранды, нинди дә булса яңалык көтеп зарыккан качкыннарның усаллыгын, кансызлыгын белә иде инде ул. Нәзек тавышы белән Сорокинга ялынырга тотынды: «Улым, Сорокин господин! Сиңа иминлек, саулык теләп Аллаһе Тәгаләгә көн-төн ялварырмын».

Аллага таянып тәки жиңде Сорокинны Чырык. Колгасарның чытык чыраена ялкау гына елмаю чыкты.

— Әй син, ходай кошы! — диде ул Чырыкның арык жилкәсенә йодрыгы белән дөп-дөп кагып.— Яланнан торып миңа тугрылыгыңны һәрчак раслый аласыңмы? Алсаң, жибәрәм.

Чырыкның чәчләре кыймылдады, чәч төбенә тир бәреп чыкты.

— Ниләр боерасың? Барын да эшлим!

— Теләгәндә мин барып йөрерлек бер бичә табасыңмы?

Әллә ниләр уйлаган иде Чырык, әмма андый мәкерле сорау көтмәгән иде. Уйга калды. Сорокин тирәсенә сырышкан дезертирлар карттан көлә, мыскыллый башладылар. Чырыкның чуалган уйлары бөтенләй буталды. «Көткән мизгел кулдан ычкына бит, ычкына!» — дип сызланды ул эченнән генә.

— Табам! — диде ул, Сорокинның үзенә сузылган учына шапылдатып сугып.— Авыл тулы солдаткалар. Кычытып бимазалый торган нәмәләре бардыр әле! Валлаһи табам, булдырам!

Сорокин Чырыкны бер читкәрәк алып китте һәм үзен-үзе ничек тотарга кирәклеген сөйләп бирде. «Авызыңнан берәр сүз ычкынса да, без сине казыкка утыртачакбыз. Мөгаллим Уразай йортын күзәт. Йорттагылар белән аралашырга тырыш.

Ике атнага бер тапкыр күл тирәсенә килеп чык. Безгә ау мылтыгы белән дары юнәтеп китер».

Чырык уйга калды. Хатын табылыр, дары белән мылтыкны каян тапсын?

Инде генә булды дисең, таң ярала дисең, шырт итә дә өмет өзелә!

Сорокин Чырыкның тел тешләп телсез калуын күреп, тагын бер тапкыр калак сөякләренә шап иттерде дә читкәрәк китте. Чырык барлык уй-сәләтен эшкә жигеп, уенда Яланның бер йортыннан икенчесенә сикерә-сикерә мылтык, дары эзли иде. Бераздан ул Сорокин янына теркелдәде:

— Табам, каһәр суккыры! Дарысын да мылтыгын да табам.

Караңгылы-яктылыда сәфәр чыккан Чырык Абдрахман туган-үскән төягенә, ата-бабадан калган нигезенә кайтып житте.

Урманда, бүре өнендә жилкә кашып ятып, ул дөнья мазаларыннан тәмам аерылган икән! Карчыгы Гөлжамал вафат! Гадәттә, татарлар

мәетне вафаты көнендә үк куялар. Абдрахманның хәләл җефете, алдагы көннәргә соңгы өмете — хәләл карчыгы сәкедә ята... Кышкы суыклар җирнең җелегенә үткән, ә кабер казып, ләхет алып җәннәткә юл ачарга Ялан авылында ир-ат калмаган икән, үсмерләр маташа-маташуын, «хәбәр көтеп торабыз, өлгертергә тиешләр!» дип юаттылар Чырыкны.

Аның күңеле тулды. Гөлҗамалы тирәсенә барып, арык кулларын кушырып катып калды. Ясин чыгарга, Коръән аятьләрен карчыгына ишеттерергә теләде, теле әйләнмәде. Тәһарәтсез килеш, Бүре Рәхмәтулла алачыгының һәр күзәнәккә сеңгән сасы исеннән арынмаган хәлдә изге сүзләрне тәкърарларга ничек Чырыкның теле әйләнсен?.. Әле генә, авыр аягын карлы юлларда сөйрәп кайтканда ул Аллаһе Тәгаләгә кат-кат ялварды: «И Ходаем, моңарчы кылган гөнаһларымны кичер, алдагы юлымны яктырт, иманымнан яздырма! Тәртипле генә яшәп, изге гамәлләр генә кылырга насыйп ит!» — дип уен беркетте. Кая монда тәһарәт алулар! Ул арада зираттан хәбәр иреште: кабер әзер икән!..

Гөлҗамалны җирләгәч, шунда зиратка җыелган карчык-корчык, хатын-кызлар, үсмер кызлар алдында Абдрахман Сәрвәр туташка кылган явызлыгы, аңа, аның якыннарына, әнкәсенә китергән хафалар өчен гафу сорады. Кыйблага карап җылый-җылый ялварды.

И Аллам! Табигать кочагында яшәп, каһәрләнгән язмышка дучар ителгән кешеләрнең дә күңелләре нечкә, йомшак була. Гафу иттеләр Чырык Абдрахманны, «моңарчы кайларда йөрдең син?» дип төпченүче булмады. Һәркемнең хәле хәл иде. Каргау түгел, Чырыкка ияреп балавыз сыгучы да булды, дөрес, сукбай картны жәлләп җыламадылар шикелле, зират капкасын керүгә, һәркемне моңсу хатирәләр көтеп тора, һәркем кайчан исә бер үзенең дә шушы кар күмгән таучыклар арасына килеп урнашасын уйлый...

*Дәвамы бар.*

## Равил Фәйзуллин



ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

# «ЗАМАН КЕМНЕҢ ЗАМАНЫ ?..»

* * *

Көтмәдекме безне баскан
басымның басылуын?
Җанга, рухка, хөр фикергә
юлларның ачылуын?

Көттек. Көттек... Ниһаять
күзләр шәрран ачылды.
Күз алмасына шәп-шәрә
чынбарлык кереп тулды.

Кануннар шартлап ярылды.
Ил-җирләр тетрәнде.
Әтрәк-әләмнәр көрәйде,
хезмәтле — бөкерәйде...

Империя коллыгында
гел күнеккәч искегә,
«Демократия»сеннән дә
юылмаган ис килә.

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) — *шагыйрь, күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт, Республиканың М. Җәлил исемендәге яшьләр премияләре лауреаты.*

Әче төтене заманның
күзләрне ачыттыра.
Яхшыга да, Яманга да
капкалар ачык тора!

Ә Вакыт ашыктыра...

## Пародокс

Көтәсең газиз кешеңне —
бер имгәк шылтырата...
Ялманып алтын эзлисең —
алдыңда нәҗес ята.

Җилләр белән җыр юллыйсың —
ул гайбәт булып кайта.
Хәер бирсәң, кыйбаткарак
үзеңә китереп сата.

Бирәүгә икмәк сузасың —
ә ул сиңа таш ата...
Гавәм җанын пакьлим дисең —
ә ул күзен акайта.

Изге хөрлеккә өндисең —
вәхи сүз ката-ката.
Ыржаеп Тарихи Хата
ботын күтәреп ята.

## Кар төшерәм түбәдән...

Кар төшерәм түбәдән, кар төшерәм.
Куеннарда назлы март җиле!
Шул карлар күк, иңнән елларның
бер кадәрен төшерәсе иде!

Ә түбәнең кояш төшкән ягы
күптән кибеп, инде ялт иткән!
Гомер төшлегеңне бер уздыргач,
гел «I love you»[1]лар оят икән...

Күләгәле якта кар катламы.
Шул якны бит кирәк көрәсе!
...Ә шулай да, яшьне тыеп, килә
Кояш якка карап көләсе!

[1] I love you (ингл.) — мин сине яратам.

## Әни ишетми калган җыр

*«Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы».*

Г. ТУКАЙ

Яшь чакта, сау чакта
дәрьялар, диңгезләр кичәргә
ишкәк тә, каек та табылыр.
Давылда адашсаң,
караңгы төннәрдә яктыртып
әнкәңнең йөрәге кабыныр.

Яшь чакта, сау чакта
даныңа, малыңа, җаныңа
дуслар да, ярлар да сарылыр.
Хәсрәткә тарысаң,
догада, күкләргә илереп,
тик газиз әнкәең сагыныр.

Яшь чаклар, сау чаклар,
болыттай, мәңгегә кайтмаска,
җилләргә сарылып агылыр.
Ахыргы көндә дә
чәчәкләр күзендә күрерсең —
әнкәең карашы чагылыр.

## Җаны көйгән Акбай турында

*Камил туганым истәлегенә*

Халык чабышып
килеп җиткәндә —
өй кысасы янып беткән...

Авыл өстендәге ап-ак болыт
киезләнгән ысланудан, төнчыгудан.

Халык «аһ-ваһ» килеп йөргәндә
абзар-кураларга ут күчкән.

...Бәйдәге эт ярсый-сикерә,
өрә бөтен җанвар тавышы белән.
Авызында кеше сүзләре дә шәйләнә —
җан ачысы шулдыр инде.

...Чылбырыннан ычкындыргач,
инеш янына барып
кан коскан.
Күзләрендә ят кызыллык
әллә ничә айга барды.

...Вокзалларда, болын, мәйданнарда
чатыр корган качакларны күргәч,
янгын тоеп, чак котылган
шул Акбай-эт искә төшә.

* * *

Сабыйдай сөенәм кайчакта, югалткан
юк кына бер нәрсәм табылса.
Уйланмый еш кына ни бәхет икәне —
әниең, әтиең сау булса!

Күпмебез бичара хәлендә калабыз
югалту убылса һәр яктан.
...Исәннәр аңа дип багышлап юллаган
догасын тапмаган әрвахтай.

## КӨЗГЕ КҮКРӘҮ

*«Мин Синең тормышыңа*
*соңга калыбрак, гомереңнең*
*көзенә табарак килеп кердем...»*

(Хатыңнан юллар)

* * *

Әйтәләрме — сине яратты дип?
Сөйлиләрме — сине сөйде дип?..
Син горурлан! Сөйсәм-сөймәсәм дә,
тормышыма инде кердең бит!

Тавышыңнан — балачакта калган
бер кадерле өнне шәйләдем.
Күз карашың Кояш булып торгач,
мин Йолдызга, ахры, әйләндем.

* * *

Сезнең урам аша үттем бүген.
Тәрәзәңдә калды күзләрем...
Керфекләрем йомып нидер әйттем,
хәзер хәтерләмим сүзләрен.

Шактый ара бардым белешмичә.
Хатирәләр алды бөтереп.
Ул елларның асыл бөеклеген
мөмкин түгел аңлап бетерү.

Булган яшьлек, булган чын ярату,
һәм яңару булган һәр даим.
Яшьлегемнең ни догасы өчен
бүләк иткән Сине ходаем?

Кеше гомереннең буладыр ул
Бәхет тажы иңгән бер чагы!
Әйтүчеләр булды: боларның бу —
сүнү белмәс Сөю учагы!

...Хатирәләр, татлы хатирәләр
керфекләргә дымны тарата.
Казан нинди мәрхәмәтле булган
бу йорт аша безгә карата.

...Калтыранып куйдым. Әйтерсең лә
кышка кердем җәйге киемнән.
Кире килгән чакта караңгы иде,
мин таксида кайттым өемә.

...Төн уртасы. Йоклый алмыйм. Ятам
мең-мең сорау биреп үземә.
Сиңа, хәзер, бәлки, ай карыйдыр
тәрәзәңдә калган күземнән...

* * *

Озак эзләдемме мин сине?
Әллә тиз таптым?..
Егермеләп еллар үткәч —
инде очраттым...

Синең яшьнәп Дөньяга
килешең иде.
Минем арып, Язмыш белән
килешү иде...

Син парлы була торып та,
канатсыз идең.
Мин җайдак була торып та,
...атсыз идем...

Дәрт очкыны чәчрәгәч
синең йөрәктән,
яшьлек таңы янә туды
минем күкрәктә!

Җандашлыктан, игезәкләрдәй
охшаш ук булдык.
Бар вөҗүд бергә кушылгач,
тоташ ут булдык.

Ходай үзе өсти мәллә
хисне, теләкне?
Икебезнең бер тәнебез
бер куш йөрәкле!

Аякларың — «алтын кайчы!»
Кисә дә тора!..
Бәгъреңдәге татлы «шартлау»
ыңгыраштыра!..

Озак эзләдемме мин сине?
Әллә тиз таптым?
Шунысын беләм: мин кич таптым.
Кичегеп таптым...

«Аралар юк, без — тиңнәр!» — дип,
рәхмәт, юаттың.
Мин дә, ахры, бәгыреңдә
нидер уяттым.

«Сөю — сәгадәт» дигәне
шушыдыр инде.
Син — Мәхәббәтемнең соңы —
«хуш»ыдыр инде.

Әйттең ничә, күземә карап,
айлы төннәрдә:
«Әй, абыем! Бу хәлемдә
калам кемнәргә?...»
Үз соравым — башым ята
синең иңнәрдә.

Нидер әйтмәкчемен, булмый
аңлатып кына!
...Күрәсең җавапны әйтер
тик Вакыт кына.

* * *

*Галәмдәш —*
*замандаш —*
*илдәш —*
*милләттәш —*
*кардәш —*
*кандаш —*
*җандаш —*

Нәрсә әйтим?
«Рәхмәт!» — диям Сиңа —
төнге яңгыр шавын тыңлап, изерәп
упкындагы чыра яктысына
дүрт күз белән карый алгач!

* * *

Бер-беребезгә артык якынаймыйк!
(ерагая башларбыз дип куркам!)
Хыял күкләренә менеп шашмыйк!

Син дә тукта!
Мин дә...
Тамчы күз яшь куйсын нокта.

Калыйк без Яшәү Картасында
сагынышлар көтәр якынлыкта,
гомер буе теләр ераклыкта!..

* * *

Мин карт булам яшәрмәгәндә.
Яшәрмәгән көнем бик сирәк!

Кемдер көлемсерәп әйтеп куя:
«Агай, сиңа күптән шул кирәк!»

...Белми алар —
Миңа Син кирәк!

* * *

Качар жир — убежищелар
нәрсәгә ди миңа?
Иң хәвефсез урын — ул бит
Синең куеныңда!

Күкрәгеңә терәлеп бер
йоклап киткәнмен дә,
төш күрдем: имеш, бер тиен
зур бер куш имәндә
нигъмәт җыяр куыш тапкан,
өй булыр дип кышкы.

...Ә төптән кисеп яталар,
чыж-чыж килә пычкы!

* * *

Элеп киптер мине кер итеп.
Яфрак булып калыйм имиеңдә.
Тәмле төшең булып уятыйм.
Өмет булып куныйм иңеңә!

Мин барсына риза.
Кеше булып калсам,
яшь-яшь жаның аша,
янә күрсәм
хыялый таң — яшьлек чагымны.

Ә Син әзерме соң,
яшел тирәк килеш
зәмһәрир кыш урталарында
яланаяк басып торырга?

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘРДӘН

* * *

*Кеше ник дип өзә икән*
*үзенә иң газиз кылны!*

Үзем эшафот та,
кискеч балтасы да...

Җәллады да,
корбаны да —
барсы — үзем...

## Сукбай

Зиннәтле сарайларда тордым...
төшләремдә.
Хур кызларын кочтым...
уйларымда.
...Күләгәмә урын тапмый иза чигәм
ирексездән иркле булып!..

* * *

Һәр зат Җирдә тигез булса —
кыя-таулар бөгелеп килеп,
үзәнгә тулыр иде!

...Каргалар шигырь укыса —
күгәрчен булыр иде!

* * *

Яшәдең, эшләп җан аттың...
Йә, үзгәрттеңме бераз
Дөньяны, Илне?

...Сизәме тау очып төшкән
Тәмәке көлен?

* * *

Кем — явызлыгыннан кибә.
Кем — изгедән сагая.

...Көнләшүдән күгәргәнче
сагынудан саргаям.

* * *

Мин, бәлки, бер бөртек
яшенә тормыймдыр?..
Ә үзенә торам!

...Безнең озын гомергә —
бер кыска юрган.

* * *

Дошманыңнан гөл алсаң син,
артык гаҗәпләнмә!
...Дусларың агу бирсәләр —
әзерме, син, бәндә?

* * *

Өметләндек: җырыбыздан
илләр куаныр, диеп.

...Комга рәсемең ясадым —
җилләр юаныр инде!

## Без!

Без бәләкәй түгел!
Сузылсаң бар буйга
гасырлар буена —
булганбыз
Тарихның муенында!

## Бер агай сүзләре

Ялган гаеп
чыннан безне
гарип иткән...

Шул ялганны
фаш итүе —
гаеп икән!..

* * *

Чәчәкле май чагым үтте.
Хәзер — җәйге мәлемдә.

...Батыр калыр көч тоеп та,
Көрәшмәгән хәлемдә.

* * *

Кирәктер карау да
таулардан — талларга.
Вакыттыр җандагы
дәрманны барларга.

...Юл ач син күнеленңдә
буылган салларга!

МЕТАМОРФОЗА

**Яшьлек (иртә)**

Ай түгел, көн торып булмый
бер-беребездән башка.
Бар газапка да ризабыз,
аерылудан башка.

**Ир чак (көндез)**

Ыгы-зыгы. Вакыт җитми.
Эш, аш, йокыдан башка.
Миһербанлы күзәнәкләр
үлеп баралар башта.

**Картлык (кич)**

Күмәклеккә омтылып
яшь җан саташа башта.
Дөньяның гармониясе
фәкать тик ялгыз башта.

## Безнең көннәр штрихы

Урылмый калдылар игеннәр.
Кыраулар өшетте мул кырны.
...Базарның чатында угрылар
гармунын алдылар сукырның.

Нур
Әхмәдиев



## Бүләк

Чәчелдем дә җирдә, әй түгелдем
Һәм үкенмим үзем, үкенмим:
Ни икәнен белдем рәхәтнең мин,
Ни икәнен белдем читеннең.

Ничек бәяләргә дуслыкны һәм
Дошманлык ни — белдем ансын да.
Йөрәгемне уч төбенә салдым
Ничә тапкыр — ялган каршында.

Хакыйкатьнең сытык чыраеннан
Өстен күрдем баллы ялганны:
Тамчы булып туган бәлаләрем
Кайгы диңгезенә ялганды.

Сер бирмәскә ләкин, сер бирмәскә!
Ир булырга нинди хәлдә дә.
И Илаһым, авыр минутларда
Елмаюлар калдыр бәндәңә.

Әй кешеләр!
Сезне сөйгән өчен
Чәчелдем дә кат-кат түгелдем.
Яшәвемне кемдер бүләк дияр,
Ә кемгәдер бүләк... үлемем.

*1994*

## Чыңгызхан

Җиңелүне белмәс чирү белән
Илләр яулап йөрдең кем өчен?

---

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946) — *шагыйрь, бернича китап авторы. Әлмәттә яши.*

Күк алласы синең аяк аска
Бар дөньяны салды, Тимучин.

Тупырдаган тояк тавышлары...
Берсен-берсе суйган кабилә...
Йолдызлы күк асты — ызгышлардан
Тыныч тора алмый әле дә.

Тупырдаган тояк тавышлары...
Мизгел — илләр көлгә әйләнгән.
Ерактагы кыргый монголларга
Кемнең «чәче ничек бәйләнгән»:

Сартларныкы, татар, урысныкы...
Ничек кенә гайрәт орсак та,
Төрле илләр, төрле гореф-гадәт,
Төрле киңлекләрдә торсак та.

Яшәсәк тә төрле кыйтгаларда,
(Без бит үзгә хәтта җырда да.)
Бөтенебез сыйган, ризык тапкан
«Каһәрләнгән» Алтын Урдада.

Бүген исә уртак Ватан да бар,
Барыбыз да «тигез» көенә
Үз-үзенә урын тапмый кеше,
Сыя алмый туган өенә.

Хыянәтне, үчлек, явызлыкны
Бармы тагын шулай җыйган җир?
Бүгенгеләр белән чагыштырсаң,
Син фәрештә генә, Җиһангир.

Ялгышлардан гына тормыйдыр ла
Алла бәндәсенең язмышы.
Колак салсам, тупыр-тупыр килә
Киң далада тояк тавышы...

*1993*

## Кызыл, кара төсләр

Без табындык бары кара төскә:
Йә кызылга, йәки карага.
Кара белән кызыл арасында
Маңгайдагы чәчләр агара.

Әле кызыл, әле кара төсе
Чын хакыйкать булып тоелды.
Төсләр белән төсләр көрәшендә
Бер гаепсез җаннар кыелды.

Җан кадерле,
Ләкин кем җаны ул?

Кара халык — кара сарык бит.
Сарык булулары, ай туйдырды,
Кеше булуларга зарыктык.

Тормыш кансыз: горур кеше итеп
Үзен кемнәр саклап тотала?
Төсләр коллыгында яшәгәндә,
Бөҗәк булып җаннар бутала.

Йә күбәләк, коңгыз, кырмыска ул,
Йә булмаса — телә, кандала.
Мескен икәнеңне аңлаулары
Хәнҗәр булып җанга кадала.

Аңласак та афәт икәнлеген,
Туктап булмый хәтәр уеннан —
Шул ике төс: кызыл белән кара
Ныклап буып алган муеннан.

*1992*

## Төнге шигырь

Мин ялгызым.
Төнге күккә карыйм:
Йолдызыңны, бәлки, танырмын.
Танырмын да зәңгәр тынлык аша
Сагындым дип хәбәр салырмын.

Юк, кычкырмам, кипкән иреннәрем
Кыяр-кыймас кына эндәшер.
Бик кычкырып әйтсәм, ишетер дә
Әрсез җилләр үлеп көнләшер.

Шыпырт кына хәбәр салырмын мин,
Фәрештәләр генә тоярлык.
Күзләремне синнән алмый идем,
Бер-береңнән ләкин туярлык.

Булмаган шул...
Гашыйк җаннарыбыз
Метагалактика кебек тартылып,
Уза гомер.
Рәхмәт сиңа, раббым,
Яраткансың безне бар кылып.

Ялгызлыклар...
Әллә язмыш шундый,
Менә тагын ялгыз бу төндә.
Ялгызлыктан ятим шигырь туа,
Язмый торсаң — бигрәк читен лә.

Фәрештәләр!
Анын йолдызына
Илтеп җиткерегез: сагындым!
Аңласалар, тик гашыйклар аңлар:
Телгәләнгән чагы җанымның.

*1992*

* * *

Җирдә генә, юк, мин кала алмам,
Килер бер көн — күккә ашармын.
Ашармын да башка киңлекләрдә,
Башка үлчәмнәрдә яшәрмен.

Ә барыбер җирдә яшәвемнең
Һәр мизгеле калыр хәтердә...
Башны киссәләр дә, әзер бит мин:
— Мин — җирнеке! — диеп әйтергә.

Башка киңлек, үлчәмнәрне буйлап,
Мин барыбер җиргә кайтырмын:
Йә кош булып күктә талпынырмын,
Йә гөл булып чәчкә атырмын.

Җаным күчәр, бәлки, колыннарга,
Бер күбәләк, бәлки, булырмын.
Мине хәтерләгән һәрбер затның
Күзләренә кереп тулар моң.

Кайтмый калмам,
Кайтмый кала алмам,
Шигъри җаным ашкан күкләрдән.
Бәхетемне бүлешәм,
Кайгыларны
Иңнәремә салып күтәрәм.

*1993*

* * *

Бер сәбәпсез, никтер, этләр өрә,
Әллә алар шундый «әдәпсез»?
Ялгышамдыр: этләр — сизгер халык,
Өрмәс алар, өрмәс сәбәпсез!

Өрә белгән эткә сәбәп юкмы:
Ихатага карак кергәндер.
Бәлки, шушы көчек белмәсен
Берәр мәче карап йөргәндер.

Йә бер күсе ауга чыккандыр да
Этне адаштырып качкандыр.
Ашарына хуҗа бирмәгәндер,
Өрүләре — бәлки, ачтандыр.

Этләр тиккә өрмәс,
Сизәләрдер
Эшнең кая табан барганын.
Буыла язып өрә, өрә этләр,
Ярсып өрә, белми арганын.

Этләр өрә, бүре йөри тора,
Зәңгәр күктә йолдыз атыла.
Өрә-өрә этләр ни саклыйдыр, —
Бездән урлап Ватан сатыла.

*1993*



**Сафа Сабиров**

# ХӘВЕФЛЕ СӘФӘР

ПОВЕСТЬ

## Җилдән туган бала

Порт тәүлек буе гөрләп тора. Төп фарватердан биек дамба белән бүлеп алынган тын рейдка икешәр, өчәр катлы ак теплоходлар, баһадир буксирлар бер-бер артлы кайсы килә, кайсы китеп тора. Тимер-бетон причалларда куәтле краннар, тасмалы транспортерлар ярдәмендә баржалардан ташкүмер, цемент, гравий, тоз бушаталар, озатасы йөкләрне төйиләр. Безнең «Зөя» баркасы да шунда тулгана: еракпардан килгән баржаларны йөкләрен бушатырга краннар янына китереп куя; бушатылганнарын, рейдка чыгарып, юлга әзерли, төрле йомыш-юлга йөрүдән туктамый.

Икенче җәй инде мин — шул баркасның механигы. Тышкы күренеше белән артык мактанырлык матур булмаса да, яратам мин «Зөя»не; күңел биреп, тел-теш тидермәслек итеп тырышып эшлим. Без вахтада өчәү торабыз. Машина бүлегендә мин, рубкада штурман Артур белән койрыкчы Харитон. Алар, матрос вазифасын бергә үтәп, акчасын урталай бүләләр.

Бүген — биш яшьлек улым Мансурның туган көне. Шунлыктан, вахтадан бушауга, шундук өйгә элдертмәкче идем. Тиз генә өс-башны алмашып, басмадан төшеп барганда штурман Артур юлымны бүлде һәм:

— Ашыкма, әйдә, безнең белән... Бераз тамак чылатып алырбыз,— дип, Харитон кулындагы канистрга ымлады.

---

Сафа САБИРОВ (1915) — *әдип. Дистәләгән китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Әһә, аңлашыла, көндез Печишега барышлый Югары Ослан кафесы мичкәләрен, он, ярма тулы капчыкларын әшнәләрчә бушлай гына илткән өчен алар сыра һәм закускага каклаган балык юнәткәннәр иде, шуның белән кәефләнергә чакыралар икән.

Әмма мин бармадым, чөнки аларның гел «юнәтү» белән шөгыльләнүләрен өнәп бетермим. Аннары, иртән эшкә киткәндә, хатыным Сәрвиназ: «Соңга кала күрмә, эштән бушагач та кичке ашка кайтып житәргә тырыш»,— дип кисәтеп куйган иде.

Кыстап-кыстап та күндерә алмагач, Артурның чырае сытылды.

— Алайса бар кайт, Сәрви чибәргә миннән кайнар сәлам әйтергә онытма,— диде, кинаяле төрттереп.

Ә мин барыбер бирешмәдем, бүтән сөйләнеп тормастан, тиз генә көймәнең моторын кабыздым да, турыдан су өсләп кенә өйгә кайтырга чыктым.

Шулай да бу моторлы көймәне әмәлләп шәп эшләдем мин. Элек Юдинодан поездда шәһәр аша портка бару-кайту шактый вакытны ала иде, әни ике сүзнең берендә: «Ташла шул җәһәннәм астына йөрүеңне. Анда көннәр буе коры-сары белән тамак ялгап, барлы-юклы жалунья хакына тимер-томыр арасында чиләнгәнче, Бәдретдин абыең янына ашханәгә керсәң, бер уңайдан тамагың да тук, өстең дә бөтен булыр»,— дип колак итен кимерә иде. Хәзер, үз моторкам булгач, эш көйләнде, станциядә поезд көтеп торулардан котылдым, портка турыдан-туры су өсләп кенә җилдертәм!

Бүген көн матур түгел. Төштән соң башланган пыскак яңгыр һаман сибәли, куе томан кебек, әйләнә-тирәне томалап алган. Зур судноլар, тиз йөрешле «Метеор»ларга комачауламас өчен фарватердан читтәрәк, сул як яр буйлап саклык белән генә кайтам.

Тиздән, кыяташ кебек биек водокачка турыннан үтеп бераз баргач, Юдино поселогына күренеш ачыла. Текә яр өстендә безнең кызыл калай түбәле, зур-зур дүрт тәрәзәсе Иделгә караган алты почмаклы өебез, челтәрле тимер рәшәткә белән уратылган җиләк-җимеш бакчабыз бөтен урамга ямь биреп тора. Арткы якта кош-корт, терлек абзары, ак мунча, яшелчә, бәрәңге бакчасы. Боларның барысы да минем эшкә уңган әни тырышлыгы белән булдырылган. Инде шактый өлкән яшьтә булуына карамастан, ул хәзер дә көнаралаш базар юлын таптый, алу-сату итә, нәрсәдер юнәтү белән мәшгуль була.

Үзебезнең турыга килеп җитәрәк күрәм: су читендә, такта басма өстендә, улым Мансур мине көтеп тора. Их, малай актыгы, мәйтәм эчтән, өйдән әбисе күрмәгәндә чыгып шылган булса кирәк, салкында яланбаш тора, курткасын да төймәләмәгән, ичмасам... Көймәдән чыгып, чалканы бәйләргә өлгермәдем, ул:

— Тукта, әтием, бәйләми тор... Әйдә, йөреп кайтыйк,— дип, көймә эченә сикерде.

— Юк белән башны катырма әле, улым, бу вакытта нинди йөреп кайту ул? — дидем мин аңа каршы, аны-моны уйламыйча.

— Һи, онытгың да мыни, әтием туган көнемдә мине моторкада йөртәм, штурвал белән идарә итәргә бирәм, дип әйткән идең ич. Менә шул көн җитте, әйдә, китәбез,— диде ул борынын турсайтып.

Хак сүз, гел сорап йөдәткәч, вәгъдә иткән идем шул. Вакыт шактый соң булса да, ташбашымның теләген үтәргә туры килде. Рульне бер-якtan Мансур, икенче яктан күрсәтмичәрәк үзем тотып кузгалып киттек. Шатлыктан малайның авызы ерылды. Аракчинога җиткәч, Сәрвиназның әтисе Зариф бабай өе каршында кире кайтырга борылганда, без килгәнне ишетсен дип, хәтта сузып-сузып сирена кычкыртып алды.

Үз басмабызга әйләнеп кайткач, көймәне су читендәге карт өянкегә чалбырладык. Аннары асылмалы моторны, бензины яртылай бушаган канистрны сарайга менгезеп куйдык.

Шул арада өй каршындагы чия, алмагачларны шаулатып, җил күтәрелде, веранда тәрәзәләренә борчак сипкәндәй бәреп, эре тамчылы яңгыр коя башлады. Бу хәлгә ничектер сагаеп калган Мансур, үзалдына уйлангән сыман:

— Әтием, мин дә шундый салкын җилдә тудыммы, туңмадым микән?— дип әйтеп куйды.

Мин аны-моны уйлап тормастан:

— Ник алай дисең, улым, кем әйтте аны?— дидем гаҗәпсенеп.

— Әби әйтте... Ул мине гел шулай, җилдән туган шалапай, дип орыша.

Әйе, шулайдыр шул, бала чакта ул еш кына мине дә шул әшәке сүз белән хурлап тирги торган иде. Шуңа күрә моңа әллә ни әһәмият бирмәдем:

— Әбиеңнең сүзен тыңламагансыңдыр,— мөгаен, шуңа орышкандыр,— дип, четерекле әңгәмәне икенчегә борып җибәрергә тырыштым.— Әйдә, юеш курткаларны верандада салып элик тә, өйгә керик. Син туган көнгә нинди сый әзерләгәннәр икән, күрик әле...

## Биләмче хатын

Бүтән көннәрне бу вакытта бездә инде ут алынган, кичке табын әзерләнеп, өй эче тантаналы төскә кергән була иде. Бүген исә, бәйрәм көн булса да, бүлмәләр ярым караңгы — түр якта шыксыз тынлык, беркем дә юк; алгы стенадагы путаллы рам эченнән әнинең әтисе, ягъни Шакир бабай фотосурәте генә җәенке кашлары астыннан ачулы карап тора. Мәрхүм бабай заманында көн күрә белгән булса кирәк, әни һаман саен аның шул хасиятен мактап сөйләргә, мине дә аның кебек эш йөртә белергә, мал җанлы булырга өйрәтеп йөдәтә.

Һи, күрми торам, әни кухняда пешеренеп маташа икән ич. Кәефе шәптән түгел бугай, никтер ордым-бәрдем йөри; әнә ул аяк астында буталып йөргән ялагай мәчегә ачу белән тибеп очырды. Берни дә күрмәгән-сизмәгәндәй, көр тавыш белән:

— Күз бәйләнә бит инде, әни, ник ут алмыйсыз? Сәрвиназ кайда, кайтмадымыни әле?— дип сорадым, залдагы люстраны кабыздым.

— Мин каян белим аны, биләмдә йөридер,— диде әни, плитә янында маташа биреп.— Җүнле хатын булса, эштән соң туры өйгә кайтыр, кәнтәйләнеп йөрмәс иде.

— Әмма тел дә инде үзеңдә, тапкансың сүз, әни... Нишләп биләмдә йөрсен ул, эшендә берәр тоткарлык килеп чыккандыр.

— Тоткарлыкмы, түгелме, анысы миңа караңгы. Аның эше беткәнгә әнә күпме инде.. Йә, үзең уйлап кара, ирен санга суккан, өйдә баласы барын онытмаган хатын шул тиклемгә олагамыни?...

Юеш өс-башны салып, кулларны юган арада Сәрвиназ кайтып керде. Ул да яңгырга эләккән, плащы манма су, чәч бөтеркәләре чигәләренә ябышкан. Кулында азык-төлек тулы сумка.

— Местком утырышы озакка сузылды, кочкә чыгып котылдым,— диде ул, соңгаруы өчен акланган дай.

Сәрвиназ кайтып керү белән өй эче җанланып китте, күңелсез киеренкелек юк булды. Моңарчы үзен ничектер басынкы тоткан Мансур да, әнкәсе чишенеп беткәнне дә көтмәстән, моторкада Аракчинога хәтле баруы, Зариф бабасы өе каршыннан гудок кычкыртып үтүе турында мактанырга тотынды. Сумка эченнән бесказырка, зәңгәр якалы матрос күлмәге килеп чыккач, тәбрикләп биргәнне дә көтмәстән, түземсезләнеп

сорап алды. Минем дә бүләккә дип алдан әзерләп куйган уенчык бинокльем бар иде. Йокы бүлмәсендә яшереп куйган җирдән шуны алып чыгып биргәч, шатлыктан малайның башы күккә тиде. Диңгезче формасы кигән, муенына бинокль аскан хәлдә көзге каршында үзенә-үзе хәйран булып карап торды.

Озакламый табын әзер булды. Әни аш-суны мулдан әзерләгән иде. Мансур үлеп яраткан сый — ит бәлеше дә зур табада тәмле ис бөркеп утыра иде. Барыбыз да ачыгып кайтканбыз икән, мактый-мактый ашадык. Сәрвиназның әлегә тикле күрсәтмәгән тагын бер күчтәнәче — пломбир мороженое булган икән, сумкасыннан шуны алып биреп, баланы тагын бер кат шатландырды.

Ниһаять, малайның алҗуы житте бугай, тамагы туйгач, якынрак күчеп, әнкәсенә сыенды. Сәрвиназның, күнеле йомшарды, күрәсең, улын кочаклап, маңгаеннан әп итеп алды.

Тышта җил тагы да көчәя төште. Бәреп яуган яңгыр тамчылары, тәрәзә пыяласында вак гөрләвектәй юл-юл булып ага башлады. Оясын давыл туздырган булса кирәк, кызыл түшле бәләкәй генә кошчык, түр тәрәзә рамына килеп кунды, ышыкка керергә теләгәндәй, канатлары белән җилпенде дә, төн караңгысы эчендә юк булды. Моны күреп торган Мансур кызганычлы тавыш белән:

— Әнием, мин дә шундый яңгырлы җилдә тудыммы, бик туңмадыммы? — дип сорап куйды.

— Чү, улкаем, ни сөйлисең син, кем сүзе ул?! — диде Сәрви.

— Әби сүзе... Җилдән туган, азман калдыгы, диде.

Табында авыр тынлык туды. Бер-беребездән уңайсызланып, һәркайсыбыз үз алдында караган хәлдә сүзсез калдык. Самавыр янында кара көеп утырган әни кинәт тончыккан сыман йөткеренеп алды. Аннары тиз генә битләрен сыйпап, амин тотты да, кухняга чыгып китте.

Ә тел бистәсе малай һаман тәтелдәүдән туктамый бит. Әбисе әйткән «азман» сүзен ул кеше исеме дип аңлаган икән, шуны сораштырырга керешеп. Кәефе кырылган Сәрвиназ рәтләп тыңламагач:

— Азман абый кайда ул, аның безгә килгәне бармыни? — дип миңа ябышты.

Бу гайбәт, үзара күрәлмаучылык, ызгышлар инде теңкәгә тия башлаган иде. Көтмәгәндә, бая баркаста Артур әйткән кинаяле «кайнар сәлам» искә төште, әнинең шикләнүендә хаклык бардыр кебек тоелды. Шуның өстенә малайның ахмак сораулары мине тәмам чыгырдан чыгарды. Күп уйлап тормастан:

— Ул азманның килгәнен-килмәгәнен мин каян белим... Әнә әниеңнән сора, бәлкем, ул белә торгандыр, — дип ычкындырдым һәм гафу ителмәслек мәсхәрәле сүз әйтеп ташлавымны азактан гына абайлап алдым.

Сәрвиназ кулында калтырый башлаган чәйле чәшкесен өстәлгә куйды, яңаклары агарып китте. Зур ачылган күзләре белән миңа бермәл аптыраулы карап:

— Ни әйткәнеңне аңлыйсыңмы син?! — диде.

Ә мин, акыллы баш, гафу үтенәсе урында, бернигә исем китмәгәндәй, турсаеп утыра бирдем. Аннары, күп тәкелдәп табынның ямен җибәргән өчен Мансурны җиңелчә тиргәдем дә, өстәл янынннан торып киттем.

Дөресен әйткәндә, монда малайның һичнинди гаебе юк иде. Һәр яңа күргән нәрсәне, яңа ишеткән сүзне аңларга тырышучан беркатлы сабый ни сөйләмәс? Андый мәнсез сүзне әни әйтергә тиеш түгел иде.

Сәрвиназ бик үпкәләде, ахрысы, миңа бүтән күтәрелеп карамыйча, сүзсез генә өстәлне җыештырырга тотынды. Әни өчен дә, үземнең дорфалыгым өчен дә иртәгә үк гафу үтенергә кирәк булыр дип уйлап куйдым.

Гадәттә кичке аштан соң Мансур белән мин икәүләшеп, телевизордан «Әлли-бәлли бәү» тапшыруын карый торган идек. Баланы йоклаткач, үзем бер-ике сәгать имтиханга әзерләнеп тә ала идем. Бүген кәеф тәмам бозылды, уку кайгысы түгел. Сәрви белән күзгә-күз калмас өчен, ул табынны җыештырган арада, тизрәк ятып йокларга ашыктым...

## Онытылмас сәфәр

Әмма үч иткән кебек, күзгә йокы керми, табын янында кузгалган күңелсез уйлар йөрәкне тырнап тора. Мин әнинең Сәрвиназны күралмавына, адым саен аңа бәйләнүенә тәмам гаҗиз идем. Бу арада бераз басылган кебек иде, никтер әнә тагын тузынып каныга башлаган. Инде нишләргә дә белгән юк болар белән. Билләһи менә, ник өйләндем дигән көнгә килеп җиттем.

Гаҗәп хәл: егет вакытта минем беркайчан өйләнмәм дип әйткән катгый сүзем бар иде. Чөнки гаилә тормышының һичнинди кызыгы юктыр, хатын-кызлар барысы да, минем әни кебек, һаман файда итү, мал арттыру турында кайгыртып, вакчылланып теңкәгә тиючәндер кебек тоела иде. Шунлыктан кыз-кыркын тирәсендә артык чуалмаска тырыштым, күз атучыларны күрмәмешкә сабыша идем.

Шулай да мин азаккача сүземдә тора алмадым, көннәрдән бер көнне антымны онытып, өйләнүемне сизми дә калдым.

Барысы да юлда машинада барганда башланды. Ул чакны без, елгачылар больницасының яшелчә бакчасына кәбестә алышырга баручы бер төркем шәфкать туташлары белән, кичтән сөйләшенгәнчә, иртән порт идарәсе алдына җыелган идек. Әйтелгән вакытка машина да килеп җитте. Такта утыргычлы ачык кузовка төялешеп кузгалырга торганда, шәфкать туташларыннан берсе:

— Бәрәч, бригадирыбыз Артур белән Сәрвиназ юк ич...— дип кычкырып җибәрде.— Әй, шофер дус, әз генә көтик әле. Клубтан гитара, транзистор алырга гына киткәннәр иде, менә-менә килеп җитәргә тиешләр.

Аның сүзләрен раслагандай, нәкъ шул минутта клуб ягыннан алар үзләре килеп чыкты. Гитара аскан тузгый башлы, чөгендер төсле кызыл борынлы чандыр егет кабинага шофер янына кереп утырды. Аның белән килгән җиңел гәүдәле яшь кенә чибәр кызга мин, кулыннан тартып, кузовка менәргә ярдәм иттем дә, күршеләрне бераз кысрыклап, үз янымнан урын бирдем. Аның зур зәңгәр күзләре һава диңгезедәй төпсез тирән иде. Үзе көмеш кыңгырау кебек ачык тавышлы икән, алсу иреннәре белән ягымлы елмаеп рәхмәт әйтүе күңелемне иркәләп үтте.

Бу кыз белән мин бөтенләй таныш түгел диярлек идем, шәһәргә барганда-кайтканда ара-тирә поездда күреп кенә бераз беләм. Ул елгачылар больницасында эшли бугай. Беренче карашка үзен горур тотучан, тәкәббер сыман күренсә дә, асылда кеше белән җиңел аралашучан, киң күңелле булса кирәк, иптәш кызлары әле бер, әле икенче яктан:

— Сәрви җаным, анда кырыйда уңайсыздыр, менә монда күчеп утыр,— дип, аны үз янына чакырып дәштеләр.

Мәгәр ул күченеп кеше борчырга арусынмады, ахры, утырган урнында кала бирде. Машина кузгалып китү белән, транзистордан яңгыраган «Юксыну» көенә үзе дә моңлы җыр сузып җибәрде. Аңа бердәм кушылып, башка кызлар да җырлый башлады.

Теге тузгый башка кабинада күңелсез тоелды бугай, машина туктаган бер арада кузовка менеп, алгы рәттәге кызлар арасына кереп утырды.

— Анда душно, бензин исеннән тошнить итә,— диде ул, ярым татарча, ярым русчалап.— Мин играть итәм, әйдәгез, сез җырлагыз,— дип, гитарасын зыңгылдатырга тотынды.

Дөресен әйтим, мин үзем аның нинди көй уйнаганын шәйли алмадым. Әле генә моңланып җырлап барган кызлар да бер-берсенә аптыраулы карanыш, тынып калды. Минем белән янәшә утыручы Сәрвиназ үзалдына уйланган сыман:

— Бу бичараны әйтәм, туган телендә адәм рәтле сөйләшә белми икән... Уйнаган көе дә ташка үлчим,— дип җәлләп куйды.

Ә машина урман эченнән сузылган тип-тигез асфальт юлдан кош кебек очып бара. Колакларда җил сызгыра, Сәрвиназның җилфердәгән йомшак чәче битемне кытыклый. Машина кинәт борылган мизгелләрдә, егылмас өчен, ул әледән-әле минем иңемә тотына һәм, гафу үтенгәндәй, сизелер-сизелмәс елмаеп куя. Моны сизеп алу белән, мин урынымны аңа биреп, үзем борт кырыена күчеп утырдым.

Больницаның ярдәмче хуҗалыгына барып җиткәч, безгә машинадан төшәргә дә ирек бирмәделәр. Яшелчәчеләр звеносы житәкчесе,— яшькелт курткасын җилбәгәй җибәргән чылгый мыеклы урта яшьләрдәге агай,— шофер янына кабинага кереп утырды да, безне шундук басуга алып китте.

Без туктаган җирдән чак кына читтәрәк кемнәрдер инде эшли башлаган иде. Бакчаны агай алар белән янәшәдә безгә дә һәркайсыбызга өчәр метр исәбеннән җир үлчәп бирде дә:

— Кәрзин һәм кучәнчапкыч пычакларны әнә тегеннән алырсыз,— дип, җир башындагы такта сарайга күрсәтте.— Сезнең белән күршедә эшләүчеләр — үзебезнең кешеләр, алардан калышмаска тырышыгыз..... Ике кеше машинада калсын, башкалар алган кәбестәне төяп, пучинкәгә амбарга ташый торырлар.

Бригадирыбыз Артурның тартырга сигареты беткән икән, яшелчәче агай белән кибеткә дип киткән җирдән озак кына йөреп килде, ә без шундук дәррәү эшкә керештек. Кучәнчапкыч белән коралланган кызлар һәркайсы үз кишәрлегендә баш калкытмый эшләде. Сәрвиназ белән мин алар алган кәбестәне машинага төяп, амбарга кайтарып бушата тордык.

Иртәнге якта көн чалт аяз иде, урман полосасы ягыннан сизелер-сизелмәс кенә искән йомшак җилдә үрмәкүч тоҗымнары оча иде. Төштән соң, эш бетәргә бер-ике сәгать каларак, күк йөзен бөдрә болытлар каплап алды, кыйгач бәреп җылы яңгыр сибәли башлады. Чыланмасын дип, мин Сәрвиназга тужуркамны салып бирмәкче идем, кешедән арусынмады бугай, алмады, сүзсез генә рәхмәт әйткәндәй:

— Юк, юк, кирәк түгел, борчылма... Тоз түгел, болай да эремәм,— дип елмайды гына.

Пучинкәнең үз кешеләре яңгыр ява башлау белән өйләренә кайтып киттеләр. Аш әзерләсеннәр, әйтергә кирәк дип, алар белән бергә бригадирыбыз Артур да алар артыннан китеп югалды.

Бу вакытта безнең эшебез күп калмаган иде, инде бетермичә туктамаска булдык. Бәхеткә, тиздән яңгыр да үтеп китте. Ә без бер-беребезне ашыктыра-ашыктыра тагы да кызурак эшли бирдек. Бераздан, бакчачы агай мотоциклда килеп төшкәндә, без инде эшне тәмамлап, соңгы кәрзиннәрне машинага төяп маташа идек. Бушап калган участокны күреп, аның исе китте:

— И-и, бетердегез дә мени... Шәп иткәнсез, безнекеләрнең борыннарына чирткәнсез.....— дип мактап рәхмәт әйтте.— Чылангансыз, карыныгыз да ачкандыр. Әйдәгез, кайтыйк, юлга чыгар алдыннан тамак ялгап алырсыз.

Хак сүз, ачыккан идек, шулпалы пилмәнне дә, куян ите белән карабодай боткасын да яратып ашадык. Без чәй эчеп бетергәндә генә ашханәгә иреннәрен ялый-ялый Артур килеп керде. Ул бераз тамак чылатып алган бугай, күзләре ут уйный, болай да чөгендер төсле борыны тагы да кызара төшкән иде. Безнең шелтәле карашны сизеп булса кирәк, акланырга теләгән сыман:

— О том, что без действительно эшләдек, заведующидан справка алдым, шунда задержался,— диде.

Без юл буе әле шаярып-көлеп, әле җырлап кайттык. Ничектер шулай килеп чыкты, мин тагын Сәрвиназ белән янәшә туры килдем, аның иңбашы җылысын тоеп, юл буе колакны иркәли торган ягымлы тавышын ишетеп кайттым. Кичкырын, һава салкыная төшкәч, минем тужурканы иңнәребезгә салып бөркәндек. Хәзер инде Сәрвиназ миннән читенсенми, бераз үз итеп, җылырак карый сыман тоела башлады. Моңарчы гомер булмаганча, сихерләнгән кебек, аның күңелгә ятышлы мөлаем йөзеннән, елмаюлы алсу иреннәреннән күзләремне аера алмый идем.

Шунда мин Артурның да Сәрвиназга битараф түгел икәнлеген, әледән-әле аңа күз атуын абайлап алдым. Кызның игътибарын җәлеп итәргә теләгәндәй, гитарасын зыңгылдатудан туктаган араларда, төче телләнеп, мәзәкләр дә әйткәли. Әмма күрәм, сүзләре барып җитми, кыз ризасызлык белән кыйгач кашларын җыерып куя.

Шәһәр вокзалы янында Сәрвиназ белән мин машинадан төшеп калып, безнең якка бара торган поездга утырдык. Юлда сөйләшеп кайтканда мин аның больницада шәфкать туташы булып эшләвен, Аракчинода Идел яры буенда үз өйләрендә карт әтисе белән торуын белдем. Поезд Аракчинога җиткәч, Сәрвиназ белән бергә вагоннан мин дә төштем.

Гадәттә күп сөйләшүчән булмасам да, ул чакны кинәт телем чишелеп, байтак сайрадым, әлегә тикле һичкемгә әйтмәгән кадерле хыялларым, киләчәккә булган планнарым белән уртаклаштым. Моңар мине, мөгаен, аның игътибар белән теләктәшлек күрсәтеп тыңлый белүе рухландыргандыр. Хәер, Сәрвиназ үзе дә тормышта күп нәрсәгә минем төсле карый, киләчәктә читтән торып укып, врач булырга ниятләнә икән.

Кичке эңгер-меңгердә Сәрвиназны өенә хәтле озатканнан соң, үзем Юдинога яр буйлап турыдан җәяү генә кайттым. Аерылганда икебез дә сизмәгәнбез, тужуркамны аның иңендә онытып калдыруымны өйдә әни әйткәч кенә искәртеп алдым.

Һәм шуннан бирле без эшкә бергә бара, бергә кайта торган булып киттек. Моңарчы туйдырып бетергән поездда йөрүләр минем өчен бәхетле якты мизгелгә әверелде. Яңа бәхетле дөнья ачкан кеше кебек, мин гел елмаеп, Сәрвиназ турында уйланып, эчтән аның белән сөйләшеп йөри торган булып киттем.

Ярты ел чамасы вакыт үтеп, өйләнешергә килешкәч, Сәрвиназ мине әтисенә күрсәтергә булды. Аның әтисе, Зариф агай, заманында авыр поездлар йөртүче атаклы машинист, безнең теләккә каршы килмәде. Әмма минем әнинең фатихасын алу җиңел булмады. Чөнки бу мәсьәләдә аның үз планы бар иде: ул мине пенсиягә чыкканда үз урынына ашханәдә мөдир итеп калдырган Азалия исемле бик тә чибәр, ут кебек чая яшь кенә тол хатынга өйләндермәкче. Шунлыктан ул Сәрвиназны үтә салкын каршылады, ник килгәнен белгәч, әдәп-нәзакат саклап тормастан, үзенә хас төрпәлек белән:

— Чак кына оят белгән кызлар кияүгә тагылып чыкмыйлар, аларга яучылап өйләнәләр,— дип кырт кисте.

Сәрвиназның түземчән, сабыр холкын, әмма нык сүзле икәнен беренче мәртәбә мин шунда күрдем. Көтелмәгән хурлаудан аның төсе китте, иреннәре калтырый башлады, әмма әнигә бер генә дорфа сүз дә әйтмәде.

— Гафу итегез, тагылып түгел... Таһир чакыргач, сездән фатиха алырга килгән идек... Алайса, борчыганым өчен гафу итүегезне үтенәм... Хушыгыз,— дип әдәпле генә саубуллашып чыгып китте.

Минем әнине ачуланып тыңлата торган түгел. Мин Сәрвиназ кебек сабыр булырга тырыштым. Бераздан аны өенә озатып, мөмкин кадәр тынычландырып кайтканнан соң, әнигә катгый рәвештә:

— Аның белән син торасы түгел, мин торачак,— дип әйттем.— Мин барыбер аңар өйләнәчәкмен... Яхшылап уйла... Әгәр дорфалыгың өчен

барып гафу үтенмәсәң, мин иртәгә үк аларга күчеп китәчәкмен, бу йортка бүтән аяк басачак түгелмен...

Икеле-микеле уйланырга урын калдырмаслык итеп каты әйттем һәм әйберләремне чемоданга тутыра башладым. Мин аның бердәнбер варисы. Минсез каласы килмәде бугай, теләсә-теләмәсә дә, зәһәрен йотып, Сәрвиләргә барып гафу үтенергә, аны үзе яучылап чакырырга мәҗбүр булды. Без гаилә корып, матур гына яши башладык, бер елдан улыбыз Мансур туды.

Хәлбуки, әни сүзендә тормады, ачыктан-ачык каты бәрелмәсә дә, хуҗалыкта, кухняда үзе «командалык» итте, җае чыккан саен Сәрвиназга, мал җанлы түгел, йорт турында кайгырта белми дип бәйләнүдән туктамады. Шулай да соңгы вакытта бераз басылган кебек иде, бүгенге кебек зәһәрләнеп тузынганы юк иде. Шайтан белсен, әнә тагын никтер җене котырган, Сәрвиназны кимсетер өчен оныгын «азман калдыгы» дип атаган.

Юк, моңа юл куярга ярамый, иртәгә үк әни белән ныклап сөйләшергә кирәк: андый гадәтен ташласын, телен тыйсын. Табын янында ялгыш дорфа сүз ычкындырган өчен үзем дә иртәгә үк Сәрвиназдан гафу итүен үтенергә тиешмен.

## Ай-һай, улың микән?..

Кичтән йоклый алмыйча озак уйланып ятканга күрә, ахрысы, иртәгесен гадәттәгедән шактый соң уяндым. Хәер, зарар юк, күз ачу белән эшкә ашыгасы түгел. Бүген мин көнозын өйдә, кич белән генә төнге вахтага чыгачакмын.

Өйдә зурлардан беркем дә юк. Сәрвиназ бу вакытта, әлбәттә, инде эштә. Мансур кичә әнкәсе бүләк иткән матрос күлмәген киеп өлгергән, түр тәрәзәне ачкан да, мин биргән бинокльдән Иделне, аргы яктагы Печише кыяларын күзәтү белән мәшгуль. Әни, көндәгечә, базарга җыена бугай, ян тәрәзә каршындагы бакчада җете кызыл кыңгырау чәчәкле лаләләрдән матур-матур букетлар ясап йөри.

Аны күрү белән кичәге ниятем искә төште, кичекмәстән хәзер үк сөйләшеп, каты гына кисәтергә булдым... Әһә, әнә ул кереп тә килә, лалә бәйләмнәре тулы кәрзинен верандага куйды да, кофтасын киеп юлга җыена башлады.

— Әни, бер генә минутка туктале, сиңа әйтер сүзем бар,— дидем, аның юлын бүлеп.— Менә нәрсә: Сәрвиназга бәйләнүеңне, Мансурга җилдән туган дип, тозсыз сүзләр әйтүеңне ташла син. Минем улым, синең оныгың бит ул. Кеше-кара ишетсә, әллә ни уйлавы бар...

Әни миңа әйтеп бетерергә дә бирмәстән:

— Ай-һай, оныгым микән?! — диде, сүземне бүлеп.— Яхшылабрак карале син аңа, безнең нәселгә аз гына да охшамаган, аның йөзендә синең чалымың да юк бит... Шуны да күрмәслек сукырмыни син... Моны бөтен күрше-күлән күрә, синнән көләләр ләбаса. Миңа ышанмасаң, әнә Азалиядән сора...

Бу сүзләр, ут бөркегәндәй, битемне көйдереп алды, кулымдагы чәшкеле чәемне чүт түгеп җибәрмәдем. Кинәт кузгалган ачуымны тыя алмыйча:

— Тукта, житте сиңа!..— дип гомеремдә беренче тапкыр әнигә каты бәрелдем.— Бүтән ләм-мим әйтәсе булма, ишетергә дә теләмим...

Минем әни хәтәр кызу канлы, нервлы, бер кабынса, тиз генә басыла торган түгел. Бу юлы чамасыз ярсуымны сизде бугай, телен тешләде, каршы бер сүз дә әйтмәде. Шулай да барыбер үзенекен итте. Верандада кәрзинен кулына алгач, ишектән башын тыгып:

— Ярар, синеңчә булыр, ул хакта миннән бүтән бер кәлимә сүз ишетмәссең... Син мескенне жәлләп, күзеңне ачарга теләп кенә әйтүем ие...— дип, йөрәккә тоз салып, шәһәргә чәчәкләрен сатарга чыгып китте.

## Үксез бәрән

Әни белән сүзләшүдән бик борчылып калган идем, байтак вакыт тынычлана алмадым. Бакчада виктория җиләге, помидор төпләрен йомшартып, Мансур белән бергә Иделдә су кереп алгач кына, бераз басылып, имтиханга әзерләнергә утырдым. Әгәр ерып чыга алсам, быел көз ничек тә су транспорты институтына читтән торып укырга керергә иде исәбем. Үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, Мансур да кәгазь, карандаш белән «коралланып», минем белән бергә нәрсәдер сызгаларга кереште.

Әмма күңелем һаман тыныч түгел, зиһенем таркау, колакта әни сүзләре яңгырый иде. Дәреслектән аерылып, улым Мансурга текәләм, йөз чалымнарыннан үземә охшашлык эзләп вәсвәсәләнәм, әнинең аны шул тикле хурлап тиргәвенә аптырыйм...

Һи, онытa язганмын, минем үземне дә шулай үртиләр иде бит. Инде күптән, бала чакта ук әле, урамда шуның өчен бер күрше малайны дөмбәсләгәндә, аның әнисе: «Үксез бәрән, җилдән туган бәдбәхет»,— дип мине яңаклады. Мин елап кайтып бу хакта әйткәч, әни урамга йөгереп чыкты да, теге хатын белән бик каты кычкырышты, әмма үзенә карата тагы да әшәкерәк сүзләр ишетте. Ул көнне кич белән Бәдретдин абый килгәч, әни теге хатынны тирги-тирги сөйләде, кеше күзенә күренерлегемне калдырмады дип зарланды. Шуннан соң күп тә үтмәде, без ул шәһәрдән бөтенләй киттек, Юдинода менә шушы алты почмаклы зур йортны сатып алдык. Тегендә туган кешебез саналган Бәдретдин абый да тиздән Казанга күчте һәм безгә еш килеп-китеп йөри башлады. Кайчандыр без яшәгән, әни пристаньда ашханә мөдире булып эшләгән шәһәрнең Чистай икәнлеген дә, күңелемә тирән сеңеп калган «үксез бәрән» дигән сүзнең мәгънәсен дә мин бераз үсә төшкәч кенә аңладым. Ул хакта әни берни дә әйтмәгәч, мин үзем:

— Бүтән балаларның әтисе бар, ник минем әтием юк, мин ник үксез?—дип сораган идем.

Әнинең иртән эшкә китәр алдыннан көзге каршында киенеп маташкан чагы иде. Минем сораудан кинәт сагаеп калды. Кашларын җыерып бермәл миңа текәлеп карап торганнан соң, кеше-кара ишетмәсен дигәндәй, акрын гына:

— Ул юк инде, үлде ул,— диде.— Бик җәнҗалчы, эчкече иде. Талашты-талашты да, синең белән мине ташлап, читкә китеп югалды. Китүенә ике ел тулганда, аның кайдадыр Ерак Көнчыгышта янгын сүндергәндә һәлак булуы турында хәбәр килде. Үлгән-беткән, хәзер инде ул хакта сүз кузгатып, хәсрәтләнеп йөрүнең кирәге юк. Моннан соң ул турыда бүтән уйлама, сораштырып башны катырма, онытсин аны.

Әмма мин оныта алмыйм, үсә төшкән саен күбрәк уйланам. Чөнки әтиемнең исемен дә, аның нindиерәк кеше булуын да, туганнары бармыюкмы икәнлеген дә әйтми әни. Безгә килеп-китеп йөрүче Бәдретдин абый да туган кешегә бер дә охшамаган. Күбрәк төшергән очракларда әни тирәсендә иркә кияү кебек сырпалана. Бездә кунган төннәрдә иртән әни бүлмәсеннән чыкканын берничә тапкыр күргәнем бар. Бу хәлне башыма сыйдыра алмыйча бик аптырап калдым һәм, моны Сәрвиназ күрмәгәе дип, әни өчен оялудан ут йотып йөрдем.

Сәрвиназ исә моны үзе дә сизгән булып чыкты һәм минем кебек уңайсызланмыйча:

— Аңа ник исең китте?.. Мин монда гайре табигый берни дә күрмим...— диде.— Берсе ирсез, икенчесе хатынсыз, шунлыктан кемгәдер хыянәт иткән, кемнеңдер гаилә тормышын җимергән, дип гаепләргә урын юк. Җилбәзәк яшь-җилкенчәкләр түгел, икесе дә өлкән яшьтәге кешеләр, ничек кирәген белә торганнардыр, үзләре теләгәнчә яши бирсеннәр. Минем өчен тик бернәрсә — күп еллар буе болай качып-посып йөргәнче, кешечә язылышып тормаулары гына бераз сәер.

Дөрес, анысы да бар. Әмма минем әни алдын-артын уйламыйча эш итә торган хатын түгел. Исемдә, миңа ачуланган минутларда ул берничә тапкыр:

— Син аңгыра бәрән өчен тырышам, сиңа артык вәристаш булдырмас өчен иргә чыкмадым,— дип тузынып алды.

Уф, бу борчулы уйлар белән башым әйләнде, имтиханга рәтләп әзерләнә дә алмадым. Баксаң, көн кичкә авышып бара икән. Әнә станция ягыннан, буш кәрзинен күтәреп, әни дә кайтып килә. Элегрәк, азык-төлек арзанрак вакытларда ул гел ипи төяп кайта, ипи ашатып үгез симертә, чәчәкләрне, алмагачларны да икмәктә ачытылган су белән тукландыра торган иде. Хәзер андый мөмкинлек юк, һәрнәрсә кыйбатланды. Товары уңышлы сатылган көннәрдә ул күтәренке күңел белән кайта, ара-тирә хәтта Мансурга кучтәнәч итеп, бармак башы хәтле генә шоколад яки «Пепси-кола» алып кайткалый иде.

Бүген ул караңгы чырайлы, кашы-күзе җимерелгән. Буш кәрзинен ишек артына ташлады да, калтыраган бармаклары белән кофта төймәләрен ычкындыра-ычкындыра:

— Ах, харап иткән, күрәселәр бар икән...— дип, ачыргаланып аһылдарга тотынды.

— Ни булды,— мәйтәм,— кем нәрсәне харап иткән?

— Кем булсын, шул синең кара еланың инде, Бәдретдин абыеңны эшеннән чыгарттырган...

— Ничек инде чыгарттырган, Сәрвиназ аның начальнигы түгел бит... Әни, син нәрсәдер бутыйсың бугай. Сәрвиназның ашханәгә һичнинди катнашы юк. Ул шәфкать туташы бит, аның эше палаталарда, авырулар арасында.

— Медсестра гына түгел, ул анда профсоюз оешмасында контроль комиссиясе члены да икән. Бүген базардан соң Бәдретдин абыеңа кергән идем, шул әйтә: әгәр ашханәгә тикшерүчеләр киләсен Сәрви алдан хәбәр итсә, барысы да шома үтәчәк, әләгәсе түгел иде, ди. Йә, уйлап кара, телефоннан шалтыратып хәбәр итсә, теле корымас иде бит... Ул оятсыз үзе дә Бәдретдин юнәткән ит, май белән тыгынып ята бит. Гонаһ шомлыгы, шул тиклe дә яхшылыкның кадерен белмәгән, ашаган табагына төкергән мәнсез булыр икән.

Әни хәтәр дуласа да, нәрсәнедер әйтеп бетерми, һаман читләтепчитләтеп тузына. Аның сүзләреннән Бәдретдин абыйның эштән куылуында Сәрвинең шинди катнашы барын аңлавы кыен. Шунлыктан хәзер ул хакта җентекләп сораштырып торудан файда юк. Анда ни булганын иртәгә Сәрвиназның үзеннән белермен.

Ә хәзер миңа төнге вахтага әзерләнергә кирәк.

## Көтелмәгән командировка

Рәсми исеменнән тыш, безнең баркасның «Йөзмә тәрбияханә» дигән кушаматы бар; ә капитаныбыз Әюпгәрәй агайны үзе артында кайберәүләр «Аяклы устав» дип йөртәләр. Чөнки бүтән суднолардан куылган төрле штрафчы, сәрхүшләрне кадрлар бүлеге акылга утыртырга безгә җибәрә. Гаҗәп хәл, һич теләмичә, мәҗбүрән килүчеләрнең күбесе гадәттә төзәлеп, кешелеклегә, гадел таләпчәнлегә өчен капитанга рәхмәт әйтеп китә. Быел яз башында килгән яшь штурман Артур Со-

лтанов кына әле һаман акылга утыра алмый, сәрхүшлеген дәвам иттерә бирә.

Безнең «Зөя»нең тагын бер үзгәлеге бар — ул кайчандыр хәрби судно итеп төзелгән булган, мачтасында күзәтү мәйданчыгы — «карга оясы» да бар. Шунлыктан без аны еракган күрү белән танып алабыз.

Гадәттә, «Зөя» смена алмашу алдыннан диспетчер дебаркадеры янына килеп туктаган була иде. Ә бүген суднобыз үз урынында юк, күрәм, никтер ул күрше причалда тәэминат склады каршында тора, палубасына төрле ящик, мичкә, капчык-капчык йөк төйиләр. Моторкамны үзебезнең дебаркадер басмасына чылбырлап, палубага менгәч белдем: безнең баркаска ашыгыч рәвештә Кама елгасындагы гравий чыгару районына ун көнлек командировкага барырга фәрман булган; шул форсаттан файдаланып, тәэминатчылар андагы ашханәгә азык-төлек, кибеткә товар озатмакчы икән.

Ә мин бу көтелмәгән хәбәрдән, нишләргә белмичә, тәмам аптырашта калдым. Үч иткән кебек, шундый уңайсыз вакытка туры килүен күр син.

— Өйдәгеләргә әйтмичә, болай бернәрсәсез баралармыни?..— дидем.— Һич югында алмашка эчке кием, сабын-сөлге, кырынырга пәкемазар алырга кирәктер бит.

Капитан Әюпгәрәй агай миңа авыз ачарга да бирмәде:

— Юк, туганкаем, һичкая бардым юк,— диде җөйле-ямаулы чыраен сытып.— Озакка түгел, ун көнгә генә эчке бельесыз да түзәрбез... Анда баркаслары ватылган, безне бик көтәләр, сәгать саен диярлек шалтыратып ашыктыралар. Менә бу йөкне төяп бетерү белән хәзер үк кузгалып китәргә приказ булды.

Әнә шулай Сәрвиназга берәр җылы сүз дә әйтә алмыйча, борчулы уйлар белән кинәт китеп барырга туры килде. Ахыр килеп, бу пошыну басыла төшкән кебек булды. Ярар, дөнья җимерелмәс әле, өйдәге җәнҗалдан бераз тынычланып торырмын дип, үзем дә ул хакта артык уйламаска кирәк таптым.

## Кама буе — туган як

Моңарчы минем Кама елгасында беркайчан булганым, аны үз күзем белән күргәнем юк иде. Мин аны бары тик юл күрсәткеч китаплардан укып, «Гүзәллеге күңелләрдән жырга күчкән як» дип җырлаудан ишетеп, атаклы рәссамнарның сурәтләреннән күреп кенә азмы-күпме төсмерли идем. Шуңа күрә юлда, эштән буш вакытларда, әйләнә-тирәгә игътибар беләнрәк барырга уйлап куйдым.

Кама елгасы тамагына без кояш баеганда барып кердек. Әйләнәтирә чиксез киң һәм моңсу. Кичке шәфәкъ балкышына алсуланган тын дәрья күңел түрендә яткан сагышлы уйларны уята; бик еракта калган борынгы заманнарны һәм бүгенге көннәрне берьюлы күргән кебек хис итәсең... Кайчандыр бу җирләр Бөек Болгар иленең үзәге булган, бу яр буйларында безнең ерак бабаларыбыз иген иккән, мал асраган, шәһәрләр төзегән, суларында җәтмә белән балык сөзгән, җилкәнле корабларда ерак илләргә барып сәүдә иткән, һәркайда мул тормыш гөрләп торган бит... Мәгәр, көннәрдән бер көнне, аяусыз язмыш җиле боларның барысын да тар-мар иткән, мәһабәт сарайлар, гыйбадәтханәләр булган урыннарда хәрабәләр генә торып калган, җимерелгән мәчет һәм бабаларыбызның кабер ташларыннан кемнәрдер чиркәү салган. Ирексездән башта сорау туа, ник болай булган, кем гаепле дип уйланасың...

Кайчандыр мин атаклы француз географы Ж. Реклюның: «Елгалар үзләренең дулкыннарында халыклар тарихын һәм тормышын алып килә»,— дигән сүзләрен укыган идем. Хәзер бу тирәдән үткәндә ул сүзләрне

тагын хәтерләдем. Хәлбуки, илләр, халыклар кебек, елгалар үзләре дә бозыла, тереклек чыганагы булган чиста улар заарлы матдәләр белән агулана. Әнә бит ургып агып торган куәтле елга, торгын сулы күл кебек, акрынлап сөрси, өсте яшелләнә, суы эчәргә һәм балыклар яшәргә яраксызлана, акрынлап һәлакәткә бара. Бигрәк тә шунысы аяныч: адәм баласы күп очракта моны күрергә теләми, үзе утырган ботакка үзе балта чапкан гамьсез кеше кебек, бу һәлакәтне үзе ашыктыра.

...Баркас зур тизлек белән үргә каршы бара бирә. Алда — кичке шәфәкъ балкышыннан алсуланган су өсте көзгедәй шома. Артта — без кузгаткан йөгерек дулкыннар сыртында җемелдек маяк утлары тибрәнеп кала.

Безнең штурманнар, рулевойлар Кама фарватерын белмиләр, баркасны саклык белән, маякларга карап кына алып баралар. Капитан Әюпгәрәй агай да тыныч түгел. Үз вахтасы булмаса да, палубада транзистордан концерт тыңлап утырган җиреннән әледән-әле алга борчулы каранып ала һәм, баркас юлдан читкә тайпыла башласа, рубкадагыларга рульне уңга яки сулгарак тотарга команда бирә.

Койрык якта ашханә мөдире Азалия порттан алган азык-төлек өемнәре арасында актарына иде. Менә шул кинәт ачыргалы тавыш белән:

— Ах, бер ящик ит консервалары юк... Сезнекеләр урлаган, башка беркем түгел...— дип шәрран ярды.

Капитан транзисторны борып туктатты, Азалия янына якынрак килеп:

— Ут чыккан кебек ник тавыш күтәрәсез, ни булды? — диде.

— Ничек кычкырмаска, бөтен бер ящикны урлаганнар ич... Хәзер үк сезнең белән бергәләп, акт төзергә кирәк. Юкса, бәясен миңа түләргә туры киләчәк бит.

— Әлегә тикле бездә андый кыек эш күренгәне юк иде. Бөтен командага зур гаеп бит бу. Акт төзегәнче, әйдәгез, яхшылабрак карыйк әле, ялгышмадыгыз микән.

Капитанның сүзе рас килде. Базадан бирелгән накладной буенча җентекләп санагач, берни дә югалмаган, консервалы ящик он капчыклары артында яткан булып чыкты. Азалиягә шундук телен тешләргә туры килде.

Тагын берәр аңлашылмаучылык тумасын, җил-яңгыр чыгып чылатмасын өчен, капитан кушуы буенча, рулевой Харитон белән Азалия барча азык-төлекне бер тирәгә җыеп, аның өстенә брезент капладылар да, аны аркылы-торкылы сүс бау белән тарттырып бәйләргә керештеләр. Шулчак, кулындагы бау ычкынып китеп, Азалия арты белән суга ауды, винт кузгаткан күбекле дулкыннар кайнамында юк булды... Аннары өскә калкып, кулын болгый-болгый ашыгыч ярдәм сорап кычкыра башлады...

Бераз саф һавада җиләсләнергә теләп, тамбурдан яртылай чыгып торган чагым иде. Бу хәлне күрү белән тиз генә аска төштем дә, рубкадан команда булганны да көтмичә, машинаны акрынайттым.

Берничә минуттан мин иллюминатордан караганда баркас инде агым уңаена борылган, якында гына прожектор белән яктыртылган су өстендә кемдер бер кулы белән ишә-ишә Азалияне өстерәп йөзеп килә иде. Безнең егетләр аларны палубага күтәреп алдылар. Коткаручының капитаныбыз Әюпгәрәй агай икәнен шунда гына таныдым. Ул трусиктан гына, ялангач тәнле, еш-еш сулый, битләре кебек үк, аның күкрәге, беләге, ботлары да күп санлы җөй-ямаулык белән капланган иде.

Азалия дә баштанаяк манма су, бөтен өс-башы тәненә ябышкан. Ул бик курыккан һәм тончыккан, күрәсең, бизгәк тоткандагы кебек, дер-дер калтырый, буылып-буылып су коса. Бераз тын алгач кына көч-хәл белән:

— Уф-ф, чак кына харап булмадым,— диде...— Мин бер дә йөзә белмим бит... Әюпгәрәй агай, сезгә рәхмәт инде... Сез коткармасагыз, су төбенә китәчәк идем.

Капитан эскәмиядә салып калдырган киемнәрен җыеп маташкан җирдән:

— Үзем дә нәкъ шуннан курыккан идем... Арткы палубада беркем дә белмагач, тиз генә чишенеп, суга үземә ташланырга туры килде,— диде һәм, юлны дәвам итәргә күрсәтмә бирде дә, каютасына киенергә кереп китте.

Моңарчы мин чәчләренә кырау төшкән бу агайның ямаулы йөзенә ихтирам катнаш кызганып карый идем, гомеренең көзе җиткән, гәүдәсе сызлана, хәлсезлектән интегә торгандыр дип уйлый идем. Әмма аның турында аз белгәнмен икән. Бүген мин аның көч-куәткә ия, хәрәкәтләре ныклы икәнен күрдем... Минем уйларымны раслагандай, Азалия дә соклану белән:

— Кара син аны, төп кебек таза һәм житез...— диде.— Алгы палубада домина уйнаучы яшьләр кыймылдаганчы, ул яшен тизлеге белән килеп коткарды. Әйтәм ич, юкса су төбенә китәчәк идем.

## Якыннан танышабыз

Комташ чыгару урыны Кама елгасының түбәнге агымында урнашкан. Елгачылар җәй буе шунда су төбеннән кыймматле төзелеш материалы — миллионнарча тонна комташ чыгарып, ерак республикаларга, өлкәләргә озаталар. Бирегә килеп житү белән без дә шул кайнамга чумдык: нәкъ порттагы кебек, буш баржаларны краннар, җирсуыткычлар янына китереп куябыз, йөкләләрен юлга озатырга әзерләп җыябыз, төягәндә эчләренә тулган суны насос белән бушатабыз, кешеләрне эшкә илтәбез, вахтадан бушаганнарын базага алып кайтабыз.

Комташ чыгару идарәсе куе урманлы биек тау итәгенә бәйләп куелган «Баһадир» исемле ике этажлы иске пароходка урнашкан икән. Элемтә бүлеге, медпункт, кибет, клуб һәм ашханәләр дә шунда. Каюталарында механизаторлар, канцелярчеләр яши. Террасада, коридорларда эрелеваклы бала-чага дөбер-шатыр куыша, качыш-качыш уйный.

Безнең баркас командасын өске каттагы икешәр урынлы каюталарга урнаштырдылар. Мин Әюпгәрәй Харисович белән бер каютага туры килдем. Ике яруслы агач караватның аскы катында — ул, өстә — минем урын; менеп-төшеп йөргәндә олы кешене борчымас өчен, мөмкин кадәр саграк булырга, шауламаска тырышам.

Әюпгәрәй агай — отставкага чыккан хәрби-диңгез флоты офицеры, капитан булып ул безгә былтыр гына килде һәм, хәрби корабтагы кебек, һәр эштә тәртип таләп итә башлады. Безнең арада кайберәүләр аны өнәп бетерми, үзен эре тотучан дип сукраналар. Шуңа күрә көтмәгәндә аның белән бер каютага эләккәч, ирексездән сагаеп калдым.

Мәгәр юкка шикләнгәнмен икән, мин моны шул кичне үк күрдем. Монда килгән көнне без урнашып, баш-күз алган арада ашханә ябылган булып чыкты, төнгә каршы кичке ашсыз калдык. Чәйнек белән кайнар су алып кереп чәй пешергәч, Әюпгәрәй агай өеннән алып килгән азыктан миңа да өлеш чыгарды, тартынып торуымны күреп, кыстый-кыстый сыйлады.

Төрле сменада эшләгәнгә күрә моңарчы без вахта алмашынганда гына очрашып, бер-беребезне аз белә идек. Чәй янында әңгәмә корып утыра торгач, якыннанрак таныштык. Сүз арасында ул, сәер нәрсә күргәндәй, кинәт миңа текәп карый башлады, аннары да берничә тапкыр күз кырыен маңгаема төшереп алды. Ахыр килеп түзмәдем:

— Әюп агай, ник алай карыйсыз, нәрсә күрдегез?— дип сорап куйдым.

Ул көтелмәгән уңайсызлану белән:

— Юк, болай гына... Каш өстендә яңа ай урагы сыман ярым түгәрәк минем бар икән, шуңа каравым,— диде һәм үз маңгаендагы җөйле ямавына бармакларын тидереп алды.

Әюпгәрәй агайның егет вакытында ике сабый баланы янгыннан коткаруын, үзенең ут эчендә һәлак була язганын, табипларның аны зур кыенлык белән үлемнән саклап калганын мин моңарчы да ишетеп белә идем. Менә хәзер йокларга ятар алдыннан җинсез майкадан гына калгач, киң күкрәгендә, иңбашларында зур-зур ямау җөйләрен якыннан күргәч тәмам тетрәндем һәм дулкынлануымны тыя алмыйча:

— Әюп агай, бик авыр булгандыр бит, шул тикле яну-көюгә, врачларның тирегезне каезлау, ямауга ничек чыдадыгыз?— дип сорау бирдем.

— Түзми нишлисең, башыңа төшкәч, чыдыйсың инде,— диде ул, җиңелчә елмаеп.— Ярый әле кичекмәстән, һушсыз ятканда, самолетта Владивостокка озатканнар. Ярты елдан артык госпитальдә аунап ятарга туры килде... Озак югалып торгач, үзем хезмәт иткән погранпостта исән калыр дип уйламаганнар, уттан балаларны коткарганда һәлак булды дип, туган шәһәрем Чистайга хәбәр җибәргәннәр... Әмма мин исән калдым, дәваланып чыккач, хәрби-диңгез училищесына укырга кердем. Хәер, башта медкомиссия үткәрмәгән иде. Әмма мин ярдәм итүен үтенеп, флот командующиена гариза яздым. Шуның кушуы буенча, комиссия кабат караганнан соң, эчке органнарымнан авыру тапмадылар, тышкы ямау-җөйләре төзәлгән дип, мине училищега кабул иттеләр. Җөйле курсант булып укый башладым.

Бу «җөй» миңа гомерлеккә ябышты, соңыннан корабларда хезмәт иткәндә иптәшләрем дә үзара мине шул кушамат белән атап йөрттәләр иде... Әмма кайда гына яшәсәң дә, күпме еллар үтсә дә, туган-үскән җир гел истә була икән, төшләргә кереп йөдәтә икән. Шуңа күрә отставкага чыгу белән туган шәһәрем Чистайга кайттым, әтием-әниемнең чардуганын буяттым, сәдака биреп, ясин чыгарттым. Үләр алдыннан әни мәрхүмнең әйтеп калдырган васыяте шундый иде. Монда вакытны ничек тә тагын барып, каберләрен рәтләп кайтырга кирәк.

Ул кичне без караңгы каютада байтак гәп корып яттык. Башлыча Әюпгәрәй агай сөйләде. Минем дә тумышым буенча Чистайдан икәнлегемне белгәч, ул кинәт җанланып, гаилә тормышым, әнием турында кайта-кайта сораштыра башлады һәм сүз аралаш:

— Шулаймыни!.. Шулаймыни!..— дип, мине хәтта бераз гаҗәпкә дә калдырды әле.

## Хат һаман килми

«Баһадир»ның беренче класс салонын «клуб» дип йөртәләр. Кичләрен анда үзешчәннәр концерты, танцалар булгалый, телевизор карыйлар. Зур-зур тәрәзәләре шар ачылган, куәтле лампалар белән яктыртылган иркен салон төн уртасына хәтле шау-гөр килеп тора.

Бирегә килгәннән соң атна-ун көн чамасы үткәч, бер кичне клубка мин дә кергән идем. Көндез эш киемнәреннән ничектер килбәтсез күренгән кызлар, егетләр хәзер бәйрәмчә киенгән-ясанганнар һәм күңелле музыкага җиңел хәрәкәтләр белән парлашып бөтереләләр. Аларга карап утыра торгач, мин дә күршемдәге коңгырт чәчле чибәр генә бер кызны танцага чакырдым. Сүз арасында мин аның Гөлбикә исемле икәнен, быел гына кулинария училищесын тәмамлап, бирегә өч кыз белән бергә пешекче булып килүләрен белдем. Танцалар бетеп, клубта ут сүнгәннән соң да, алар белән террасада беравык сөйләшеп йөрдек.

Көндезге вахта һәм танцалардан соң шактый арылганлыктан, бик тиз йокыга китәрмен шикелле иде. Мәгәр алай булмады, шыпырт кына

урыныма менеп яту белән, күз алдыма өйдәге хәл килеп басты, башта берсеннән-берсе күңелсез уйлар кайный башлады. Бигрәк тә Сәрвиназны үпкәләтүем өчен оят, аннан гафу үтенмичә, тынычландырмыйча китүем өчен уңайсыз. Әнинең әлегә тикле беркайчан булмаганча зәһәрләнүенең сәбәбе дә аңлашылмый, нәрсәнедер әйтеп бетерми. Һәрхәлдә, гадәттән тыш нидер булган. Кайту белән ачыкларга, бу ызгышка чик куярга кирәк, дигән карарга килдем мин.

Мәгәр безнең командировка башта уйлаганча ункөнлек кенә булмады. Чистай заводында районның үз баркасын ремонтлау озакка сузылачагы беленде. Димәк, безгә монда Кама суларын тагын байтак сукаларга туры киләчәк икән әле.

Эшләр болайга киткәч, мин өйгә кайтуны көтмәскә булдым, ялгышлык белән ычкындырган дорфалыгым өчен Сәрвидән кичерүен үтенеп, аны да, улым Мансурны да бик сагынуымны, еш кына төшләремдә күрүемне әйтеп хат язып салдым.

Бу хатны җибәргәннән соң дүрт көн үткәч, почта йөртә торган «Метеор»ны ике күзем дүрт итеп каршылый, өйдән җавап көтә башладым. Кыенлык белән булса да, берничә тапкыр телефоннан шалтыратып та караган идем, кызганычка күрә, Сәрвиназның эштә юк чагы туры килде.

Шулай ут эчендә тагын бер атна үтте, ә җавап һаман юк та юк. Отыры борчуга төштем, көн саен өйгә бер-бер артлы хат яудыра башладым. Көтеп-көтеп тә һичнинди хәбәр килмәгәч, әллә ниләр уйлап бетердем. Ашым аш, йокым йокы түгел иде, тәмам авыруга сабыштым.

## Ихтирамлы дәвамчы

Ниһаять, түзәр хәлем калмады, капитан белән сөйләшеп, бер тәүлеккә өйгә кайтып килергә рөхсәт алдым. Шуның өстенә кием-салым да керләнгән, ашаган өчен түләргә янымда акчам да юк иде. Әюпгәрәй агайга рәхмәт, үтенечемне кире какмады, сәбәбен сораштырып казынмады. Каш өстемдәге миңемә күзләрен текәп карады да:

— Соңга калма, әйткән вакытка кайтып җитәргә тырыш,— дип, якыннарча җылы сүз әйтеп озатып калды.

Азалия иртән ашханәдә, юлга ашыгуымны белү белән, мине конторкасына алып керде дә, кулыма зур гына сумка тоттырып:

— Менә, Миләүшә апайга аз гына кучтәнәч әзерләп куйган идем,— диде.— Монда күчеп киткәннән бирле күргән дә юк үзен, миннән күп итеп сәлам әйт... Җәйнең иң матур чагы бит, әйт үзенә: ничек тә вакыт табып, атна-ун көнгә безгә кунакка килсен. Бераз ял итеп китәр, эшләгән җирләрен күреп, исенә төшереп китәр.

— Шактый авыр икән бу, шул тиклем нәрсә соң монда?— дип гаҗәпләндем мин төенчекне кулыма алып.

— Юк, юк, һич тә авыр түгел... Анда нибары берничә банка икра, өсетер консервасы һәм һинд чәе белән шоколад кына. Телдән әйт үзенә: бер төргәген минем әнигә кертеп бирсен... Мондый йомышны теләсә кемгә ышанып булмый. Син, зинһар, авырсынма инде, алып кайта күр инде.

— Авырсынудан түгел, шул тикле деликатесны каян таптың дип әйтүем генә.

— Һи, каян таптың дип инде.— Азалия сәер генә елмаеп куйды.— Миләүшә апай мине кешедән кешене аера белергә, тормыш итәргә өйрәткән остазым бит ул. Пенсиягә чыкканда, начальство белән сөйләшеп, үз урынына мөдир итеп калдырды. Аның каршында мин гомерем буена түләп бетергесез бурычлымын.

Шул ук көнне кичкырын мин Чаллы белән Казан арасында йөри торган «Метеор»да Казанга кайтып төштем. Аннары үземнең шкиперда калдырган моторкама күчеп утырып, таныш юлдан су өсләп туп-туры Юдинога элдерттем. Чөнки вакыт тар, ашыгырга, бар эшне җайлап, иртәнге рейска өлгерергә кирәк иде.

Аракчино турыннан үткәндә су читендә уйнаучы балаларның трусик кына кигән берсе мине күрү белән кулларын болгарга тотынды, башка берәү белән бутап булса кирәк, хәтта абына-сөртенә яр буйлап бераз йөгереп тә барды. Шул вакытта мин, ярар, кайтып җиткәч, улым Мансур да мине шулай каршылар, дип уйлап куйдым.

Үзебезнең такта басма янына килеп туктаганда инде кояш батып барган вакыт иде, яр өстендәге өебезнең каралҗым күләгәсе вак дулкыннар өстендә тибрәнә. Бүтән көннәрне бу вакытта эштән кайтканда мине улым Мансур каршылый иде дә, һаман саен, әйдә, көймәдә йөреп кайтыйк, дип йөдәтә иде. Бүген ул юк. Мин кайтасын белми бит, уйнап арып, өйгә кергәндер. Басма янында карт өянке генә нәүмиз, уйга талгандай, су читендә бер ялгызы йокымсырап тора иде.

Тәрәзәләрдә никтер ут юк. Веранда ишеге бикле булгач, әни өйдә юктыр, дип уйлаган идем. Үз ачкычым белән ачып керсәм, ул өйдә булып чыкты, түр яктагы зур көзге каршында авыз эченнән нидер көйли-көйли бит очларын, күз төпләрен сыйпап утыра иде. Мине күрүгә ул ярамаган эш өстендә тотылгандай сискәнеп:

— Аһ, син кайттыңмыни?! — диде һәм куллары белән күкрәген каплый-каплый тиз генә үз бүлмәсенә кереп китте.

Өстәл өстендә буш аракы шешәсе, ике рюмка һәм ашамлык калдыклары. Күрше бүлмәдә әни ишетелер-ишетелмәс кенә нәрсәдер мыгырдый шикелле. Менә ул ефәк халатын киеп инде каушавыннан арынган хәлдә, һәрвакыттагыча ныклы адымнар белән үзе килеп чыкты да, ни өчендер акланган сыман:

— Билләрем сызлап тора... Бераз ярдәм итмәсме дип, мунчадан соң чак кына менә бу нәстәне капкан идем,— дип тиз генә өстәлдәге шешәне, рюмкаларны җыештыра башлады.— Үзең нихәл, бөтенләйгә кайттыңмы?.. Әбәү, сакал-мыегыңны күрми торам, йоннан төргән кебек булгансың.

Тегеннән Азалия биреп җибәргән күчтәнәчләрне әни бик шатланып кабул итте, рәхмәтләр әйтә-әйтә сумканы бушатырга тотынды. Шунда сервант өстендә яткан конвертлар күземә чалынды. Алып карасам, күрәм, барысы да мин җибәргән хатлар, берсе дә ачып каралмаган.

— Болар ник болай ачылмыйча ята? — дидем, бик аптырап.— Сәрвиназ белән Мансур кайда?

— Өйдә түгелләр, алар хәзер бездә тормый ич...— диде әни.

— Ничек инде бездә тормый? — Ник киттеләр, кая киттеләр?

— Анысын белмим, тәгаен генә әйтә алмыйм. Ул ләтчә синнән соң монда күп тормады, җилдән туган көчеген җитәкләде дә чыгып китте. Шуннан бирле күренгәне юк, ире өйдә юкта иркендә сөйрәлеп йөрүедер. Ул хәзер әтисе янында булса кирәк, беркөн шәһәрдән кайтканда поездда Аракчино хатыннарының шулайрак такылдавы колагыма чагылып калган ие.

Тегендә борчылуларым юкка булмаган, күңелем сизенгән икән. Шулай да бу тикле булыр дип уйламаган идем. Әнинең сүзләреннән кинәт миңгерәгәндәй, нишләргә белмичә аптырап калдым. Кузгалган ачуымны көч-хәл белән тыеп, сыкрану белән:

— Тагын дөньяга сыймагансың, харап иткәнсең икән...— дип кенә әйтә алдым.

— Әй, пүчтәккә борчылма сана...— диде әни, искитмәле берни дә булмагандай.— Олагуы хәерле, күптән шулай кирәк ие. Бүтән чакыра күрмә, эзе дә булмасын берүк... Дөньяда хатыннар беткәнмени. Синдәй бай иргә менә дигәне табылыр... Әнә, Азалиянең кай җире килмәгән. Тәсе-бите, уңганлыгы белән синең нәсел корткычың ише генә түгел. Шуңа өйләнерсең, йорт җанлы хатын рәхәтен күреп яшәрсең, ичмасам.

— Ни сөйлисең син, әни, нәсел корткыч булып Сәрвиназның безгә ни зыяны тигәне бар?

— Корткыч булмаса, Бәдретдин абыеңны эшеннән кудыртмас, контрольгә киләбез, сак тор, дип хәбәр итәр ие...

Әни Сәрвиназны әшәке сүзләр белән хурлап сөйли, шул арада әледән-әле күз кырые белән генә үз бүлмәсе ягына борчулы каранып ала... Чү, анда чынлап та ниндидер хәрәкәт бар бугай, ара-тирә нәрсәдер кыштырдый, уфылдап куя шикелле. Менә кемдер сулышы кысылгандай буыла-буыла кычкырып җырлый да башлады:

> Җырлыйк әле, җырлыйк әле, бал мичкәсе көенә;
> Яратмаса кайтып китсен анасының өенә...
>
> Алла биреп баесам, камалы тун тектерәм.
> Җә баермын, җә бөләрмен, бүгенгесен типтерәм...

Җырлаучының Бәдретдин абый икәнен мин беренче сүзләреннән үк танып алдым. Артыграк төшерде исә, ул һаман «Бал мичкәсе көе»нә шушы ике җырын мөгрәргә тотына иде. Бүген ул тәмам хәлдән тайганчы чөмергән булса кирәк, рәтләп сүзләрен дә әйтә алмый, тамагына төер тыгылгандай, әледән-әле гырылдап куя.

Менә ул яткан бүлмәдә ниндидер авыр нәрсә дөп итеп куйды һәм Бәдретдин абый ах-ух килеп ыңгыраша башлады. Әлегә тикле берни дә ишетмәмешкә салынып маташкан әни дә инде, бүтән яшеренеп тормастан:

— Ай, караваттан егылды бугай, имгәнмәгәе...— дип хафаланып бүлмәсенең ишеген ачты.

Бәдретдин абый, дөрестән дә, караватыннан егылып төшкән дә кулларын як-якка җәеп идәндә «бүгенгесен типтерәм»не мөгрәп ята иде. Без аны көч-хәл белән караватка күтәреп салдык. Әни аның өстенә ак җәймә япты, форточканы ачты, оялырлык берни дә булмагандай:

— Барысы да шуның аркасында...— дип тагын Сәрвиназны каһәрләргә тотынды.— Элек болай үк булмый ие, синең азгының эштән чыгарткач, кайгыдан башын югалтты, һаман эчә дә эчә...

И, тик хәзер генә шәйләп алдым, бу ыгы-зыгы белән күрми торам, бөтен өй эче, талап чыккан кебек, бушап калган ич: ян стенадагы бизәкле зур келәм дә, сервант тулы хрусталь савыт-саба да, төсле телевизор белән тегү машинасы да урыннарында юк иде.

— Нинди бөлгенлек бу, караклар баскан кебек... Син өйдә юкта Сәрвиназ төяп киттеме әллә?— дип шаккаттым.

— Юк, хәзергә аңа барып җитмәде әле, булмаганны әйтә алмыйм...— Әни як-ягына искәртүле каранып, тавышын акрынайта төште.— Шулай да Алла саклаганны саклармын дигән бит. Бәдретдин тотылганнан соң, тентү-опись булмагае дип, затлырак әйберләрне Азалиянең әниләренә кертеп куйган ием.

Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер, дип тикмәгә әйтмиләр, күрәсең. Әнә бит ничек, кәкре куллы булгач, калтырап яшәргә туры килә. Ә мин, күзле сукыр, нинди мохиттә яшәгәнемне дә күрмәгәнмен.

Мәгәр ара тар, минем монда озын-озак чуалырга вакытым юк. Иртәнге теплоходка хәтле Аракчинога барып, үземнекеләрне күрәсем бар бит әле. Артык зурга киткән бу низагны болай гына калдырып китеп булмый ич инде. Барыннан да бигрәк Сәрвиназны тынычландырырга, ничек тә күндереп, икесен дә өйгә кайтарырга кирәк.

Иртәдән бирле тамакка тәгам капканым юк иде, әнигә тиз генә берәр нәрсә әзерләргә куштым. Ул кухняда маташкан арада тиз генә юынып кырындым да, алмаш кием киеп, сабын-сөлге алдым. Монда күз көеге булып тормасыннар дип, бер уңайдан ачылмаган конвертлы хатларымны да сумкага салдым.

Иркенләп ашап-эчеп утырырга вакыт та, теләгем дә юк иде. Кан кайнаган чак, кызулык белән берәр ахмаклык эшләп ташлаганчы дип, бу бозыклык оясыннан тизрәк чыгып китәргә ашыктым. Әни бүлмәсе турыннан үткәндә эчке яктан сәрхүш Бәдретдин абыйның йокы аралаш көчәнә-көчәнә «Бал мичкәсе көе»нә мөгрәве ишетелеп калды.

## Сәрвиназ

Тыштa инде төн уртасы. Куе томан төшкән. Су өстендәге маяклар, елга аръягындагы утлар, ерак галәм җисемнәре кебек җемелди. Аргы якта бер теплоход, томан таралганны көтеп, якорьда тора булса кирәк, сузып-сузып гудок кычкырта. Югыйсә, мондый томанда башка бүтән судноның килеп бәрелүе бик ихтимал.

Әмма мин томан таралганны көтеп тора алмыйм. Суднолар йөртү кагыйдәсен бозып булса да, тәвәккәлләп кузгалдым һәм көндез дә, төннәрен дә күп тапкырлар йөрелгән таныш юлдан саклык белән йөзеп китеп бардым.

Зариф бабайлар әле йокларга ятмаган бугай, елгага караган тәрәзәләренең берсендә ут бар. Әкрен генә шакуга өйалдында ут кабынды, мин икәнне белгәч, ишекне Сәрвиназ ачты. Әлерәк кенә башын юып, сөртенгән чагы булса кирәк, иңендә ак сөлге, чәче юеш.

Бер-беребезне сагынып эштән кайткач, гадәттә, Сәрви мине якты йөз белән каршылый иде, өйдә икебез генә булганда җиңелчә әп итеп тә ала торган иде. Бу юлы алай итмәде, елмаймады да. Күрәм, аның үзен тотышында моңарчы төсмерләнмәгән яңа чалым бар, ничектер күзгә туры карамый. Төскә-биткә дә сизелерлек үзгәргән: күз карашы моңсу, яңаклары суырыла төшкән. Кыйгач кашлары арасында күренер-күренмәс кенә җыерчык сызыгы хасил булган. Мине күрүгә әллә ни исе китмәде шикелле. Гадәттәгечә елмаеп каршы алмады. Алгы бүлмәгә кергәч сөлгесен чөйгә элеп куйды да:

— Түр якта әти белән Мансур йоклый, шунда гына сөйләшик,— дип өстәл янындагы урындыкка күрсәтте, үзе каршыга утырды. Беравык сүзсез утырганнан соң ризасызлык белән:

— Инде төн уртасы бит, ничек болай соң киләсе иттең?— диде.

Мин бу очрашуны бөтенләй башкача күз алдыма китергән идем, тегендә төннәр буе йокламыйча борчылуларымны әйтергә җыенып, кара гайбәт аркасында арабызда туган салкынлыктан арынырга өметләнеп кайткан идем бит. Аның шул тикле илтифатсыз каршылавыннан тел очымдагы җылы сүзләрем, җил алгандай, юкка чыкты, ирексездән күңелемдә шик кузгата башлады. Әни дөрес әйтә, күрәсең, ул миннән тәмам бизгән, күзгә туры карап сөйләшми дә, дип уйлап куйдым... Шулай да эчемдәге сиздермәскә тырыштым, мөмкин кадәр сабырлык белән:

— Ни булды сиңа, кеше күлкәсе ясап, ник өйдән чыгып киттең?— дип сорадым.

— Юк, үзем китмәдем, алар куып чыгарды мине,— диде Сәрвиназ.— Ул кичне Бәдретдин абый бик исереп килгән иде, башта шул тиргәп бәйләнде. Аннары, дары кебек кабынып, әниең ташланды, әллә ниләр әйтеп хурлап бетерде.

— Бәдретдин абый эшенә ник тыгыласың? Әләкләмәгән булсаң, сиңа беркем дә тимәс иде.

— Һич алай түгел, минем һичкемнең эшенә тыгылганым да, әләкләгәнем дә юк,— диде Сәрви, күзгә туры карап.— Дөресе нә болай булды аның: палаталарда авырулар ачлы-туклы утырабыз, ашларның тәме юк дип шаулый башлагач, профком кушуы буенча контроль группасы төшке аш вакытында ашханәдә тикшерү үткәрде. Нәтиҗәдә, кухняда Бәдретдин абый салып биргән һәр порциядә ит нормадан ким чыкты. Шуның өстенә кухня суыткычында аның сумкасына салып куелган ике килодан артык ит, ике пачка атлан май табылды. Ул инде моңарчы бер эләккән булган, шуның өчен эшеннән чыгардылар... Кызганычка каршы, контроль группасында мин дә бар идем, шунлыктан Бәдретдин абый каршында мин гаепле булып калдым: тикшерү киләсен берничә минут кына алдан шалтыратып хәбәр итсәм дә, беркем һичнәрсә сизмәячәк, барысы да шома гына үтеп китәчәк иде дип, мине таларга тотындылар.

Мин, акыллы баш, күп уйлап тормастан:

— Чынлап та, ник хәбәр итмәдең? — дип әйтеп ташладым.

Бу сорау Сәрвиназга сәер тоелды бугай, колакларына ышанмагандай, бермәл гаҗәпләнеп карап торды да:

— Андый уй ничектер башыма килмәде,— диде.— Минем урында булсаң, син нишләр идең, хәбәр итәр идеңмени?

— Минме, синең урыныңда булсаммы?.. М-мин..— дип ык-мык килеп, сүземне әйтеп бетерә алмыйча, уңайсызланып калдым. Миңа эсселесуыклы булып китте, кызаруымны сиздем.— Шулаймыни... Алайса теге чакны ул якларын мин күреп бетермәгәнмен. Син дә ачык итеп әйтмәдең,— дидем, акланырга теләп.

— Һи, ул кичне син әйткәнне тыңларлык түгел идең шул, авызыңа су капкан кебек, иреннәреңне турсайтып, сүзсез утырдың. Баланың беркатлы соравына: Азман абыеңның безгә кайчан килгәнен әнә әниеңнән сора, бәлкем, ул белә торгандыр дип әйткәнеңне оныттыңмыни?..

— Юк, онытмадым... Андый сүзне тиктомалдан ничек әйтеп ташлавымны хәзер дә һич башыма сыйдыра алмыйм, бик үкенәм. Күңелеңдә үпкә саклама, зинһар, кичер. Һич тә сине кимсетергә теләп әйтмәгән идем. Үзең дә беләсең, мин андый кеше түгел...

— Кайчандыр беләм шикелле иде, ышана идем... Әмма белеп җиткермәгән, күрәсең...

— Ялгышасың, бер дә алай түгел, кичер мине. Болай ярамый, әйдә хәзер үк кайтарып куям үзегезне.

— Ялварып сорама, ул комсызлар янына мин бүтән аяк басачак түгелмен.

Үгетләп-үгетләп тә күндерә алмагач, мин аңа:

— Алайса әйдә болай итәбез: мин үзем сезгә күчеп киләм. Монда бергә яшәрбез, мин синсез тора алмыйм,— дип кинәт башыма килгән яңа ниятемне әйттем.

Минем уйлавымча, Сәрвиназ моңа каршы килмәскә тиеш, элегрәк шундый фикерне берничә тапкыр үзенең дә әйткәне бар иде. Хәзер исә ул берни дә ишетмәгән сыман, үз уйларына чумган хәлдә битараф чырай белән сүзсез утыра бирде. Бу минутта ул безнең өйдән, холыксыз әнидән генә түгел, минем үземнән дә бизгән, тәмам суынган кебек тоелды. Үзе телдән әйтмәсә дә, мин моны күңелем белән сиздем һәм, суга бата башлаган кеше саламга тотынган кебек, безне бер-беребезгә бәйләүче йөрәк парәбез булуын искәртү теләге белән:

— Мансур нихәл йөри, мине телгә алгалыймы? — дип кызыксындым.

Сәрвиназ күзләрен һаман каядыр читкә төбәгән хәлдә:

— Ни булсын аңа, көнозын бабасы белән йә бакчада казыналар, йә су буенда кармак салып утыралар,— дип теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды.

Улымның мине телгә алу-алмавы турында берни әйтмәгәч, йөрәгем ачынды:

— Мансур мине шулай бик тиз онытты микәнни, бер дә искә алмыймыни?— дип кабат сорадым.
— Искә алмаган кая ул, телендә һаман син генә... Су өстендә мотор тавышы ишетелсә, әти түгелме дип, тәрәзәгә ташлана. Ә бүген кичкырын безнең турыдан үткәнеңне күргәч, ут чыккандай атылып керде дә, әти кайтты, әти... Әйдә аның янына,— дип шашына башлады. Көчкә тынычландырып йоклата алдык.
Кара син аны, таныган икән балакаем, мин сезнең турыдан үткәндә яр буеннан миңа кул болгап калучы шул булган икән ләбаса. Яшермим, моны белү йөрәгемә май булып ятты.
Минем шатлыгымны уртаклашкандай, нәкъ шул мәлне ябылып бетмәгән ишек аша түр яктан улым Мансурның йокы аралаш:
— Ур-ра, безнең көймә... Әти кайтып килә...— дип кычкырганы ишетелде, улым мин монда дип, аның янына атылып керүдән чүт тыелып калдым.
Сәрвиназ халәтемне сизде бугай, тиз генә барып, ишекне кысыбрак япты. Аннары стенадагы сәгатькә карап:
— Таң атарга да күп калмаган...— диде.— Иртән эшкә барыр алдыннан бераз черем итеп алырга кирәк. Бар, сиңа да вакыттыр инде.
Аның сүзләрен раслагандай төнге тынлыкны бозып, өй артындагы кетәклектә таң әтәче кычкыра башлады. Көнчыгышка караган ян тәрәзәдә дөрестән дә караңгылык сыегаеп килә иде. Миңа юлга кузгалыр вакыт җитте.
Сәрвиназ мине озата чыкты. Караңгы өйалдында мин аны кулыннан алып:
— Сәрви бәгырем, син бер дә болай түгел идең ич,— дидем өзгәләнеп.— Мин тегендә синең өчен ут йотып, төннәр буе рәтләп йокламыйча борчылып, сагынып кайттым. Шулай бер генә җылы сүз дә әйтмичә җибәрәсеңмени?.. Нишләвең бу, һич аңламыйм...
— Хәзерге вакытта нишләвемне үзем дә белмим, башым тәмам түнгән...— диде Сәрвиназ, күз яшьле тавыш белән.— Син дә мине аңларга тырыш: түзмәдем түгел, алты ел түздем, бүтән тәкатем калмады. Тәмам җаным бизде, ул якка борылып та карыйсым килми.
Өй эченнән Зариф агайның картларча буылып йөткергәне ишетелде.
— Ярар, болай аяк өсли генә сөйләшә торган сүз түгел бу. Бар, хәерле юл сиңа...— дип, Сәрвиназ минем артымнан өйалды ишеген ябып калды.
Сагынып кайткан хатынымнан бер генә җылы сүз дә ишетмичә, улымны да күрмичә, тагын да авыррак уйларга чумган хәлдә кире китәргә мәҗбүр булдым.

## Кадерен белмәдем

Гомер булмаган хәл, юлда моторым сүнеп кәҗәләнде, аны рәтләп маташып, иртәнге рейска чүт соңга калмадым. Мин портка төшеп җиткәндә иртәнге «Метеор» инде пассажирларны кабул итеп бетергән, чалкаларын ычкындырып, ашыкмый гына юлга кузгала башлаган иде. Йөгереп килгән шәпкә теплоходның койрык ягына башта сумкамны ыргыттым, аннары причал култыксасы аша тиз генә атлап чыгып, үзем сикердем. Шунда мин дебаркадер кырыенда кулын болгап кемнедер озатучы бөдрә чәчле яшь кенә бер ханымны ашыгычлык белән чүт бәреп екмадым һәм теплоход палубасыннан гафу итүен үтенеп башымны идем. Чөнки мин кеше алдында тиргәп кызартыр дип уңайсызланган идем. Әмма киң күңелле икән, ачуланмады, хәлемә кергәндәй, сизелер-сизелмәс елмаеп, бармак кына янаган булды.

Теплоход халык белән шыгырым тулы. Шулай да салонның сул як ишеге янында бер буш урын табылды. Шунда утырган хәлдә йокымсырап барганда янымдагы сумкамны кемдер тарткан кебек тоелды. Күтәрелеп карасам, техникумда минем белән бер группада укыган сабакташым Петр Некрасов шаярта булып чыкты. Шушы теплоходта механик ярдәмчесе икән, шундук үз каютасына алып керде. Эше тыгыз вакыт иде, озак сөйләшеп утыра алмады. Исәнлек-саулыкны белешкәннән соң, миңа һичнинди тартынусыз урнашырга әйтте дә, үз эше белән машина бүлегенә төшеп китте.

Бу Некрасов безнең группада укуда барыбыздан алда баручы булды, шуның өстенә ике ел эчендә үзлегеннән саф татарча сөйләшергә өйрәнде. Тик шунысы бераз сәер, кәефе начар кеше кебек, һәрвакыт караңгы чырайлы, аз сүзле, акрын кыймылдаучан иде. Хәзер аны тиз генә танырлык та түгел: шатлыгы эченә сыймаган кеше кебек, ачык йөзле, җиңел хәрәкәтчән һәм уенчан булып үзгәргән иде.

Кичәдән бирле аяк өсли йөрүдән һәм берсеннән-берсе күңелсез кичерешләр арасында бик арыган идем. Җиңелчә тамак ялгап, чәйләп алгач, ятып бераз черем итәргә булдым. Шунда караватт белән янәшә тумбочка өстендә Некрасовның бөдрә чәчле бик тә чибәр яшь хатын-кыз белән башын башка куеп төшкән фоторәсеме күземә чалынды. Былтыр бугай, мин аны өйләнгән дип ишеткән идем, хатыны шушы ерык авыз булса кирәк. Рәсем астына кызыл кара белән: «Гомергә бергә» дип язылган, икесе дә кул куйган, йөзләрендә сөю-сөелү шатлыгы балкый. Шунда мин бу бөдрә чәчбинең бая причалда миңа бармак янаган хатын икәнен танып алдым.

Их, без дә болардан ким түгел идек, күзгә-күз карашып кына яши идек ич. Әлеге дә баягы һаман шул минем ваемсызлыгым, адым саен бәйләнү, җәберләрдән яклый белмичә, Сәрвиназымны үзем биздердем.

Шулай да арыганлык үзенекен иткән иде, авыр уйларга чумып ята торгач, оеп киткәнемне сизми дә калганмын...

Күпме йоклаганмындыр, белмим, бермәлне саташулы төш күреп уяндым. Сабый бала чагым, бик зур залда тимер караватта утырам имеш. Як-ягымда рәт-рәт тезелгән тимер караватларда да минем ише мескен нәниләр җанәрнеткеч ачы тавыш белән елый-елый кычкыралар:

— Әнием, мине монда калдырма...

— Өйгә кайтасым килә...

— Су бирегез, әчәсем килә...

Алар белән бергә мин дә шыңшыйм. «Әнием, мине тизрәк ал, монда каласым килми»,— дип кычкырып елый башладым һәм шул вакыт уянып киттем.

Бактым исә, әйләнә-тирәмдә һичнинди бала-чага да, ак халатлы сестралар да юк. Каршымда каюта хуҗасы Некрасов өстәл янында чәй эчә-эчә газета караштырып утыра. Минем аңгы-миңге уянуым аңа сәер тоелса кирәк:

— Тынгысыз йокладың, шау-шулы төш күрдең бугай, берничә тапкыр кычкырып кемгәдер эндәштең,— диде, термостан чәй салып, өстәл янына чакырды.

— Әйе, бик сәер һәм чын тормыш белән һичнинди бәйләнеше булмаган төш күрдем,— дип үзем дә гаҗәпкә калдым.— Хәтерлисеңдер, техникумда физиология укытучысы безгә кеше төштә өнендә башыннан кичергән хәлләрне күрә, дип сөйләгән иде. Ә менә мин моны чынлыкка туры килми дип саныйм... Тукта, авыз ерма син... Чөнки минем беркайчан ятим сабыйлар йортында булганым юк, әмма бала чакта үземне шунда итеп еш төштә күрәм. Менә хәзер дә шунда елап яткан җирдән уяндым.

Некрасов мине игътибар белән тыңлаган кебек булса да, ара-тирә күз чите белән тумбочка өстендәге фоторәсемгә елмаюлы карап ала иде. Менә ул мин тынып торган бер арада:

— Ихтимал, шулайдыр, син әйткәнчәдер,— диде, көтмәгәндә күңелле кәмиткә юлыккан кеше кебек елмаеп.— Ярар, хәзергә катлаулы фән дөньясын калдырып торыйк. Дусларча дөресен генә әйт әле, сиңа ни булды? Ничектер үзгәргәнсең, күз карашың сагышлы... Күңелсез күренәсең, шуңа соравым.

Өйдәге ызгыш-талаш күңелле хәбәр түгел, аны теләсә кемгә әйтеп булмый бит.

— Бик алҗыган чагым, шунлыктандыр,— дип икеле-микеле җавап бирдем һәм Некрасовның үз хәл-әхвәле белән кызыксындым.

Ул исә шуны гына көтеп торган кебек, үзенең эше, быел институтка керергә әзерләнүе, тиздән бәби көтүләре турында җанланып сөйләп китте һәм сүз арасында тагын берничә тапкыр хатыны рәсеменә кайгыртучан күзләре белән карап:

— Исән-сау котыла гына күрсен, берүк,— диде.

Эчендә җаны булган мәнле кеше хатыны турында әнә ничек кайгырта, аның өчен ут йотып йөри. Ә мин, туң йөрәк, Сәрвиназымны һәртөрле җәберләү, кимсетүләрдән яклап, вакытында канат астыма ала белмәдем.

## Әюпгәрәй агай ник дулкынлана?

Сүземдә тордым, төнге вахтам башланырга өч сәгать кала мин гравий чыгару районына барып җиттем. Әюпгәрәй агай инде борчыла башлаган булса кирәк, мин каютага барып керүгә җөйләямаулы йөзе яктырып китте:

— Менә шәп булган, әйткән вакытка кичекмичә кайтып өлгергәнсең,— диде һәм, мине күздән кичергәннән соң, кинәт сагаеп калды:— Чү, ни булды сиңа? — Төсең качкан, каты авырудан терелеп, яңа гына аякка баскан кешегә охшап калгансың...

Гөнаһ шомлыгы, юлда килгәндә механик Некрасов та әйткән иде. Менә тагын шул. Шифоньер ишегендәге көзгегә карагач, үзем дә аптырап калдым: бер тәүлек эчендә сизелерлек ябыкканмын, яңак сөякләрем калкып тора, борчылуларым йөземә чыккан иде. Ихтыярсыздан авыр көрсенеп куйдым.

Әмма бу болай аяк өсли берничә сүз белән генә әйтә торган хәл түгел. Әюпгәрәй агайның соравына, берни дә булмагандай, күтәренке кыяфәт белән:

— Зыян юк, Әюп агай, шактый арыдым, шуның галәмәтедер... Фәкать шул гына, ял иткәч үтәр-китәр,— дип күңелсез әңгәмәдән котылырга тырыштым.

Вахтага чыкканчы тамакка кабып, юлдан соң, аз гына булса да ял итеп алырга кирәк иде. Әюпгәрәй агай да әле ашамаган икән, ашханәгә бергә төштек. Азалия мине күрү белән алтын тешен җемелдәтеп:

— Әле кызлар әйткәч кенә белдем, Таһир кайткан ич...— диде, төче телләнеп.— Әйбәт йөреп кайттыңмы?.. Минем әманәтемне тапшырдыңмы үзенә?

Бу артык төчеләнеп елмаю беркөн әнинең: «Әнә Азалиягә өйләнерсең, кай җире кемнән ким»,— дип әйткән сүзләрен хәтерләтте. Моны Әюпгәрәй агай да сизгән булып чыкты, ашап-эчеп каютага менгәч:

— Бу Азалиянең сиңа күзе төшкән, ахры, чамасыз чытлыклана,— диде шаяртып.— Карале, ул кайгыртучанлык күрсәтеп сораштырган хатын аның кеме, туган-тумачасы түгелдер ич?

— Юк, туган-тумачасы түгел, ә остазы, эшкә өйрәтүчесе. Минем әнием ул.

— Синең әниең шундый остаз кешемени?

— Әйе, Азалиянең остазы булган кеше... Аңа ник шаккаттыгыз әле?

— Шаккатудан түгел... Бер таныш хатынны хәтерләтте, шуннан гына әйтүем...

Әюпгәрәй агай күзләрен миңа төбәгән хәлдә хәрәкәтсез калды, кинәт дулкынланудан иреннәре генә дерелдәп куйды. Әмма ул моны сиздермәскә тырышты бугай, шундук үзен кулга алды, җиңелчә елмаю белән:

— Ә-ә, алай-й икән, ихтимал, бик ихтимал...— диде, үзалдына уйлангандай. Аннары сүзне икенчегә борып җибәрергә теләгәндәй:— Азалияне әйтәм, чытлыкланучан булса да, яхшылыкка игелек кайтара белә икән. Беркөн судан коткарган өчен миңа да очраган саен рәхмәт әйтә, ашханәгә керсәм, калҗаның тәмлесен үзе салып биреп, мине кеше алдында уңайсыз хәлгә куя.

— Әни Азалиянең уңганлыгын училищедан килгәч тә күргән, канаты астына алып шомарткан. Пенсиягә чыгар вакыт җиткәч, үз урынына аны ашханәдә мөдир итеп калдырган.

— Алай икән, тәрбияләп үстергән тугрылыклы дәвамчысы икән,— диде Әюп агай.— Ярар, алар калып торсын әле. Йә, үзең ничек йөреп кайттың? Өеңдә нихәлләр, иминлекме?

— Юк, Әюпгәрәй агай, кызганычка каршы, хәлләр имин түгел,— дидем.— Мин монда вакытта хатыным малайны җитәкләп, Аракчинога әтисе янына кайтып киткән.

— Ничек инде кайтып киткән, шулай ярыймыни?! Хатының кызу канлымыни? Әллә чынлап җитди сәбәбе бармы?

Монда бергә булган кыска гына вакыт эчендә безнең арада инде җылы мөнәсәбәт урнашкан иде; мин Әюп агайны рәсми начальнигым булудан бигрәк, кеше хәлен аңлый белүчән киң күңеллелеге өчен якын туганым кебек үз итәм, аның белән аралашудан җан азыгы табам. Шуңа күрә һични яшермичә, өйдә һәрдаим сизелеп торган киеренкелекне, әнинең Сәрвиназны күрәлмавын, адым саен төрлечә бәйләнеп җәберләвен — һәммәсен сөйләп бирдем.

Әюп агай игътибар белән тыңлады, мин туктагач, ямаулы битләре тартышып куйды, кашлары җыерылды. Беравык сүзсез утырганнан соң, күңеленнән кичергәндәй:

— Эшләрең шәптән түгел икән,— диде сузып кына.— Әниең алай бик зәһәрле булгач, бераз тыярга, хатыныңны якларга кирәк булмады микән?.. Әллә араларына тыгылып, вакланырга теләмәдеңме?

— Әйе, шулайрак булды, игътибар җитмәде, хатынны яклый белмәдем.

— Ху-у-ш, әниең шулай булсын ди... Ә әтиең ничек? Әллә ул да синең кебек, салкын канлымы, бу хәлгә битараф караучанмы?

Әюпгәрәй агай бу соравы белән минем бик авырткан җиремә кагылды, ни әйтергә дә белмичә аптырап калдым. Чөнки мин әтисез үскәнмен, аның кем икәнен, исемен-фамилиясен дә белмим. Әнинең әйтүенә караганда, ул бик җәнҗалчы, вөҗдансыз кеше булган, миңа ике яшь чакта безне ташлап китеп, кайдадыр еракта эзсез югалган. Берничә ел үткәннән соң, пожар вакытында янып һәлак булган бугай.

Бер башлагач, уңайсыз булса да, Әюпгәрәй агайга боларын да сөйләргә туры килде. Башта тыныч кына тыңласа да, ул тиздән гадәти сабырлыгын югалтып, түземсезлек белән: «Шулаймыни, йә, йә, шуннан, аннары ничек?» — дип ашыктыра-ашыктыра сөйләтте, үзенә урын тапмагандай, ишекле-түрле иләс-миләс йөренә башлады.

## Безне эзәрлекләделәрме?

Баркас командасы яңа урынга бик тиз ияләште. Тик мин генә тынгысыз, миңгерәү балык кебек, кая барып бәрелергә белмичә каңгырып йөрим.

Башта бу буталчык нигез, минемчә, болай зурга китмәс. Сәрвиназ белән рәтләп сөйләшкәч, барсы да җайланыр кебек иде, шул өмет белән юанып йөргән идем. Чынлыкта киресенчә килеп чыкты, томанлы диңгездә калган ишкәксез көймәче кебек, гаҗизлеккә төштем. Ашым — аш, йокым — йокы түгел, эренле шеш сыман, җанны һаман бер хәсрәт тырнап тора.

Шуның өстенә бу арада эшнең дә рәте-чираты юк, кәнитил арты кәнитил туып тора, бигрәк тә төнге вахталар ыгы-зыгылы үтә. Узган төнне эштән бушрак арада бераз һава алыйм дип өскә күтәрелсәм, нинди дер тар елга тармагында, әрәмәле яр буена бәйләп куелган кечерәк кенә агач баржа янында торабыз, имеш. Палубасында бозау хәтле зур эт ачулы ырылдап арлы-бирле йөренә. Алгы якта кемнәрдер берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра баркаска нәрсәдер төйиләр. Караңгыда кемнәр икәнен, нәрсә төягәннәрен рәтләп күрергә өлгермәдем, баржа палубасыннан карлыккан тавышлы кемдер:

— Әй, «Зөя» баркасында... Бар, тизрәк ычкыныгыз...— дип кабаланып кычкырды.— Әнә үрге яктан шикле ут якынайганы күренә, балык инспекторы яки милиция булмагае... Әгәр куып җитеп төпченә башласа, телеңне кыска тот: сез монда булмаган, мин сезне күрмәгән... Тагын менә нәрсә: Азалия чибәркәйнең исенә төшер әле: саранланмасын, котырган үгез сөтен күбрәк җибәрсен, бездән эш тормас диген...

Безнең баркас рубкасыннан штурман Артур сагаеп кына:

— Аңлашылды, әйтермен... Тизрәк чалканы ычкындыр, без шылыйк,— дип җавап кайтарды һәм машинаны эшләтә башларга команда бирде.

Без, кузгалу белән, зур тизлектә китеп бардык. Чалулы юлдан барган чана кебек, баркас әле уңга, әле сулга ташлана, елга төбенә бәрелеп, бөтен корпусы белән сикереп-сикереп куя. Сигнал утларыбыз сүндерелгән. Бая баржа янында торганда утлары күренгән теге шикле судно гудок кычкырта-кычкырта һаман эзәрлекләп килә, менә-менә куып җитеп, койрыкка басар шикелле.

Шулай да ул куып җиткәнче, без кысан елга тармагыннан Кама киңлегенә чыгып өлгердек һәм төнге рейдта мәш килгән күпсанлы суднолар, гравий чыгару агрегатлары, йөзмә краннар арасында эз югалтып, эзәрлекләүчеләрдән җиңел котылдык.

Тиздән без хәвеф-хәтәрсез базага кайтып җиттек. Инде төн уртасы үткән булуга карамастан, ашханә мөдире Азалия безне көтеп торган, күрәсең. Баркас «Баһадир» янына барып туктауга ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Кайттыгызмы, булдымы?..— дип каршылады һәм, кладовой ишеген ачып, йөкне бушатырга урын күрсәтте.

Рулевой, сыек гәүдәле сузан егет Харитон, балык тулы капчык күтәреп чыкканда аягы таеп егылды. Әгәр шунда мин тотып калмасам, капчыгы белән бергә үзе дә ике судно арасына барып төшәчәк иде. Бу балык бер капчык кына түгел, шактый күп булып чыкты, рубкага менә торган тимер трап астындагы кәрзиннәр дә балык белән тулы иде.

Азалия кесә фонаре яктысында мине күрүгә, бу нинди артык күз дигәндәй, кинәт аптырап калды. Штурман Артур аны шундук аңлады булса кирәк:

— Ой, бирергә онытканмын, менә балыкка квитанция,— дип Азалиягә кәгазь кисәге сузды.— Балык ашарга барыбыз да яратабыз, әйдәгез, бушатырга помогать итәргә кирәк.

Дөресен әйтим, башта миңа монда ниндидер кыек эш, урлашу бар кебек тоелган иде. Әмма ялгышканмын, юкка шикләнгәнмен. Ашханәгә дип законлы рәвештә алганнар бугай, әнә квитанцияләре дә бар бит. Өчәү бергә без балыкны кладовойга тиз ташып бетердек, бер уңайдан палубада калган пычракны да швабра белән сөртеп чыгардык. Бар эш тәмам булгач, штурман Артур безне алгы кубрикка дәшеп алды:

— Тырыш хезмәт өчен Азалия безгә менә нәрсә бирде,— дип өстәлгә үгез рәсемле бер шешә аракы, ярты кирпеч икмәк һәм каклаган өч балык, өч пачка сигарет куйды.

Ул үзе инде авыз итеп өлгергән, тукмак борыны сизелерлек кызара төшкән иде. Моңарчы ничек күрмәгәнмендер, бу минутта ул бик тә Бәдретдин абыйга охшаган, нәкъ аның кебек итеп, тел очы белән әледән-әле аскы иренен ялап ала иде. Аракыны стаканнарга бүлеп салды да: «Тотыгыз, әйдә, чәкешми генә күтәрик»,— дип чөмереп куйды, һәм теш-ләре белән балыгын ботарлый башлады. Аның ярдәмендә эчүгә остарып өлгергән Харитон да стаканын бер тында чәйкәлтеп җибәрде. Эчмичә балык капкалап утыруыма башта кырын карасалар да, азактан урталай бүлеп, алар минем өлешне дә бушаттылар.

Шуның белән дөньялары түгәрәкләнде, телләре чишелде. Азалиянең эш йөртә белүен, чибәрлеген мактый-мактый сигарет көйрәтергә тотындылар.

Ә мин һаман үзебезнең караклар кебек кемнәндер куркып качуыбызның сәбәбен һич төшенә алмыйм. Юкса, төягән балыкка документ та бар шикелле бит. Аптырагач, әллә һичнинди куучы булмады, миңа шулай тоелды гынамы, дип уйлап та куям.

## Тау белән тау очрашмаса да...

Гадәттә, мин төнге вахтадан бушаган көннәрне сәгать унбердә уянып, төшке ашка хәтле физзарядка ясарга, коенып, кырынып алырга өлгерә идем. Бүген күбрәк йоклаганмын, инде ашханәгә төшәргә вакыт җитеп килә иде. «Ах, син йокы капчыгы, шул тикле урын өстендә аунап ятырга ярыймыни...» — дип үземне җиңелчә тиргәп алдым.

— Таһир туган, кемне битәрлисең син анда? — дип аста Әюпгәрәй агайның сөйләнгәне ишетелде.

— Юк, беркемне дә түгел, үземне генә...— дидем һәм, өлкән кешене көттермәс өчен, тиз генә юынып өстемә киенә башладым.

Әюп агай өстәл янында нindидер пичәтле кәгазьләр карап утыра иде. Мин торуга ул аларны тиз генә җыеп, курткасының куен кесәсенә салды. Нидер эзләгәндәй, эш киемнәре шкафын ачып иснәнә-иснәнә:

— Фу, менә моннан икән... Борынга балык исе бәреп керә, синең эш костюмыңнан бугай,— диде.

— Әйе, шуннандыр... Төнлә ашханәгә алып кайткан балыкны бушатуда булышкан идем, мөгаен, шуның иседер,— дидем.— Монда каютаны сасытып тормасын, тышка чыгарып, җилләтергә кирәк булыр...

— Туктале, нинди балык ул, кайдан алдыгыз? — дип Әюпгәрәй агай күзләрен миңа текәде.

— Бигрәк инде сез... Машина бүлегеннән торып, аның кайдан, кемнән икәнен мин ничек белим. Ул хакта штурман белә торгандыр, бик кирәксенсәгез, аннан белергә мөмкин.

— Юк, әлләни кызыксынудан түгел... Беркөн син юкта гражданский киемнән бер милиционер килгән иде. Моннан ерак түгел, аргы яктагы иске елга утравындагы балыкчылар базасына нindидер судно иялашкан ди. Кемнәрдер аракы, самогонга алмаштырып, капчык-капчык балык, тозлы икра төяп китәләр икән. Милиционер шуны эзләп килгән, берәр шикле судно күрмәдегезме, дип сораштырды.

— Ул җәһәттән шикләнмәскә мөмкин. Хәер, башта миңа да бераз шикле тоелган иде. Әмма ялгышканмын, законлы рәвештә яздырып алынган булып чыкты, квитанциясен үз күзем белән күрдем.

— Алайса бүтән сүзем юк,— диде Әюп агай.— Безнең команданы оятлы итәрлек булмасын дип әйтүем генә.

Балык караклары турында сүз белән мавыгып, көндезгә ашка соңга кала язганбыз ич. Без ашханәгә барып кергәндә инде бар халык ашап-эчеп эшкә таралган, ян тәрәзә катындагы өстәлдә безнең штурман Артур белән рулевой Харитон гына чәйләп утыралар. Бераз кәефләнеп өлгергәннәр бугай, битләре кызарган, өстәл астында буш шешә ялтырап тора. Безне күрүгә сәлам бирделәр дә, авызларын сөртә-сөртә тизрәк чыгып юк булдылар.

Тик шунысы сәер — зур бәйрәмгә әзерләнгән кебек, бүген бөтен ашханә ялт иткән. Өстәлләргә зәңгәр чәчәкле яңа клеенка җәелгән, стакан белән кәгазь салфетка, матур-матур фарфор савытларда тоз, борыч, горчица куелган, юынгыч янына бизәкле тастымал эленгән. Залдан прилавка белән генә аерылган кухняда ашчы хатын-кыз тыз-быз килә. Кыска ак халат кигән Азалия касса янында көндезге керемне саный булса кирәк, чут төймәләрен чалт-чолт салып утыра. Әйтәсе дә түгел, бик тә тырыш, бик тә уңган: ашханәдә мөдир генә түгел, кладовойчы да, кассир да — барсына өлгерә, барсы да аның кулында.

Безне күрүгә аның җитди чырае яктырып китте. Акчаларын тиз генә касса ящигына салып бикләде дә:

— Хуш киләсез, менә монда рәхим итегез,— дип түр почмактагы өстәлгә күрсәтте, аннары кухня ягына борылып:— Әй, Гөлбикә җаным, Әюп агай белән Таһирга ашарга китер... Аны кара, өсетер ухасына яшел суган салырга онытма,— диде.

Быел гына кулинария училищесын тәмамлап килүенә карамастан, һәр эштә Азалиянең уң кулы булып өлгергән сөйкемле кыз Гөлбикә әсетер ухасын да, икенчегә итле бәрәңгене дә мул итеп китерде. Әюп агай бигрәк тә яратып, мактый-мактый тәмләп ашады, азактан чынаяк чокырларына салып мәтрүшкәле чәй китергән Гөлбикәгә җиңелчә шаярту белән:

— Күптән болай сыйланганым юк иде, тәмле аш-су өчен рәхмәт сиңа, тормышта барча теләкләрең кабул булсын,— диде.

Менә ул чәйле чокырын авызына китергән хәлдә кухня ягына карап кинәт хәрәкәтсез калды, яртылай көйгән кашлары җыерылды, нервлануы йөзенә чыкты... Әмма ул үзен кулга алырга тырышты шикелле, телдән аны-моны белгертмәде. Чокырын өстәлгә куеп сәгатенә карагандай итте дә:

— Ах, мин порт белән сөйләшергә заказ биргән идем, телефонга ашыгам,— диде һәм аш-су өчен тиз генә түләп, элемтә бүлегенә менеп китте.

Өстәл янында үзем генә калгач, мин ирексездән кухня ягына каерылып карадым һәм анда пешекче хатын-кыз арасында әниемнең никахсыз ире Бәдретдин абыйны күреп шаккаттым. Авырулар өлешенә кул сузган өчен шушы арада гына больница ашханәсеннән куылган шеф-повар монда килеп оялаган түгелме?..

## Загс язуы ниләр сөйли

Берничә минуттан соң мин каютага менгәндә Әюпгәрәй агай әле һаман тынычланмаган, авыз эченнән нидер сөйләнә-сөйләнә ишек-ле-түрле йөри, ризасызлык белән әледән-әле тамак кырып куя иде. Гадәттә һәрвакыт сабыр холыклы капитанның бу халәте миңа сәер тоелды:

— Әюпгәрәй агай, ни булды, нәрсәгәдер кинәт кәефегез кырылды шикелле? — дип сорадым.

— Әле генә кухняда поварлар арасында беләсеңме кемне күрдем мин...— диде ул, һәмишә басыла алмыйча.— Хәтерлисеңдер, беркөн мин сиңа Чистай порты ашханәсендә мөдир булып эшләүче бер азгын

хатынның бергә эшләүче повар белән зина кылып яманаты чыгуы, аннары ире читтә эзсез югалгач, йорт-җирен сатып, ике яшьлек улын ятим сабыйлар йортына калдырып, сөяркәсе белән каядыр күчеп китүе турында сөйләгән идем бит. Менә хәзер кухняда шул хатынның сөйрәлчеген күреп шаккаттым.

— Ялгышасыз, Әюп агай, башка берәү белән бутыйсыз бугай. Сез әйткән кешене мин дә күрдем, кечкенәдән беләм мин аны. Бәдретдин исемле, безгә еш килеп йөри. Әнинең әйтүенә караганда, кем ягыннандыр туганы кебек иде. Әмма үсә төшкәч белдем, туган-тумача түгел, тик болай гына, күптән белгән-күргән дус кешесе сыман...

Күрәм, Әюп агай тагы да катырак дулкынлана башлады, уңайсызлану белән:

— Туктале, Таһир туган, әнием кем синең, исеме ничек?—дип сорады.

— Миләүшә исемле.

— Миләүшәме?!. Әтисенең исеме, ягъни отчествосы ничек? Маликовна түгелме?

— Әйе, Маликовна... Сез аны каян беләсез?—дип хәзер инде мин гаҗәпкә калдым.

— Әһә, алай икән, Миләүшә Маликовна икән-н... Алайса аңлашыла, барысы да мин уйлаганча килеп чыга...

— Нәрсә аңлашыла?—дидем мин түземсезләнеп.— Ачыграк әйтегез, сез уйлаганча нәрсә килеп чыга? Миңа берни дә аңлашылмый...

— Тукта, сабырсызланма. Алай бер-ике сүз белән генә әйтә торган түгел бу. Керәшен әйтмешли, әкрен кирәк, иплэп кирәк сөйләшергә... Шунсыз мөмкин түгел.—Сабыр булырга әйтсә дә, Әюп агай үзе дә дулкынлана, әммә сиздермәскә, тыныч күренергә тырыша. Сүзен ничек башларга белмәгән сыман, беравык уйланып торды да, минем иңемә кулын салып, ашыкмый гына сөйләп китте:—«Зоя» баркасына капитан булып килеп, беренче тапкыр күргәч тә, син минем игътибарны җәлеп иттең, күңелемдә дулкынландыргыч сизенү уяттың. Үзеңә белгертмәсәм дә, шуннан бирле игътибар белән күзәтеп, һәр сүзеңә колак салып киләм. Әмма ул хакта турыдан-туры сөйләшеп аңлашырга кыенсынып йөрдем. Күрәм, сизенүем нигезсез булмаган, хәзер мин моны ышанып әйтә алам. Менә бу кәгазь аны тагын бер кабат исбатлый.—Әюп агай курткасының куен кесәсеннән алып, кечерәк кенә форматтагы яшькелт кәгазь күрсәтте:—Мә, игътибар белән кара, бәлкем, сиңа да кайбер нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итәр.

Аның бу сүзләре миңа бик сәер тоелды:

— Нинди тылсымлы кәгазь ул, кайдан таптыгыз, кем бирде аны?—дип мәзәксенеп сорадым.

— Анысы болай булды аның. Узган атнада Чистайга азау тешемне дәвалатырга барган идем. Шунда врачка чират торганда кайчандыр бергә укып үскән, суднолар ремонтлау заводында бергә эшләгән кордашым Каюмовны очраттым. Бик ябыккан, кечерәеп калган. Мине үзем әйткәч кенә таныды, шунда да күзләренә ышанмагандай, битләремдәге җөйләргә озак кына шаккатып карап торганнан соң: «Гафу ит, тиз генә төсмерләрлек түгелсең... Синең үлгән хәбәрең килгән иде бит, сөбханалла, исән-сау икәнсең...»—дип бик гаҗәпләнде.

Поликлиникадан чыккач та җибәрмәде, өенә алып кайтты. Өй каршындагы бакчасында берничә баш умартасы бар икән. Карчыгы чәй әзерләгән арада берәр чынаяк әчегән бал белән сыйлады. Карчыгы сүзгә саран күренсә дә, мин күршеләрендәге теге ашханәче хатынның баласы турында сораштыра башлагач, өстәл янына килеп утырып, теле чишелде:

— Хәтерлим, исемен дә хәтерлим, Җантаһир атлы иде,—дип сөйләп китте.—Ятим сабыйлар йортында яңа гына эшли башлаган көннәрем иде. Әнкәсе калдырып киткәннән соң, өйгә кайтасым килә дип кычкырып

елый-елый тәмам шешенеп, тамагы карлыкты. Мескенне юата-юата йөдәп беттем... Әнкәсе аны ике ел чамасы вакыт үткәч алып китте. Бу вакытта ул хатын, йорт-җирен сатып, инде каядыр күченеп киткән, бүтән җирдә тора иде. Шуңа күрә ул баланың шуннан соңгы язмышын белмим, бүтән берни дә әйтә алмыйм...

Каюмовның гаиләсе зур түгел, загста мөдир булып эшләүче сазау кызлары белән өчәү бергә торалар. Өйлә вакыты җитәрәк төшке ашка шул кыз кайтып керде. Сазау кызлар гадәттә ачулы, усал була торган иде. Ә бу, киресенчә, ачык йөзле, йомшак күңелле икән. Әнисе сабый малайның ятимнәр йортында интегүләрен телгә алып тагын сөйләгәч, бик тә кызганып, авыр сулап куйды. Алар тынып торган бер арада мин загс мөдиреннән:

— Сез ничек уйлыйсыз, ул баланың фамилиясен, әтисе, әнисе кемнәр икәнен ачыклап булмас микән? — дип сорадым.

— Эзләп карарга кирәк,— диде загс мөдире.— Исеме, чама белән туган елы да билгеле булса, безнең архивта табылырга тиеш.

Һәм нәкъ шулай, ул әйткәнчә, килеп тә чыкты: иске кенәгәләрдән бергәләп эзләп тапканнан соң, малайга... «Туу турында таныклык» дубликаты язып бирде. Шунда бер уңайдан хатынымның миннән аерылуы хакында таныклык та алдым. Мә башта менә шунысын күр.

Әюпгәрәй агай биргән таныклыкка карау белән ике күзем дүрт булды, әллә ялгыш күрәмме дип, кабат укып чыктым. Чөнки бу минем әни белән Әюп агайның никахы бозылганлыгын, ягъни аерылышуларын раслый торган рәсми документ иде.

Мин моны башыма сыйдырырга, рәтләп аңларга өлгермәдем, Әюпгәрәй агай миңа икенче кәгазьне тоттырды. Монысы Җантаһир дигән малайның тууы турында таныклык дубликаты: әтисе кем дигән графада — безнең баркас капитаны Кирамиев Әюпгәрәй дип язылган, анасы кем дигән графада исә — минем әнинең исеме, фамилиясе.

Дөресен әйтим, акылга сыймастай бу көтелмәгән хәлдән күз алларым томанланып китте, төштәге кебек зиһенем чуалды. Шуңа күрәдер, аны-моны уйламастан, механик рәвештә:

— Кара син аны, бу Җантаһир минем белән бер елда, хәтта бер числода туган икән...— дип әйтеп куйдым һәм, ниһаять, үзем турында сүз барганын, Әюп агайның минем... әтием икәнен абайлап, кинәт исемакылым китте. Моны башыма сыйдыра алмыйча телсез калдым...

Минем дулкынлануым йөземә чыкты бугай, Әюп агай беравык сынаулы карап торды да:

— Ник уйга баттың әле син? Барып җитмимени? — диде.

Ул тагын нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, шулчак өстәл кырыендагы репродуктордан кемнеңдер бераз карлыккан тавыш белән:

— «Зөя» баркасы капитанын ашыгыч рәвештә район начальнигы кабинетына чакыралар... Тиз булыгыз, сезне көтәләр...— дигән команда сүзләре яңгырап үтте.

Әюп агай, дөресрәге, хәзер инде әтием, мине иңемнән кочаклап:

— Фу, тапканнар вакытын...— диде, канәгатьсезлек белән.— Ашыктырып чакыргач, бармый ярамас. Мин кереп чыккач, иркенләп сөйләшербез.

## Ур-ра, мин әтиемне таптым!

Әти район начальнигы янына кереп киткәннән соң, кинәт зиһене чуалган кешедәй, каютада миңгерәп калдым. Эчемә сыймаган зур шатлыктан: «Әй, кешеләр, барыгыз да ишетегез, белегез: мин әтиле булдым, кара язмыш югалткан әтиемне таптым»...— дип горурланып кычкырудан көчкә тыелып утырам, аның һәр җәһәттән әйбәт кеше булуына куанам.

Бераз тынычлана төшкәч, ул калдырган герблы, түгәрәк печатьле таныклыкны алып кабат карый башладым һәм бик аптырап калдым. Чөнки мин, кечкенәдән әни фамилиясендә йөрим икән, паспортымда да шулай язылганмын. Таныклыкта Җантаһир дигән исемем паспортта кыскартып Таһирга әйләнгән, әтисе кем дигән графада Әюпгәрәй түгел, ә Гәрәй дип кенә кыскартып язылган. Әнә шулай мин бөтенләй бүтән кешегә әверелгәнмен.

Тик шунысы сәер: игътибарсызлык аркасында килеп чыккан очраклы хәлме, әллә берәр максат белән эшләнгән махинацияме бу? Һәрхәлдә, монда нидер бар, мондый әверелү үзеннән-үзе генә булырга тиеш түгел. Хәзер әти керү белән ачыкларга кирәк.

Әһә, аны озак көтәргә туры килмәде, район начальнигы янынннан ул тиз чыкты. Үзалдына нидер сөйләнә-сөйләнә каютага керә-керүгә:

— Бүген төштән соң, монда зур түрә — пароходчылыкның тәэминат начальнигы киләчәк икән,— диде.— Безнең баркаска керсә-нитсә, тиешенчә рапорт биреп каршыларга кушты.

— Кара син аны, кешеләр белән борын чөеп кенә сөйләшсә дә, үзеннән өстеннәр каршында әнә ничек яхшатланмакчы,— дидем, гаҗәпләнеп.

— Ташла, төкер башына, ул турыда башыңны ватма... Бүген безнең иң шатлыклы көнебез бит, бер-беребезне табуга сөен син... Җантаһир, улым минем, кая яхшылап күрим әле үзеңне...— дип әти иңнәремә кулларын салды, маңгаемнан үбеп алды. Ничәмә-ничә еллардан соң, ниһаять, табыштык бит. Шунысы гаҗәп, мин сине һаман сабый бала итеп күңелдә йөртә идем, төшләремдә күрә идем. Ә син әнә нинди баһадир булгансың, бер-беребезне белмичә, ничаклы вакыт бергә эшләгәнбез...

— Әткәй, мин дә сине бик юксына идем, урамда әтисе кулына тотынып барган шат бала күргән саен үземне дөньяда иң бәхетсез ятим итеп тоя идем. Бу табышуга мин әйтеп бетергесез шатмын. Күпме вакыт бергә эшләп, шушы көнгә кадәр бер-беребезне танымавыбыз гына гаҗәпләндерә... Шулай да мин сине өлкән туганым кебек якын итә идем, димәк безнең арада рухи уртаклык, кан тарту дигән нәрсә сизелерлек булган.

— Мин бу уртаклыкны беренче очрашулардан ук сизендем һәм игътибар белән күзәтә башладым, вакытыннан элек әйтмәдем генә. Чөнки бу имеш-мимешкә, сизенүгә таянып кына кузгата торган сүз түгел. Менә хәзер загс таныклыгы белән дә раслангач, һич тә икеләнмичә, аяк терәп сөйләшергә мөмкин.

— Әлбәттә, шулай, монда аз гына да икеләнергә сәбәп юк. Тик шунысы бик сәер: загста әтием фамилиясендә теркәлеп тә, мин кечкенәдән әнием фамилиясендә йөргәнмен, паспортымда шулай язылган. Үз исемем, әтием исеме дә яртылай кыскартылган. Андый алмаштыру, кыскартулар кем тарафыннан, нинди максат белән эшләнүе аңлашылмый. Әллә болар бар да берәр игътибарсызлык нәтиҗәсендә, очраклы рәвештә генә килеп чыккан микән?

— Юк, юк, һич тә очраклы түгел, бу ныклы уйлап, синең белән мине табыша алмаслык итеп адаштыру максаты белән эшләнгән. Ул вакытта Миләүшәнең әтисе милиция бүлеге начальнигы иде, бу махинация, һичшиксез, аның эше булырга тиеш. Шуннан элегрәк, кызымны кыйнады дип, минем гаебемне күпертеп, ялган акт төзүдә, мине иректән мәхрүм итүдә, соңыннан минем йорт-җиремне кызы исеменә күчереп яздыруда — барысында аның кулы уйнаган. Күрше-колан моны сизеп, иштеп торган; өлкән яшьтәге агайлар, түтиләр әле дә булса онытмаганнар, аталы-кызлы икесен дә комсыз-карун дип яманлап сөйлиләр.

— Дөрес әйтәләр, әни комсызлануын хәзер дә дәвам итә, андый сыйфатым булмаган өчен мине еш шелтәли, Сәрвиназны өзлексез җәберли. Мин монда вакытта әтисе янына кайтып китәргә мәҗбүр иткән.

— Ә син күрә торып, шуңа юл куясыңмыни, хатыныңны нахакка кыерсытудан якламыйсыңмыни?

— Әйе, шулайрак килеп чыкты, вакытында әнине тыя белмәдем... Сәрвиназ миңа бик үпкәләде. Телдән әйтмәсә дә, беркөн очрашканда салкын сөйләште, ул йортка кире кайтачак түгелмен диде.

— Йә, ярар, ул хакта калып торсын әле. Адәм рәтле хатын булса, гаиләсен алай кинәт кенә җимереп ташламас. Ничек тә аңлашырсыз, килешерсез дип өметләник. Зур шатлыклы көнне күнелсез уйларга бирешмик әле... Шулай да молодец, син, намуслы егет булып үскәнсең, барыннан бигрәк, шуңа шатмын.

Төш вакытында ашханәдә күзгә чалынган чистарыну, аш-суның гадәттәгедән мулрак һәм тәмлерәк булуы, гомумән, бәйрәмчә күңелле җанлылык юкка түгел икән: менә-менә зур дәрәҗәле түрә — пароходчылыкның тәэминат начальнигы килергә тиеш, һәммәсе дә шуны олылап каршыларга әзерләнә. Барыннан бигрәк пешекчеләр тырыша. Ашханә залын, кухняны ялт иттерүдән тыш, дәрәҗәле кунакка дигән иң шәп каютаның урын-җирен, тәрәзә пәрдәләрен тиз генә алмаштырдылар, хәтта клубтагы телевизорны, район начальнигы өстәлендәге вентиляторны да шунда кертеп куйдылар. Ашханә мөдире Азалия боларның барысын да үзе карап эшләтте.

Олы түрәнең килгәнен ерактан күреп хәбәр итү өчен махсус күзәтүче куелган иде. Кояш инешкә авышкач күп тә үтмәде, өске каттан каты тавыш белән: «Киләләр-р... Әнә наратлы борыш артыннан «Тәэминатчы» килеп чыкты...» — дип бар көченә кычкырып хәбәр итте. Аннары радиоузелдан пароходтагы бар кешегә сул як бортка чыгып, начальствоны каршыларга команда булды.

Әти белән мин шунда күләгәдә күңелле гәпләшеп утыра идек. Тантаналы очрашуга иң башлап Азалия командасы, ак халат, ак башлык кигән, кайберләре чәчәк бәйләме тоткан пешекчеләр килеп чыкты; алар артыннан күп төрле канцеляриячеләр, эштән буш механизаторлар, матрослар җыела башлады. Кайберләрен вахтадан соң ял иткән җирдән уятып чыгарганнар, күрәсең, арадан ризасызлык белән: «Ут чыкканмыни, ни шайтаныма вакытлы-вакытсыз борчыйлар», — дигән сүзләр ишетелде.

Озакламыйча «Тәэминатчы» теплоходы рейдка килеп керде һәм, йөрешен акрынайтып, салмак кына сулга борыла башлады. Йөзмә магазиннан үзгәртеп яраштырылган кечерәк кенә судно булса да, карар күзгә ул ярыйсы гына: тоташтан акка буялган, иллюминаторларында кояш нурлары җемелди, арткы мачтасы очында флаг салмак кына чайкала.

Пароходчылыкның баш тәэминатчысы — шактый өлкән яшьләрдәге калын гәүдәле агай — рубка каршындагы чыбыктан үрелгән диванда түрәләрчә җәелеп утыра. Ак тужуркасының җиңнәрендә сары укалы нашивкалары, күкрәгендә бер-ике орден, медаль җемелди; озынча баш очында зонтик сыман киң читле, сары эмблемалы зур фуражка. Озата йөрүчесе булса кирәк, аннан сулда басканы — чеви кебек чандыр, чәй тәлинкәсе хәтле зур күзлекле яшьрәк елгачы, әйләнә-тирәгә бинокльдән карый-карый килә һәм, әледән-әле борылып, хуҗасына нәрсә турындадыр хәбәр итә.

Дәрәҗәле кунак каршылаучылар белән ягымлы елмаеп исәнләште, район начальнигы Петраков һәм Азалия белән кул биреп күреште. Шунда ул тәрәзә каршында эскәмиядә утырган әтине күреп, кинәт хәрәкәтсез калды, үз күзләренә ышанмагандай, аксыл кашларын җыерып карап торды да:

— Ба-а, кемне күрәм мин?!. Иптәш капитан-лейтенант, сезне күрәмме?.. — дип гаҗәпләнеп кулларын җәеп җибәрде. Аннары, моның белән үзен ничек тотарга дигән сыман, күз кырые белән генә район начальнигына карап алды. Петраков әтинең баркас капитаны икәнен әйтү

белән, шундук каушавыннан арынды, түрәләрчә кыю тонга күчте:—Менә бу чынлап та көтелмәгән очрашу... Әйдәгез, кул биреп күрешик әле, исәнмесез...

Мәгәр әти танымады:

— Гафу итегез, сез ялгышасыз, мине башка берәү белән бутыйсыз,— диде.

— Юк, һич ялгышмыйм, сезнең физиономиягезне башка беркем белән дә бутарлык түгел. Оныттыгызмыни, Тын океан флотында бергә хезмәт иттек бит. Сез командалык иткән корабта мин индендант идем.

— Әһә, менә хәзер искә төште, хәтерем ялгышмаса, сез Хазанов Сәмин Фидаярович бит?

— Нәкъ шулай, Хазанов, исемем, отчеством гына бераз башкачарак. Әйтергә уңайлырак булсын өчен мине хәзер Семен Федорович дип йөртәләр, сезгә дә шулай гына дәшәргә киңәш итәм.

— Әйбәт эшлисез, заманасы шундый,— диде әти, ирония белән.— Хәер, сез киң натуралы интернационалист бит, хәрби хезмәттә чакта ук үзегезне шулай йөртә идегез. Ул чакны сез какча гына гәүдәле яшь офицер идегез, хәзер әнә нинди зур дәрәҗәле җитәкче булып күтәрелгәнсез, тәскә-биткә дә солидныйлангансыз.

Бу сүзләр киная белән әйтелгән булса да, адым саен ялагайлану күреп күнеккән Хазанов моны сизмәде, туры мәгънәсендә мактау итеп аңлады, үзенә бер горурлык белән:

— Дөресен әйтәсез, безнең идарәдә булдыклы кешеләрнең кадерен беләләр,— диде.

## Безнең заман каһарманы

Ашханә мөдире Азалиянең люкс каютасын зур тырышлык белән матурлап җиһазландыртуы юкка булып чыкты. Баш тәэминатчы туктаган портларда, затоннарда казна кунакханәләренә күченеп мәшәкатьләнүгә караганда, бөтен уңайлыклары булган үзенең персональ теплоходын кулайрак күрә, туктаган урыннарда киңәшмәләрне шуның салонында үткәрә, кешеләр дә шунда кабул итә икән.

Шуңа күрә ул зур тырышлык белән әзерләнгән комфортлы каютага кереп тормады. Очрашып хәл-әхвәл белешкәч тә, азык һәм промышленность товарлары кибетләренә кереп чыкты, иңенә ак халат салып, пекарняны, ашханәне, камбуз җиһазларын күздән кичерде, пешергән ашларын татып карады. Кешеләр тарафыннан әйтелгән зарлануларны, үтенечләрне озата йөрүчесенә яза барырга кушты.

Пешекчеләрдән кемдер ашханә кладовоенда яшерен рәвештә кудырылган самогон биреп, браконьерлардан балык алу, шуны халыкка ашатудан кергән акчаны мөдир үзләштерүе турында идарәгә ике тапкыр жалоба язган булган. Идарәдә аны да игътибарсыз калдырмаганнар:

— Аноним сигнал булса да, монда килер алдыннан мин аны махсус тикшерттем, әмма андый факт расланмады,— диде һәм киләчәктә алай яла ягу белән шөгыльләнмәскә кисәтте.

Семен Федоровичның базадагы инспекциясе шуның белән тәмам булды һәм ул эшләрнең торышы белән канәгать калды. Аннары район начальнигы Петраков белән бергә үз судносына утырып, гравий чыгаручы земснарядларда инспекция үткәрергә китеп барды. Азалия аларны озак йөрмәскә, бик соңгармыйча, мөмкин кадәр иртәрәк әйләнеп кайтырга искәртеп озатып калды.

Район халкы бу шау-шулы каршылауга мәҗбүри бер чара итеп карады, искитмәле һични булмагандай, шундук таралышып, һәркем үзенең көндәлек шөгыленә кереште. Хәер, мин үзем дә моңа әллә ни әһәмият бирмәгән идем. Хәлбуки, әтине бу вакыйга, төгәлрәге элекке хезмәттәше

белән очрашу никтер тәшвишкә салды, нервларын кузгатты. Каютага керү белән борсаланып, ризасызлык белән үзалдына мыгырдый башлады:

— Кара син хәрәмчене, нинди түрә булган, сугымга симертелгән чучка сыман тәмам бүртенгән...

Аның кинәт әсәрләнеп китүе миңа сәер тоелды:

— Түрә булмагае, шайтан булсын, аңа ник исең китте?.. Син аны яхшы беләсеңмени? — дип сорадым.

— Әйе, кайчандыр яхшы беләм кебек иде,— диде әти.— Безнең корабта индендант булып хезмәт иткәндә, хәрби званиесен күтәрү өчен мин аңа әйбәт характеристика язган идем. Нәкъ шуннан соң үткәрелгән ревизия вакытында аның командага дип ялган документ белән базадан алган обмундированиене үзләштерүе фаш ителде. Шулай да янмады, бөтен гаепне писер белән баталер өстенә аударып, судан коры чыкты. Гайбәт сатучы сыманрак булсам да, бер башлагач, сөйләп бетерим инде: шуннан соң күп тә үтмәде, интендантыбыз шәһәргә чыккан чакларда кергәләп йөри торган тол хатынның унөч яшьлек кызын көчләгән өчен янды. Бу юлы ул җиңел генә котыла алмады, трибуналга эләкмәс өчен авырыйм дигән булып, кемнәрнеңдер ярдәме белән тиз генә хәрби хезмәттән шылып, күздән югалды... Әнә шул адәм актыгы хәзер зур түрә булып, корсак киереп йөрсен, имеш! Кагыйдә буларак, андый җитәкче үз тирәсендә үз ише яраннарын туплый, бөтен законсызлык, бозыклыкларын шулар ярдәмендә, һичкемнән курыкмыйча, оялмыйча шулар белән бергә эшли. Андый бозык атмосферада намуслы кеше дә юлдан язарга мәҗбүр була. Юкса, аны бик тиз кысрыклап чыгарачаклар. Күпне белеп, телен теш артында тотмаса, башына җитүләре дә ихтимал.

## Гөлбикәнең хәтере калды

Кич белән эш киемнәремне киеп, мин вахтага чыкканда начальство инде рейдтан кайткан, алар утырып йөргән «Тәэминатчы» теплоходы «Баһадир»ның койрык ягына бәйләп куелган иде. Ә безнең «Зөя» баркасы исә алгы якта ашханә кладовое каршында тора. Бәдретдин абый белән пешекче хатын-кызлар аның палубасына төрле ашамлык, шешәләр тулы кәрзин, сумкалар ташыйлар. Штурман Артур алар китергән әйберләрне кабул итеп, рубкага менә торган баскыч астындагы зурларга тутыра, кубрикка төшереп урнаштыра бара иде.

Мин машинаны, ягулык, майлау материаллары запасын күздән кичереп, вахтаны кабул иткән арада, баркаска начальниклар да килеп керде. Инспекциядә йөргән җирләрендә алар сизелерлек кәефләнеп кайтканнар бугай, артык кычкырып сөйләшүләре, хахылдап көлүләре аска машина бүлегендә дә ишетелә, ара-тирә гармун тавышы да яңгырап куя. Ни булыр икән дип өскә күтәрелеп карасам, ашханә кызлары да безнең белән бара, гармунда шуларның берсе өздерә икән!

Хәзер кызлар баягы кебек ак халаттан түгел, кунакка җыелгандай, бәйрәмчә киенгәннәр, баркас кузгалып китү белән гармунга кушылып, күтәренке көйгә җырлый да башладылар. Азалия баш тәэминатчының култык астына керердәй булып сыланып утыра. Чәч бөртекләре дулкын-дулкын булып иңнәренә төшкән. Өстендә зәңгәрсу ефәк кофточка, муенса таккан, яртылай ачык күкрәк йомрылары арасында черви тузы төсле кызылсу кулон җемелди. Каш-керфекләре сөрмәле, иреннәренә мул итеп помада сөрткән һәм артык бизәнүдән үзенең табигый матурлыгын югалтып, ничектер чуар курчакка охшабрак калган.

Безнең белән баручы өч кызның берсе — үзешчәннәр хорында башлап җырлаучы Гөлбикә — артык бизәнмәсә дә, үзенең мөлаемлыгы белән җәлеп итә: кызмача кунаклар аның талчыбыктай сыгылмалы зифа буена,

кызарып пешкән чия төсле тулы канлы көлемсәр иреннәренә комсыз күзләре белән йотардай булып карап утыралар. Бигрәк тә баш тәэминатчыны озата йөрүче купшы адъютантның күзе кызган, юк сәбәпне бар итеп, кәҗә тәкәсе кебек, гел Гөлбикә тирәсендә ышкыла.

Кунаклар үзара әвәрә килгән бер арада Гөлбикә койрык якка минем янга килеп чыкты һәм ачык тамбурдан машина бүлегенә кызыксынып карап:

— Әбәү, синең монда харап эссе икән... Җитмәсә, колак тондыргыч гөрелте тагын. Ничек түзәсең, канатым,— диде, юри җәлләгән булып.

Шаян кыз алдында сер бирәсем килмәде:

— Бер иялəшкəч, əллə ни кыен түгел... Сезнең кухняда мондагыдан эссерәк булса да, түзәсез бит, зарланмыйсыз... Туктале, Гөлбикә туташ, шул тикле киенеп-ясанып кая барасыз?— дип сорадым.

— Анысы безгә билгесез, ул хакта мин үзем синнән сорамакчы идем. Азалия апай да әйтмәде, баргач күрерсең диде. Барган җирендә кунакларга хезмәт күрсәтергә булса кирәк, алар белән ягымлырак булырга, күңелләрен күрергә кушты... Юлга чыгар алдыннан алар сезнең капитаныгыз Әюп агайны да чакырганнар иде. Әмма ул теләмәде, ахры. Иртән вахтага чыгар алдыннан ял итмичә мөмкин түгел, диде, бармады.

Хәзер бу сәфәр инде миңа да сәер тоела башлады. Аны-моны уйламастан, үзем дә көтмәгәндә:

— Әйтәсе дә юк, дәрәҗәле кунакларга сый мулдан әзерләнгән. Өстәвенә десертка чәчәк кебек яшь кызлар да алып бара, тере ит белән сыйламакчы, күрәсең,— дип җиңелчә чеметтерeп алдым.

Әллә ни әдәпсез сүз әйтмәгән шикелле идем, әмма Гөлбикәнең бик ачуы килде, шелтәле тавыш белән:

— Кемне әйтәсең син, Азалия апайнымы?! — диде.— Шул тикле дә пычрак телле булырсың икән, оят түгелме сиңа?! Алай итәргә без кәнизәкләр түгел ич...

Гөлбикә чынлап торып үпкәләде һәм, минем гафу үтенүемә карамастан, бүтән берни дә әйтмичә, ачулы адымнар белән китеп барды.

## Шунсыз ярамый

Без базадан кузгалып киткәч, ярты сәгать тә үтмәгәндер, рубкадан машинаны акрынайтырга, аннары туктатырга команда булды. Тамбурдан башым тыгып карасам, яр буена бәйләп куелган кечерәк кенә агач баржа янына барып туктаганбыз икән.

Монда без киләсен алдан белеп, көтеп торганнар, ахры, шундук кемдер өзек-өзек сәер шыгырдык тавыш белән: «Киләләр-р, киләләр-р...» дип кычкырып хәбәр салды; әмма кычкыручы үзе күренми, ул каядыр яшеренгән җирдән чыжылдый сыман иде. Ул да түгел, палуба уртасындагы будка эченнән бозау хәтле зур сары эт чыгып, ярсулы тавыш белән һау-һаулап өрә башлады. Аның артыннан ук күлмәк изүен төймәлитөймәли базык гәүдәле шкипер алпан-тилпән атлап чыкты: «Дускай, шаулама, болар үз кешеләр, кунаклар...» — дип аркасыннан сыйпап, этен тынычландырды.

Ул сизелерлек сәрхүш бугай, безнең баркастан сузылган чалканы тумбага элгәндә нәрсәгәдер абынып, чүт егылмады. Шулай да якты чырай белән:

— Кадерле кунаклар, рәхим итегез... Әйдәгез, юлны үзем күрсәтәм,— диде, авызын ерып.

Азалия аның артык төчеләнүен өнәмәгәндәй, ризасызлык белән тамак кырып алды. Трап куйганны да көтмәстән, баржа палубасына сикереп чыкты да:

— Озатуның кирәге юк, юлны үзебез дә табарбыз... Ә син монда уяу бул, шикле кеше-кара күренсә, шундук хәбәр ит,— дип кисәтте һәм кунаклар белән такта басмадан яр буена төшеп китте.

Алар тәбәнәк яр өстендәге тар сукмактан тал-тирәк арасына кереп күздән югалгач, бермәл кайда икәнебезне чамалый алмыйча тордым. Шунысы сәер: без һәрвакыт эшли торган күп сулы киң Камада түгел, ниндидер тар елга тармагында, кечерәк кенә агач баржа янында торабыз. Бөтенләй таныш булмаган чит-ят җир, әйләнә-тирәдә сәер тынлык.

Һе, күрми дә торам: таныш урын, беркөн төнлә балыкны без шушы баржадан алдык бит!.. Әйе, әйе, нәкъ үзе. Әнә койрык якта киптерергә элгән җәтмә җылымнар да, эре хәрефләр белән «Карантинлы утрау, якын килмәскә!» — дигән белдерүле фанер такта да, Дускай атлы бурзай да — барысы да шулар. Ул чакны караңгыда шкиперын яхшылап күрмәсәм дә, тавышы шул — гырылдап сөйләшә ләбаса.

Әнә шулай гаҗәпкә калып торганда киткән җиреннән ут капкандай йөгерә-атлый Азалия кайтып керде:

— Черек ми, иң кирәк әйберемне онытканмын,— дип үзен-үзе әрли-әрли кубрикка төшеп китте. Бер-ике минуттан палубага чыкканда аның бер кулында кара икра тулы зур гына пыяла банка, икенчесендә — аракылы шешә һәм ниндидер төргәк иде.— Монда үзегезгә генә күңелсез булмасын, менә монысы сезгә,— дип шешә белән төргәген миңа сузды.

— Кирәк түгел, эш вакытында эчәргә ярамый,— дип шешәсен кире кактым һәм кинәт кузгалган җирәнүемне сиздермәс өчен мөмкин кадәр сабырлык белән: — Карале, ник әле син үз исеменнән ваз кичкән шул Семен Федорович каршында җаныңны ярып бирердәй булып яхшатланып йөрисең? — дип әйттем.

Азалиянең сөрмәле кашлары җыерылды, ни әйтергә белмәгәндәй чак кына уйланып торды да:

— Безнең өчен бик кирәкле кеше бит, шунсыз ярамый,— диде. Синең әнкәң Миләүшә апай башлы хатын, ул да шулай итә, кирәкле кешенең салпы ягына салам кыстыра белә иде, мине дә шуңа өйрәтә иде... Әйтәм ич, шунсыз ярамый, аңардан гына ука коелмый бит.

## Сәер утрау

Гравий чыгаручылар арасында колактан-колакка сәер сүз йөри: Кама елгасының сул як тугаенда «Карантинлы зона» дигән сәер утрау бар икән, югары оешмалардан килгән инспектор, ревизор кебек тикшеренүчеләрне шунда майлап йомшарталар, дәрәҗәлерәк түрәләрне хәтта «тере ит» белән дә кунак итәләр ди. Кайда икәнен тәгаен генә әйтмәсәләр дә, ул җылы оя һәр яктан су белән уратып алынган, аңа илтә торган бердәнбер тар сукмакны яр буенда усал эт белән мылтыклы кеше саклый, дип сөйлиләр.

Беренче тапкыр ишеткәч, мин моңа аз гына да ышанмаган идем, мәзәк өчен генә сөйләнә торган уйдырма итеп караган идем. Әмма хәзер күрәм, минем әнинең тугрылыклы шәкерте Азалия дәрәҗәле кунакны алып килгән бу урын да шундыйрак аулак ояга бик охшаган: «Карантинлы зона» дигән белдерү дә, яр буенда куе әрәмәлеккә керә торган тар сукмак та, аны саклаучы ярсу бурзайлы шкипер да бар бит.

Кунаклар әрәмәлеккә кереп киткәч, баржа палубасына чыктым. Будка тәрәзәсе каршындагы такта өстәл өстендә ике стакан, каклаган ике балык, икмәк һәм бер шешә аракы тора; аркасы белән стенага терәлгән шкипер, уйга талгандай, йокымсырап утыра иде.

— Рәхим ит, әйдә утыр... Менә Азалия калдырган күчтәнәч, сине дә сыйларга кушты,— диде дә, стаканнарга шаулатып аракы салды. Өстәл астында эсседән әлсерәп яткан бурзай ачулы ырылдый башлагач: —

Аракы исен күрәлмый, салмыш баштан якын килсәм, мине дә тешләргә генә тора,— диде.

Шул арада көтмәгәндә будка түбәсе кырыена ак канатлы саескан килеп кунды һәм гәүдәсеннән озын койрыгын болгый-болгый: «Хәерлегә түгел бу, хәерлегә түгел...» — дигәндәй, ятышсыз тавыш белән шыгырдарга тотынды.

Ул — шкиперның кулга ияләшкән һәм кешегә ияреп берничә сүз тәкелди торган саескан икән. Баягынак безне «Киләләр, киләләр» дип кычкырып каршылаучы шул булып чыкты.

— Саесканым бик әйбәт хезмәт итә, ят кеше-кара килгәнен эттән дә элгәррәк күреп хәбәр бирә торган иде,— диде шкипер.— Авылдан әни килеп, монда бераз торган иде, шуннан ишетеп кошчыгымның холкы бозылды, өстәлдә шешә күрсә: «Хәерлегә түгел бу...» — дип әнидән өйрәнеп калган сүзләрне кабатларга тотына. Попугай кебек, һаман шуны такылдап, нервыда уйный. Ярар, черт с ним... Әйдә, бераз тамак чылатып алыйк әле.

Әнә шулай, саесканнан зарлана-зарлана аракыны икегә бүлде, аннары чыраен да сытмыйча, тулы стаканын берьюлы аударып куйды, киптерелгән балык эченнән уылдык алып авызына капты. Минем гомумән аракы эчмәвем аңа бик сәер тоелды бугай, колакларына ышанмыйча, беравык гаҗәпләнеп карап торды. Аннары мине мактап берничә сүз әйтте дә, синең саулыкка булсын дип, икенче стаканны да бушатты.

Шунда будка стенасына кадаклап куелган язулы фанер тактага тагын күзем төште:

— Нинди карантин бу, сезнең монда йогышлы авыру бармыни? Аның безгә куркынычы юкмы? — дип шикләнеп сорадым.

— Юк, һичнинди карантин юк. Ул хакта аз гына да борчылма,— диде шкипер, кәефле хихылдап.— Мин аны болай гына, чит-ят кеше бу тирәгә якын килмәсен өчен язып куйган идем.

Без килгәнче үк инде шактый салмыш шкипер, тагы ике стакан өстәгәч, отыры исерә төште, балык кылчыгы белән тешләрен казый-казый:

— Тормышта иң мөһиме — файдасы тиярлек кешене табарга, аның ышанычына керә белергә кирәк,— дип акыл сатарга керешге.— Элекке ашханә мөдире Миләүшә түтигә рәхмәт, монда кладовщик шкипер итеп мине шул куйды. Бик башлы хатын иде, бу карантин белдерүен дә мин аның кушуы буенча яздым.

Дәрәҗәле ку‥аклар утырган аулак оя моннан ерак түгел, кайдадыр якында гына булса кирәк. Яр өстендәге куе тал-тирәк арасыннан гармун тавышы, кычкырып көлүләр ачык ишетелә, шау-шулы җанлылык көчәйгәннән-көчәя бара. Әле берсе, әле икенчесе мөхтәрәм Семен Федоровичны олылап, елгачылар турында аталарча кайгыртканы өчен аңа ихлас күңелдән рәхмәтләр әйтеп, озын гомер, саулык-сәламәтлек теләп тост күтәрә...

Бераздан мәҗлестә тәнәфес ясап таралыштылар бугай, өзек-өзек сөйләшү, чыр-чу килгән тавышлар төрле тарафтан килә башлады.

Әле без бирегә килеп туктаганда гына һава чалт аяз, көнбатышта офык буйдан-буйга кансу кызыл иде. Кичке эңгердә күрми калганмын, мин монда сәрхүш шкипер янында көенеп утырган арада күк йөзен болыт каплаган булып чыкты. Көтмәгәндә кичке тынлыкны бозып, баш очында гына гөрселдәп күк күкрәде, эре тамчылы җылы яңгыр сибәләргә тотынды. Әмма болыт агымы безгә кырые белән генә кагылды бугай, яңгыр озак яумады, балык чүпләре тулы өстәлне, киптерергә элгән җәтмәләрне чылатты да, агым уңаена түбән якка таба китеп барды.

Тәмам җебегән шкипер кыска вакытлы яңгырны сизми дә калды, ахры, будка стенасына аркасын терәп утырган хәлдә йокыга чумды. Ә мин үз баркасыбызда, эш юктан бер эш булсын дип, койрык якта кармак салырга утырдым.

Берсеннән-берсе күңелсез уйларга батып утырганда кинәт якында гына кемнәрнеңдер ыгы-зыгы килгәне, чытырманлык арасында дөп-дөп басып йөгергәне ишетелде. Караңгы тынлыкта ачы тавыш белән:

— Таһир-р... ярдәмгә кил-л...— дип бер хатын-кызның кычкырганы яңгырап үтте.

Чү, мине атап кычкыра бит, безнең ашханә кызларыннан берәрсе бугай. Тиз генә йөгереп чыгып, тайгак сукмактан яр өстенә менсәм, якында гына дәрәҗәле түрәнең озата йөрүчесе нәрсәдер мыгырдый-мыгырдый пешекче кыз Гөлбикә белән тарткалаша, култыклап аны куе чытырманлыкка алып керергә маташа иде.

— Нишлисез сез, туктагыз... Оят түгелме...— дип туктатып, оялтмакчы булган идем.

Кая ул оялу... Төкереп тә бирмәде, ичмасам. Искитмәле берни дә булмагандай:

— Нинди оят булсын,— диде ул.— Бу дуамал кыз тегендә минем күзлегемне төшереп югалтты, шуны эзләшергә генә алып бармакчы идем. Ә ул шуны аңламыйча, көйсез бала кебек, тавыш куптара...

## Мин Гөлбикәне тыңлыйм

Бик дулкынланган Гөлбикә баркас палубасына кергәч тә тиз генә тынычлана алмады. Аның өс-башы таушалган, чәче тузгыган, үзе, каты йөгереп килгән кебек, еш-еш тын ала, бөтен гәүдәсе сулкылдап калтырый.

— Ярый әле син килеп җиттең, юкса эш харап иде,— диде һәм, тузгыган чәчен рәтли-рәтли, башыннан үткәннәрне сөйләп китте.— «Яшел ресторан» дигәннәре әрәмәле кечерәк кенә утрауда зур өстәл, бүкән утыргычлар белән җиһазландырылган, һәрьяктан үрмәле колмак җәтмәсе белән каплаулы түгәрәк беседка булып чыкты. Шунда тиз генә табын әзерләгәч, Азалия апай миңа начальникны озата йөрүче — чүлән кебек ябык гәүдәле, чәй тәлинкәсе хәтле зур күзлекле бәндә янына утырырга, аңа илтифатлы булырга, күңелен күрергә кушты. Үзе исә һаман дәрәҗәле кунак янында булды, кайнар тостлар әйтә-әйтә аны сыйлады. Ә минем баштарак тәкәббер күренгән кунагым, киресенчә, үзе кайгыртучанлык күрсәтеп, тәлинкәмә закускалар алып салды, рюмкаларны чәкештерә-чәкештерә мине кыстап, көлдергеч мәзәкләр сөйләп утырды. Моның юкка булмаганын, сизгерлегемне онытгырып, мине исертү өчен эшләнгәнен чак кына соңрак күрдем.

Сезнең Артур дигән штурманыгыз эчүгә сәләрәй, ахрысы. Азалия апай аны: син эштәге кеше, безне алып кайтасың бар, күп эчмә, дип берничә тапкыр кисәтүгә карамастан, теге күрмәгән арада чөмерә дә чөмерә.

Бераздан тәнәфескә таралышып, сәйранда йөргәндә шыбырдап җылы яңгыр коеп ява башлады. Ярый әле, безнең бәхеткә, якында гына алан читендә печән богылы бар икән. Бик чыланмас өчен, тиз генә йөгереп барып, шуның астындагы куышка кереп сыендык.

Куыш эче дөм караңгы, күзгә төртсәң дә берни күрерлек түгел. Әлегә тикле азмы-күпме әдәп саклаган кавалерым аулакта тыйнаксызланырга, шаярган булып, кулына ирек бирергә, капшанырга тотынды. Башта кунак хакына каты бәрелмәскә тырышкан идем. Әмма артык узынырга тотынгач түзмәдем, бар көчемә этәреп җибәрдем. Караңгыда ялгыш битенә эләкте бугай. Ул шунда: «Ай, харап иттең, күзлегемне бәреп төшердең»...— дип аяк астындагы печән арасында кармалана калды, ә мин шул арада куыштан тиз генә чыгып ычкындым.

Мин инде котылдым дип тынычланып, караңгыда ашыкмый гына кайтып бара идем. Ә ул әле һаман суынмаган, күрәсең, тиздән куып

житте дә, баудан ычкынган кебек исәренеп, тагын бәйләнергә тотынды. Минем тавышка шунда тиз генә син килеп житмәсәң, хәлем хөрти иде.

## Хәерлегә түгел

Тәнәфестән соң утрауда мәҗлес тагын җанланып китсә кирәк, берсеннән-берсе катырак кычкырып сөйләшү, гармун, җыр тавышлары оторы көчәя барды. Кунакларның булуы җиткән бугай, нинди көйгә җырлауларын да аңларлык түгел, һәркайсы үзенчә мөгри. Ул да түгел, арадан берсе әче итеп сызгырып җибәрә, кемнәрдер тыпыр-тыпыр бииләр. Пәри туе кебек дөбер-шатырдан бөтен әрәмәлек гөр килә, куркудан уянган кош-корт коркылдап куя.

Бу шау-шуга шкиперның саесканы да йокламаган, уяк булган икән. Кинәт шул һич көтмәгән җирдән: «Киләләр... Киләләр-р...» — дигән сыман тавыш күтәрде, аңар ияреп бурзай ярсулы ырылдарга тотынды. Әле һаман өстәл янында йоклап утырган шкипер үзе дә шундук уянып, пружина кебек, ялт торып басты.

Тиктомалдан кузгалган бу ыгы-зыгы башта миңа һичнинди сәбәпсез, йокы аралаш саташу, иләс-миләсләнү кебек тоелган иде. Колак салыбрак тыңлап карасам, чынлап та безгә таба нәрсәдер үкереп килә, ара якынайган саен аның тавышы көчәя бара иде. Мин аның кай тарафтан,— үр яктанмы, түбәннәнме,— ишетелгәнен чамаларга өлгермәдем, төн карасы эченнән зур тизлектә моторлы көймә килеп чыкты һәм, тын су өстендә дулкыннар кузгатып, баржа белән янәшә туктады. Аның мотористы — тузгак чәчле чандыр егет — шыпырт кына нәрсәдер хәбәр итүгә, сәрхүш шкипер кинәт корт чаккандай:

— Милиция нарядымы?!. Кай яктан киләчәкләр?..— дип кычкырып җибәрде.— Хәзер үк барып әйтергә кирәк, тизрәк таралсыннар... Әйдә син дә минем белән, ярдәм итәрсең...

Алар бик тиз йөгереп барып җиттеләр, күрәсең, берничә минуттан тегендә җыр, гармун тавышлары басылды. Әйләнә-тирәгә шом таратып шау-шулы ыгы-зыгы, тәртипсез кабалану кузгалды. Тиздән алар берберсен ашыктыра-ашыктыра әрәмәлектән яр читенә килеп чыктылар. Баш кунак көчкә басып тора, бер яктан аны район начальнигы Петраков, икенче яктан — Азалия култыклаган. Озата йөрүчесе күзлексез начар күрә, ахрысы, штурман Артурга тотынган. Башкалары төрле савыт-саба, аш-сый тулы сумка, тартма күтәргән. Барысы да иләс-миләс, бер-берсен этә-төртә кабаланып ашыга.

Сыгылмалы тар такта басмадан баржага күтәрелгәндә авыр гәүдәле Семен Федорович тотрыклыгын югалтып, кинәт як-якка авыша, һавада тотка эзләгәндәй, кулларын болгый башлады, башындагы кайма читле шәп фуражкасы суга төшеп китте. Аның үзен мәтәлеп егылудан көчкә тотып калдылар.

Бу шау-шу зирәк саесканга җитә калды булса кирәк, ул бәла хәбәрчеседәй: «Хәерлегә түгел... Хәерлегә түгел...» — дип әсәренеп шомлы тавыш күтәрде. Якында гына бәйдә тыныч яткан бурзай да ыгы-зыгылы сәрхүш кунакларны кертмәс өчен өзгәләп ташлардай ярсып өрә башлады. Хуҗасы аны читкәрәк күчереп бәйләде. Тик шуннан соң гына мөхтәрәм кунаклар баржа аша хәвеф-хәтәрсез үттеләр һәм, баркас палубасына аяк басып, ниһаять, җиңел сулыш алдылар.

Бары тик ярсулы саескан гына, кемнедер ләгънәтләгәндәй:

— Хәерлегә түгел!.. Хәерлегә түгел!..— дип гыжылдап, әйләнә-тирәгә шом тарата иде.

Штурман Артур сизелерлек сәрхүш булса да, ничек тә берешмәскә, үзен кулга алырга тырыша. Район начальнигы Петраков хәзер үк кузгалырга кушу белән абына-сөртенә тимер баскычтан рубкага менеп китте. Аның артыннан күтәрелгән рулевой Харитонның чалбар кесәсеннән аракы шешәсе тырпаеп тора иде.

Мин дә тиз генә аска үз постыма төштем, рубкадан машинаны худка җибәрергә, аннары бар куәтенә эшләтергә фәрман булды. Ишкеч вал зур тизлектә зырылдап әйләнә, бөтен корпус дер-дер калтырый башлады, ә без бәйләп куйган кебек, һаман бер урында торабыз, һич кузгалып китә алмыйбыз. Менә өстә нәрсәдер ухылдап куптарылган, шарт-шорт сынган кебек булды. Әле генә куштанланып кунакларга булышып йөргән шкипер кинәт ут чыккандай:

— Туктагыз, шайтаннар! Күзегез чыккырлары, бөтен ныгытмаларны җимерәсез ич,— дип яман сүзләр белән сүгенә башлады; аннан катырак ярсып бурзай һау-һу куптарды, шомлы тавыш белән саескан тагын: «Хәер-рлегә түгел... Хәер-рлегә түгел...»— дип гыжылдарга тотынды.

Тиз генә машинаны туктату белән моның сәбәбе дә ачыкланды. Исерек баш рулевой-матрос Харитон арткы чалканы ычкындырырга оныткан, штурман Артур шуны күрмичә, машинаны бар куәтенә эшләтергә команда биргән булып чыкты. Нәтиҗәдә, баржаны яр буена тарттырып бәйләнгән тросларны өздереп, басманы җимереп, үзебез белән тарттырып китә язганбыз. Бүтән чакны моның аркасында зур җәнҗал чыгар, закон кушканча рәсми акт язылып, штурман җавапка тартылыр иде. Хәзер вакланып торырга вакыт юк. Зыян-низагны зурга җибәрмәделәр.

— Ярар, тамак ертып кычкырышудан файда юк. Иртәгә балыкчылар кайткач, боларын алар белән бергә үзем рәтләрмен,— дип, иң акыллы фикерне исерек шкипер әйтте.— Булышкан өчен аларга тамак чылатырга бераз шайтан сөте калдырыгыз да, тизрәк шылыгыз. Шуның белән вәссәлам: сез монда булмаган, мин күрмәгән...

Бу киңәшкә барысы да бик теләп, берсүзсез риза булдылар. Азалия кушуы буенча Бәдретдин абый сумкадан берничә шешә аракы тартып чыгарды. Шкипер аларны борт аша гына сузылып алды да:

— Әнә үр яктан ниндидер ут якынаеп килә... Милиция катеры булмагае, тизрәк шылыгыз. Төн караңгы, бәла-казага юлыгуыгыз бар, сак йөрегез,— дип, безгә хәерле юл теләп калды.

Баржа янынннан кузгалу белән, узышка чыккан кайнар чабышкы кебек, зур тизлектә китеп бардык. Бу тирәдә елга тармагы бик тар һәм дугайлы-дугайлы, әледән-әле уңга-сулга борыла-борыла элдертәбез. Сайрак урыннардан үткәндә елга төбенә бәрелүдән баркас сикереп-сикереп куя, яр читендә суга салынып үскән талчыбык иллюминаторларны чалт-чолт камчылый.

Ниһаять, түзмәдем, нигә болай чамасыз кызулыйлар дип, тамбурдан башым күтәреп карадым. Алда — дөм караңгы. Артыбыздан гудок кычкырта-кычкырта һәм прожектор белән яктырта-яктырта ниндидер судно каулап килә. Ә безнең сигнал утларыбыз сүндерелгән, бәладән качкан пиратлар шикелле, җан-фәрман җилдертәбез.

Эзәрлекләүче судно безнең койрыкка баса килә, ара якыная бугай, штурман Артур калтыравыклы тавыш белән:

«Самый полный... Ишетәсеңме, самый полный»...— дип әледән-әле мине дә куыра.

Машина каты шауласа да, сөйләшү трубкасына якынрак килеп тыңласаң, рубкада ниләр булганын ишетеп чамаларга мөмкин. Штурманның күзләре, әлбәттә, алга төбәлгән, артка борылып карарга вакыты юк. Рулевой Харитон аңа әледән-әле:

— Якыная... якыная... Өч-дүрт минуттан куып җитүе ихтимал,— дип хәбәр итеп тора.

— Өч-дүрт минутмы?.. Алайса котылдык...— диде, штурман шатланып.— Әнә Кама киңлегенә чыктык бит. Алар монда килеп җиткәнче, без төн карасы эчендә эреп югалачакбыз... Ух, тамагым кипте. Харитон дус, кесәңдәге шешәңне ач әле, хәзер инде шатлыктан авыз чылатып алырга да мөм...

Ул соңгы сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, кинәт үзгәргән йөрәк яргыч тавыш белән: — Ах-х... Харап булабыз...— дип кычкырып җибәрде. Һәм шунда ук безнең баркасны нәрсәдер төртеп аударды һәм, дөбер-шатыр шыгырдап өстебездән үтеп китте. Ут сүнде, асты өскә әйләнгән корпус эченә гөрләп су тула башлады. Мин караңгыда нинди бәлагә дучар булуыбызны абайламый да калдым, башыма нәрсәдер бәрелеп, күземнән утлар күренде, аңымны югалттым...

## Су төбендә бер төн

Авызыма су тулуга чыдый алмыйча, тончыгып уяндым һәм буылып-буылып укшый башладым. Үзем муен тиңентен су эчендә утырам. Кайда икәнемне, бу хәлгә ничек эләгүемне һич белә алмыйм.

Өнемме, бу әллә төшемме дип беравык шомланып торганнан соң, коточкыч һәлакәткә дучар булуыбызны хәтерләдем һәм асты өскә әйләнеп суга баткан баркас эчендә калуымны төшендем. Әҗәлем шушы икән дип йөрәгем жу-у итеп китте.

Әйләнә-тирәмдә тынлык, кайдадыр якында гына йөрәккә шом салып ишетелер-ишетелмәс кенә нәрсәдер чырылдый. Караңгыда кармалап эзли торгач таптым, ябылып бетмәгән иллюминатор ярыгыннан чаптырып су керә икән. Көч-хәл белән ябып, суны туктаттым.

Әмма су барыбер бүтән тишек-ярыклардан керүен дәвам итә, акрынлап күтәрелә бара, тончыкмас өчен аягүрә бастым. Хәлем хөрти, тиздән корпус эче тулып, мин баштанаяк су эчендә калып, гарык булачакмын.

Асты өскә әйләнгән булса да, хәзергә баркас әле йөзмә хәлдә, салмак кына тибрәнә-тибрәнә агым уңаена бара бирә. Менә ул елга төбендәге сайлыкка төртелеп, кинәт кыйшайды, корпус эчендә шул якка ташланган су массасы мине дә тәгәрәтеп алып китте. Көч-хәл белән аякка бастым, шул арада эчемә тулган мазутлы судан косып арындым.

Мәгәр бераздан корпус эчендә су басымы белән һава басымы тигезләнде бугай, су күтәрелү тукталды шикелле. Аның каравы һава басымы күкрәкне кыса, тын алуы сизелерлек кыенлаша башлады. Гел басып торудан тез буыннарым калтырый, трап култыксасына көчкә тотынып торам, хәлдән тая баруымны, уйларым буталуын сизәм. Аңым ачылган араларда: «Бирешмә, ничек тә түз... Минем монда икәнемне беләләр бит, тиздән ярдәмгә килеп җитәрләр...» — дип үземне өметләндерергә тырышам.

Мин аркам белән сөялеп торган тимер стенаның (переборканың) теге ягында кинәт нәрсәдер кыштырдаган кебек тоелды. Мин тук-тук итеп җавап бирүгә, аннан кемдер тагы да катырак шакый башлады, хәтта ачыргаланып кычкырган тавыш та тонык кына ишетелгәндәй булды... Бу аның соңгы өне булды бугай. Шуның белән тыны бетте, җан тәслим кылды, күрәсең, ул яктан бүтән берни дә ишетелмәде. Ирексездән, инде күп калмады, миңа да чират җитә, дип уйлап куйдым. Барыннан да бигрәк улым Мансурны ятим калдырып, хатыным Сәрвиназдан, яңа гына табылган әтиемнән аерылып китүе аяныч...

Ә өстә тормыш үз юлыннан бара бирә бит. Мин моны сизеп торам. Якыннан гына суднолар үткән саен шаулы дулкыннар килеп бәрелеп, баркасны як-якка кыйшайта, корпус эчендәге су чалт-чолт чайкала, биткә

чәчрәп йөдәтә.. Ярый әле әти бу өергә ияреп бармаган, югыйсә, минем кебек, ул да харап булачак иде бит.

Хәзер инде минем тез буыннарым гына түгел, бөтен гәүдәм калтырый, аның саен хәлдән тая барам. Авыз, борынга мазутлы су тулмасын өчен иягемне югары күтәрәеп торырга мәҗбүрмен.

Әнә шулай җәфа чигә торгач, мәңге бетмәс кебек тоелган озын төн, ниһаять, үтте, таң атуын хәбәр итеп, су катламы аша иллюминаторлардан тонык кына булып яктылык шәүләсе күренде, шуның белән күңелдә янә өмет туган кебек булды.

Тиздән мин тагын аягүрә баскан килеш саташа башладым, ахры. Түшемдә якында гына нәрсәдер шакыганын ишетәм, баш өстемдә кемнәрдер дөп-дөп басып йөриләр шикелле.

Чү, төш түгел, коткаручылар килгән ич... Водолазлар булса кирәк. Бик акрын кыймылдасалар да, корпус тирәсендә нәрсәдер маташтыралар. Ә мин тәмам йончыганмын, тез буыннарым дер-дер калтырый, бер генә минут та басып торыр хәлем юк. Түзә алмыйча чүгәләсәм, мин бүтән күтәреләчәк түгелмен, ниһаять, котылам дигәндә генә суга батып харап булачакмын... Кызганыч, тышкы якта һаман сузалар, шак-шок бәреләләр, нәрсәдер җайлыйлар...

Менә әлегә тикле сайда хәрәкәтсез утырган баркас кинәт чак кына кузгалган кебек булды. Әһә, трослар белән эләктереп, йөзмә кран ярдәмендә күтәртәләр бугай. Баркас югары күтәрелә барган саен, әйләнәмдә суның кимүен сизәм, иллюминаторларның өскә калкып чыгуын күрәм һәм, бүтән басып тора алмыйча, сыек чыбык кебек сыгылып төшәм.

Корпус эченнән су бушап бетү белән машина бүлегенә барыннан да элек әти килеп керде һәм ярым караңгыда миңа абынып чүт егылмады. Тел тибрәтерлек дәрманым булмаса да, мәгәр күрәм: мине үлгән дип хәсрәткә төште, ахры, таш кебек катып калды, авыр сулап куйды. Аннары минем иреннәрем кыймылдавын күрде бугай, тиз генә иелеп, пульсымны капшап карады да, шат тавыш белән:

— Тере бит... Чынлаптыр исән, йөрәге тибә!..— дип кычкырып җибәрде.

Шул арада машина бүлегенә тагын кемнәрдер кереп, минем тирәмдә ах-ух итteләр. Арадан берсе үзалдына сөйләгәндәй:

— Кара син аны, монысы исән калган, бәхете бар икән...— дип гаҗәпләнде.

Шунда мин хәлсезләнеп, тагын һуштан язганмын, бүтән берни дә хәтерләмим...

## Сәрвиназ нишләгән?

Ургыл агымлы зур елгада су коенганда кинәт төпсез упкынга эләктем. Гөрелдәп бөтерелгән агым үз тирәсендә әйләндереп йөртәйөртә мине төпкә тарта. Ярдәмгә чакырып кул болгыйм, кычкырам. Яр буенда җитәкләшеп йөрүче улым Мансур белән Сәрвиназ, мине бар дип тә белмәгәндәй, ашыкмый гына китеп баралар. Ә упкын мине аның саен төпкә тарта. Менә-менә батам, инде бетәм дигәндә:

— Коткарыгыз-з... харап булам-м...— дип көчкә кычкырып җибәрдем һәм үз тавышыма уянып киттем.

Шөкерана, бу бәла өндә түгел, төштә генә икән. Үзем шабыр тиргә батканмын, дер-дер калтырыйм. Кыйнап ташлаган кебек бөтен гәүдәм үтереп сызлый, кыймылдарлык та җегәрем юк.

Күземне ачсам, тирә-юнем караңгы, йомшак урында ятам. Еракта-еракта, күк күкрәгән шикелле тонык кына гудок тавышлары яңгырап үтә. Менә мин йокыдан тәмам айныдым, су астында газаплануларымны хәтерләп, йөрәгем кузгалды. Тик бернәрсә, бу бәлагә ничек дучар

булуыбыз, безне кем аударып суга батыруы аңлашылмый. Кешеләр нихәл икән, бәла-казага тарымадылар микән?..

Ул хакта уйлый башлау белән тагын йөрәгем кузгалды. Тыным кысылуга чыдый алмыйча:

— Уф, һава җитми...— дип авыр көрсендем.

Мин моны эчтән уйлагандай акрын гына әйттем, якын-тирәдә беркем дә юк сыман иде. Чынлыкта исә янәшәдә генә кемдер балаларча түземсезлек белән:

— Әнә, әти уянды ич... Әти уянды...— дип кычкырып җибәрде, калын шторны яртылай ачып, мин яткан якка улым Мансур атылып керде, караватка сикереп менеп, муеныма сарылды, әтәләнеп битләремнән үбә башлады.

Күктән төшкәндәй Сәрвиназ да пәйда булды, тәрәзә, бүлмә шторларын ачты, Мансурны бераз тыярга теләп:

— Ай, тукта, улым, алай ярамый... Әтиеңне авырттырырсың,— диде, баш очыма утырып, маңгай тиремне сөртеп алды.

Әле генә төшемдә Сәрвиназ белән улым мине упкын эчендә калдырып киткәнгә бик нәүмиз идем. Менә хәзер көтмәгәндә шуларның килеп керүе — күзгә яңгырлы көнне караңгы болытлар арасыннан кояш елмаеп караган кебек, дөнья яктырып китте. Сәрвиназга рәхмәт инде, хәвефле хәбәр ишетүгә, улымны ияртеп, күне-сәгате белән килеп җиткән бит.

Ә Мансур мине әле һаман танып бетермәгәндәй, күзләрен түгәрәкләндереп, бермәл сәерсенеп карап торды да:

— Әтием, синең чәчең мондый түгел иде, менә бу төшен агарткансың икән,— диде, маңгай чәчемә кагылып.

— Фу, бу очлы күзнең күрмәгәне юк. Бер уч маңгай чәчең чынлап та ап-ак булган икән,— дип Сәрвиназ да бик гаҗәпләнде.— Әйтүе генә ансат, шул тикле коточкыч газаптан чәчең агару түгел, акылдан язуың да ихтимал.

Хәер, Сәрвинең үзенең дә битләре сизелерлек суырылган, күз төпләренә борчылу күләгәсе кунган. Аның белән сөйләшүдән мин үземнең база медпунктында ятуымны белдем. Ашыгыч ярдәм врачы имгәнү, яралану юк, берничә көннән нервлары тынычланып хәл кергәч, аякка басар дигән. Турыдан-туры әйтмичә, йомшатып кына сөйләсә дә, Сәрвиназ үзе дә рухи ударга дучар булган: ирең су төбендәге баркас эчендә һәлак булды, дигән хәбәр алгач, бирегә юл буе елап килгән. Менә хәзер тагын күз яшьләрен сөртә-сөртә:

— Сине исән-сау күрер көн дә бар икән, күңел әле һаман ышанып бетә алмый,— диде.

— Ник ышанмыйсың... Әти яр буенда яткан мәетләр арасында түгел, менә исән ич... Җитәр, елама инде,— дип, Мансур әнисен юатырга кереште.

Ә мин аның сүзләрен башыма сыйдыра алмыйча кинәт миңгерәп киттем, зиһенем чуалды. Көч хәл белән:

— Нинди мәет, кемнәр ул?!.— дип әйтә алдым.

Минем нервлануым йөземә чыкты, булса кирәк, Сәрвиназ ничектер югалып калды. Ни әйтергә белмәгәндәй ык-мык итеп:

— Рәтләп күрмәдем, кемнәр икәнен танымадым,— диде.

— Оныттыңмыни, әни... Азалия апайны таныдык ич...

— Их, син малай актыгы, әти-әниең сөйләшкәндә тик тор әле,— дип, Сәрвиназ Мансурны җиңелчә шелтәләп туктатты:— Таһир җаным, мин сиңа барысын да үзем сөйләрмен... Ә хәзер менә нәрсә: врач сиңа уянгач та укол бирергә язган иде, әйдә шуны эшлик әле.

Әнә шулай үзалдына сөйләнә-сөйләнә ул күлмәк җиңемне кайтарып күтәрде, шприц белән беләгемә чәнчеде. Боз тигәндәй, шул төшемне дару

тундырып алды. Аннары бу салкын төер жылы агымга әверелеп, бөтен тәнгә таралды, салмак дулкын мине каядыр алып китте.

## Бабай, ник син безгә килмисең?

Йокыдан уянып күземне ачу белән:

— Сәрвиназ... Мансур... Бик сусадым, су бирегез...— дип сорадым.

Яртылаш ачык шторның теге ягыннан:

— Су кирәкме?.. Хәзер була ул,— дип ир кеше җавап кайтарды. Кем тавышы икәнен танырга өлгермәдем, сулы стакан тотып әти килеп керде.— Сәрвиназ белән Мансур ашханәгә төшеп киткәннәр иде, тиздән менеп җитәрләр. Алар бүген көндезге теплоход белән килеп төштеләр. Без таныштык инде, Мансур белән дуслашып та өлгердек. Әмма мин синең әтиең икәнне белмиләр әле, анысын үзең әйтсәң, әйбәтрәк булыр шикелле... Шулай да бәхетебез бар икән, мәйтәм. Юкса бик борчылган идем, күп еллар көтеп табышканнан соң, шундук сине бөтенләйгә югалту ифрат авыр булачак иде...

Инде үзем бала атасы булсам да, әтинең бу сүзләреннән күңелем тулды, күзләрем яшьләнде...

Әмма, күрәм, әтинең яртылаш өтелгән кашлары салынкы, сүз арасында әледән-әле чырае сытылып куя иде. Ирексездән:

— Әтием, кәефең шәп түгел шикелле, берәр җирең авыртамы әллә?— дип сорадым.

— Юк, авыртудан түгел,— диде әти, тирән көрсенеп.— Әлерәк кенә мәетләрне теплоходка төяп шәһәргә озаткан идек. Бик авыр күренеш, шуның тәэсиредер... Азгын бәндәләр аркасында харап булган гаепсез кешеләрнең мәетләрен төяп озату, туганнарының күз яшьләрен күрү җанны әрнетә.

Аста машина бүлегендә булганлыктан, мин авариягә ничек эләгүебезне күрмәдем бит. Бер башлагач, әти анысын да бәян итте: тар елга тармагыннан Кама киңлегенә чыгу белән безнең баркас үрге яктан ыжгырып килүче зур теплоход борыны астына барып кергән дә йөзтүбән капланып тапталган. Чөнки рубкада штурман да, рулевой да исерек, аңгы-миңге; караңгыда теплоходтан да күрмәгәннәр, баркасның сигнал утлары сүндерелгән булган. Нәтиҗәдә баркастагы бар халык җан тәслим кылган, бер мин генә исән калганмын. Мәрхүмнәрнең агым уңаена үле гәүдәләрен балыкчылар җәтмә белән җыешканнар. Арада бары тик безнең Бәдретдин абый гына әле һаман табылмаган...

Бу җан өшеткеч авыр хәбәрдән, башыма тау ишелгәндәй, тәмам миңгерәп калдым, күз алларым томаланды. Көч-хәл белән аңга килдем. Су төбендәге баркас эчендә өметсезлеккә төшкән газаплы минутларда мин алар турында: бәхетлеләр, исән калалар, дип уйлаган идем бит.

Озакламый ашханәдән Сәрвиназ белән Мансур менеп җитте. Өстенә тәлинкә каплаган мискидә миңа да нәрсәдер алып менгәннәр. Мансур миңа килеп сыенды, зур ачылган күзләре белән әтигә карап:

— Абзый, синең маңгаең, битләрең ник әтинеке төсле түгел, ник ямаулы-ямаулы?— диде кыюсыз гына.

Бу сорау Сәрвиназга урынсыз тоелды бугай:

— Ах, син, тел бистәсе, олылар янында тик кенә утыр, тының чыкмасын,— дип малайны туктатырга теләгән иде.

— Зыян юк, сораштырсын, кызыксынучан, төпченүчән булып үссен,— диде әти.— Минем бит битләрем дә сезнеке шикелле шома иде. Кайчандыр Мансур яшендәге бер малайны ут эченнән алып чыкканда каты пештем, врачлар үлемнән көчкә саклап калдылар, тәнемнең көйгән җирләренә ямау салдылар, җөйләделәр.

Әтинең бу сүзләреннән, Мансурдан бигрәк, Сәрвиназ ныграк әсәрләнде.

## Ышаныргамы, юкмы?

Безнең Кама елгасына гравий чыгару районына командировкага баруыбыз әнә шундый авыр фаҗига белән тәмамланды. Ул хакта сатлык җаннарны гаепләп, шулар аркасында һәлак булган пешекче кызларны кызганып язылган үзәк өзгеч бәет көне-сәгате белән тирә-юньдәге шәһәр, авылларга, пристаньнарга таралып, халык күңеленә шом вә хәсрәт салды.

Бу фаҗигадән соң бераз хәлем җиңеләйгәч, Сәрвиназ мине Аракчинога үзләренә алып кайтты. Менә икенче ай инде мин монда, Сәрвиназ эштә вакытта Зариф бабай белән улым Мансур тәрбиясендә яшим. Әти әле һаман командировкада, ватылган баркасны Чистай заводында ремонтлата. Ара-тирә хәл белергә бергә эшләүче иптәшләрдән берәрсе килгәли.

Беркөн транспорт милициясеннән тикшерүче килеп озак төпченде. Башта ул миңа авария турында, сәрхүш түрәләр, аларны зурлап сыйлаучы артык кунакчыл хуҗалар турында сораштырыр кебек тоелган иде. Ә ул исем, фамилия, адрес кебек формаль мәгълүматларны язып алганнан соң:

— Әйтегез әле, гравий чыгару районыннан кайткач, сезгә монда шеф-повар Солтанов Бәдретдин белән очрашырга туры килмәдеме? — дип сорады.

— Чү, ни сөйлисез сез?.. — дидем, шаккатып. — Шеф-повар Бәдретдин Солтанов авария вакытында һәлак булды бит ул, үлгән кеше белән ничек очрашыйм мин?!.

Хәзер инде тикшерүче аптырап калды:

— Туктагыз әле, ни сөйлисез сез? — Әниегез сезгә берни дә әйтмәдемени? — дип кара күн тышлы портфеленнән кәгазь чыгарды. — Әниегез милиция бүлегенә биргән гариза бу. Анда авария булган төннең иртәгесен Бәдретдин Солтановны күршеләрегез поселокта күргән, әниегез базарга киткән арада, аның алтын балдак-беләзекләрен, асыл ташлы алка, муенсаларын, акчасын, сатып алынган ваучерларын урлап качты, дип зарланып язылган. Әниегезнең әйтүенә караганда, ул хәзинәнең күп өлеше шәхсән сезнеке исәпләнә... Дөрестән дә шулаймы, ул тикле алтын, акча, ваучерлар чынлап та булганмы, аның күпме өлеше сезнеке?

— Нинди хәзинә, нинди ваучер ул... Белмим, һич күргән, ишеткән нәрсәләрем түгел.

Бу минем өчен һич тә көтелмәгән яңалык булды. Кара син ә, әнинең иң ышанычлы кешесе әнә кем булып чыккан, имеш!..

— Ихтимал, белмәвегез бик ихтимал, әнкәгез астыртын, хәйләкәр кешегә охшаган, — диде тикшерүче.

Аның бу сүзләреннән икеләнеп калдым: Бәдретдин чынлап та кайтканмы, әллә кемдер әйткән имеш-мимеш кенәме бу? Әгәр авариядән исән калып кайткан булса, әнинең хәзинәсен сыптыруы бик мөмкин, бу аның холкына туры килә бит.

## Әнине кем талаган

Мин Аракчинода тора башлаганнан бирле әнинең килгәне юк иде. Бүген шәһәр базарыннан кайтышлый кереп чыкты. Почмак тәрәзәдән карап тордым, кеше-кара күрмәсен дигәндәй, як-ягына карана-карана бакча яктан гына керде. Редиска, кыяклы суган саткан

булса кирәк, кулында буш кәрзин. Өйдә үзем генә икәнне күргәч, кыюлана төште, һичкайчан булмаганча якты чырай белән:

— Син анда зур бәхетсезлеккә очрагансың, чак кына башың бетмәгән икән. Шуны ишетеп, хәлеңне белергә килүем ие,— дип сораштырган булды.

Аннары, минем җавап биргәнне дә көтеп тормастан, үзенең бәлагә таруы, кемдер кыйммәтле әйберләрен урлап чыгуы турында үрсәләнеп зарланырга кереште. — Бәдретдин урлаган булса кирәк, әйберләрнең кайда икәнен ул гына белә ие. Соңгы вакытта милиция еш кызыксына башлагач, каядыр ычкынып, эзен югалтырга җыена иде. Һичшиксез, шуның эше, шул урлап качкан. Ул хакта милициягә биргән жалобамда да только шуннан шикләнәм дип яздым... Улым, игътибар белән тыңла, тагын менә нәрсә: ул жалобада мин җыен алкашлардан сатып алган ваучерларны синеке, ә алтын беләзек, йөзек, балдакларны Сәрвиназныкы дип язган ием. Икегез дә белеп торыгыз, килеп сораштырсалар-нитсәләр, зинһар, шулай дип, безнеке дип әйтә күрегез. Юкса шул тикле акчаны ничек җыйдың, кайдан алдың дип төпченүләре бар.

Мине, ятим бала кебек әтисез үсәргә дучар иткән, Сәрвиназны рәхимсез җәберләп гаиләмне җимерә язган әнигә ни әйтергә белмичә сүзсез калдым. Бер-беребезнең эчке уйларын аңларга теләгәндәй, беравык күзгә-күз төбәлеп торганнан соң:

— Син зиһенле, үткен күзле хатын бит,— дидем.— Гомер буе хәерсез тормышта яшәвеңне менә хәзер, упкын читенә барып чыккач кына күрдеңмени?!. Әмма мин сиңа берничек тә ярдәм итә алмыйм.

— Ничек инде ярдәм итә алмыйсың? Туган әниеңә булышырга теләмисеңмени, әллә хатының ачуланудан куркасыңмы?! — диде әни, кинәт агарынып.

— Теләмәүдән дә, куркудан да түгел. Чөнки тикшерүче синнән элгәрәк монда булып, миннән сорау алды инде. Аннары син бу гаепне Бәдретдинеңә ягып ялгышмыйсың микән? Әлегә тикле мәете табылмаса да, ул авария вакытында һәлак булган санала бит.

— Юк, үлмәгән ул... Әгәр үлгән булса, мин шәһәргә чыккан вакытны безнең ишекләрне ачып, өйгә керә алмас ие.

— Бәлкем, ул булмагандыр, башка берәү ачкыч яратып кергәндер. Хәзер андый осталар аз түгел, аның саен квартира басып чыгалар.

— Бүтән кеше керсә, идән астындагы күмелгән чүлмәкне таба алмас ие... Соңгы вакытта ниндидер теплоходта буфетчы булып эшәүче яшь кәнтәй белән бутала башлавы сизелә ие, шуның белән кыяклаган, димәк. Мин бит аңа үземә ышанган кебек ышана иям, ләгънәт төшсен үзенә!..

Авыр хәсрәт баскан, юка иреннәре дер-дер калтыраган әни әнә шулай сөяркәсен каргый-каргый өйдән чыгып китте.

## Бабай белән онык

Бүген төштән соң Чистайдан, заводта баркасны карап ремонтлаткан җирдән әти кайтып төште. Ишектән керүгә каршына йөгереп барып сарылган Мансурны күтәреп кочаклады:

— Исән-саумы, үскәнем...— дип күкрәгенә кысты, сумкасыннан алып, кул сәгате хәтле генә түгәрәк уенчык бирде.— Компас бу, диңгездә корабларга юл күрсәтә торган прибор. Урманда адашсаң, сиңа да дөрес юл табарга ярдәм итәр.

Мин аны Сәрвиназның әтисе Зариф бабай белән таныштырдым. Хәләхвәл белешеп, бераз тын алгач, без яр астына төшеп Иделдә су коендык. Мансур һаман Әюп бабасы янында мәш килде, басма өстеннән баштүбән суга чумып күрсәтте, колачлап йөзә белүе белән мактанды, компасына карап дөнья кисәкләрен күрсәтте.

Без су буеннан менгәндә Сәрвиназның табыны әзер иде. Яңа өлгергән редиска һәм яшел суганнан салат ясаган, көндез Зариф бабай белән Мансур алып кайткан мәрсин балыгыннан уха пешергән. Бабайның былтыргы җиләк-җимеш вареньесыннан әчеткән ширбәте бар иде, хрусталь графин белән өстәл уртасына шуны китереп утыртты. Очрашу хөрмәтенә берәр рюмка бушатып, азрак капкалап алганнан соң әңгәмә корып, ике кода бер-берсе белән якынрак таныштылар. Аннары сүз безнең баркас фаҗигасенә күчте, әти аны махсус комиссия килеп җентекле тикшерүе турында сөйләде. «Зөя»не ремонтлау көзгә тикле сузылачак, савыгып аякка баскач, мин дә шунда әтигә ярдәмгә барачакмын икән.

Табын янында гәп корып утыра торгач, шактый вакыт үтте, кояш түбәнәйде, әти кайтырга җыена башлады. Аны поездга озата киттек. Урам буйлап сөйләшеп барганда, станциягә җитәрәк, әти мине култыклап алды, эчке дулкынлану белән:

— Шулай да бәхетебез бар икән, озак еллардан соң булса да, ниһаять, табыштык бит. Безнең өчен иң мөһиме шул...— диде.— Синең өчен мин бик шатмын, шундый болгавыр кешеләр арасында намуслы булып үскәнсең. Комсыз түгел, күпләр кебек эчүчелеккә бирелмәгәнсең, әйбәт гаилә коргансың. Сәрвиназың да, улың Мансур да әйбәтләр. Бер-берегезнең кадерен белеп, матур гомер итегез.

Бер-беребезне табышканнан бирле әтигә әйтергә уңайсызланып йөргән сүзем бар иде. Станциягә барып җитәрәк, менә шул тел очыма килде:

— Әткәй, синең гаиләң бармы, кайда, кем белән торасың?— дип сорадым.

— Гаиләм бар иде, бик тату тора идек, былтыр Казанга кайткач, хатыным вафат булды. Татарстан урамында ике бүлмәле фатирда торам. Болай һичнигә мохтаҗчылык күрмәсәм дә, төзәлмәс яра кебек гел бер хәсрәт — синең табылмавың интектерә иде. Аллага шөкер, менә сез табылдыгыз. Инде бергә яши башларбыз, бу болгавыр заманда берберебезгә таяныч булырбыз.

Тиздән поезд килеп җитте. Без әтине вагон ишегенә тикле озатып куйдык. Шунда аерылышыр алдыннан Мансур аны җиңеннән тартып иелдереп, кечкенә куллары белән муенынннан кысып кочаклап алды да:

— Әйбәт бабай син, иртәгә дә кил, яме... Мин көтәрмен, бергә балыкка барырбыз...— дип битләреннән үбә-үбә саубуллашты.

Мансурның дулкынлануы миңа да күчте, кинәт балага әверелгәндәй, әтине кочаклап үптем. Сабый авызыннан ихластыр әйтелгән җылы сүзләрдән аның да күңеле тулды, күрәсең, әсәренүе йөзенә чыкты. Тиз генә иелеп, калтыраган тавыш белән Мансурга:

— Килермен, үскәнем, килермен...— Бүгенгә хушыгыз, кадерлеләрем,— диде, йомшаруын сиздерергә теләмәгәндәй, күз төпләрендәге яшь бөрчекләрен тиз генә кул сырты белән сөртеп алды.

Вагон эченә кергәч, ул безгә баш изәп елмайды. Без аны поезд күздән югалганчы кул болгап озатып калдык:

— Хуш, әйбәт бабай, сау бул...

— Хәерле юл, әткәй, исән-сау кайтып җит...



# Лена Шагыйрьҗан

## Багышлану

...Ул томаннар калган инде җанда,
таратсагыз, таратмасагыз да...
Мин сезнеке инде, и туганнар,
яратсагыз, яратмасагыз да...

Мәхәббәтсез үрдәк баласыннан
охшап барам инде аккошларга...
Тәңрем кушкан миңа — тумыштан ук
бәхетемне сезгә багышларга...
Мин сезнеке инде бөтенләйгә...
Яратсагыз, яратмасагыз да,—
Салават күперенә керми калган
ак тасмагыз, кара тасмагыз да...

Кайтавазы — даһи мескенлекнең,
шәүләсе бер — сынык сыныгызның.
Җаныгызның тере бер кисәге.
Өзеге бер — сулыш-тыныгызның...
Үзегез мин — иң шәп чагымда да,
ясасам да исәр-ялгыш адым...
Яратсагыз, яратмасагыз да —
нарат-сагыз булып ябышмадым...

Мин сезнеке инде, ватандашлар!
Кай җирләрдә калсам каңгырап та...
Ерак ташлар тавышын тапшыргыч мин,
Бик якында торсам яңгырап та...

*1992.*

---

Лена ШАГЫЙРЬҖАН — *шагыйрә, «Мөлдерәмә күңел», «Ышанам йөрәгемә», «Иман әлифбасы» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

## Кызганыч...

Ялгыз роза чәчкәседәй, янып,
өшеп калдым көзгә бу бакчада...
Җитми калды сөю ялкыннары
дөрләп янган дәртле учакка да...

Җитми калды күкрәү-яшеннәре,
ашыгып узган кыска җәйләр кебек...
Бушап калды җаным, дәртсез каным,
кайнар уксыз калган җәя кебек...

Җитми калды хәтта артык сүзләр,
үтте яшьлек — әйләнеп тә бакмый.
Чәбәләнер идем бии-бии,—
ни кызганыч, инде корт та чакмый...

*1990*

## Аңлашуга өмет

Безнең җырлар — үрсәләнгән
җаннарга терәк әле...
Без аңладык... Сезгә — безне
аңларга кирәк әле...
Чакырсалар, җитәм барып —
чакырымнар киртә түгел.
Соңардым... Аның каравы
инде бик иртә түгел...

Без сезне аңладык күптән...
(Андыйлар сирәк әле.)
Сезгә дә безне тирәннән
аңларга кирәк әле...
Сез миңа — карап тордыгыз.
Мин сезне — күреп тордым...
Сез мине — тыңлап тордыгыз.
Мин сезне — ишетеп тордым...
Күпләр миңа ук аттылар —
ә мин үткен сүз аттым...
Салкын караш, салкын сүздән
өши-өши, боз ваттым...

Йа, Ходам, иңдер җаныма
Галәми ярашуны!..
Аңлатыйм Кеше телендә
мин кешеләргә шуны...
Аңлатыйм шигырь телендә,
яраклашмыйча гына...
Бик якын килмичә, әмма
ераклашмыйча гына...

...Без сезне аңладык күптән —
(Андыйлар сирәк әле)...
Сезгә менә — безне төптән
аңларга кирәк әле...

*1992.*

## Чишмә белән күрешү

— Исән-саумы, Чишмәкәем!
Тигезме агышларың?..
Ничек үтте ничә җәең,
Ничә яз-көз, кышларың?..

Иңнәремдә суларыңны
Күп ташыдым, Чишмәкәй.
Никтер сиңа төшә идем
Гел ашыгып, Чишмәкәй...

Сөйләшергә, серләшергә,
Тыңларга тавышыңны
Гел тар була иде ара...
Үзең дә сагышыңны
Тормагансың сөйләп безгә,
Яшьләр аңламас диеп.
Әйтермен әле, үзләре
Аңлый башлагач, диеп...
Чишмәкәем, күптән сиңа
Су сорап үрелмәдем...
— Кайларда йөрдең соң, бала?..
Бик озак күренмәдең..
Ю битеңне суым белән,
Арын бар сагышыңнан...
Сагынганмын бит үзем дә —
Таныдым тавышыңнан...
Сез китеп югалсагыз да,
Мин бит кипмәдем әле...
Сусап кайтырсыз дип көттем,
Агып бетмәдем әле...

— И, Чишмәкәй! Әнкәм сыман
Юмартсың икән һаман...
Тезләнеп эчим суыңны,
Янам бит, янам, янам...
Оялып синнән — янам...

*1983—93.*

## Юксыллар илендә

*«...Сотри случайные черты...»*
(А. Блок)

Атасызлар, Анасызлар...
Ватансызлар, Алласызлар...
Алма бакчаларын корытып,
Мәхрүм калган алмасызлар...
Корабсызлар, җилкәнсезләр...
Мәчетсезләр, имамсызлар...
Мәгънәсезләр вә тозсызлар,
Шәригатьсез, имансызлар...
Җилләр калган хәрәкәтсез,
Илләр калган бәрәкәтсез,
Бала туган — мәхәббәтсез,
Дөнья туңган — мәрхәмәтсез...
Хәттин ашкан «сыз»лар, «сез»ләр,—
Безга каткан шыксыз сүзләр...
Сызып ташлар идем «сыз»ын,
Бетсә шуннан бәхетсезләр...
Шул «сыз»ларга карап, кемнең
Исән калган җаны сызлар?..
Шул тозсызлар, комсызланып,
Кисмәк-кисмәк кыяр тозлар...

*1992.*

## Шулпасының шулпасы...

Рәхмәт, дөнья! Шәп «сыйладың»,
тәмле булды шул ашың:
Кемнәрдән калган бу «куян
шулпасының шулпасы»?...
Кемнәр өчен пешкән куе
өйрәләрнең өйрәсен
иртә-кичен туглыйсың да,
саласың да бирәсең...
Рәхмәт инде... туйдык тәмам:
көләсе дә, җырлыйсы...
Төште безгә — кояшның да
җылысының җылысы.
Шулпа нәрсә! Чын тормышның
татыйсы иде тәмен! —
Бәлки, Бәхетнең үзен бер
күрсәтер әле Тәңрем...

*1985.*

## Син ышанма, Аллам, аларга!

Алар сиңа ихлас бирелмәгән...
Син ышанма, Аллам, аларга!
Синең исемең белән тырыша алар
Адым саен Сине алдарга...

Алар сиңа барыбер ышанмыйлар...
Һич ышанма син дә аларга.
Алар Җиргә Синнән качып килгән,
Алар оста алдап таларга...

Гөнаһлары артык күп булганга,
«Хәер» суза алар чат саен...
Ышанмасаң минем сүзгә генә,
Шаһитым бар — чатта Ак каен...

Алар көн-төн синең исемең белән
Почмак саен сату итәләр...
Кирәк чакта, иблис-шайтанның да
Үзе белән тату бит алар...

Китап тотып аннан ант итәләр...
Үбү түгел — әзер яларга...
Алар сиңа тамчы ышанмыйлар —
Бик ышанма Син дә аларга!..

Күк тарафларында түгел — фәкать
Акча янчыгында күзләре...
Алтынга бит алар табыналар,
Тиеннәрдән башлап сүзләрен...

Син ышанма, Аллам, андыйларга,
Бер кәлимә сүзләренә дә...
Сиңа түгел, алар — гомер буе
Ышанмыйлар үзләренә дә...

*1993.*

## Кара рәсем

Кара рәсем, тупас пумалалар...
Җанны урлап карак, томалаган...
Ай-Кояш күк тотыла-тотыла янам,
Чыра ягып, кем ул юмалаган?..

Җаныма ул кара буяу салган,
Нәкыш чигеп, йолдыз уясына...
Алып менер чакта кулдан тотып,
Мәхәббәтнең бәллүр кыясына...

Бу җаныма чәчри тора таплар,
Шәфәкъләрдән нурлар коеласына...

Ә адашкан күңел гел тартыла
Һаман шул бер Сөю кыйбласына...
Әҗерен көтә һаман күңелемнең
Ап-ак киндер тарткан киергесе.
Кара буяу сылап үтә җанга,
Әле берсе очрап, әле берсе...

Иң нарасый бизәкләремне дә
Йолкып, талап, урлап китмәсәләр!..
Чәчкәләрдән күчереп алган идем —
Шул җаныма дегет сипмәсәләр!..

*1991.*

## Күңел нечкәргәндә...


Минем дә бит тулган ай күк,
Мөлдерәп туласым килә...
Минем дә бит, синең кебек,
Бәхетле буласым килә.
Бер-береңнең кадерен белү
Нигә соң болай соң килә? —
Синең дә бит, минем кебек,
Бәхетле буласың килә...

Матур димә яздан — җәйне,
Матур, димә җәйдән — көзне.
Һәр бәхетнең кабатланмас
Үз сулышы, үз мизгеле...
Яз килсә дә, җәй килсә дә,
Тигезләми бәхет безне...
Тик эзләмик — бәхетсезләр
Арасыннан үзебезне...
Күңелемнең ак энәсе
Нечкәргәннән нечкәрә гел...
Моңсуланам — моң суларын
Бик тирәннән эчкәнгәме?
Бер-береңнең хәлен белү
Нигә соң болай соң килә? —
Минем дә бит, нәкъ синең күк,
Бәхетле буласым килә!
Синең дә бит — нәкъ минем күк, —
Бәхетле буласың килә...

*10.12.93.*

**Рим**

**Идиятуллин**



## Шундый көннәр була

Була шундый көннәр: көләч Кояш
Күзен кыса миңа беренче,
Яртылаш ят кешең, шат елмаеп,
Әйтер кебек: «Рим, сөенче!»

Кызык та соң дөнья,— көнгә чыксаң,
Куанычлы хәбәр көтәсең;
И ваемсыз бәндә! — онытасың
Кайтып булмас җиргә китәсең.

...Сүнә кояш, салкын чоңгылына
Чәнти бармак чаклы арадыр;
Сөенечтән мәхрүм бәндәләрнең
Йөрәгеннән каннар тамадыр.

*1994.*

* * *

«Гөнаһсыз фәрештә түгелсең...» —
Дип йөрәкне өзгәләмәгез;
Мин кечкенә кояш (кичке),
Нурларым да сүрән төште,
Якыннарым, үпкәләмәгез!

«Мәхәббәттә Мәҗнүн түгелсең...» —
Дип бәгырьне кискәләмәгез;
Шагыйрь халкы гомер бакый
Гүзәллеккә тәрәз шакый,
Сөйгәннәрем, үпкәләмәгез!

«Дөньяда мәңгелек түгелсең...» —
Дип җанымны телгәләмәгез;
Алмаларны юып, сөрттем,

---

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) — *Уфада яшәүче татар шагыйре. Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, башкорт телендә дөнья күргән «Хәерле иртә» исемле китап авторы.*

Гөлләргә су сибеп киттем,
Исәннәрем, үпкәләмәгез!

*1994.*

* * *

Җир-күктәге барча җисемне дә
Кунак иттем җылы җанымда,
Суга баткан җәйдә яр читеннән
Сыек кулын сузган Талыма
Рәхмәтлемен.

Зар-кайгымны тыңлап тормыйча да
Куган чакта якын туганым,
Ялгызны бит ялгыз аңлар диеп,
Көткән идем Айның тулганын
Дүрт күз белән.

Ә күктә соң күпме кардәшләрем!
Ага Болыт. Аһ, ул болытлар! —
Тезләремә чүгеп, көлә-көлә
Күз яшьләрен сыккан оныклар
Минем алар.

Күк йөзенең җем-җем шадралары,—
Йолдызлар бит,— яшьле күзләрем.
Көзге төндә өшеп күшексәләр,
Учларыма алып үзләрен
Җылыттым мин.

Бер җанымны меңгә бүлә-бүлә
Яшәмәдем, бугай, мин юкка:
Йолдызны Ай белән кавыштырдым,
Сыек Талны елак Болытка
Тоташтырдым.

...И Җаныем, сәламнәр дә бармас
Җирләргә мин китеп юлыксам,
Түкмә яшең, көзге йолдызларны
Кочагыңа алып җылытсаң,
Кайтырмын мин.

*1994.*

* * *

О, Могҗиза! Торма якында,
Торыр булсаң әгәр якында
Гайбәт кубар синең хакыңда.

Туры килер шуны татырга:
Кояш булсаң, бирмәс балкырга,
Алтын булсаң, манчыр бакырга.

*1994.*

## Бер сөйләгән идең...

Саламга дип киткәнсең кыш, мине
Салкын өйдә ялгыз калдырып:
— Көчкә эзләп таптым сине,— дидең,—
Мич эченнән, чыра яндырып...

Бүген сине мин югалттым, әнкәм:
Каберендә киттем калдырып,
Тик табалмам сине — эзләсәм дә
Көндезләрен чыра яндырып...

*14 февраль, 1992.*

* * *

И әнкәем, табутың! —
Сабый чагымда тирбәлгән
Бишегем кадәр генә.
Жаның берлән тәнеңне дә
Әллә безгә өләшкәнне,—
И ваемсыз балаларың! —
Белдекме бүген генә?..

* * *

Кайларда калды сүрелеп
Жаннарны өтәр хисләр?
Баешларга баккан саен
Калкына үкенечләр.

...Барасы юлым бик ерак,
Офыктан ашкан иде,
Анда бәхет каршыларга
Кочагын ачкан иде;

Елларның мин җилләрдән дә
Житез атында җилдем,
Хыялым белән күкләрнең
Жиде катында идем;

Ак иде минем иманым,
Ярдым һава: «Ха — ак җинә!»

...Сөрлекте атым кинәттән
Һәм кадалдым как җиргә:

Егылганнар кемгә хаҗәт! —
Атым тукталмый китте,
Шөкер иттем шул хәлемә:
«Ярый, таптамый үтте!»

Яраларым ялый-ялый
Киттем тагын кузгалып,
Ялгыз башым шау яланда,
Йөрәгемнән куз алып.

Яктым учак. Тән салкыны
Җанга күчмәсен, дидем,
Сабыйлар бар, дөньясына
Кырау төшмәсен, дидем;

Ут-учагым йолдызларны
Балкытмагандыр, бәлкем,
Тик күкләрне, тик күзләрне
Төтәсләмәдем ләкин;

Бетмәгән икән омтылыш:
Җиһанның тын алышын
Тыңлый-тыңлый акрын гына
Һаман алга барышым:

Көенмәмен,— алда бәхет
Ачмаса да кочагын,
Сөенәмен,— дөрләтерләр,—
Тере калды учагым.

...Көн сүнә үтә күренеп,
Тәмен югалта төсләр;
Ишелә кояш офыкка,—
Ишәя үкенечләр.

*1983.*

## Тоташтыр

*Йосыф ага Гәрәй истәлегенә*

«Арабыздан китте ул»,— дип
Сөйләү, бәлкем, ялгыштыр.
Китмәү, бәлкем, шагыйрьләргә
Килә торган язмыштыр.

Төренсә дә күз яшьләре
Кайгы төсе — карага,
Тереләрдән-тере булып
Утырасың арада.

Халкыңның аһ-зарын тойсаң,
Аһ, авыр кичерәсең,
Ә үзең белеп торасың
Йөрәкнең киселәсен.

Ә язмышың каһарманга
Төшә торган язмыштыр;
Син исәнсең, исәннәрне
Киткәннәргә тоташтыр,
Тоташтыр!

*9 апрель, 1994.*

## Белеп тор!

*(Энекәшкә шаян киңәш)*

Син белеп тор, сине ялантәпи
Утлы куз өстендә биетер,
Бер тамчысы ялгыш тама калса,
Котыпның бар бозын эретер,—
Хатын-кызның кайнар күз яше.

Син сынап тор, агу сораганда
Дару салыр бәллүр савытка,
Гөнаһың юк килеш оҗмахыңны
Әйләндерер утлы тәмугка,—
Хатын-кызның зәһәр күз яше.

Син күреп тор, сыек муеныңа
Камытның иң зурын кидерер,
Әгәр шайтан ияләшкән булса,
Шайтанына башың идерер,—
Хатын-кызның төче күз яше.

Син әзер тор, имеш-мимеш хәбәр
Колагыңа кунса кайдандыр,
Бөртек «юк»ны тулы бер йөк «бар»га
Алыштырып алып кайтартыр,—
Хатын-кызның ялган күз яше.

Син түзеп тор, кала күрмә көнгә
Үзең теләп Себер китәрлек,
Өмет итмә, көн-төн түгелсә дә
Түгел һич тә агып бетәрлек,—
Хатын-кызның дәрья күз яше.

*1994.*

* * *

Тотып булса җилне ятьмәгә,
Булса аңа элмәк кидереп,

Ялган заманнарда турыдан
Ярган өчен күптән асарлар
Иде сине дарга мендереп.

Шул җил кебек чая, ирекле
Ирне күрсәм кышын саламын
Исән башымдагы бүрекне.

*1994.*

ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

## Президентның нотыгы

Ил дә алтын, җир дә алтын,
Рәсәй халкы эштә алдын,
Җиде диңгез артларыннан
Алтын биреп, ашлык алдым.

* * *

*«Билгесез солдат кабере» янында*

Санамагыз безне диванага,
Хакыйкать бар, беркем тигесез:
Нинди ил ул, илен яклаган ир
Үз илендә булса билгесез?!

* * *

Бер авылда бары бер өй калган,
Салкын өйдә — кеше җылысы.
Сөйләп туйгач, көйләп алды әби,—
Туң гасырның соңгы җырчысы.

* * *

«Нинди гүзәл чәчкә!» Бактым аңа
Әллә күпме вакыт тоташтан;
«Нигә әле сула башлады ул?» —
Каплап торам икән кояштан.

* * *

Тор син сакта, Шагыйрь, Җиргә
Бәла-каза килгән вакытта,
Син табиб та, хәзрәт тә бит
Бәндәләрдә хәсрәт бар чакта.

*1969—94.*



**Мөхәммәт Мәһдиев**

# САГЫНАМ, ДУСЛАР, ИЛКӘЙНЕ...

**Мин нәкъ утыз ел Казан университетының татар бүлегендә укытучы булып эшләдем. Шул эшнең күп дәрәҗәләрен түбәннән югарыга таба уздым: ассистент, өлкән укытучы, доцент... Колга башына менеп җилдә җилфердәгән ефәк яулыкны алам дигәндә генә Обком һәм аның факультеттагы иярченнәре аягымнан тартып төшерделәр. Кызу төшкәндә гадәттә кул, тез тиреләре яна, ләкин минем кул да, тез дә янмады.**

**Булса да ул чакта бездә керсез иман, саф күңел,**
**Күп саташтырдык рәзил шәйтанны чын инсан белән.**
**Аңгы-миңге баш белән дә эшләдек, булсын кабул;**
**Җәбраил ачкай ул эшләргә сигез кат күккә юл.**

**(ТУКАЙ.)**

**Һәм менә истәлекләр. Гомерем узган факультет кичәләре турында кечкенә генә хикәячекләр. Хронология сакланмый. Хәтергә кем килә — шул кеше турында. Ләкин күңелемдә әчүташ юк. Юк...**

## I

Коридорда торабыз, тотен чигәбез. Лаборантка әйтә: «Таралышмагыз, бүген ашыгыч рәвештә кафедра утырышы булуы мөмкин, Уфадан бер диссертацияне укырга кешеләр билгеләргә кирәк, Хатип Усманович сәгать икегә килеп җитә»,— ди.

Шулай, эшсез, кагылып-сугылып коридорда йөрибез, сигарет тартабыз. Ниһаять, сәгать ике. Химкорпусның дүртенче кат коридорыннан,

гадәттәгечә авыр атлап, Хатип абый килә. Бераз бөкрәя төшкән, ике култык астында да калын папкалар. Күреп торабыз — йөзе чытык. Димәк, кайсыбызгадыр әйтер сүзе, үпкәсе бар. Аның гел шулай, йөзенә чыга. Исәнләшәбез, ишеген ачып кабинетына уздырабыз. Бераздан көтү булып керәбез, шыбыр-шыбыр урнашабыз. Ул җимерелеп каш астыннан безгә карый, гаҗәпләнә.

— Нәрсәгә җыелдыгыз?

— Хатип ага, безгә кафедра утырышы буласы дип әйткәннәр иде.

Шунда ул безгә җыерылып нәфрәтле караш ташлый һәм зәңгәрлеяшелле тавыш белән өстебезгә ике җөмле ишеп төшерә:

— Нинди кафедра утырышы ул, әнә сез Анголада нинди хәлләр барганын ишетмәдегезмени? Радио тыңламыйсызмыни сез?

Без дә шатланышып таралышабыз — тамак бик ачкан иде. Ә Анголада, тәгаен генә переворот ясап йә берәр полковник властька килгәндер, йә Брежнев безгә әйтмичә генә гаскәр керткәндер. Әмма, безнең тамак бик ачкан иде әле...

## II

Факультет фестивале бара. Партбюро, профбюро мине кыса: мин кураторлык иткән группадан фестивальдә берәү дә катнашмый икән. Әллә нинди сәер группа булды бу: ни җырлаучы, ни биюче юк. Барысы да тәнкыйть мәкаләсе яза, стена газетасына әллә нинди рецензияләр урнаштыралар. Арада икеме-өчме инвалид егет тә бар, лекцияне бүлдереп сораулар бирәләр, семинарда гел бәйләнеп утыручылар бар. Әмма җырчы, биюче юк.

Шулай да, бик нык тырышып, ярымҗырчы берәүне таптым. Октябрь Норлаты мишәре. Гел бишкә укый, бернигә исе китми, юл өстендә «манигъ күрсә» (Тукай), тибә дә аудара...

Сәхнәгә шуны чыгардык «истфилфак» фестивале көнендә. Университетның Актлар залын биргәннәр иде. Бик кыю чыкты сәхнәгә әлеге «Октябрь манигы» (манигъ — киртә мәгънәсендә). Мин горурланып партбюро һәм профбюроның «әдәбият-сәнгать бүлеге» белән җитәкчелек итүчеләренә — ул йә Зәет Мәҗитев, йә Людмила Куткова була инде — карап алам: күрдегезме, Мәһдиев кураторлык иткән группадан фестивальгә нинди егет катнаша! Шалишь, брат, безнең группа белән...

Һәм әлеге «манигъ» баян шавы астында бер җырны бирмәсенме! Зал — аһ! Каян килгән бу егет? Нинди көчле тавыш бу? Кем бу?

Ә, бу — Мәһдиев кураторлык иткән группадан, Октябрь Норлаты егете. Сез «не думайте».... Без менә шулай эшлибез... Ну-ка, ну-ка әле, егетем.

Һәм егетем, залны сихерләп, залны кул чаптырып җырлый:

Суда, суда,<br>
Суда йөзаласыңмы?

Мин горурланып артка борылып карыйм: күрдегезме? Егетем залны тетрәтә:

Мин сине күрми түзалам,<br>
Ә син түзаласыңмы?

Фу ты, блин... Фу ты, мля... Зал егылып, тәгәрәп көлә. Минем башта — инфаркт. Хәер, инфаркт башта булмый бугай ул. Ну инде, миндә инфаркт булды, анысы «тучны», әмма, ул аякларда иде. Горький яза бит әле «Минем университетларым»да: «Минем теш сызлау авыруым бар, әмма ул — йөрәктә».

...Кайтырга чыгабыз. Вестибюльдә кием элгечләре янында фикер алышабыз. Коллегаларым миңа көлеп карый. Миңа кыен.

— Нуруллин алган группа бит ул, што ты хочешь? — ди берсе.— Анда бит гел сәер кеше генә була.

Шунда күзем ачылып китте, җинел сулап куйдым. Ачылды «алдында тарихтан театр пәрдәсе» (Тукай).

Татар бүлегендә шундый легенда яши иде. Доцентлар, профессорлар чират буенча, уртача биш елга бер тапкыр, җәен кабул итү имтиханнарында өлкән экзаменатор булып эшлиләр. Урта мәктәп тәмамлап килгән яшьләрдән студентлар группасын әнә шул өлкән экзаменатор формалаштыра. Үзенә ошаган өметле абитуриентларның колагыннан тарта, тарих, чит тел экзаменаторларының артыннан чаба «ыслушай, менә бу абитуриентны батырма инде», дип телләрен тасма итә. Өлкән экзаменатор нинди — группа шундый. Моны беренче сентябрь көнне беренче лекциягә кергән беренче укытучы шундук аңлап ала. Җайсыз, ерпач, кытыршы бер группа утырамы алдында? Беркемнән дә сорама — бу җәйдә өлкән экзаменатор булып Ибраһим Нуруллин эшләгән. Чибәрчибәр, буйлы, мыеклы егетләр утырамы группада? Әһә, «понятно», бу җәйдә бит имтиханда фәлән ханым белән фәлән ханым эшләгән иде... Ясно... Тез башларын ялтыратып, авыр майлы керфекләрен салындырып, юеш кара карлыган төсле күзләреннән авыр нурлар «сачеп» утырармы ун-унбиш кыз егерме биш кешелек группада? Бәрәч, аңа ник гаҗәпләнәсез, бу җәйдә бит өлкән экзаменатор булып Мәһдиев эшләгән иде...

Университетның тарих-филология факультетында шундый легенда яши иде. Дөреслеккә туры килеп бетми инде ул...

Легенда — сүзлекләрдә әйтелгәнчә, «уйлап чыгарылган» нәрсә. Иң гади итеп әйткәндә — әкият.

Без киенеп университет бинасыннан чыкканда теге «манигъ» Володя Ульянов һәйкәле артына өелгән кар өстенә дүрт-биш кызны бәреп егып, шуларны чикылдатып әвәләп, дөнья шаулата, «Старая клиника» янындагы карт тополь башында йоклаган чәүкәләрне уятып, нервларын боза иде.

## III

Кабул итү имтиханнары бара. Химкорпуста, дүртенче катта, 93 нче ике ишекле аудиториядә. Алгы ишектән керәсең, теманы кара тактага язып куясың (инша), өч тема инде ул, аны бөтен Татарстан белә: 1. Нинди матур минем туган җирем; 2. «Җырларым, сез, шытып йөрәгемдә...»; 3. Һади Такташ традицияләре бүгенге әдәбиятта... Ничә ел инде шулай...

Мин теманы кара тактага язам, кыштыр-мыштыр эш башлана. Өлкән экзаменатор — профессор Вахит Хаков. Без аның белән гомерлек дуслар. Мин — алама, тәртипсез, җайсыз кеше. Вахит Хаков — җайлы, тәртипле кеше. Без — альянс.

Ара-тирә коридорга чыгабыз. Кем алдагы ишектән, кем — арттагысыннан. Арттагысыннан кергәнне, бичара абитуриент сизми, шпаргалка куллана. Университет уставы буенча болай: сочинение (инша) вакытында шпаргалка кулланган абитуриент «автоматически» төшеп кала һәм «приемная комиссиядән делосын алып кайтып китә». Моны бөтен абитуриент белә.

Ләкин бит минем сигарет тартырга дип алгы ишектән чыгып китеп, коридорда сигаретны сүндереп, арткы ишектән шыпырт кына кереп рәтләр арасыннан килгәнне белми ул теге бала, теге бахыр...

Киләм арткы рәтләрдән, киләм күзәтеп. Күрәм, якты ботлы, кыска итәкле бер кыз ботлары арасына шпаргалканы куйган һәм шуннан үзенең өстәлдәге кәгазенә умыра гына бит! Нишләргә? Кыз бик чибәр. Хәзер мин моны тотсам, «дело» сын ябып, университеттан куарга кирәк. «Жалко ведь!» Нишләргә? Бу кызны саклап калырга иде. Шәһәр кызы булса кирәк, юбкасы бик кыска. Шпаргалка өчен бер дә җайлы түгел ул кыска юбка. Киләм арттан әкрен генә, ә теге сизми бит. Әйтерсең, тәрәзә кәрнизенә бәйләп куйган каза итен песнәк чукый. Ләкин песнәк ул, өч-дүрт тапкыр чукыгач, як-ягына каранып ала. Ә бу кыз карамый. Ә мәче һаман якыная. Нишләргә? Тотыла, әрәм була бит бу. Юк, бу баланы сакларга кирәк. Шунда мин аның артына килеп басам да, бик ыспай хәрәкәт белән генә теге шпаргалканы алам. Дөрес, бераз мәшәкать чыга: кызыкай кискен хәрәкәт белән «гармошканы» (шпаргалка гармун формасында эшләнә) эчкәрәк шудырмакчы булды, ләкин кәгазъ минем кулда иде инде. Безнең бу «бәрелеш»не берәү дә сизмәде, күрмәде. Шпаргалканы мин чалбар кесәсенә яшердем. Бераздан бу тирәгә яңадан килдем. Кызыем берни язмыйча тик утыра, яңакларыннан ялкын бәрә иде. Мин аңа шыпырт кына:

— Нигә язмыйча утырасың? — дидем.

Бу инде тулы реабилитация иде һәм ул сулыш алды. Кызу-кызу яза башлады. Мин дә, кешегә яхшылык эшләвемә сөенеп, җиңел сулап куйдым...

Ләкин беренче сентябрь көнне аудиториядә мин аны күрмәдем. Бичара, йә язганы икелек булган инде аның, йә баллары җитмичә калган...

## IV

Факультетның партбюросында «оргсекретарь» булып эшлим. Яхшы итеп, тырышып эшләргә кушалар. «Әнә Табеев үзенең карьерасын шуннан башлады, студент вакытта ук партоешма секретаре булды, диләр». Уйлап йөрим: начар булмас иде, шулай күтәрелеп дөнья оҗмахында бер яшәп алсаң...

Ләкин миндә җыен «пычрак» эш: «персональное дело»ларны мин әзерлим. Кемгә кисәтү, кемгә каты кисәтү, кемнедер партиядән үк чыгарырга. Бүгенге бюрода ике эш: партиягә әле генә кабул ителгән (кандидатлыкка) бишенче курс студенты Х.ның тәртибен тикшерәбез. Җитмәсә, рекомендациянең берсен мин биргән идем.

Гаеп зур: яңа елны каршы алганда студент Х. салкын портвейн эчкән. Тулай торак бүлмәсендә бәйрәм иткәннәр. Бервакыт салкын портвейннан моның эче бора башлаган. Түзгән бу, түзмәгән түгел. Әмма актык чигенә җиткәч, урыныннан сикереп торган һәм, бөтен егет-кызларны гаҗәпкә калдырып, бүлмәдән чыгып йөгергән. Тик... Туалетка барып җитә алмаган, коридорның караңгы башында, бер ишек янында эшен бетергән. Шуннан үз бүлмәсенә кайтып яткан. Ә төн уртасында бу урынга якын бүлмәдә яшәүче кыз торып караңгы коридорга чыгып аяк атлауга, таеп, гөрселдәп барып төшә, яңак сөяген кара янарлык итеп паркетка бәрә...

— Ну, что это такое? — дип гаҗәпсенә профессор Николай Александрович Гуляев, бюро әгъзасы.— Что это за дикость? Просто, я не понимаю.

Х. ның өстенә очып-кунып мин сүгәм.

— Вы же не с того мероприятия начали свой кандидатский стаж,— дип үрсәләнәм (бюро утырышлары бары тик рус телендә генә бара, КПСС, гомумән, рус телендә генә яши иде).

Бичара егетне партиядән чыгарырга дип карар кабул итәбез. Бу инде — миңа эш. Моның «эше» буенча папканы күтәреп мин университет

парткомы белән ике араны таптарга тиеш, аннары Вахитов райкомы бюросына — папканы, егетне алып барырга кирәк.

«Персональ эш»нең икенчесе — аспирант Рим Шириязданновныкы. Сәләтле, шәп егет. Алтын медаль белән мәктәп бетереп Башкортстаннан килгән. Аспирантурада калдырганнар. Без — дуслар. Без — ике кафедрага (тел, әдәбият) өч аспирант. Өченчебез — Фәрваз Миңнуллин. Яшь тәнкыйтьче. Өчебез дә бер үк төрле нужада: берәр балабыз бар, кайсыбыз коммуналкада, кайсыбыз тулай торакта. Аена туксан сигез сум стипендия алабыз. Шуны алган көнне, һичшиксез, «Восток» ресторанына төшеп өстәл алабыз. Борын башына биш сум чыга. И ул андагы утырулар, мәсәхәбә, бездәге акыл. Хәзерге бер генә кооператор да миллион сум түләп өстәл янында безнең дәрәҗәдә акыллы сөйләшеп утырмыйдыр. Ә без — шулай. Рим — татар теле белгече, Фәрваз — татар әдәбияты белгече, мин — тарихчы (теге өлкәләрдә миннән юк). Римны татар теле өлкәсендә шулкадәр әзерлекле диләр, менә бер генә мисал. Мин үземнең бик тә әзерлексез көе аспирантурага эләккәнемне аңлагач (бу турыда «Ачы тәҗрибә» дигән китабымда яздым), ике көннең берендә фәнни җитәкчем Хатип Госман янына йөрдем. Гел консультация алдым. Ул да моңа иялә нде, берәр көнне килми калсам, миңа кисәтү ясый иде. Ә Шириязданов, кайдадыр еракта, кирпеч заводы тирәсендәге коммуналкада яши, ялгышмасам, бала да карый иде кебек. Минем шикелле белемгә ач әрвах булып авызын ачып йөрми. Килми университетка, йөрми консультациягә. Һәм сөйләүләре чын булса, аптырагач, аның «коммуналка»сына фәнни җитәкчесе профессор Мирфатыйх Зәкиев үзе барып йөри икән. Булыр, булыр, университетта шундый галимнәр бар иде ул чакта: берәр аспирант кулына килеп кердеме, ул инде аны кеше итмичә калмый: болар И. М. Ионенко, Н. А. Гуляев, А. С. Шофман, М. Зәкиев — шундыйлардан...

Менә шул мактаулы Шириязданов янган бит әле. Нәрсә белән дигез? Биш ай буе партвзнос түләмәгән. Юк, акча кызганудан түгел. Болай, «просто» ул факультетка килгән көнне взнос җыючы килмәгән, взнос җыючы килгән көнне Шириязданов күренмәгән.

Декан Н. А. Гуляев яңадан гаҗәпсенә:

— Ну что это такое? Я просто не понимаю...

Рим аклана, бала янында утырдым, җае чыкмады, ди. Минем тырышлык белән нибары «телдән кисәтергә» дигән карар кабул итәбез. «А задолженность немедленно погасить».

«Дело»ны мин шул көнне үк университет парткомына илтеп тапшырам. Әле безне анда карарга тиешләр.

Шулай, көтәм. Февраль, март узды, апрель узды — парткомга чакыручы юк. Майның матур бер көнендә партбюрога телефон:

— Магдеев, немедленно разыщите члена КПСС Шириязданова. Завтра в 15 часов слушается его дело.

Бөтен кафедраны эшкә җигеп Римне эзләп табабыз, вәгъдәсен алабыз. Икенче көнне ул парткомның кабул итү бүлмәсендә иде инде. Безне чакырдылар. Партоешма (университет) секретаре мәрхүм Виссариан Федорович Семенов иде (мин боларны язып утырудан бер ай элек, 1993 елның декабрь башындамы, ноябрь ахырындамы В. Ф. Семенов урамда йөрәгә туктап үлде).

Мин «эш»не сөйләп бирдем. Бәхәс китте. Берәүләр «строгач, без занесения в личное дело», икенчеләр «строгий выговор с занесением в личное дело» тәкъдим иттеләр. Рим дә башын аска иеп, өстәл башында басып тора.

Ректор Михаил Тихонович сөйли — бер үк сүзләр!

— Я просто не понимаю. Как это можно в течение пяти месяцев не платить взносов? Вы же молодой коммунист. Это же элементарная обязанность коммуниста. Почему, я, ректор, нахожу время для этого, а

вы — молодой аспирант — не находите? Или не считаете нужным? Может он, в самом деле, не нужен партии? — Ул сораулы карашын В. Ф. Семеновка юнәлтә.

Римне партиядән куып чыгарабыз дигәндә КПСС тарихы кафедрасы мөдире Р. И. Нәфыйков күтәрелә (партком әгъзасы).

— Мин аңлап бетермим. Бу егет миндә укыды, һәйбәт, юньле егет иде. Мин аңлап бетермим. Бу — ниндидер недоразумение. Бу егет андый булырга тиеш түгел иде.

Һәм Рәфыйк Нәфыйковның бу чыгышы Римнең язмышын хәл итте. «Строгий выговор без занесения в личное дело» дигәнгә партком әгъзалары кул күтәрделәр, секретарь кыз беркетмәгә нәкъ шулай дип язып куйды: «за» — 18, «против» — берәү, «воздержались» — 2. Беркетмәгә кул куелды. В. Семенов безгә үзенең шома ияге белән ишара ясады: «бездельник» Шириязданов белән сиңа, — «бездельниккә» чыгып китәргә мөмкин, дигәнне аңлатты.

Шунда, шунда... Виссарион Семенов... минем «подопечный» Римнан... партбилетын сорады. Рим бирде партбилетын, бирде. Әмма, бирмәсә шәп буласы икән. Чөнки... Рим Шириязданов взносын «погошать» итмәү генә түгел, әле май аенда да теге «әҗәтен» түләмәгән, һәм ул инде сигез ай түләмәгән икән.

Партком «ах» итте, ләкин карарын инде үзгәртә алмый иде. Парткомнан чыгып киткәндә күреп алдым: ректор Михаил Тихонович күкрәк кесәсеннән алып ниндидер таблеткалар йотып маташа иде...

## V

**1990** ел. Минем өчен авыр ел. Гыйнвар аенда сөекле апам үлде. Явыз авырудан тазара алмады. Аннан үзем авырый башладым. Яз айларында бик каты авырый идем инде, кешегә әйтмәдем. Кулыма каләм тотып автографлар бирерлек хәлем юк иде. Тукай исемендәге бүләкне алган көнне митингтан качып машина эченә кереп утырдым. Бер әрсез ханым шулай да тапты, автограф сорады. Ә мин каләм тота алмыйм. Үзем белән бергә эшләгән бер иптәш моны бик гади итеп аңлаткан бер мәҗлестә: «Кулына каләм тота алмыймы? Рюмканы бик еш тотканныкы ул», — дигән.

Бу гайбәт миңа килеп җиткәндә мин хастәханәдә идем инде. Диагнозны тиз куйдылар: панкреатит.

Һәм мин, яшем җитеп, пенсиягә чыгарга әзерләнә башладым.

Сентябрь ахырында эшкә килсәм — коридорда стена газетасы. Бер ватман күләмендә мәкалә — минем иҗат турында. «Бәхилләшү» дигән китабымнан каерып алып рәсемемне дә биргәннәр. Тукай исемендәге бүләк белән тәбриклиләр. Мин инде быел икенче тапкыр шулай стенада телгә алынам. Беренчесе — гыйнвар аенда. Апамны җирләгәч эшкә килсәм — стенада кара шрифтлы бер табак ватман. «Апасы үлү сәбәпле доцент Мәһдиевнең...» Миңа моны күрү бик авыр булды, ләкин шунда җиңел бер сулыш та алып куйдым: коллективта мине ихтирам итүчеләр бар икән. Белеп торам инде, моның инициаторы — факультетның партоешма секретаре Флюра Сафиуллина. Гомере буе кеше кайгысын кайгыртып, авыр вакытта коллегалары янына очып килеп җитә торган кеше. Вулкан булып, зил-зилә булып...

Менә, ниһаять, декабрь ае җитте. Алдан биргән вәгъдәм бар: паспорт буенча алтмыш яшем тулган көнне ярты көн эшлим дә, төштән соң кайтам да китәм.

Һәм шул «ярты көн»гә дип килсәм... килсәм... Коридорда стена газетасы, «әпәйт-тәки» минем рәсем һәм бер табак ватманда котлау: «хөрмәтле фәлән-фәләнич... Сезне 60 яшь тулу...»

Кыен булып китте. Нәрсәгә дип әле сиксән проценты кызлардан торган факультет алдында минем картлыкка басым ясап котлыйсыз?

Коридорда йөрим. Бүлмәләрнең ишекләре юка, катырылган пычкы чүбеннән. Бер бүлмәдән тавыш ишетелә.

— Юк, мин аңлый алмыйм. Бер кешенең портретын елына ничә тапкыр бирергә мөмкин, ә?! Мин беләм, ышту, Мәһдиев популярлыкка мохтаҗ түгел. Ну да ләкин, нәрсә дип елына ике тапкыр аның рәсемен бирәбез әле? Мин моны аңлый алмыйм...

И агайне, коллега... Киттем инде мин сездән, киттем. Минем портрет анда бүтән күренмәс инде, тыныч бул.

Ләкин, белмәссең... Кара рамка эчендә күренеп алуым бар бит әле минем. Соңгы тапкыр... Ни әйтсәң дә утыз ел шунда эшләдем бит. Ул көнне дә син шулай дуларсыңмы? Юктыр инде, дуламассың...

## VI

Мин студентлар алдында лекция сөйлим, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов әсәрләренә анализ ясаганда искелекне, борынгы гореф-гадәтләрне, җен-пәри, аждаһаларга ышануны тәнкыйть итәм, ләкин үзем гел җеннәр чолганышында яшим. Бу менә болай: мин университетка эшкә барам, трамвайга кереп утырам. Алдагы тукталышта мин утырган вагонга ун-унбиш кеше керә, шулар арасында җитмешсиксән яшьлек бер карчык була. Әнә шул карчык, һичшиксез, минем янга килеп баса. Кысыла-кысыла килә. Әллә никадәр яшь җилбәзәк утырып бара югыйсә, ә бу нәкъ менә минем урындыкка килеп тотына. Бу, әлбәттә, җен эше. Бу һәркөнне шулай булганлыктан, трамвай тукталышында берәр карт, карчыкны күрсәм уйлап куям:

— И иптәшкәем, син инде минеке...

Лекцияләрем бетә, «Ленин бакчасы» дигән тукталышка чыгып басам. Трамвай яки троллейбус көтәбез. Көтүчеләр арасында бер исерек бар. Мыркылдый, сүгенә, кемгәдер бәйләнәсе килә. Бу — шулай ук минеке. Һичшиксез, мин утырган вагонга керәчәк ул. Һичшиксез, минем янга килеп басачак ул, һичшиксез, минем белән сөйләшергә, бәйләнергә омтылачак бу. Әнә шуны алдан белгәнлектән, мин кайвакыт аның янына үзем киләм һәм үзем сүз башлыйм, чөнки ул барыбер минеке инде.

Яз килә, мин өстәлем янында көннәр буе утырам: лекцияләргә дә әзерләнәм, аз-маз әдәби әсәрләр дә язгалыйм. Безнең йорт алты подъездлы, урам ягында матур аллея йорт буйлап сузылган. Ул аллеяда асфальт кибүгә, балалар «сызык» уйный башлый, ләкин алар бары тик минем тәрәзә турысында гына уйныйлар. Яз буе, җәй буе шулай. Каршыбызда гына кибет бар, анда кереп-чыгып йөрүчеләр кара-каршы очрашканда сөйләшеп тору өчен нәкъ минем тәрәзә астына киләләр. Сәгатьләр буе сөйләшеп торалар. Мин кайвакытта урамга чыгып карыйм: йөз метрдан да артыкка сузылган йортыбызның бары тик бер генә урынында — минем тәрәзә турысында гына хатын-кыз сөйләшеп тора, бала уйната. Әле алай гына да түгел. Урамда көтүе белән хуҗасыз этләр йөри. Төннәрен форточка аша ишетеп ятам, алар сөрлегешеп чабалар, каядыр китеп баралар. Ләкин мин көтеп ятам: бераз чабышып, каннарын кыздырып алгач, болар, һичшиксез, минем тәрәзә турысына җыелалар. Котчыккыч гауга куптарачаклар, мине йоклатмаячаклар. Кайвакытта аллеядагы куаклар арасында ике мәче котчыккыч ямьсез мыраулап йә мәхәббәт, йә нәфрәт хисләре белән урталашалар. Мин йоклый алмыйча урамга чыгам. Бөтен подъездлар тыныч, теге оятсызлар нәкъ менә минем тәрәзә астында. Болар, әлбәттә, җен эше. Ул җен гел мине тәрәзә астында саклап яши. Хәер, минем бүлмәдә дә берсе яши аның. Җәйге ял вакытында мин, гадәттә, әдәби әсәр язам. Бүлмәмнең ишеген ябып

сәгатьләр буе берүзем утырам. Язам, арыйм. Ике, өч, дүрт сәгать язам, берәү дә борчымый, керми. Шунда бик нык арыганымны сылтау итеп, дәва булсын дип бер рюмка гына хәмер эчмәкче булам. Яшереп куйган җирдән шешәне алам (балалар күрергә тиеш түгел), бик шыпырт кына рюмкага салам... дигәндә генә дыркъ итеп ишек ачыла һәм мин тотылам. Һәр очракта да тотылам. Югыйсә, ярты көн буе ишегем янына килүче дә булмый.

Кешеләр теләсә нәрсә әйтсеннәр, әмма мин җеннәр белән әвәрә килеп яшим.

## VII

Университет — туган йортымны сагынып яшәрлек булгач, ник аннан киттем? Миңа бу сорауны гел биреп торалар. Минем җавап стандарт: яшьләргә юл бирергә кирәк. Ләкин тулы җавап түгел бу. Төп сәбәбе башкачарак.

Менә бервакыт Казанга без еллар буе сүккән Гали ага Акыш килде. Опера театрында моның белән очрашу булачак. Миңа чылтыратып әйтәләр: фәлән-фәлән йортның фәлән бүлмәсендә сезгә билет бар, кереп алыгыз. Киттем, эзләп таптым. Керә-керешкә бер егет белән очраштым, кул биреп күрештек.

— Нихәл, Фирзәр,— дим,— синең җырлавыңны бик яратам,— дим. Ул да билетка килгән икән. Ләкин билет бирүчеләр аңа Фирзәр дип түгел, Ренат дип дәшәләр. Чынлыкта ул «Сорнай» ансамбленең җитәкчесе Ренат Гыйләҗев икән. Хуш, кып-кызыл булып янып йорттан чыгып киттем. Театрда урыным өске яруста иде, Гали аганың мәһабәт борынын чамалап булырлык иде. Очрашуда ыбыр-чыбырлы чыгышлардан туеп кайтып киттем: Гали ага белән иртәгә аерым очрашабыз, «Татарстан — Төркия» җәмгыятен тәкъдир итү мәҗлесендә. Ә ул мәҗлесне, бу оешманың президиум әгъзасы буларак, мин алып барырга тиеш.

Киттем мин икенче көнне Галимнәр йортына «презентация»гә. Кердем йортка, күтәрелдем икенче катка, халык җыелган, күрәм, каршымда Гали ага. Барып күрештем, бик якын итеп күрештем.

— Кичә бик арыттылар сезне, ничек йокладыгыз? — дидем.

Ул бераз гына гаҗәпләнгән сыман булды:

— Рәхмәт, әйбәт йокладым,— диде.

Мәҗлес зур булмаган бер залда, шампанскийлы, лимонлы, алмалы дүртәр кешелек өстәлләр янында башланып китте. Америка, Төркиядән килгән унлап татар бар иде — калганнары үзебезнең галимнәр, артистлар. Хуш, мин бит алып баручы инде.

— Хөрмәтле ханымнар һәм әфәнделәр, хөрмәтле кунаклар,— дип тезеп киттем мин.— Бүген безнең шатлыклы көнебез: татар халкының зур галиме, ватанпәрвәр бер улы Гали ага бездә кунакта...— Сул як өстәлгә таба кулым белән ишарә ясадым, күп кеше шунда таба борылды. Оешмабызның президенты Фирдүс Фәтхелисламов йөзенә зур канәгатьлек хисе бөркеп миңа карап алды: ул бит атна буе телефоннан төшмәде.

— Мөхәммәт абый, пожалуйста, мәҗлесне алып баруны өстеңә ал инде,— дип күпме-күпме тапкыр әйтте. Менә хәзер ул бәхетле: бөтен кешедән дә булмый ул андый кереш сүзләр...

Мәҗлес кызды, шампань бөкеләре Синопта Төркия флоты белән Россия флоты бәрелешкәндәгедәй гөп тә гөп килеп атылып тордылар, Шамил Әхмәтҗанов төрекчә бер җыр җырлап Төркия кунакларын таң калдырды...

Шунда... шунда... (руслар андый очракта: «Фу ты, ну ты, лапти гнуты» диләр) шунда пышылдау купты, залны урталай ярып, таза гына бер ир килә иде безнең өстәлгә таба...

— Гали ага! Әссәламе галәйкүм!

— Гали ага! Исәнмесез, әйдә узыгыз,— дигән тавышлардан мин гәүдәмнең авырлыгын югалттым. Өстәлебез янына Гали Акышның үзе килеп утырды, ә теге, мин күрешкәне экстрасенс доктор Наил Хәкимов икән...

Мин шактый вакыт «шок» дәрәҗәсендә утырдым. Чит телләр сүзлегендә «шок»ны француз сүзе дип аңлаталар. Минем үз версиям бар: шок — татар сүзе. «Шаккату»— аптырау, югалып калу — безнекеме? «Шакай»— бернинди эмоциясез карап торган кешегә шулай диләрме? Шопшома, йомры тезбаш сөяген «шакай сөяге» диләрме сыер-үгезләрнең? «Шок» безнеке. Әнә шуңа күрә мин әлеге мизгелдә «шокайган» хәлдә идем.

Хуш, өстәлгә бер кәгазь китерәләр. Минем исемгә. «Мөхәммәт абый, миңа ике минутлык кына сүз бирсәгез иде. Төрек гимназиясенең директоры Айдар Низамов». Ник бирмәскә инде, Айдар? Мин сине гомер буе ихтирам итеп яшим, син акыллы егет. Казан désinститутына синең янга йомыш белән дә килгәнем бар һәм син минем үтенечемә колак салдың, тыңладың. Хәзер, Рәшит Мостафин гармуннарында уйнап бетерсен дә...

Ул арада Айдар безнең өстәл янына килеп утырды. Чөнки безнең өстәлгә беркетелгән бер ханым Америкадан килгән кунак янына күчеп утырган, бездә бер урындык бушаган иде.

Айдар белән сөйләшеп киттек. Мин әйтәм, Рәшит Мостафин уйнап бетерүгә сиңа сүз бирәм, иркенрәк сөйлә, нигә ике минут кына, дим. Ул биш минутлап сөйләргә вәгъдә бирә.

Гармун туктауга, мин пычак сырты белән фужерга суккалап (Ә. Еники: «Төнге тамчылар» әсәренең бер персонажы — Кәли; прототибы — мәрхүм Хәмит Ярми), болай дим:

— Хөрмәтле ханымнар, әфәнделәр! Хәзер сезнең алдыгызда башкалабызның педогогия институты каршындагы төрек гимназиясе директоры Айдар Низамов сүз әйтә.

Һәм кулым белән ишарәләп әлеге көдрә чәчле кара егетне күрсәтәм. Шунда... шунда... Иң арткы өстәл яныннан күтәрелеп безгә таба бер ир килә. Кара чәчле, кара тут йөзле. Бу — Айдар Низамов икән, килде, рәхмәт әйтте, сөйли башлады...

Мәҗлестә минем улым Искәндәр дә бар иде, кайтканда ул мине гел саклады, бишенче трамвайга утыртты, «Совет мәйданы» дигән тукталышта мине төшерде, үз өебезгә кадәр алып кайтты. Рәхмәт инде аңа. Тик өебезгә кергәч безне ишек ачып каршы алган хатыныма, улымның әнисенә, мин бераз шикләнеп карадым: ә «вдруг» бу — минем хатын түгел, ә кибет идәнен юучы Маша түти?

## VIII

Әдәбият галиме Тәлгать Галиуллинның «Еллар юлга чакыра» дигән исем белән тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы басылып чыкты. Т. Галиуллин — республикада иң яшь ректор, докторлыкны якларга йөри. Радиода әдәбият-сәнгать бүлеген алып баручы Рим Кәримов (Тәлгатьнең иң якын дусты иде, мәрхүм) телефоннан чылтырата миңа (иллә дә шәп бәрхет тавышлы иде!):

— Карале, Мөхәммәт, бер юньле эш эшлик, ә? Тәлгатьнең теге монографиясе турында радиотапшыру эшлик әле алдагы якшәмбе өчен.

— Анда кемнәр катнаша соң?

— Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин һәм университет галиме булаpак — син. Кереш сүзне үзем әйтәм. Димәк, килештек. Син бераз әзерләнеп тор: «запись» (магнитофон лентасына язу) иртәгә сәгать унбердә була. Фәрваз да нәкъ шул вакытка килә.

Иртәгесен сәгать унбердә мин радиокомитетта идем инде. Рим үзенең кереш сүзен инде яздырган, миңа сорау биргән. Мин аның сөйләгәнен тыңладым да шундук ялгап алып киттем. Биш-алты минут сөйләдем бугай. Фәрваз күренмәде. Без студиядән чыктык, бүлмәсенә керсәк — телефон. Фәрваз икән:

— Ашыгыч эш чыкты, мин кичке дүрткә генә килә алам, яздыра алырсызмы?

Рим аны көтәргә вәгъдә бирде.

Бер көн үткәч Рим белән телефоннан сөйләшәбез:

— Фәрваз килдеме?

— Килде, язылды.

— Миннән соң сөйлиме? Ничек ялгадыгыз? Мин сөйләгәнне тыңлаттыңмы?

— Юк, вакыт бик тыгыз иде, туп-туры сөйләп китте. Әйбәт язылды.

— Ну бит ул ялгарга тиеш иде мин сөйләгәнгә. Ул бит минем нәрсә әйткәнемне белми.

— Ялгады, бик әйбәт ялгады.

— Ну, карагыз аны...

Ял көне радио янында утырам. Менә Рим сөйли. Әйбәт тавыш белән затлы итеп сөйли. Менә бик үк бай булмаган тавышым белән мин сөйлим. Тәлгатьнең китабын мактыйм. Менә сөйләп бетерәм. Хәзер ул Миңнуллин ничек итеп ялгый инде? Дер калтырап утырам.

— Әйе, Мәһдиев хаклы,— дип башлап китә Фәрваз,— мин аның фикере белән килешәм. Ну, «дает»! Тапшыру тәмамлануга, мин Фәрвазга телефоннан чылтыратам:

— Ничек инде син минем фикеремне белмәгән көе «әйе, Мәһдиев хаклы» дип ялгап китәсең? Бәлки, минем сөйләвемнең соңгы җөмләсе менә мондыйдыр: «Тәлгать Галиуллинның бу монографиясе әдәбият белеменә берни дә өстәми». Алай булса, ничек?

— Юк, мин синең кайда, нәрсә, ничек сөйләячәгеңне алдан ук беләм. Шуңа күрә, курыкмыйча шулай ялгадым.— ди Фәрваз Миңнуллин.

## IX

Ангина белән авырып ятам. Бер көн, ике көн. Менә бервакыт хәлем начарланды, тамак төбе тыгылды. «Ашыгыч ярдәм» чакырырга булдык. Балалар — әле кечкенәләр — куркып калдылар. Шунда мин аларны янымa чакырып китердем дә, башларыннан сыпырып васыятемне әйттем:

— Андый-мондый үлеп китсәм, китапларны болай бүлегез: балалар әдәбиятының барысы да — кызыма. Әкият китапларының барысы да — улыма.

Болар дәшмичә, аңлап бетермичә, күзләрен мөлдерәтеп карап тордылар да, тиз үк минем бүлмәдән чыгып киттеләр.

Ул арада врачлар килеп керде. Карадылар, рецепт яздылар, нинди-дер бер укол бирделәр дә чыгып та киттеләр. Хатын аларны озатып йөргәндә ишетәм, балалар бүлмәсендә ыгы-зыгы, дөбердәү тавышы. Урынымнан авырлык белән торып бүлмәләренә барып керсәм, күрәм: балалар идәндә әүмәкләшеп, тәгәрәшеп бер-берсеннән китап йолкыйлар, нинди-дер китапларны бүлешә алмыйча сугышалар икән. Бөртенеп беткәннәр. Миңа җиңел булып китте, сабыйлардагы эчкерсезлек, самимилеккә сокландым. Беренчедән, алар үлемнең нәрсә икәнен белмиләр, икенчедән, алар «безнең әти үләр» дип башларына да китермиләр. Өченчедән, алар бу турыда бөтенләй уйламыйлар да. Китаплар бүләсе бар — вәссәлам. Мин авыру килеш елмаеп бүлмәмә кереп киттем, балалар исә байтак сугышты әле.

...Терелеп эшкә чыккач, мин бу хәлне кызыклы бер хикмәт итеп кафедраның лаборантлар бүлмәсендә сөйләп утырдым. Укытучылар керә-чыга йөриләр иде әле. Гадәти эш көне башланды.

Өйдә дә тынычлык, кичләрен китап укыйбыз, мультфильм карыйбыз. Китап бүлешү турында да сүз юк. Гадәти эш атнасы узып та китте. Ә бер көнне миңа, кайчандыр безнең бүлектә укып диплом алып чыккан бер ханым очрый. Хәл-әхвәл сорашабыз. Ие, кияүдә, кияүе прораб, бер балалары бар, үзе китапханәдә эшли.

— Безнең ике бала,— дип ялгап алып китәм мин.— Безнеке бер кыз, бер...

Ләкин ханым мине бүлдерә, күзләрен зур ачып сөйли башлый:

— И, Мөхәммәт абый, чынмы ул? Беркөнне сөйләп тордылар: ну да бәхете булмаса булмас икән бу Мәһдиев абыйның,— дип.— Кеп-кечкенә балалары әтиләренең үлемен көтеп, мал бүлешеп сугышалар икән,— дип...— Чынмы шул?

Ник чын булмасын инде, үзем сөйләгән идем бит кафедрага барып...

## X

Факультетның партҗыелышы төнге унга кадәр сузылды. Ул елларда без тарих-филология, журналистика бер коллектив идек. Һәр җыелыш шулай сузыла безнең. Моның сәбәбен мин аңлыйм: карар проектын кабул иткәндә бит фәлән-фәлән эшне башкаруны фәлән коммунистка тапшырырга, дип конкрет күрсәтелә. Әнә шул конкретлыктан качу өчен өч-дүрт өлкән коммунист проектны «нигездә кабул итkәч» котчыккыч бәхәс ачалар. Ул бәхәс, гадәттә, бер-ике сүзгә бәйләнүдән башлана. Әйтик, карарда «рассмотреть» диелгән булса, тегеһәйләкәрләр җыелышта зур активлык белән тавышланалар: «пересмотреть» кирәк; карарда «поручить это коммунисту такому-то» булса, һәм ул әлеге өлкәннәрнең берсенә кагылса, алар гөж киләләр: «рассмотреть в рабочем порядке» һ.б. Нәтиҗәдә, тел гомуми сүздән генә торган бер документ кабул ителә.

Шундый җыелышларның берсеннән кайтып ишек янагындагы төймәгә бастым. Безнең өйдә гадәт: «Кем анда?»— дип сорала. Бу юлы сорау бирүче булмады, ишек дырык итеп ачылды, хатын шундук кухняга кереп юк булды. Гадәттәгечә, «ай-йәй, озак тордың» дигән җөмлә әйтелмәде, гадәттәгечә, кулымдагы дипломатны алып залга узу булмады. Залда балалар телевизор карыйлар иде, алар да каршы чыкмады. Мин чишендем, киемнәремне алыштырдым, кулларымны юып кухняга уздым. Өстәл янына килеп утыргач хатынның чыраена карасам... Хиросима өстендәге төтен. Күзләр шешенгән. Димәк, елаган. Ул арада аның кулыннан аш кашыгы төшеп китә (мине ашатырга өстәл әзерли), шуны бөгелеп идәннән алам дигәндә яулык очы белән электереп плитә өстендәге озын саплы алюмин чүмечне өстерәп төшерә, идән кайнар сөт белән тула. Нәрсәдер булган — факт. Мин ашый башлыйм, үзем уйланам: тә-ә-к, дим. Әтисе дә, әнисе дә исән моның. Аларга бер хәл булган булса, ишектән керүемә муеныма асылынып елый башлар иде бу. Димәк, исәннәр. Балалар исән — залда үзем күреп чыктым. Минем әти инде утыз җиденче елда ук хәл ителгән, әнине җирләгәнебезгә дә инде ун еллар. Димәк, монда мәсьәлә туп-туры миңа кагыла. Димәк, мин югында моңа бер кеше чылтыраткан. Тә-ә-к. Димәк, хәзер нишләргә? Бер сорау да бирмәскә. Ул бит миннән сорау көтә, ә инде хатын-кызны беләбез, ирe кайтышка аның инде җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова яки Венера Ганиева концерты озынлыгында гына кассетасы булмый калмый. Хатын-кызны беләбез инде, эчендәгесен барыбер озак саклый алмый ул, мин никадәр вакыт дәшмәсәм, аның чыдамлыгы шулкадәр тиз кими. Карт бүре бит мин...

Һәм, ниһаять, чәй биргәндә, ялгыш төшереп бер чынаяк чокырыбызны ватып, минем уң аякны шактый ук пешереп, идәнне янадан сөртеп, яңадан кулларын юып, яңадан чәй биргәч, хатын түзә алмады:

— Ленинский районнан трамвай белән кайттыңмы?

Ә мин университеттан, «Ленинский сад»тан кайткан идем.

Тә-ә-к. Бер «ачкыч»ны бирде бит бу. Мин бит Кызыл Байраклы Балтик флотының бер базасында СНИСта («Служба наблюдения и связи») элемтәчеләр, шифровальчиклар белән, разведчик, контрразведчиклар белән әвәрә килеп, телеграф ленталарыннан чыккан шартлы сүзләрне укып утырган егет яшьлегемдә. Анда бит сигнальщик, флагларын болгап, корабльдән яр буендагы постка шундый хәбәр бирә: «Иванов хуҗалыгына ике тонна ит, егерме өч коробка кефир төятегез. Имза: Ахияшвили». Шифровальщиклар өчен бу текст менә болай ачыла: «Киров» крейсерына бүген төнге егерме өч сәгатьтә командующий вице-адмирал Алексеев килә, рейдны саклау өчен база командующие контр-адмирал Кисилев җаваплы. Имза: флот адмиралы Горшков».

Димәк, мин Ленин районында кич уздырганмын. Дәшмим, чәй чөмерәм. Тагын бер ачкыч:

— Квартирасы бер бүлмәлеме?

— Ие, бер бүлмәле,— кызык булып китте үземә дә. Хатын да җиңелрәк сөйләшә башлады.

— Кооперативныймы?

— Ие, кооперативный (чәй эчәм).

— Синең акчага алындымы?

— Ие, бөтенесен мин түләдем.

— Балагыз күпмелек инде?

Монда бераз уйларга кирәк. Күпме дип әйтергә? Быел армиягә китте, Әфганстанга эләкте, дип үк әйтсәм җитди түгел. Ә миңа бу уенны беткәнче җитди итеп алып барырга кирәк. Һәм мин киттем... Ычкындым...

— Бүген җиде ай тулды. Шуның туган көне иде...

Бүтән сораулар бирелмәде. Ә сорау бирелмәү хатынны борчый. Аның сорау бирдертәсе, шуңа җавап алып, эчен бушатасы килә. Мин исә әле гел чәй эчәм. Шунда ул түзмәде:

— Мине сатмыйсыңмы?

— Ничек итеп?

— Кем чылтыратканын әйтсәм, мине сатмыйсыңмы?

— Нәрсәсен сатасың аның, гел дөресен сөйләгән бит (ну, мин дә явыз инде).

Хатын шунда җиңел сулап куйды һәм миннән «сатмаска» тагын ант сорады. Ант итәргә туры килде, ләкин әйттем:

— Мине бу кешенең кем булуы һич кызыксындырмый,— дидем.

Шунда ул... ул... кайчандыр читтән торып бездә укыган, миңа имтиханнар тапшырган, бераздан укуын ташлап чыккан, ире белән мин исәнләшеп, хәл-әхвәл белешеп йөргән бер хатынның исемен әйтте. Теге хатын безнең өйгә әнә шундый информация биргән.

— Ирең, бу минутта Ленинский районда үзе алып биргән квартирада, яшь хатыны, баласы янында утыра,— дигән...

Юләр икән бу — үзенең кем икәнен дә әйткән.

Ни гаҗәп, исеменен дөресен әйткән... Гадәттә, алай булмый.

Иртәгесен кафедрга киләм. Лекцияләр башланырга әле ярты сәгать бар. Гайбәт сөйлибез: бишенче трамвай рәтле йөрми, уникенчесендә дә рәт юк. Җиденче троллейбуска якын да килмә, эченә керсәң — сытып бетерәләр, әнә минем пальтоның бер төймәсен бүген ничә кеше эзләп тә таба алмады...

Шунда мин иркенләп кафедра халкына (доцентлар, ассистентлар, лаборанткалар) кичәге хәлне сөйлим. Дөресен әйтим, өйдә ни булса,

килеп шул турыда сөйләп бетерүче кеше коллективта бер мин генә идем. Сөйләвемне әсәренеп тыңлыйлар һәм мин нокта куйгач, бер-ике секунд тын алгач, лаборанткабыз кычкырып көлеп җибәрә.

— И, Мөхәммәт Сөнгатович (бездә рәсми дәшү шулай гына иде ул заманда)! Сез бик соңга калгансыз. Ул хатын инде безнең гаиләгә әллә кайчан мондый спектакльне күрсәтте...

## XI

Кайсыдыр советка сайлаулар вакыты. Сайлау участогыбыз Красная Позициядәге студентлар тулай торагында. Мин тагын секретарь. Ну рәхәтләнде партком авылдан килгән бу йөк атына! Буш эштән авыл мәктәбендә укытканда да туеп беткән идем. Каян белеп алдылар мине? Безнең авылда сугыш вакытында егерме бишенче елгыларга комиссиягә хәбәр килгәч ике кызы һәм бик кадерле төпчек малае белән фәкыйрьлектә көн итүче тол карчык Маһирәтти урамга чыгып:

— Минем улым барын Арча урыслары каян белсен, күршеләр эше бу, шулар чаккан, көнләшәләр,— дип елап йөргән иде.

Мин дә шулай уйлый идем партком ишегеннән кергәндә.

Менә төнге сәгать уникене сугарга җыена, бюллетень санау булачак. Райком вәкиле килеп керде: университетның элеккеге ректоры Кирилл Прокофьевич Ситников. Мәһабәт гәүдәле, таза бәдәнле. Әдәп белән генә ярым елмаеп сөйләшә.

Уникене сукты, ишекләрне бикләдек. Урналарны кызыл комачлы зур өстәлгә бушаттык. Саный башладык.

— Мәһди, тутыра башла протоколыңны,— диде участок сайлау комиссиясе рәисе Әнвәр Ахунҗанов.— Ул моны татарча әйтте. Мин гаҗәпләндем:

— Туктагыз, әле бит нәтиҗәсе билгеле түгел...

— Ә, кишерем, санасаң да, санамасаң да туксан тугыз бөтен йөздән туксан тугыз инде ул. Әйдә, тутыра башла...

Мин беркетмәнең кайбер пунктларын тутырдым, әмма цифралар куярга иртә иде әле.

Бер сәгать эчендә санап бетердек. Ләкин нәтиҗә ясаганда бер матавык чыкты: өләшенгән бюллетеньнәр саны белән урнадан чыккан бюллетеньнәр саны туры килми. Тагын бер кат санадык. Чыкмый, вәссәлам. Кырыклап бюллетень җитми. Өнсез-телсез калдык. Дөрес, кырыйда гына запас бар безнең, ал да куй. Әнвәр абый үзенең елтыр кара күзләрен әлләничә тапкыр юнәлтте ул пачкага, әмма райком вәкиле утыра бит. Әнвәр абый миңа күз кыса: рөхсәт сора әле Кирилл Прокофьевичтан, янәсе.

Һәм мин, авыл малае, шулай сорыйм да:

— Кирилл Прокофьевич, теге чиста бюллетеннарны кушыйк монда,— дим.

Акыллы карт, урыныннан тора һәм ишеккә таба барышлый миңа әйтә:

— Мин сезгә бу турыда берни дә әйтә алмыйм,— ди һәм коридорга чыгып ук китә.

Аның артыннан ишек ябылуга Әнвәр Ахунҗанов — ялт! — бер уч бюллетенне теге запастан алып безнең алга чәчте.

— Ни кишеремә дип баш ватып торасың, менә ич алар, табылды. Аларны бит бүген төн буе райисполкомның котельныенда яндыралар.. Бездән бит райисполкомга протокол гына кирәк...

Һәм ул җәһәт-җәһәт атлап ишеккә китте, ишекне ачып кычкырды:

— Кирилл Прокофьевич! Кирилл Прокофьевич! Бюллетени нашлись! Оказывается, лежали под моей рабочей папкой! Надо же, а??

Бөтенебез дә бәхетле идек, мул таза йөзеннән нурлар «сачып» бүлмәгә мәһабәт ир килеп керде, өстәл янына килеп утырды һәм әйтте:

— Ну и отлично. Хорошо то, что хорошо кончается.

Әнвәр абый бәхетле кыяфәт белән мундштугына сигарет киертеп маташа иде.

Сәгатьләребезгә карадык: ике тулып унбиш минут икән. Ул арада райисполком машинасы килеп җитте. Кәгазь төяп шунда мин барасы. Узышлый Кирилл Прокофьевич, Әнвәр Мәхмудовичларны өйләренә төшереп калдырасы...

Иртән, исән булсак радио тыңлыйсы: партияле һәм партиясезләр блогы өчен туксан тугыз бөтен йөздән туксан тугыз процент... Эстониядә, Литвада туксан сигез... Төрки халыкларның кайберсендә йөз....

Без барыбыз да шат идек: зур эш башкардык.

## XII

Төмәннән килеп татар бүлегендә укып йөрүче Рәфыйкъ исемле егет (исемен үзгәрттем) бар иде. Себер татарлары бик кызык халык: кышкы салкында да, җәйге эсседә дә аякларында кирза итек. Алар икеме-өчме егет иде Себердән. Ике-өч мең студент арасында җәй дә, кыш та кирза итектән йөрүчеләр бары тик шулар гына иде.

Менә шул Рәфыйк бер көнне айныткычка эләккән бит. Тиз үк деканатка кәгазь килеп җитте. Деканат «тикшереп чара күрергә» дип бу кәгазьне кафедрага чыгарды. Чакырдык теге егетне кафедра утырышына, бастырып куйдык. Сораулар конкрет: ник эчтең? Әйе, Ленин укыган университетның абруен төшереп ник эчтең? Хәзер бит ректор приказы белән сине университеттан куалар...

Әмма егет һич тә каушамады, бик җитди кыяфәт белән әйтте дә куйды:

— Куалар дип... Анысы инде Ленинның үзен дә куганнар.— Без, яшьрәкләр, чүт кенә көлеп җибәрмәдек, әмма өлкәннәр кыза калды. Бигрәк тә кафедра мөдире Хатип ага.

— Ни сәбәпле эчтегез, сөйләп бирегез,— диде ул. Егет тамагын кырып болай башлады:

— Стипендия алган көн иде. Бауман урамына төштем. Урамнан барам, күрәм: «Закусочная». Стипендия алган көн итеп әллә кереп чыгаргамы? Шунда минем башымда ике фикер сугыша башлады: кара фикер һәм кызыл фикер. Кара фикер әйтә: Рәфыйкъ, кереп бер стакан эч, ди, синең моңа хакың бар, ди. Беренчедән, ди, син бүген стипендия алдың. Икенчедән, син кичә генә Гафур Колахметов иҗаты буенча уңышлы гына курс эше якладың. Кер, ди, салып чык, ди. Ләкин кызыл фикер моңа каршы килә, мине каһәрли. Кермә, Рәфыйкъ, ди, син данлыклы Казан университеты студенты. Бу олы исемне пычратма, ди. Шулай, бер фикерем ике булды. Озак сугыштылар алар. Нәтиҗәдә кара фикер җиңде. Минем сезгә бүтән әйтер сүзем юк...

Җәза бирү өчен җыелган коллективның бөтен энергиясе комик ситуациядә инде йомшаган, хәлсезләнгән иде. Егетне чыгарып, ишекне яптык. Киңәш башланды. Нинди җәза бирергә? Шул чак Якуп ага Агишев, кафедрада иң өлкән кеше, болай диде:

— Җәмәгать, телдән генә кисәтик, егет бик ошады миңа, диде.— Бу бит коеп куйган әдәбият галиме...

Барыбыз да җиңел сулап куйдык һәм егетне чакырып керттек. Хөкем карарын тыңлаганда да аның чырае нәкъ бер үк төсле иде: әллә тикшерделәр аның эшен, әллә телгә дә алмадылар... Менә ул Себер характеры...

## XIII

Университетта райком дәрәҗәсендәге профком рәисе булып эшлим. Безнең эшне югарыдан гел тикшереп торалар: йә Облсовпрофтан, йә Мәскәүнең үзеннән үк — ВцСПСтан. Өлкәдән килгәне белән эш җайлы, подвалдагы ашханәгә алып төшеп бер ашатасың да, пальтосын киертеп озатып каласың. Мәскәүдән килгәне белән эш авыррак: кунакханәгә кадәр култыклап озатасың, поездга илтәсе, сумкасын тотырасы — болар гадәти хәлләр. Моңа расход каян чыгарасы? Минем кесәдән түгелдер ич инде? Мине өйрәтәләр үземнең аппараттагы хатыннар: безнең кулда бит спортклуб бар. Ул безнең бюджетта. Аның акчасы байтак. Чакырыгыз Мөнирне, диләр, ул рәтен белә. Сездән һәм бухгалтердан имза гына кирәк.

Чакыртам Мөнирне, ул — спортклуб директоры. Сөйлим кыйссаны: Мәскәүдән килгән тикшерүче ир кеше булса, бүлмәсенә бер шешә коньяк, апельсин, лимон, бер тавык һ.б. әйберләрне номерына илтмичә булмый; хатын-кыз булса — алмадыр, торттыр, чорттыр...

— Ә, була ул,— ди Мөнир, иманлы йөзле егет.— Хәзер миңа бухгалтер рөхсәт итсә, бер документ кирәк булыр... — Итмиме соң инде, үз тамагыбыз өчен түгел бит, ялганның иң шәбе — коллектив ялган инде аның...

Һәм бухгалтерның өстәленә бер ведомость китереп салына. Анда язылганча, бүген безнең спорт залында КДУ белән КАИ волейбол командалары очрашкан икән, ә ул очрашуда катнашкан спортсменнарга ашау-эчү өчен күпмедер акча түләнә. Менә Иванов, Семенов, Хәйруллин, Петров, Мөхәррәмов — егермеләп кеше. Рас! — Мин тегенең почмагына: «Бухгалтеру: оплатить, подпись». Эшең бетте, кодагый. Кунакханәгә кем барып килә? Тәк—с. Һәр эшнең дә җае бар, ботканың да мае бар, диләрме? Без моңа ияләнгән идек инде. Әмма, бер комиссия белән борчак пешмәде. ВцСПСтан килгән таза-таза ике ир иде. Болар мине, хуҗалык эшләре буенча проректор Николай Одринскийны, партком секретаре Марат Садыйковны алып студентлар тулай торагына киттеләр. Ике машинага төяләп бардык. Бүлмәләрдәге тәртипне тикшереп йөрибез, сентябрь ае, студентларның күбесе бәрәңгедә. Әһә, бәрәңгедәме? Димәк, кандалалар ач. Әнә шуңа күрә стенага ачык җиргә чыкканнар алар. Тук кандала беркайчан да кеше күзенә күренмәс. Бүлмә саен кандала күреп мәскәүлеләр шаккатты. Телләрен цок то цок китерделәр. Күңелсез генә аерылыштык. Төштән соң миңа Облсовпрофка утырышлар залына килергә куштылар. Килсәм барысы да танышлар. Казан ВУЗларының профком рәисләре. Без шулай семинарларда, пленумнарда гел очрашабыз, фикер алышабыз. Мәскәүлеләр ике көн эчендә студент тулай торакларының барысын да карап чыкканнар. Әлбәттә, теге кызыл партизаннар очраштырган, әмма инде университет тулай торагындагы кебек... алла сакласын.

Һәм мине бастырып куйдылар. Сорау ала башладылар. Минем инде өченче елым бу эштә, азу ярган. Кандала тулай торакларда элек тә бар иде. Һәм комиссия белән минем арада шундый диалог бара:

— Ни өчен тулай торагыгызда кандала бар?

— Кандала мин уйлап тапкан бөҗәк түгел.

— Сезгә ничек оят түгел! Ленин укыган университетта, понимаете ли... Һәм кандала.

— Ә ул кандалалар бездә Ленин укыганны белмиләр.

Мәскәү комиссиясе телсез калды. Миңа ниндидер бер кисәтү белдереп җыелышны яптылар.

Минем дә Мөнирне борчыйсы булмады...

## XIV

Кафедрадан өемә Ибраһим ага Нуруллин чылтырата:

— Әйдә, иртәгә кызыклы бер сәяхәткә чыгыйк әле: университет, китап нәшриятының Кырлайдагы Тукай музеена культпоходы. Машина миннән, лекцияләрең төштән соңмы? Кичке биштә? Һи-и, көндезге өчтә монда булабыз без. Килештек. Димәк, нәшрияттан Рәис Даутов, Шәүкәт Галиев. Тарихи бер экспедиция булачак бу. Димәк, без сине юл уңаеннан кереп алабыз...

Иртәгесен бу компанияне мин үзебезнең урам башында көтеп алдым. Кеп-кечкенә «Запорожец»ның артына таза-таза Рәис белән Шәүкәт кереп сеңгән, миңа алгы утыргыч калдырылган иде. Шәп сәяхәт бу! Кайткач бу турыда факультетның «Әдәби сүз» газетасына бер ватман табагына җитәрлек мәкалә язармын дип уйлап алдым мин машина ишеген шапылдатып ябуга. Ләкин... Ах! Ух! Фу-у-у! Ибраһим абый кызыл утка керде. Якында гына ГАИ инспекторы тора иде. Ибраһим абый: е-е-х! Ы-ы-х! — машинасын артка бирде. Ләкин артта... чыкырт! деңгерт! — металл, пыяла тавышы ишетелде. Ибраһим абый үзе дә:

— Ы-ыһ! Мы-ыһ! — дигән газаплы авазлар чыгарды, ярый әле артта машина юк, тимербетон багана гына икән. Ярый әле арттагы фаралар гына кырылып беткән икән...

Тагын ике-өч тапкыр шулай чыкырдашкалап, ухылдашкалап, уфылдашкалап, ниһаять, тыгыз Казан каласын чыгып Казан-Арча-Балтач трассасына тәгәрмәч бастык («аяк бастык» дигән сүзгә юри иярүем). Биектау тирәсендә трасса тагын тыгызланды, юл тулы тимер, таш, торба төягән авыр йөк машиналары. Берсе үзәгебезгә үтте: бортының арт ягы ябылусыз, авыш соскыч формасында эшләнгән тимер кузовлы машина. Күәс чиләге хәтле чупай ташларын тутырган. Зур бер кисәге бераз йомрырак, иң артта шунысы гел селкенеп бара.

— Әз генә ара калдыр инде, Ибраһим абый, — дим, — бер тукталышта безнең өскә төшәчәк бит бу.

— Ие шул, ие шул, — ди машинабызның хуҗасы һәм бераз газны киметә, ләкин шул вакытта артта чыкырдаган тавыш ишетелә, безне бер КамАз җиңелчә генә этеп маташа икән.

Без тагын теге таш астына килеп җиттек, мин борчылам, Ибраһим абый ара-тирә ыңгырышкалап куя, Шәүкәт утырган җиреннән борсалана:

— Мондый җайсыз, каты утыдгычны беденче тапкыд күдүем, — ди ул.

Бер Рәис Даутов кына Будда кебек тыныч утыра. Коркачыкның патша заманында ук салынган тар таш күпере тирәсендә... «бөке» ясалган. Без теге куәс чиләгеннән дә зур, дөресрәге шырпы ящигы кадәр иләмсез кырлы сары таш астына тагын барып кердек, ярты минут чамасы көттек. Колонна кузгалды, Шәүкәт урынында борсалана иде, мин аңа таба борылганда Ибраһим абыйның «ох» иткән тавышы ишетелде һәм, миң аңлап алганчы, ярты тонналы сары таш (машина кузгалган секундта) безнең өскә тәгәрәде, чыкырдау тавышы ишетелде. Мин күзләремне ачтым: таш безнең өскә төшкәндә ян якка авышып киткән һәм капотның уң як борынын гына изеп узган иде. Без исән калдык, инде Шәүкәт тә зарланмый, шул рәвешчә эчтән генә уйланып Кырлайга кадәр барып җитте. Шөкер ходага, исән калдык дип музей каршында туктап машинадан чыктык. Безне анда көтәләр иде, бер көн алдан телефоннан хәбәр ителгән. Машинадан иң ахыргы булып, аякларын җыя алмыйча газапланып Шәүкәт чыкты.

— Билләһи, кайтканда бу удынга утыдмыйм мин, хадап итте бу мине, — дип ул аякларын яза башлады.

— Нәрсә дип зарланасың син? Әле моңарчы бер кешенең дә зарланганы юк иде, — дип, Ибраһим абый машинасының ишеген ачып артка үрелде һәм утыргычның җаймәсен рәтли башлады.

— Бәрәч! — дип кычкырды ул шатлыклы аваз белән. — Бәрәч! Менә бәхет! Мин бит моны инде өч көн буе эзлим. Менә шатлык!

Җәймә астыннан, Шәүкәт утырган турыдан ул саллы гына монтировка тимерен тартып чыгарды. Авызы ерык, чыраенда шатлык бөркелә иде. Тик Шәүкәт кенә, аш шулпасын капканда авызыннан пешкән таракан тапкан кешедәй, чыраен сытып читтә басып тора иде.

Музейны, Сәгъди абзый йортын карадык, дуслар белән чәй эчтек. Кыскасы, ял иттек. Кайтканда инде урыннар да җайлы булыр, таш йөге астына да кермәбез, дигән матур хыяллар белән юлга чыктык. Әмма Кырлай басуын узып олы юлга борылуга, Ибраһим абый ыңгырашып куйды:

— Ы-ыһ... Ах, чурт...

Мин куркынып алга-артка карадым: әлегә безне бәрдерерлек машина юк иде, монтировка тимере дә безнең аяк астында ята иде.

Сәгъди абзый өенең чоланында Ибраһим абыйның таягы калган икән, кире борылып Кырлайга керергә туры килде. Безне озаткан дуслар урамда әле таралышмаган иде (бездән соң берәр нәрсә оештырыргадыр инде исәпләре, безнең белән булмады бит: беребез рульдә, минем лекциягә кайтып керәсем бар), безне күреп бик гаҗәпләнделәр. Без таякны алып тагын юлга чыктык. Уф, алла... Тыныч кына кайтыйк әле, кайтыйк әле, кайт...

— Ы-ы-һ, — дигән тавышка сискәнеп киттем. Тагын бәрелдекме? Тормоз чыкырдады, әсәренеп Ибраһим агайга карадык. Ул ялварулы караш белән миңа дәште:

— Мөхәммәт! Минем бит чәй эчкән җирдәме, әллә музейдамы, портфель калган (без инде Арчага җитеп килә идек), нишлибез?

Нишлисең? Хәзер кире борылсак — мин лекциягә соңга калам. Кафедра мөдире мине яратмый, берәр «промах» биргәнне көтеп кенә яши.

— Юк, Ибраһим абый, сез мине лекциягә өлгертергә вәгъдә бирдегез, мине яндырмагыз...

— Ну бит анда минем документлар: паспорт, машина йөртергә «права». Болай булмый бит!

Сүзгә Шәүкәт кушыла, Даутов әле һаман Будда хәлендә тыныч утыра. Шәүкәт әйтә:

— Ул подфелең кайда иде? Мин аны күрмәдем. Ни төсле иде?

— Сары, чын күннән. Кулымда иде.

Сүзгә Будда катнаша:

— Мин менә бүген грамм да эчмәгән, миңа ышана аласыз, сезнең машинада андый крокодил тиресеннән эшләнгән портфель юк иде.

Шулай бәхәсләшә-бәхәсләшә Арчаның «АЗС»ына килеп туктыйбыз: минем лекция башланырга сәгать ярым калып бара. Шлангны кертеп, кассир белән алыш-биреш ясаганда Ибраһим аганың куртка кесәсеннән паспорты белән «права»сы килеп чыга. Шатлык! Портфель генә эзлисе калды...

Ә анысы — кайтуга табылды. Университетның «химкорпус» бинасында эшли идек без ул чакта. Килеп туктап, «стоянка»га куйганда чигенеп, машинаны тагын бер җиреннән чүт кенә яньчеп алгач, Ибраһим ага минем белән бергә дүртенче катка күтәрелде: 97-нче аудиториядә бер урындык өстендә аның, крокодил ук булып бетмәсә дә, яхшы гына портфеле ята иде...

Хикәя шуның белән тәмам... Юк, юк... Русчалатып әйтсәк, «никаких!». Дәвамы бар. Лекция башланырга әле унбиш минут. Инде тынычлап бер тәмәке тартып алырга да була. Коридорга чыгабыз. Шунда Ибраһим аганың исенә төшә: сигаретлары бит машина эчендә калган. Ә мин тартмыйм. Дүртенче каттан аска йөгереп төшеп, машинаны ачып сигарет эзлим: юк, бер җирендә дә юк. Теге монтировканы да кузгатып карыйм урыныннан: сигарет кабы юк. Күңелсезләнеп кенә

өскә күтәреләм. Күрәм — болар Әнвәр Ахунҗанов белән бер тәрәзә төбенә кунаклаганнар да, тәмләп төтен чигәләр.

— Ә, Мөхәммәт... Сигаретлар куртка кесәсендә икән минем. Напрасно төшеп йөргәнсең. Ну күңелле дә йөреп кайттык инде, ә? Әле шул турыда Әнвәр Мәхмудовичка сөйләп торам...

Иртәгесен кафедрада, лекцияләр башланыр алдыннан мин спектакль куям, күрсәтәм: без ничек кузгалып киткәнбез, ничек бәрелгәнбез, ничек итеп өстебезгә таш төшкән һ.б. Миңа берьюлы ике рольдә уйнарга туры килде: Ибраһим ага һәм монтировка өстендә утырып барган Шәүкәт. Тавыш, интонацияләрне куйдым, бөтен ымлыклар, аһылдаулар, «р» авазсызлыкны бирдем. Күзлеген идәнгә төшерә-төшерә көлүче Хатип Миңнегулов булды.

Ул арада кыңгырау һәм без аудиторияләргә таралдык. Тәнәфес вакытында Миңнегулов миңа әйтте:

— Сезне соңгы курс студентлары каршыдагы аудиториядә көтәләр, кереп чыксын иде, диләр.

Мин тиз үк кереп киттем. Керсәм — җиткән кызлар, солдат хезмәтен узып кайткан мыеклы егетләр шат елмаеп минем белән исәнләшteләр. Күрәм — өстәлдә кәгазь:

«Мөхәммәт Сөнгатович. Ибраһим абый булып машина алып барып һәм Шәүкәт Галиев булып арткы сиденьедә утырып күрсәтегез әле».

Мин матур рәнҗеп аудиториядән чыгып киттем. Нәрсә, мин клоунмы әллә?

... Ләкин шул аудиторияне мин сагынып яшим.

## XV

Без уналты катлы «учебный корпус»та эшлибез: математиклар, географлар, тарихчылар, журналистлар, рус һәм татар филологлары... тагын әллә кемнәр. Без — танышлар. Математикмы син, географмы, телчеме, әдәбиятчымы, тарихчымы...

Иртән эшкә килгәндә лифт янында очрашабыз, күрешәбез, хәл-әхвәл сорашабыз. Монда «специализация» юк: без — ирләр, танышлар, коллегалар. Син укыт үзеңнең «а» плюс «б»ыңны, мин укытам Дәрдемәнд иҗатын, теге иптәш Патагониядәге кара тәнлеләрнең хижина төзү ысулларын, бу иптәш — Мережковскийны, тагын бер иптәш — суффикс, аффиксларны, ә менә бу иптәш, инде Чыңгыз хан походлары белән шашкан.

Бүген исә мине бер иптәш туктатты. Иртән лифт янында аның белән очраштык. Һәр җөмләсе алдына «үзең әйткәндәй» дигән бер кисәк кыстырып сөйләшергә ярата.

Лифт көтәбез. Галим-голәма, студентлар. Тып-тын. Әлеге иптәш сүз башлый:

— Әй, дим, кичә телевизор карадыңмы син? Үзең әйткәндәй, теге шапылдык шыр надан, ялганчы икән бит (сүз Л. И. Брежневның КПСС съездында кичәге докладына турында бара).— Минем, куркудан, тәнемә каз итләре чыга. Студентлар безгә игътибар юнәлтәләр. Моны КГБ ишетсә? Минем бит алай әйткәнем юк Брежнев турында...

Лифтка керәбез. Гадәттә, лифт кабинасында тынлык була, сөйләшмиләр. Ә бу — орып та бирми:

— Әй, ул безнең ректор, үзең әйткәндәй, аңгырайган икән бит. Беркөнне зур советта чыгышын тыңладык без аның.— Минем чәчләр үрә тора, студентлар моны тыңлый. Лифттан мин чыгарга тиеш. Ул әле бер-ике кат өскәрәк күтәреләә. Минем лекция — тугызынчы катта. Соңгы сүзе:

— Карале, бу обкомның беренче секретаре, үзең әйткәндәй, чисти үз кешеләрен тутыра бит җитәкчелеккә. Болай барса, үзең әйткәндәй, Татарстанны сатып бетерә бит бу, ач калдыра бит бу безне...

...Юк, юк, боларны әйткәнем юк минем. Мин андый кеше түгел. Начар кәеф белән өйгә кайтам, ишек кыңгыравын басам, хатын каршы ала. Ишектән кергәндә беренче җөмләм автомат рәвештә авызымнан чыга:

— Син! Үзең әйткәндәй, шыр тиле син, белдеңме? Үзең әйткәндәй, надан син... Татарстанны, үзең әйткәндәй, сатып бетердең син...

Хатын тиз үк пустырник тамчылары, валериан әзерли.

## XVI

Банкет шаулый. Ундүртенче каттагы буфет залында утырабыз. Аста — «Кольцо». Трамвайлар — пенал, тукталышта торучылар курчак хәтле генә күренә.

Банкет — алтынчы курсларныкы, читтән торып укып диплом алганнарныкы. Аларда акча бар, банкетны шәп оештырганнар. Күңелсез генә утырам, тәрәзәләр шар ачык, аста — Казан гөрли, Казан яши. Тегене җырладылар, моны җырладылар, биеп тә алдылар. Һәм... кинәт:

— Дамский вальс!

Без — татар кемнән ким? Болконскийлар, Ростовлар танцевать иткәнме? Пушкиннар, Анна Кернлар, Татьяна Тургеневалар танцевать иткәнме? Менә без Апастан, Сабадан, Балтачтан, Мамадыштан килгән кызлар, ханымнар алардан киммени? Нигә әле классик рус романнарында гына «бальный танец»ка биилләр, ә без нигә әле «Ярлы кызы Гөлсараны» җырлап утырырга тиеш? Болконскийлар, Ростовлар, Кернлар бит без — Казан ягыннан түләгән налог хисабына, бездән киткән ит, май, бал, мех хисабына шулай гуләйт иткәннәр. Әйе, без кемнән ким?

Дип, уйланып утыра идем салат ашап, яныма чибәр бер кыз килеп басты, елмайды, мине танцыга чакырды. Тордым, биеп киттек, йөземдә шатлык юк, ә танцыга бары тик оптимист кешене генә чакырасы. Минем белән биеп йөрү ул — котельная трубасын кочаклап йөрү белән бер. Хуш, кем әле бу, мине танцыга чакырган чибәр, яше узып бара торган «заочница»? Беләм, сеңлем, сине, бик нык хәтерлим. «Егерменче йөз башы татар әдәбияты» курсы буенча нәкъ өч тапкыр «икеле» алып чыктың син миннән. Син бик чибәр, ә бик чибәр кызлар, гадәттә, бәхетсез булалар. Мин сиңа ярдәм итәргә теләдем, инструкция буенча исә ике тапкыр бер үк фәннән бирә алмаган студент инде имтиханын комиссия алдында бирә, шунда да бирә алмаса, аны университеттан приказ белән чыгаралар, ә мин синең бәхетле булуыңны теләдем, комиссия төзетмәдем, чөнки син, йә группа белән, йә, районнан килеп, сессия араларында, ялгыз гына имтихан бирмәкче булып минем каршымда утыра идең. Икеле сиңа, заманча әйтсәк, «неуд» сиңа. Син шулай елмаеп утырып миннән өч тапкыр «неуд» алдың. Син дә дәшмәдең (укымагансың бит!), мин дә дәшмәдем. Безнең факультетта йөргән гайбәт ул — гайбәт кенә: имеш, Мәһдиев чибәр кызларга, җавап бирмәсәләр дә, гел бишле генә куеп утыра. «Шалишь, кума, не с той ноги плясать пошла». Һәм, ниһаять, син дүртенче тапкыр килүеңдә менә дигән итеп җавап бирдең билетыңдагы сорауларга, мин җиңел сулап сиңа «дүртле» куйдым, «бишле» куярга минем хакым юк иде, чөнки — «пересдача». Университетның үз кануннары бар, ул кануннарга буйсынырга мин мәҗбүрмен...

Мин сине бит ике ел буе «мутузить» иттем, «тәк просто» гына сиңа билге куймадым. Синең иң зур дошманың — мин. Туктале, туктале, син нигә мине ачык тәрәзә янына таба алып барасың? Вальсны бит мондарак та, буфет ишеге төбенәрәк тә барып биеп була... Туктале, зур тәрәзә янына нәрсәгә өстерисең әле син мине, сеңелкәем? «Куйбышев мәйданы» дигән җиргә син мине этеп, тәрәзәдән ташлап, минем изелгән гәүдәмне күреп, теге өч тапкыр алган «ике»леңне бәйрәм итмәкчеме...

Юк, «шалишь брат», мин теге чибәрнең нечкә билен кысып, тәрәзәдән читкәрәк алып китәм. Буфет, кухня, тирәсенә. Беләм мин: Апас кызлары «опасно»!

Шулай буфет тирәсенә якынлашкач, мин тегеңә сорау бирәм:

— Туташ! Нигә дип мине танцыга чакырасыз? Сезнең бит факультетта иң яратмаган кешегез — мин. Мин бит Сездән бер үк курс буенча дүрт тапкыр имтихан алдым. «Вы же меня ненавидите»...

Туташ елмайды:

— Ялгышасыз, Мөхәммәт абый. Мин бүген диплом алдым, бәхетле көнем. Мин хәзер дөресен сөйли алам. Беренчедән, мин сезгә дүрт тапкыр кермәдем, ә биш тапкыр. Шуның дүртесендә әзерлексез кердем, елмаеп кына «дүртле» яки «бишле» алып чыгармын дип уйлаган идем. Кайбер фәннәрдән, кайбер ирләрдән мин шулай алгалаган идем. Сезне дә сынап карадым. Сезнең турыда матур кызларга сорап та тормыйча, «бишле» куясыз икән, дигән гайбәт йөри. Менә мин сезне сынап карадым: сез иң гадел кеше икәнсез. Мин сезне ихтирам итәм. Шуңа күрә иң беренче итеп сезне «дамский вальска» чакырдым.

Без инде гүзәл туташ белән ундүртенче катның ачык тәрәзәсе янында биеп йөри идек...

## XVII

Аядской паркында (бакчасында) кичке һава сулап йөрибез. Мин — ярлы аспирант, тегеләр — зубрлар. Әдәбият, татар филологиясенең башында торучылар, мин алардан арттарак калып атлыйм. Теге эшелон — Гомәр Бәширов, Хәмит Ярми, Хәсән Туфан, әле генә докторлыкны яклаган Хатип Госман. Сүз кыза, әңгәмә кыза, иң кызган чагында Шәйхи Маннур килеп чыга: сигарет мөштектә, пыс-пыс...

— Мин,— ди Хатип ага (минем гыйльми җитәкчем) бүген бер ачыш ясадым: без — татарлар, бөек рус культурасын тудыручылар булганбыз бит. Ул Эрмитажлар, Третьяковкалар, Казанский соборлар, Смольныйлар, Кремльләр бит барысы да безнең Казан ханлыгы кушылгач төзелгәннәр. Димәк, без — бөек рус культурасына нигез салганбыз...

Карт гвардия дәшми. Шыгыр-шыгыр карлы сукмактан атлый. Татар әдәбияты кафедрасы мөдире Хатип ага исә үз фикеренә бәя көтә. Шунда усал Шәйхи ага бер җөмлә әйтә:

— Алай икән, ызначит, без урыс культурасы үссен өчен тирес ролен үтәгәнбез икән...

Һәм ул, шундук, төркемнән аерылып, өенә кайтып китә...

## XVIII

Минем белән исәпләшкән (бәлки ихтирам белән караганнардыр) нибары өч кешене сагынып искә алам мин. Ни гаҗәп, берсе дә татар түгел. Болар: күпмедер еллар декан булып эшләгән профессор (аны мордвамы, удмуртмы диләр иде) Николай Александрович Гуляев, борынгы тарих кафедрасы мөдире, минем пединститут буенча остазым, зур галим, профессор Аркадий Семенович Шофман һәм СССР тарихы кафедрасы мөдире Иван Михайлович Ионенко. Иллә дә үзебезнең татар галимнәре мине яратмады инде... «Яратмады» дигән сүз бик кечкенә сүз, иң төгәле «ненавидели». Бу мәсьәләдә мин иң бәхетсез кеше булып утыз ел шунда яшәдем, эшләдем. Дәлилләр?

Менә ГЭК комиссиясе («Государственная экзаменационная комиссия») утырышы бара. Диплом яклыйлар егетләр, кызлар. Әгәр син

кафедра мөдире, яки декан яки куәтле тавышлы кеше икәнсең — синең җитәкчелектә язылган диплом эшенә бары тик «биш»ле генә. Әгәр син «рядовой» доцент икәнсең (әйтик, М. Мәһдиев), синең җитәкчелектә язылган диплом эшенә — «өчле» яки, тартып-сузып «дүртле». Мин утыз ел буе шушы экзекуцияне үз тәнемдә татып яшәдем. Деканнар, кафедра мөдирләре, көчле бугазлы укытучылар җитәкләгән диплом эшенә гел «биш» кенә тезәләр, минекеләргә гел «өч» тә «дүрт». Мин комиссия утырышларында үз студентларыма югары билге өчен беркайчан да көрәшмәдем: мин якламыйм, студент яклый бит.

Нурания исемле бик юньле бер кыз бар иде, әйбәт укый, сәхнәдә бик матур итеп җырлый, активистка. Бәхетсезлегенә каршы, миннән тема алды. Бик тә әйбәт, тирән бер хезмәт язды. Моңа «пять с плюсом» дип оппоненты чыгыш ясады. Аның белән бер үк утырышта декан, кафедра мөдирләре җитәкчелек иткән тагын берничә диплом эше каралды:

Нуранияныкенә караганда күпкә кайтыш эшләр бар иде. Комиссия студентларны һәм ГЭК әгъзасы булмаган укытучыларны чыгарып җибәреп, тегеләргә «биш»ле тезде, ә Нуранияга чак-чак «дүрт»ле куйды. Студентларны чакырып комиссиянең карарын игълан иткәч, аудитория телсез калды.

Нурания... кинәт сикереп торды, ишектән чыгып китте. Аның артыннан мин. Әмма ул озын коридор буйлап томырылып йөгерде дә, лифтны да көтеп тормастан аска төшеп китте. Шул көннән соң ул университетта бөтенләй күренмәде.

Наил дигән төпле, акыллы егет яклый. Бик әйбәт язган диплом эшен. Оппонент «биш»ле тәкъдим итә. Җитәкчесе — мин. Зачет кенәгәсен актарабыз. Алты ел буе гел әйбәт билгеләр генә алып килгән. Менә шуңа каныкты гына бит комиссиянең бер әгъзасы. Унбиш-егерме сорау бирде, егетне тәмам йончытты. Мин катышмадым, гаделсезлекнең берәр чиге буламы икән, дип газапланып утырдым. Түрәләр и бәхет чиктеләр инде, миңа карап ала-ала. Егет кызганыч иде. Студентлар чыгып киткәч болай сөйләшәләр:

— Моңа ничә куябыз? «Дүрт»леме?

— Оппонент бит «биш»ле диде.

— Ә мин «ике»ле куйыйк дип утырам әле (монысы аеруча миңа дошман — М. М).

Чак-чак «дүрт»ле куйдылар.

Ун еллар узгач, егеттән аны якламаганым өчен мин гафу үтендем. Ул миңа игелек, игътибар күрсәтеп яши, Казанда зур, җаваплы эштә.

Фирая исемле отличница яклый. СНО (Студенческое научное общество) җитәкчесе. Биш ел буе гел «биш»ле генә алып укыды. Баскан җиреннән ут чыгара. Инде моңа да «биш»ле куймасалар... Ләкин кызыйның «биш»ле алырга комачау итә торган бер «кимчелеге» бар: диплом эшенең җитәкчесе... әлеге дә баягы Мәһдиев. Һәм кызыйны «тәгәрәтә» башлыйлар.

— Ә менә син «Учительская газета»ның быелгы икенче апрель санын укыдыңмы?

— Ә менә син «Советская педагогика» журналының 4 нче санындагы баш мәкаләне укыдыңмы?

Шулай бер ахмагы үзе нәрсә укыган, шуларны санап, унлап сорау биреп, кызыйны кешелектән чыгарды. Биш ел буе бөтен факультетны бер итеп иҗтимагый эш алып барган, гел «биш»легә укыган, кара карлыгандай күзле, кап-кара, көлтә чәчле, куәте ташып торган Фирая, бичара, мондый хәлгә әзер түгел иде, жеби башлады. Оппонент ябык утырышта күпме генә тырышса да аның диплом эшенә «бишле»не куйдырта алмады. Нәтиҗәләрне әйткән вакытта мин ул бүлмәгә кермәдем: мораль хакым юк иде, чөнки Фираяны яклап бер сүз дә әйтмәдем.

Менә бер вакыт коридор гөрли башлады, чәчәк төргән целлофан чытырдавы, букет бирүләр, рәхмәт әйтүләр. Мин лаборантлар

бүлмәсендә үземне «побитая собака» дип хис итеп түбән карап басып тора идем.

Ишектә букет тоткан Фирая күренде. Минем янга килде... бер сүз әйтә алмый... кинәт кенә минем җилкәгә башын салды да дер-дер килеп елап җибәрде... Аны изгәннәр, ватканнар иде.

Фирая, бу язмамны укысаң, синең алда гафу үтенүем дип аңла. Мин сине ул көнне яклый алмадым.

Дөньяда синең кебек куәтлеләрне дә елата торган гаделсезлекләр бар...

## Соңгы сүз

Мин бу истәлекләремнең җыелмасын «Сагынам сине, илкәем» дип исемләгән идем. Җырдан бер өзек бу. Аңлашылса кирәк, гали уку йортын сагынып яшим мин. Әйе, мин дә фәрештә түгел, минем дә хаталарым булгандыр. Хаталар Маркста да, Энгельста да, Ленинда да булгандыр (соңгысыныкы — бүген күз алдыбызда). Мин — алар түгел.

Ләкин минем теләгем изге: 60—80 еллардагы университетның татар бүлеге тарихыннан кайбер «штрих»лар бирү.

Кем ничек кабул итә моны — аларның эше. Истәлекләремнең әлеге өлешендә матурракларын сайларга тырыштым, чөнки бу елның көзендә татар бүлеге үзенең 50 еллык юбилеен билгели. Аннары карарбыз әле.

Бәйрәмнәр котлы, мөбарәк булсын!

*(Истәлекләрнең беренче көлтәсе тәмам).*

# МӘДӘНИЯТЕБЕЗ САГЫНДАГЫ МӘДИНӘ



Безнең арабызда дистәләрчә ел гомерләрен милли тарихыбызны, мәдәниятебезне өйрәнүгә, яктыртуга, пропагандалауга биниһая зур өлеш керткән олпат шәхесләр бар. Шунысы куанычлы, алар арасында махсус тарихи, иҗтимагый-гуманитар белемгә ия булмаган, зур фәнни дәрәҗәләргә, дан-шөһрәткә ирешүне максат итеп куймаган, җаваплы урыннар биләмәгән, әмма халкына хезмәт итүне тормышның кыйбласына әйләндергән, аны намус-вөҗдан эше дип санаган һәвәскәр зыялылар да очрый. Мондый зыялылар үзләрен профессиональ белгечләр, тарихчылар дип күкрәк каккан, ничәмә еллар дәвамында үткәнебезне чалыш көзгедә күрсәтеп килгән кайбер «фән әһелләре»нә караганда мәдәниятебезгә чагыштыргысыз дәрәҗәдә күп файда китерделәр. Берәүләр халкыбызның үткәненә, тарихына яла ягып, гамәлләренә дегет сылап ятканда, болар иң авыр шартларда да җиң сызганып ата-бабаларыбыз рухын пакьладылар, аларның изге исемнәрен халыкка кайтару өчен көрәштеләр, милләтебезнең, бигрәк тә яшь буынның күзеннән гафләт элпәсен салдыру юлында армый-талмый хезмәт иттеләр. Мондый энтузиастларның эшчәнлеген чын мәгънәсендә рухи азаматлык, тарихи каһарманлык дип атарга мөмкин.

Шундый мәгърур шәхесләребезнең, гасыр башы тәгъбире белән әйтсәк, милләт аналарының берсе — Оренбур каласында ярты гасыр дәвамында игелекле гамәлләр кылып гомер кичерүче милләтпәрвәр Мәдинә апа Рәхимкулова булыр. Элекке СССР География җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, педагог, армый-тал-

мый эзләнүче, актив каләм әһеле буларак, яшәгән шәһәрендә генә түгел, ул төрки халыклар гомер сөргән байтак төбәкләрдә дә яхшы билгеле. Урысча укыган башка халыклар да аны күп язмалары аркылы беләләр. Бу шәхеснең күпкырлы эшчәнлегенә шундый эчкерсез бирелгәнлек, сихри омтылыш, иҗади муллык хас ки, аның хакында гомуми шәкелдә генә булса да каләм тибрәтмәсәк, заман-вакыт каршында зур гөнаһ кылынган булыр иде. Беренче нәүбәттә бал кортыдай уңган, эшлекле замандашыбызның тәрҗемәи хәленә үзебез белгән күләмдә күз салып китәрбез.

Мәдинә Фәтхетдин кызы Рәхимкулова 1916 елның 30 июнендә элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе Кыргыз-Миякә волостеның (хәзерге Башкортостанның Миякә районы) Олы Кәркәле авылында дөньяга килә. Зур һәм бай тарихлы гаиләдә үсә. Бу гаиләнең көнкүреше, яшәү рәвеше, заманы өчен типик булса да, үтә гыйбрәтле. Ул зыялы татар кешеләренең, руханиларның, милләт мәнфәгатьләрен күз уңында тотучы эшлеклеләрнең совет чорындагы аяныч хәлен шәрехләү ягыннан бигрәк тә әһәмиятле. Шуңа күрә без тарихыбызда мәгълүм бер эз калдырган Рәхимкуловлар язмышына кинрәк тукталуны кирәк саныйбыз. Мәдинәнең әтисе Фәтхетдин Галләметдин улы Рәхимкулов (1870—1937) таза хәлле крестьян гаиләсеннән чыккан, яшьлегендә Мисырның Искәндәрия һәм Каһирә шәһәрләрендә тыйбб (медицина) институтында белем алган, берничә чит телдә иркенләп сөйләшкән укымышлы кеше була. Русиягә әйләнеп кайтканнан соң, ул башта патша хезмәтенә, ягъни гаскәргә алына. Хезмәт срогын тутыру белән үк туган авылына юл тота. Ләкин авылда авырулар булмау сәбәпле, аңа табиблык вазифасын калдырып торырга һәм икенче бер изге эш — балалар укытырга керешергә туры килә.

Бу чорларда, бигрәк тә 1905—07 еллардан соң, җәдидчелек, ягъни ауропача белем бирүгә йөз белән борылу, яңа ысуллы мәктәпләр ачу аеруча киң колач җәя. Укымышлы Фәтхетдин дә үзенең кадими (иске ысуллы) мәктәбен яңача нигезгә күчерә. Балаларны сыйныфларга (классларга) бүлә, парталар, кара такталар һәм башка әсбап-җайланмалар, җиһазлар кайтарта. Һәр сыйныфта аерым мөгаллим булдыра. Ләкин бу яңалыклар фанатик элементлар, иске карашлы руханилар, «Фәтхулла хәзрәт»ләр тарафыннан үтә тискәре кабул ителә. Алар, анда мөселман баласыннан урыс ясап чыгаралар, дип, авыл халкын үз балаларын бу мәктәпкә бирүдән тыялар. Мөгаллимнең икенче зур «гөнаһы» да фаш ителә. Үзенең кызын урыс гимназиясенә укырга биргән өчен, мөхтәсиб карары буенча, Фәтхетдин камчы белән суктырыла. Табиб һәм мөгаллимнең үтә матур тавыш белән җырлавы да аны күп авылдашларыннан аерып торган. Ул олыгайганчы үзенең җырга һәвәслеген онытмаган. Әлбәттә, иске фикерлеләр монысын да өнәмәгәннәрдер инде.

Заманында атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укыган мөгаллим үзенең укытучылык эшен рәсми һәм ышанычлы нигезгә салу өчен мулла булырга карар бирә. 1910 елда ул Уфага, Диния нәзарәтенә юнәлә һәм мөфти хәзрәтләре каршында тиешле имтихан тота, нәтиҗәдә имам-мөдәррис, ягъни укытучы-мулла исеменә лаек була. Бу гамәлнең зур гына файдасы тия: яңача мәктәпнең язмышы уңай якка хәл ителә, балаларга сабакка йөрергә киртә калмый. Әлбәттә, имамлык чорында Фәтхетдин тиешле хәзрәт вазифаларын да үти, күләмле эшләр башкара: халыкның демографик үсешен, никахларны терки, шәригать кануннары нигезендә гамәл кыла, Диния нәзарәтенә даими хисап-отчет биреп тора һ. б.

Совет чорында Фәтхетдин язмышы аяныч борылышларга тап була. Дин әһелләренә ясалган иләмсез басымга, кысрыклауга түзә алмыйча, ул 1924 елда үзенең муллалыгыннан мәҗбүри сурәттә ваз кичә. Инде җир эше, авыл хуҗалыгыннан башка шөгыле калмый. Мисырда алган тыйбб гыйлемен элекке мулла гомеренең соңгы елларында гына беркадәр куллануга ирешә. Мәсәлән, 1930—35 елларда Фәтхетдин Рәхимкулов Сәмәрканд ветеринария техникумында вахтер булып эшли һәм студентларга гайре рәсми рәвештә анатомиядән консультацияләр бирә. Ә 1936—37 елларда үзенең төп белгечлегеннән, ниһаять, кыска гына вакыт рәсми төстә файдаланып ала: Сәмәрканд өлкәсенең Жизак шәһәрендә чәчәк салучы (оспопрививатель) һәм хинин белән дәвалаучы булып эшли.

67 яшен тутырыр-тутырмас, Фәтхетдин абзый иң дәһшәтле елларда үлеп китә. Аның дөньядан совет хакимиятенә рәнҗеп үтүенә шикләнмәскә мөмкин: матди һәм рухи яктан шыксыз рәнҗетүләрдән тыш, аны тавыш бирү хокукыннан да мәхрүм итәләр. Ул вакыттагы атама буенча, Фәтхетдин карт барлык гражданлык хокуклары киселгән кеше, ягъни, урысча әйткәндә, «лишенец» булып йөри.

Мәдинәнең әнисе, Фатыйма Гомәр кызы Козлова (1888—1962) Казанда мәшһүр Кәримовларның тире чимал җыючысы булган приказчик гаиләсендә дөньяга килә. Атасының эш урыны хәзерге Башкортостанның Шафраново станциясе янындагы Сләк-баш авылы булганлыктан, Фатыйманың балалыгы һәм яшьлеге күбесенчә шул авылда үтә. Мәдинәнең әбисе: ягъни Гомәр Козловның хатыны, авыл балаларына сабак укыта. 1906 елда Олы Кәркәледә яшәгән Фәтхетдин Рәхимкуловның хәләл җефете, ике баласын ятим калдырып, вафат була. Шуннан соң 18 яшьлек Фатыйманы 36 яшьлек Фәтхетдингә димлиләр. Никахлашу нәтиҗәсендә, яңа гаиләгә нигез салына. Яшь хатын, ягъни Мәдинәнең әнисе, гаилә традициясенә тугрылыклы калып, кыз балаларны укырга-язарга һәм кул эшләренә өйрәтә. Фатыйма укытучылык шөгылен 1929 елга кадәр дәвам итә, күп яшь җилкенчәккә аң-белем бирә. Димәк, Мәдинә Рәхимкулованың педагогик эшчәнлеге гаилә традициясенең бер чагылышы икән.

1910 елда, ире Фәтхетдиннең беренче чиратта имам-мөдәррис булуына ризасызлык белдереп, Фатыйма авылны ташлап китә һәм Иж-Буби авылының мәшһүр Мәхлисә абыстай мәдрәсәсенә барып керә. Үз балалары белән берлектә, иренең беренче хатыныннан калган үги балаларын да ияртә. Иж-Бубига Сләкбаштан, шулай ук балаларын алып, Фатыйманың әнисе дә килеп төшә. Болар күмәкләшеп бер өй алып торалар, энҗе һәм ука белән чигүнең зур осталары булганлыктан, бай укучыларның заказларын үтәп, кул эшләре белән үзләренең һәм балаларының тамакларын туйдыралар. Шул ук вакытта мәдрәсәдә дәрес алырга да онытмыйлар. Ләкин 1911 елның февралендә Иж-Буби авылы мәдрәсәсе патша хакимияте тарафыннан тар-мар ителә. Фатыйма да, аның әнисе дә чарасыз калып, ирләре янына кайтып китәләр.

Мәдинәнең әнисе Фатыйма совет чоры вәзгыятендә үз урынын җиңелрәк тапкан булса кирәк. 1917 елдан соң ул авыл советы депутаты булып китә, хатын-кызлар хәрәкәтен, батраклар комитетын җитәкли, комсомолларга булышлык күрсәтә, авылда наданлыкны бетерү кампаниясендә актив катнаша. Бер мәлне Мәдинәләр авылы укый-яза белүчелек буенча кантон күләмендә хәтта беренчелекне яулый.

Рәхимкуловлар гаиләсе ишле була. Берничә бала сабый чакта ук дөнья куя. Исән калганнары турында берничә сүз. Мәдинәнең бертуган абыйсы Хәмит 1910 елда туган, 1941—45 елгы сугышта катнашкан, аннары институт тәмам иткән, озак еллар укытучы булып эшләп, пенсиягә чыккан, хәзер Мәскәүдә яши. Сәлимә 1912 елда дөньяга килгән, 7 класс бетереп, тегүчелек һөнәрен сайлаган, инде оныклар үстерү белән мәшгуль. Мөнҗия 1914 елда туган, юстиция хезмәткәре (адвокат) булып эшләгән, хәзер лаеклы ялда. Аннары мәкаләбез каһарманы Мәдинә дөньяга аваз салган (1916). Энеләре Исмәгыйль (1923 елгы) үз теләге белән фронтка киткән, авыр яраланып, бер ел госпитальдә яткан, аннан инвалид булып чыкса да, янадан алгы сызыкка ыргылган. Сугыштан кайткач, башта урта мәктәпне, аннары нефть институтын тәмам иткән, нефть эзләүче булып эшләгән, техник фәннәр кандидаты. Уфа шәһәрендә әле дә булса җиң сызганып эшли.

... 1929 ел керә. Сталин диктатурасының казык тешләре зәһәр шыкырдый башлаган чор инде бу. Фәтхетдингә, барлык иске һәм яңа «гөнаһларын» искә төшереп, күтәрә алмастай салым салалар. Шушы җәза салымын түләүдән гаҗиз калып, ишле гаилә, «бурыч»ны каплау өчен бар өй-каралтысыннан, мал-мөлкәтеннән колак кага. Унөч яшьлек Мәдинәнең күңелендә җәрәхәт булып уелып калган иң әрнүле хатирәләрнең берсе әтисенең гаҗәеп бай китапханәсе белән бәйле. Барлык тартып алынган мөлкәттән иң кызганычы минем өчен шул булды, дип, ул бу турыда бүгенгәчә сыкранып искә ала. Китапханәдә Фәтхетдин абзыйның үз вакытында Мисырдан алып кайткан анатомия һәм физиология буенча калын-калын китаплары, чыга башлаган көненнән алып җыелган татарча гәзит-журналлар, төрле телләрдәге проза әсәрләре, фәлсәфә буенча хезмәтләр, революциягәчә һәм совет чорында дөнья күргән, фәннең төрле тармакларына караган дәреслекләр, методик кулланмалар һ. б. була. Барлык бу басмалар талаучылар (экспроприаторлар) тарафыннан өйнең гөрләп янган миченә ыргытыла. Учак тергезү өчен утын ишек алдында җитәрлек булса да, инквизиция өйдә үткәрелә. Хәер, бу җәза операциясе «сыйфат» ягыннан 1938 елдан беркадәр кайтыш була әле. Асу-кисү-ату механизмы көйләнеп беткәч, җәзага юлыккан «дошманнар»ның китаплары инде урам учакларында көл ителә. Мәдинә апа, ирония белән искәрткәнчә, яндырылачак китапханәдән сала агайлары Ленин «Искра»сын гына үз итәләр: махра тәрү өчен аннан да кулай кәгазь табылмый. Пушкинның нәни тартмачыкларга салып эшләнгән әкиятләре, кечкенәлекләре сәбәпле, бу максатка җавап бирә алмый. Ә тыгыз, авыр китаплар урыс мичендә дә начар яна.

Кыскасы, Рәхимкуловларны, заманының бөтен җинаятьчел таләпләренә туры китереп, җәзага тарталар, «кулак гаиләсе» дигән мөһер сугып, читкә сөрәләр. «Кулак калдыгы»ның гаиләсе хәзерге Башкортостанның Әлшәй районы Чурай авылына килеп сыгына.

Иң сәере шул булды, дип искә ала Мәдинә апа, налог салу һәм «раскулачивание» дигән галәмәт, ни хикмәттер, бик сайланмалы, сәер, төрле кешегә, авылга, районга карата төрле кимәлдә уздырылды. Әйтик, Чурай авылында бер генә атлы башкорт һәм аты гомумән булмаган татар (Фәтхетдиннең туганы) кулакка чыгарылса, күрше Михайловка авылындагы урыс, бер көтү ат-сыеры, бай йорты, хуҗалыгы була торып та имин калды. Кемнәрдер гаиләләре белән Себернең төньягына сөрелде, чит-ят җирләрдә әҗәлен тапты, ә кемнәрдер, чыннан да бик мөлкәтле булуларына карамастан, дөньяның артына тибеп яши бирде. «Кулакны сыйныф буларак юк итү» шигаре үтә гаделсез һәм эзлексез рәвештә тормышка ашырылды. Аның төп фәлсәфи мәгънәсен гади татар белән башкорт агае түгел, кремль идеологларының үзләре дә бик үк аңлап бетермәде шикелле. Һәрхәлдә, аны тормышка ашыруда төпле бер тәртип юк иде. «Кулакны бетерү» еш кына үзмаксаттан чыгып, һәр авылның «тиешле норма»сын күздә тотып, ә күп кенә очракта көнчелек, ачу, үч алу нигезендә эшләнде. Бу өлкәдә җирле хакимият үз каланчасыннан торып эш итүне төп принцибына әйләндерде.

Шулай итеп, Мәдинәләр гаиләсе туган төбәкләреннән читкә сөрелә. Ләкин шушы вакытта Фатыйма апаның үз авылында активистка һәм озак вакытлар авыл советы депутаты булып торуы ярап куя. Гаиләне, Фәтхетдин абзыйдан башка, гражданлык хокукларыннан мәхрүм итмиләр. Әмма дөнья көпчәгенең кая тәгәрәгәнен сизеп торган, лаеш шулпасын чүмечләп эчкән адәмнәр боларга Чурайны да тизрәк ташларга киңәш итәләр.

Әйтергә кирәк, Мәдинәләр гаиләсе әле чагыштырмача «ансат» котыла. Судан коры ук чыкмаса да, үлем-җитем булмый. Ә менә Фәтхетдиннең бертуган энесе Сәхабетдиннең язмышы, гомумән, фаҗигале тәмамлана. Казан укытучылар семинариясен тәмамлап, гомер буе үз авылында урыс классларында укыткан педагогны 1930 елда зинданга салалар һәм шунда кыйнап үтерәләр. Хатынын, бер яшьтән унике яшькәчә биш кечкенә баласы белән, морҗасыз кара мунчага куып чыгаралар. Иң аянычы шунда: шактыен Сәхабетдин Рәхимкулов укучылары тәшкил иткән активистлар төркеменең үч алуыннан куркып, бу мескен гаиләгә берәү дә ярдәм кулы сузмый. Тиздән тол хатын һәм аның олы кызы кара мунча ләүкәсендә җан бирәләр, ә калган үксез сабыйларны балалар йортына озаталар. Әлбәттә, 1939 елда фин, 1941 елда герман сугышы башлангач, бу «кулак калдыклары», кыйнап үтерелгән «халык дошманнары» балаларының да кирәге чыга: аларны «туп ите» сыйфатында алгы сызыкка, үзләрен нахакка җәзалаган системаны якларга, канлы диктатураны саклап калу өчен ут эченә илтеп тыгалар.

Алай да Рәхимкуловлар төшеп калганнардан булмый. Әйтик, Сәхабетдин абзыйның улы Хәсән фронттан кайткач, Казан медицина институтын тәмамлый, диссертация яклый, «восстановительная хирургия» дигән бүлектә эшли, үкчәләре белән алга басып торучыларны төзәтә. Галимнәр арасында үзен «Волжский Илизаров» дип йөртәләр икән. Хәзер Казанда яши.

50 нче елларның урталарына таба элекке «халык дошманнары», аларның нәселе гаепсез табылып, рәсми төстә аклана башласа да, кулак дип сөрелгән, гражданлык хокуклары киселгәннәрнең нәсел-нәсәбеннән кара тамга һаман да юылмый әле. Шуңа күрә «лишенец» нәселе буларак күргән кагылу-сугылулары хакында Мәдинә апа да, аның туганнары да бүгенгәчә артык җәелгәннәре юк. Автобиографияләрдә дә бу момент, бәладән башаяк дигәндәй, дистә еллар дәвамында читләтеп үтелгән. Хәлбуки, әлеге афәт үзенә бер аерым тема.

Сүз уңаенда шуны искәртик, 1976 елда җирле район газетендә Рәхимкуловларның рухына дога сыйфатында, бу нәселнең мәгърифәтчелек эшчәнлеге турында мәкалә басылып чыга.

Сөрелгән «кулак» балалары, кайда гына яшәсәләр дә, үзләренең «җинаятьчел» чыгышларын яшерергә мәҗбүр булалар, чөнки мондый «контрлар»ны иң кара эштән дә ике дә сөйләшеп тормыйча куалар. Мәдинә 14—15 яшендә яңа төзелгән совхозда эшкә урнашу бәхетенә ирешә. Кара тиргә батканчы көлтә бәйли ул анда. Әмма анда да озак юанырга туры килми. Кемдер үзендә мулла кызы эшләве турында совхоз директорына серне чишә, сыйнфый дошман токымын сыендыру өчен җәзага тарыячагына ишарәли. Эшче кулларга кытлык чамасыз зур булса да, «сыйнфый сизгерлек» күрсәтеп, житәкчелек үсмер кызны эштән куып чыгара. Мәдинәнең барлык абый-апалары да шул ук язмышны уртаклаша.

Алай да, туп урынына типкәләп йөртелүенә карамастан, Мәдинә Самар-Златоуст тимер юлына караган Дәүләкән станциясендә (татарча исеме Иткол) Ф. З. С., ягъни фабрика-завод җидееллыгында, өч ел уку бәхетенә ирешә, шул ук вакытта элеваторда төрле эшләрдә эшли. Ләкин эзәрлекләнгән гаилә әгъзалары даими эш урыны табалмыйлар. Төрле җирләрдән кат-кат куылгач, Рәхимкуловлар ахыр чиктә туган якларын бөтенләйгә калдырып, Кыргызыстан тарафына юл тоталар. Сөрелүнең яңа этабы башлана.

1932 ел. 16 яшьлек Мәдинә Кыргызстанның Беловодск районы Кош-Төбе авылында башлангыч кыргыз мәктәбен житәкли. Апасы Сәлимә күршедәге кыргыз мәктәбенә эшкә урнаша. Әниләре Фатыйма да шунда җыештыручы вазифасын үти. Бераздан язмыш Мәдинәне Кыргызстанның Югары Аларча авылына илтеп ташлый. Ул биредә дә кыргыз мәктәбендә белем бирә. Сәләтле кыз вакытын бушка уздырмый: параллель рәвештә читтән торып педагогия техникумының ике курсын тәмам итә. Мөгаллимлек вазифасыннан тыш, Мәдинә, апасы белән берлектә, гәрчә сизелерлек уңышка ирешә алмасалар да, наданлыкны бетерү шаукымында актив катнаша, кыз балаларны 11 яшьтән кияүгә бирү йоласына каршы чыгып, халык арасында аңлату эшләре алып бара. Тик сабый кыз балаларның ата-аналары, «карт кызлар» (16—17 яшьтә!) дип, боларның күзләрен ачырмыйлар, үзләренә кияү чыкмаячагы белән куркыталар. 11 яшь иргә бару өчен иң кулай вакыт, дип зәһәр чәчәләр...

1936 ел керә. Мәдинә Сәмәрканд шәһәренә күчеп килә, «Узтранс» автобазасына наряд бирүче булып урнаша, шул ук вакытта Үзбәк дәүләт университетының кичке рабфагына аяк баса. 1938 елның язында кыз рабфакны бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый һәм Казанга килеп, университетка укырга керә.

1941 елның язында, матди хәле начарлану сәбәпле, Казан студенткасы Оренбурга барып төпләнә, андагы педагогия институтының соңгы курсында укуын дәвам итә. Озакламый дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, «кызыл» диплом ала, вуз юлламасы буенча Оренбур өлкәсе Мостай районының Мостай урта мәктәбенә физика-математика укытучысы итеп җибәрелә. 1944 елда яңадан Оренбурга кайта, биредә 1953 елга кадәр кичке урта мәктәптә дәресләр бирә. Шул ук елның көзендә Мәдинә Фәтхетдин кызын без инде Оренбур авыл хуҗалыгы институтында физика һәм электротехника кафедрасында өлкән укытучы сыйфатында күрәбез. Бирелән ул 1971 елда лаеклы ялга китә. Һәр җирдә тулы омтылыш, бирелгәнлек белән эшләргә күнеккән Мәдинә ханым 1951—52 елларда кичке марксизм-ленинизм институтын бик муаффәкыятьле сурәттә тәмамлый, шул чорда (1952), заман таләбенә буйсынып һәм үзенең «кара», һичьюгы «чуар» үткәнен йолу максатында большевиклар партиясе сафларына керә. Институтта эшләү елларында кандидатлык имтиханнары тапшыра, бик кызыклы темага диссертация дә яза. Темасы (татарчага күчерсәк) болайрак яңгырый: «Революциягә кадәрге татар дини мәктәпләрендә табигать фәннәрен укыту һәм шул ук чорда Русиядә табигать белеме һәм төгәл фәннәр буенча татарча басылган дәреслекләр». Кызганычка күрә, сәламәтлеге начарланып китү сәбәпле, безнең укытучыбыз диссертациясен яклый алмый кала. Хәзерге вакытта Мәдинә апа аны китап итеп әзерли.

Мәкаләбез каһарманының биографиясен мөмкин кадәр тулырак яктырту максатында без Мәдинә апаның иң якын даирәсе, ягъни гаиләсе турында да берничә сүз әйтеп китәрбез. Аның ире — Якуб Габдрахман улы Шабакаев 1911 елда элекке Сарытау губернасының Хвалыйн өязе Иске Карамалы авылында туа. Оренбур педагогия институтын тәмамлап, фронтка китә, аннан кайткannан соң пенсиягә чыкканчы математика укыта. Якуб ага Оренбурда сакланып калган соңгы татар мәктәбенең директоры була, башта аны үстерү, аннары коткарып калу, ягъни яптырмау өчен арысланнарча көрәшә. Ләкин Никита Хрущевның, коммунизмга бер тел белән тизрәк барып житәчәкбез, дип саташуы, сафсата сатуы чорында, 1962 елда бу белем учагы татар мәктәбе буларак сүнә. Аны өстән килгән фәрман белән юкка чыгаралар. Якуб Шабакаев җыр-музыкага да бик һәвәс, күп милли көй-җырлар туплаган, тасмага яки табакка яздырган, аларны төрлечә алга сөргән энтузиаст кеше. Гаҗәп матур тавыш белән җырлап, озак еллар милләттәшләрен соклandырган, куандырган шәхес. Хәзерге вакытта, олы яшьтә булуына карамастан, татар китапханәсе каршында теләгән мөэмин-мөселманны Коръән укырга өйрәтә.

Мәдинә апаның тагын берничә горурлыгы бар. Берсе — өлкән кызы Дина Шабакаева (1944 елгы). Ул 1962 елда Оренбурдагы урта мәктәпне көмеш медальгә тәмамлый, МГУга (Мәскәү университеты) конкурс буенча үтә, чит телләр өйрәнә, студент чагында ук төрле очрашу-җыелышларда инглиз һәм румын телләреннән тәрҗемәче вазифасын үти. 1970 елда бу татар кызы Хелги

Харалдссон дигән бер Исландия егетенә кияүгә чыга. Яшь гаилә 1971 елда Исландиягә юнәлә. Хелги Мәскәүдә урыс теле буенча аспирантура тәмамлый, диссертация яклый. Динә ире ватанында төрле урта уку йортларында инглиз һәм урыс телләре укыта. Бу пар 1972 елда Исландия башкаласы Рейкъявикта үткәрелгән Спасский-Фишер матчы турында шахмат журналында урысча язып чыга, әлеге тарихи бәйге турында өлгер һәм кызыклы информация бирә. Икенче елны яшьләр Исфьюрдур шәһәренә күчәләр, гаилә санын ишәйтеп җибәрәләр. Бер-бер артлы ике кызлары туа, алар өлгереш һәм уңганлык ягыннан әти-әниләре һәм әби-бабалары йөзенә кызыллык китермиләр. Мәдинә апа кызы һәм кияве янына Исландиягә бара (1973—1974), бу сәяхәтнең тәэссоратлары турында «Исландия буйлап» дигән мәкаләләре белән «Совет Башкортстаны» һәм «Южный Урал» гәзитләрендә чыгыш ясый. 1974 елда Харалдссоннар Норвегиягә күчеп киләләр. Башта университетта укыталар, аннары Хелги үзе бер институтның директоры булып китә. Динә белән Хелги озак еллардан бирле бик зур күләмле исландча-урысча сүзлек төзү өстендә эшлиләр икән. Мәдинә апа Норвегиягә дә ике тапкыр (1977, 1983) барып кайта, кызы исә гаиләсе белән Оренбурга ике елга бер кайтып йөри.

Мәдинә апаның икенче кызы — Диләрә Шабакаева (1946 елгы) урта мәктәпне, апасы кебек үк, көмеш медальгә бетерә. Динәнең дә, Диләрәнең дә сурәтләре «мәктәп алар белән горурлана» дигән плакат астында тора. Ләкин боларга алтын медаль бирмәс өчен барысын да эшлиләр, тиешле «бишле» урынына «дүртле» куеп, «татарка не может писать на отлично сочинение на русском языке» дип мөһер сугалар. Диләрә Ленинград университетының физика факультетын тәмамлый, аннары ясалма сүс фабрикасында эшли, белеме буенча шулай ук физик Игорь Поздняков дигән урыс егетенә кияүгә чыга, инде ике балалары үсеп буйга җиткән. Санкт-Петербургта яшиләр. Өлкән кызлары Настя математик, аспирантурада укый. Улы Антон (1976 елгы), гомумән, вундеркинд. 1993 елда урта мәктәпне тәмамлаган. Берничә ел буена Алма-Ата, Анапа, Мәскәүдә математика олимпиадаларында җиңеп чыккан. 1993 елның июлендә Истанбулда халыкара олимпиадада шәхси беренчелектә зур уңыш казанып, алтын медальгә лаек булган. Санкт-Петербург университетының механика-математика факультеты студенты Антон Поздняковның һәм дусларының җиңүе хакында «Санкт-Петербургские ведомости» гәзите язып чыкты (1993, 6 август).

Мәкаләбез каһарманының өченче йөрәк җимеше — Рәшид (1952 елгы) инженер-электрик. Бихисап техник һөнәрләре өстенә, аерым бер хоббие да бар икән. Ул төрле рәвештәге самолет модельләре, планерлар ясау белән мавыга, фантазиягә байлыгы белән күпләрне җәлеп итәрдәй алтын куллы оста. Җитмәсә, дельтапланеризмнан өлкә чемпионы да үзе.

Мәдинә апаны атаклы кардәшләр мәсьәләсендә Аллаһе Тәгалә, гомумән, кыерсытмаган. Аның туганнан туган (әтисе ягыннан) абыйсы Габдрахман Рәхимкулов 1922—33 елларда совет илчелегенең Төркиядәге сәркатибе булып эшләгән. Җиде телдә сөйләшкән. 1959 елда вафат булган инде.

Мәшһүр җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрь Айдар Хәлим дә Мәдинә апаның туганнарыннан (өч туган кардәш) икән...

* * *

Мәдинә Рәхимкулованың иҗади эшчәнлеге, нигездә, 1953 елдан, Оренбур авыл хуҗалыгы институтында укыткан чордан башланып китә. Физика белгече буларак, аның тәүге хезмәтләре төгәл фәннәр юнәлешендә тәрәккый таба. Ул институтның барлык факультетлары өчен тәҗрибә нигезендәге лаборатор эшләнмәләр әзерли, махсус кулланмаларның бөтен бер сериясен иҗат итә. Дистәләгән мондый кулланмалар арасында без, мәсәлән, мондый исемдәгеләрен дә очратабыз (бу һәм моннан соңгы урысча хезмәтләрнең исемнәре тәрҗемәдә бирелә): «Микрометр белән үлчәү», «Чәчелмә каты һәм сыек җисем-матдәләрнең тыгызлыгын билгеләү», «Броун хәрәкәтен күзәтү» һ. б. 1962 елдан ул фәнни күзәтүләре белән матбугат битләрендә чыгышлар ясый башлый.

60 нчы елларның азакларына таба Мәдинә ханымның «төгәл» фәннәр фасылындагы чыгышлары иҗтимагый-тарихи юнәлеш белән үрелеп бара башлый. Үзенең төп белгечлегеннән читләшмәгән хәлдә, ул мәсьәләнең тарихи яссылыгына кереп китә, һәвәскәр краеведчылыкка таба ышанычлы адымнар ясый. Мондый характердагы материаллар исәбенә аның төрле җирле басмаларда дөнья күргән «Оренбур физика-медицина җәмгыятенең 1865-1912

еллардагы эшчәнлеге», «Оренбурлылар — беренче Менделеев съездларында катнашучылар», «Оренбурның «Тургайская газета»сы Д. И. Менделеев турында», «Орск 95 ел элек», «Революциягәчә татар мәктәпләрендә химия буенча бер дәреслек турында», «Оренбур Татар укытучылар мәктәбе» кебек мәкаләләрен кертергә мөмкин. Шунысы гыйбрәтле, Мәдинә Рәхимкулова популяр мәкаләләренә «яшел ут» биргәндә беренче нәүбәттә Оренбурның «Южный Урал» гәзитен үз итә. Шул басма битләрендә «урыс телле» укучыларны тарихи, иҗтимагый, мәдәни, милли мәсьәләләр буенча инде чирек гасыр дәвамында агартып килә. Колачы, офыклары һаман саен киңәя барган тикшеренүче бер үк вакытта «Совет мәктәбе», «Казан утлары», «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә»), «Чаян» журналларында, «Совет Башкортстаны», «Кызыл таң», «Социалистик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан»), «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») кебек популяр, зур тиражлы гәзитләрдә чыгышлар ясый. Соңгы елларда яңа гәзит-журналлар дөньяга аваз салгач, Мәдинә ханым «Идел», «Шәһри Казан», «Татарстан хәбәрләре»дәй трибуналарны да үз «орбитасына» алды. Терекөмештәй актив, тиктормас бу шәхес төрле өлкә, район күләмендәге урысча һәм татарча гәзитләрен дә читкә кагмый. Аның дистәләрчә мәкаләләрен, күзәтүләрен, хәбәрләрен Оренбурның «Комсомольское племя», «Булгар иле», Оренбур өлкәсе Саракташ шәһәренең «Путь Ленина», Күмертауның «Путь Ильича», Ульянның «Өмет», Ульян өлкәсе Иске Кулаткы районының «Күмәк көч», Самараның «Бердәмлек», Чиләбенең «Дуслык», Семипалатның «Иртыш» гәзитләрендә дә очратасың. Мәсьәләнең бер үзенчәлекле ягы да бар. Торгынлык еллары дип исемләнгән чорда кайбер татарча басмалар, милләтчелектә гаепләмәгәйләре, дип аерым иркен сулыш белән язылган мәкаләләрне кире борганда, урыс телле гәзитләр Мәдинә апаның вакыты өчен байтак четерекле материалларын да аз бастырмадылар. Бу җәһәттән тикшеренүче-краевед башка татар зыялылары эшли алмаган гамәлләре белән дә танылды дияргә ярый.

Мәдинә Рәхимкулова иярләгән актуаль темалар арасында татарларда мәгърифәтчелек, мәшһүр уку йортлары, милли театр, матбугат, дәреслекләр, мәдәният учаклары, мәчетләр тарихы, дин, әхлак, тәрбия һ. б. мәсьәләләр бар. Ул шулай ук төрле китапларга үзенчәлекле рецензияләр яза, юбилей уңае белән материаллар тезмәсе иҗат итә, үгетли, туры юлга өнди, кыскасы, журналистика жанрының түреннән урын яулый. Мондый фасылдагы иҗат җимешләреннән тынгысыз каләм иясенең кайбер мәкаләләрен санап үтү дә җитә: «Хатаны архив төзәтә», «Тәрбия дәреслекләре», «Милли моңнар», «Тукайга мәхәббәт белән», «Теле булмаса, халык та юк», «Һәлакәткә ун адым», «Татар Каргалысы», «Ислам бүген», «Сабантуй», «Синең исемең», «Татарча сөйлә», «Китаплар китабы», «Хәдисләр дөньясында» һ. б.

Мәдинә апа татарның атаклы мәгърифәтчеләре, галимнәре, сүз осталары, күренекле зыялылары турында бөтен бер образлар галереясе иҗат иткән кеше булarak та абруй казанды. Аның «казанышы» исемлегендә милләт каймагы дип аталырлык шәхесләрнең иң абруйлылары теркәлгән. Менә алар: Ризаэтдин бине Фәхретдин, Мифтахетдин Акмулла, Исмәгыйль Гаспралы, Дәрдемәнд, Фатыйх Кәрими, Габдулла Шонаси, Муса Биги, Габдулла Тукай, Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар, Сәгыйть Рәмиев, Сәгыйть Сүнчәләй, Галимҗан Ибраһимов, Гобәйдулла Рәдүди, Котлы-Мөхәммәд Тәфкилев, Шәмсетдин Зәки, Нургали Надиев, Борһан Шәрәф, Ильяс Кудашев-Ашказарский, Мирхәйдәр Фәйзи, Давыт Юлтый, Рәкыйб Рәкыйби, Салих Сәйдәшев, Афзал Таһиров, Якуб Хәлили, Сәлах Камал, Муса Җәлил һ. б. Мондый күренекле затлар турында язу үзе үк иҗади офыклар киңлегенә саллы дәлил.

Шулай да галимәбезнең төп кыйблаларыннан берсе — Ризаэтдин Фәхретдин иҗаты икәнен аерым әйтергә кирәктер. Бу өлкәдә Мәдинә апа биниһая зур, игелекле эш башкарды һәм башкарып килә. Аны, минемчә, бер дә икеләнмичә, «фәхретдинче»ләребезнең берсе дип атарга төпле нигезебез бар. Иң әүвәл бастырган хезмәтләре турында. Р. Фәхретдиннең Россия Фәннәр Академиясенең 200 еллык юбилеенда катнашуы (1925) хакындагы материал 1974 елда ук «Южный Урал» гәзитендә дөнья күрә. 1984 елда бөек галимнең бәрәкәтле эшчәнлеге турындагы язмалар «Совет мәктәбе», «Азат хатын» журналларында һәм шул ук «Южный Урал» гәзитендә басыла. 1988—89 елларда галим иҗатын пропагандалау яңа баскычка күтәрелә. Мәдинә ханым Риза казыйга багышланган махсус җыентыкта (Уфа, 1989) берьюлы ике материал бастыра. Беренчесе бер табак күләмле төпле фәнни мәкалә, икенчесе — тикшеренүчеләр өчен зур әһәмияткә ия булган Ризаэтдин Фәхретдин хезмәтләренең бай библиографиясе.

Әле ул гынамы соң! Мәдинә апа бик күп белгечләрнең теше үтмәгән, ифрат зур көч, күп вакыт сорый торган эшләрдән дә тайчынмыды. Бу хезмәтләре өчен генә дә аңа гыйльми дәрәҗә бирерлек. 1975 елда галимәбез Ризаэтдин Фәхретдингә багышланган 103 битле, эченә кыйммәтле унбер сурәт сыйдырган альбомны хәтерләткәнрәк хезмәт әзерли. Ул хәзергәчә кулъязма хәлендә. Аннары атаклы якташының «Әхмәд бай» дигән китабын кириллицага күчерә (1978), аны урысчага тәрҗемә итә (1985), һәр икесен төпләтә, соңрак Оренбурда ике мәртәбә урысча бастырып чыгара (1989, 1991). «Исмәгыйль сәяхәте» дә күчерелеп, төпләнә (1982). Шуннан соң Р. Фәхретдиннең тәрбия-нәсихәт мәсьәләләренә кагылышлы «Тәрбияле бала», «Тәрбияле ана», «Шәкертлек әдәбе», «Тәрбияле хатын», «Гаилә», «Нәсихәт-I», «Нәсихәт-II» кебек җәүһәрләр дистәләгән күмәк дәфтәргә хәзерге хәрефкә күчерелә. Ә менә Ризаэтдин Фәхретдиннең ифрат кыйммәтле «Җәвамигуль кәлим шәрхе» дигән хезмәтен кириллицага күчереп, Равил Үтәбай ярдәмендә басмага әзерләнүе үзенә бер каһарманлык. 605 бит күләмендәге бу китап 1984 елда тәмамланган һәм берничә ел элек Татарстан китап нәшриятына тапшырылган булса да, безнең белүебезчә, әлегәчә хәрәкәтсез ята. Ә кызганыч. Хәзер бу «китаплар китабы» М. Рәхимкулова тәрҗемәсендә шушы елның 3 нче саныннан «Аргамак» журналында урысча чыга башлады. Мәдинә апа, галим Җәүдәт Миңнуллин белән берлектә, Казанда чыгарырга тиешле бер китап өчен Р. Фәхретдин исеме телгә алынган һәм аның хакында язылган мәкаләләрнең зур бер исемлеген дә төзегән. Бөек мәгърифәтче-галимнең иҗатын, эшчәнлеген пропагандалау болар белән генә дә чикләнми әле. 1994 елның 23 гыйнварында Оренбурның Хөсәен Ямашев исемендәге китапханәсендә Р. Фәхретдиннең 135 еллыгына багышланган фәнни конференция үткәрелә. Шунда тирән эчтәлекле доклад белән Мәдинә ханым чыгыш ясый.

Конференция, махсус сәхифә мәсьәләсенә кабат әйләнеп кайтмас өчен бу урында шуны да әйтик. 1993 елның 28 ноябрендә югарыда исеме телгә алынган китапханәдә Дәрдемәнднең туган көненә һәм иҗатына багышланган зур кичә оештырыла. Мәдинә Рәхимкулова кичәнең түрендә утыра, Рәмиевләр гаиләсенә бәйле истәлекләре белән уртаклаша, хәтта аларның бергә җыелганда яратып җырлаган җырларын да көйләп күрсәтә. Һәм, әлбәттә, «Яңа вакыт»та (1993, № 36) Дәрдемәнд һәм аның нәсел-нәсәбе турында кыйммәтле рәсемнәр фонында махсус сәхифә бирә.

Һәвәскәр тарихчы-краеведның иң әһәмиятле иҗат җимешләреннән берсе — аның 1975 елда төзелгән 300 битле, 120 фотосурәтле альбомы. Ул «Оренбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсе» дип атала, мәгълүматларга искиткеч бай булуы белән аерылып тора. Татар мәгарифе тарихын өйрәнүче галимнәр өчен чын мәгънәсендә хәзинә бу. Мондый характердагы кыйммәтле һәм күләмле хезмәтләрдән шулай ук: «Оренбурның «музыка-драма» җәмгыяте һәм Шәрекь музыкасы мәктәбенең эшчәнлеге» (60 бит, 20 фотосурәт), «Оренбур драматурглары» (100 бит һәм һәртөрле күргәзмә материаллар), «Оренбур татар театры режиссерлары» (160 бит, күргәзмә язмалар), «Музыкаль Оренбур ягы. Тарихи күзәтү» (95 бит, фотодокументлар), «Рәмиевләр альбомы» (120 бит, фотосурәтләр) дигән яхшылап төпләнгән кулъязмаларны күрсәтергә мөмкин. Мәдинә апаның бер дә тик ятмый торган хәрәкәтчән архивында мәдәниятебезнең төрле тармакларына караган һәм ул үзе төзегән тагын башка төр альбомнар, бихисап төпләнмәләр, коллекцияләр, мәшһүр шәхесләр турында документаль язмалар, фотосурәтләр тулып ята. Аларның исемнәрен, тематикасын санап кына чыгу да байтак урын алыр иде. Гомумән, галимәбезнең фатиры гүя Әбүгалисина белән Әбелхарис гыйлем эстәгән мәгарәне хәтерләтә. Анда төрле-төрле китапларның, альбомнарның, төпләнмәләрнең, кулъязмаларның, фотоматериалларның һ. б. иге-чиге юк. Гарәп шрифтыннан хәзерге хәрефкә күчерү, проза һәм драма әсәрләрен, тарихи һәм дини характердагы хезмәтләрне тәрҗемә итү, төрле рәвештәге кулъязмаларны барлап, тасвирлап, пөхтәләп, тәртипкә салу да аның яраткан эше, җан азыгы. Тынгы белмәс ханымның мәшһүр тарихчыбыз Газиз Гобәйдуллинның 1924 елда дөнья күргән «Татар тарихы» китабын 250 дәфтәр бите күләмендә кириллицага күчерүе генә дә ни тора! Аннан башка да ул татар Оренбур драматургларының моңарчы беркайда да басылмаган, 1925 — 1968 елларда язылган (күбесе гарәп һәм латин графикасында) бик күп кулъязмаларны кириллицага күчергән, яисә машинкада бастырган, төпләгән икән. Монысы үзе театрыбыз тарихын барлау, җуелган сәхифәләрне торгызу буенча бәһасез хезмәт.

М. Рәхимкулованың эчтәлекле фәнни мәкаләләре турында да бер-ике сүз. Бу җәһәттән беренче чиратта галимәбезнең язучы һәм журналист Лирон Хәмидуллин белән берлектә язылган «Хөсәения» мәдрәсәсе» («Мәдрәсәләрдә китап киштәсе» дигән китапта. Казан, 1992, 40 бит күләмле), «Казан утлары» журналында

(1992, № 7) басылган «Университетлар үрнәгендә», Е. К. Карпова белән берлектә иҗат ителгән «XX йөз башы беренче уньеллыкларында Оренбур-Шәрыкъ халыклары музыкаль мәдәнияте үзәкләреннән берсе» («Актуальные проблемы музыкальной культуры народов Востока» дигән китапта. Ташкент, 1989), «Җәлилнең «Хөсәения чоры» («Казан утлары», 1975, № 2), Оренбур татар драма театры турында «Юл башында» мәкаләсе («Казан утлары», 1980, № 4) һ. б. телгә килә. Алар барысы да фактик материалга бай булулары белән игътибарны җәлеп итә.

Гомумән, галимә — фәнни, фәнни-популяр мәкаләләр, хәбәрләр, парчалар, нәсихәтләр, кыскасы, журналистиканың төрле жанрлары, төрләренә караган 200 дән артык язма авторы. Ул гына җитмәсә, хәзер кызу темплар белән әзерләнә торган «Татар энциклопедиясе» дә байтак мәкаләләр язып биргән. Соңгы елларда аның публицистик, журналистлык эшчәнлеге бигрәк тә Оренбур каласында 1991 елда кабат торгызылган «Яңа вакыт» газите белән бәйле. Хәзер абруе киң татар дөньясына таралып килә торган ошбу басманы М. Рәхимкулова язмаларыннан башка күз алдына китерүе дә кыен. Мин шәхсән Мәдинә ханымның бу газит битләрендә басылган 40 тан артык материалы белән таныш.

Даими эзләнүчән, иҗат дәрьясына чумган бу киң колачлы тикшеренүче бер ук вакытта публицист та, тарихчы да, фольклорчы да, вәгазьче дә, дин белгече дә, археограф та, әкият сөйләүче дә... Әкият дигәннән, аның «Миндрай», «Өч аккош» кебек үзе иҗат иткән тылсымлы хикәятләре аеруча сокландыра. Әле җитмәсә, шагыйрә дә икән үзе. Кимендә дүрт дистә поэтик әсәр авторы. Урысча яңгыраш алганнары да бар. Моңа үзенчәлекле, тормышчан фәлсәфә белән өретелгән шигъри юллар да дәлил. Мәсәлән:

Тәнең көчле — көрәшләрдә җиңдермәсәң,
Җаның көчле — әрнүләрен сиздермәсәң,
Бәхетле син — зур байлыклар йөрми эзләп,
Итсәң илгә кадәри хәл тугры хезмәт.

Яки мондый мисал:

Тормыш бавын үргән булсаң ике җептән,
Сүтә алмас аны синә дошман кеше —
Әгәр булса бер җеп — картның тәҗрибәсе,
Икенче җеп булу кирәк яшьнең көче.

Шагыйрә яшәешебезне агулап, киләчәгебезне корыта торган, хәятыбызга көннән-көн ныграк килеп сара барган афәткә, ягъни эчүчелеккә, сәрхушлеккә карата да үзенең сүзен кистереп әйтә, бу яшел еланның зәһәр угыннан сакланырга өнди, «галиҗәнап» хәмернең үз авызыннан мондый котсыз сүзләр әйттерә:

Чәчәм илгә әлегәчә фән белмәгән чирләрне,
Илле яшькә дә җиткермим бура кебек ирләрне...
*(«Яңа хөкемдар»).*

Шул ук темага «эссе салып», әхлакый ягына басым ясап һәм рәсүлебезгә тугрылык, мәхәббәт хисе тәрбияләп, ул күңел кылының иң нечкәсен дә чиртеп куя:

Үз мәзһәбен исерткечтән тыйган,
Хөкеме булган каты-мөкәммәл,
Аек халык — илнең таянычы,
Улым булса, кушам Мөхәммәд.
*(«Улым булса»).*

Әлбәттә, Мәдинә Рәхимкулова яшен ташыдай актив җәмәгать эшлеклесе дә. Үзенең замандашлары, фикердәшләре Тәлгать Абдрашитов, Үлмәс Биляева, Зиннур Шакиров, Тәүфыйк Сабитов, Фатыйх Кыргызбаев, Якуб Сабитов, Якуб Шабакаев, Гөлсем Хәсәнова, Майя Сөләйманова, Рамзес Абдрашитов кебекләр белән бергә, ул милләт язмышына кагылышлы булган һәр адымның, күренешнең, вакыйганың үзәгендә кайнады яки кайный. Кайнап кына да калмый, урта буынны, яшь-җилкенчәкне газиз халкына тугрылык белән хезмәт итәргә, аның бай тарихын, мәдәниятен, казанышларын өйрәнергә, пропагандаларга чакыра, милләтнең өметле киләчәге өчен нәтиҗәле көрәшкә рухландыра. Халкы язмышы өчен янып йөргән, аның тарихына, мәдәниятенә мөкиббән киткәннәргә тере әлге ул Мәдинә апа. Менә берничә шундый мисал. Алны-ялны белмәс ветеран 1990

елдан бирле шул ук елны ачылган 3 нче номерлы Оренбур педагогия училищесының татар һәм башкорт группаларында гарәп графикасын һәм гарәп теленең башлангыч курсын укыта. Һәм укытып кына да калмый. Үзе меценат, үзе учредитель буларак, ул бу училищеның татар-башкорт группаларындагы иң алдынгы студентлар өчен Ризаэтдин Фәхретдин, Дәрдемәнд, Фатих Кәрими, Мөхәммәтша Бурангулов исемнәрендә дүрт бүләк (премия) булдыра. Бүләкнең шартлары мондый икән: ул уку елы азагында иң яхшы өлгереш күрсәткән, тәртибе камил булган, җәмәгать эшендә даими катнашып килгән укучыларга бирелә. Бүләкләнгәннәрнең исеме училищеның махсус альбомына кертелә,җиңүчеләр елына кимендә бер тапкыр, алынган премиянең исеменә карап, ул шәхеснең тормышы һәм эшчәнлеге турында радио, телевидение буенча яки матбугатта чыгыш ясарга тиеш. Премиягә лаек булучыларның саны өч яки аннан күбрәк, меценатлары исә төрле булулары мөмкин. Күрсәткечләр тигез булган очракта өстенлек туган телдә югарырак баллга ия булган һәм премияне беренче мәртәбә алучыга бирелә. Башлангыч чорында 200 сум дип тәгаенләнгән бу премияләр, инфляциягә нисбәтле рәвештә, ел саен үсә бара. Әйтик, М. Рәхимкулова 1992/93 уку елының кышкы һәм язгы семестрларын уңышлы тәмамлаган студентлар — Әлфия Хәйруллинага (Дәрдемәнд исемендәге бүләк), Лира Мусаловага (Фатих Кәрими), Рәмзия Улумбековага (Риза Фәхретдин), Эльмира Агиевага (Мөхәммәтша Бургангулов) 2000 шәр сумлык, ә нимес курсыннан фәкать «бишле»гә генә укыган Тирбах Викториягә 3000 сум күләмендәге премияләр тапшырды. Ул вакыттагы акча курсын исәпкә алганда, кечкенә сумма түгел иде бу.

Мәдинә апа — Хөсәен Ямашев исемендәге көтепханәнең нигез ташларын салучылардан, аның эшендә иң актив катнашучылардан, биредә үткәрелгән конференцияләрдә, кичәләрдә, очрашуларда, әңгәмәләрдә әйдәп баручылардан берсе. Ул милли-мәдәни, тарихи, иҗтимагый мәсьәләләр буенча күп мәртәбәләр җирле радио, телевидениедән чыгышлар ясаган һәм ясап торучы кеше. Фатиры исә милләт проблемаларына җан аткан зыялылар өчен очрашу-гәпләшү урыны гына түгел, мәгълүм дәрәҗәдә штаб вазифасын да үти дияргә ярый. Яше инде олы булуга, сәламәтлегенең шактый какшавына карамастан, ул бик күп фикердәшләре белән очраша, аралаша, хат алыша, бай тормыш тәҗрибәсе һәм гыйбрәтле язмалары белән юмарт уртаклаша, газиз халкына тугрылыклы хезмәт итүчеләргә аналарча фатихасын биреп, игелекле гамәлләргә рух өрә.

Кимендә ун гасырлык төкәнмәс тарихы, мәдәнияте булган милләтебезнең йөзек кашына торырлык шушындый вәкилләре белән без горурланырга хаклыбыз. Ә аның гаҗәеп бәрәкәтле эшчәнлеген, иңли алмастай фигълиятен, мокатдәс омтылышларын барыбызга да затлы өлге итәсе иде. Мәдинә апа моңа бик лаек кеше. Озын гомер, корычтай сәламәтлек, яңа иҗади уңышлар Сезгә, фидакяр замандашыбыз!

**Равил ӘМИРХАН**

**Андреас Каппелер**

# ИДЕЛ БУЕ ТӨРКИЛӘРЕНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ

Халыкларның килеп чыгышы һәм беренче ватаннары мәсьәләсе Көнбатыш Европада аеруча XIX гасыр башыннан бәхәс кузгата. Үтә милләтчеләр һәм фашистлар тарафыннан дәрәҗәсе төшерелгән бу мәсьәләләрне Көнбатыш тикшеренүчеләре хәзерге вакытта хәтта искә дә алмыйлар; «этногенез» атамасын этнология дәреслекләрендә дә очратмыйсың. Элекке Советлар Берлегендә һәм социалистик илләрнең күбесендә этногенез проблемасы, киресенчә, этнографиянең генә түгел, бәлки пархеологиянең, лингвистиканың һәм антропологиянең дә күз уңында тора.

«Большая советская энциклопедия»дә «этногенез» атамасы «халыкның килеп чыгышы» дип аңлатыла һәм махсус рәвештә «төрле җәмгыятьләрнең, димәк, төрле этник төркемнәрнең үзара төрлечә йогынтысының, кушылуының һәм кучешенең эчке барышы гомуми законнарын чагылдыручы эзлекле тарихи процесс» дип шәрехләнә. Шулай итеп, «этнонегез» атамасы, беренче ватан төшенчәсенә каршы буларак, хәрәкәтчән үсешне чагылдыра һәм этник төркемнәрнең башы да, ахыры да күренмәгән әверелешләренә басым ясый.

Совет галимнәре марксистик фикерләү калыбына таянып, мәгълүм социаль-икътисадый үсеш дәверенә теге яки бу этник оешу баскычы туры килә, дип саный. Ягъни тарихкача җәмгыятьтә — кабилә һәм ыруглар, феодализмда — халык, капитализмда — буржуаз милләт, социализмда социалистик милләт формалаша. Этногенетик тикшеренү, барыннан да элек, халыкның барлыкка килү мәсьәләсенә, аның аерым өлешләрен өйрәнүгә юнәлдерелә. Бу өлешләр исә тәгаен бер заманда кайсы да булса этник җәмгыять составына керә һәм аларны хәзерге милләтнең элгәрләре итеп карарга мөмкин.

Этногенетик тикшеренүләрнең беренче баскычы егерменче елларда билгеле бер милләтчелек юнәлеш-омтылышлары белән аерылып тора. Нәкъ шул чорда Кавказ, Урта Азия һәм Урта Идел буе халыклары үзләренең килеп чыгышы мәсьәләсен күтәрәләр. Әмма этногенезны өйрәнү өлкәсендә системалы тикшеренүгә кырыгынчы еллар башында гына керешелә. Бу яңа фәнгә «буталчык этногенетик риваятьләр», «җирле буржуаз милләтчеләр»нең «ялган фәнни конструкцияләр»е һәм, шул ук вакытта, милли социализм калыплары белән көрәшү бурычын куялар. Сугыштан соң совет халыкларының килеп чыгышы буенча күп хезмәтләр басыла. Аларның барысы да совет археологиясендә, тел белемендә һәм этнографиядә соңгы егерме елда өстенлек иткән марризмның көчле йогынтысы белән билгеләнгән. Сталинның 1950 елда басылган тел белеме буенча мәкаләләре СССРда этногенез фикер агышында яңа дәвер ачты. Марризмнан

---

Андреас КАППЕЛЕР (1943) — *Алманиянең Кельн шәһәре университеты профессоры (1982), Көнчыгыш Европа тарихын өйрәнүгә багышланган күп кенә хезмәтләр авторы.*

Мәкаләнең гыйльми мөхәррире — Дамир Исхаков. Французчадан урысчага А. Арысланова, урысчадан татарчага М. Хуҗин тәрҗемәсе.

азат ителгән өлкәләрдә, нәкъ менә тел белемендә, күтәрелеш башланды, археологик, этнографик һәм антропологик экспедицияләр оештыру ешайды. Тик бу өлкәдәге тырышлыклар фәннәрара теориянең яңа базасында килештерелмәде. Илленче еллар ахырында этногенетик тикшеренүләр билгеле бер дәрәҗәдә сүлпәнләнде. Дискуссия әлегә дәвам итә, ләкин ул инде элекке Советлар Берлегеннән читтә бара. Бүгенгечә этногенез теориясе буенча да, СССРның күпчелек халыкларының килеп чыгышы буенча да уртак фикергә киленмәде. Төрле фәннәр арасында, милли һәм региональ мәктәпләр арасында яки совет фәнендә иң яшәүчән өлкәләрнең берсе — этногенетик тикшеренүләр буенча төрле карашларда торучылар арасында бәхәсләр җанлангалап китә...

## Урта Идел буе халыклары

Этник картага карагач, элекке Советлар Берлегенең Европа өлешендә шактый ук бертөрлелек күрәбез. Ләкин үзәгендә урыслар урнашкан киң җирләрдә — Урта Идел буенда һәм Себердә төрле төрки һәм фин-угыр халыклары яшәве дә бу картадан ачык аңлашыла. Шушы төбәкләрнең үзара этник йогынтылары һәм вакыйгалар тулы тарихы этногенетик тикшеренүләр өчен нигез булып тора. Мондый тикшеренүләр исә бик тә кызыклы, әмма шул ук вакытта гаять катлаулы.

Идел дәрьясы элек-электән үк регионны Европага һәм Азиягә, урманнарга һәм далаларга бүлеп тора. Бу төбәктә төрле телдә сөйләшүче, төрле мәдәниятле, төрле раса һәм цивилизация кешеләре очрашкан һәм очраша килә. Безнең эраның беренче меңьеллыгы ахырында монда — Идел буенда Болгар дәүләте оеша. Шактый үскән бу цивилизация унөченче гасырда Алтын Урда хакимлегендә кала. Аннан соң унбишенче гасырда оешкан Казан ханлыгы, Мәскәү тарафыннан уналтынчы гасырда яулап алынып, Русь дәүләтенең бер өлешенә әверелә.

## Төрки халыкларның килеп чыгышы

Төрки халыклар зур гаиләсенең төньяк-көнбатыш өлешен Казан татарлары һәм чувашлар тәшкил итә. Урыслар, бу халыкларның кемлеген белгәч, аларның килеп чыгышы турындагы мәсьәләне унсигезенче гасырда үзләре кузгата. Хәзерге вакытта Казан татарларының һәм чувашларның килеп чыгышы турында күпсанлы бәхәсләр алып барыла.

Бер хәлне искәртү зарур: рәсми совет статистикасында Казан татарлары хакында аерым һәм анык әйтелми. 1959 һәм 1970 елларда халык санын алу нәтиҗәләре буенча гомум татар милләте — Кырым татарлары, нугайлар, Әстерхан, Себер, Казан татарлары бергә исәпкә алына. 1917 елга чаклы исә урыслар «татар» атамасын Русия империясенең тагын да күбрәк санлы төрки-мөселман халыкларына (мәсәлән, әзәрбайҗаннарга) мөнәсәбәттә дә кулланганнар. Хәзер Казан татарлары үзләренең бердәйлегенә ирешкән, күрәсең. Совет фәне татарларны төрле төркемнәргә аерса да, рәсми власть, этнографик бүлгәләүләрне исәпкә алмастан, патша заманы традицияләрен бүген дә дәвам итә. Халык санын алу мәгълүматларында татарларның төрле төркемнәре бер исем астына кертелүе шуңа мисал.

Революциягә чаклы урыс галимнәре, Русия империясенең билгеле бер сандагы төрки-мөселманнарына һәм унөченче гасырның монгол басып алучыларына карата Алтын Урдада хакимлек иткән сыйныфларны белдерүче «татарлар» этнонимын кулланып, Казан татарларын Алтын Урда монгол-татарлары белән үзеннән-үзе бердәйләштерә. 1909 елда татар тикшеренүчесе Г. Н. Әхмәров Казан татарларының Идел болгарлары белән туганлыгы фикерен әлеге теориягә каршы куя. Капма-каршы шушы ике теория соңрак кубачак бәхәсләрнең ике котыбы барлыкка килүен билгели.

XX йөз башында үсеп баручы татар милли хәрәкәте бу мәсьәләләр белән җитди кызыксына. Кайбер татар милләтчеләре, Алтын Урданы күкләргә чөеп мактап, аның мисалында бердәм татар дәүләтен күрәләр һәм «Чыңгыз ханның данлы заманнарына кире кайтырга» чакыралар яки, пантөркизм билгесе астында, татарларның беренче ватанын Алтайдан эзлиләр. Татар галиме Г. С. Гобәйдуллин әлеге карашларны 1928 елда тәнкыйтьләсә дә, ә 1941 елда татар тарихчысы Х. Г. Гыймади, Г. Н. Әхмәров кебек үк, бу халыкның килеп чыгышында болгар

элементы булуын расласа да, Казан татарларын монгол-татарлар белән бер дип тану теориясе юкка чыгып бетми.

1944 елда ВКП(б) Үзәк Комитеты татар тарихчыларының Алтын Урданы идеаллаштыруын гаепләргә мәҗбүр була һәм аларга Татарстан республикасының фәнни тарихын язуны йөкли. Галимнәр этногенез мәсьәләсенең чишелмичә калуын шул чакта тагын бер кат төшенәләр. 1946 елның апрелендә Фәннәр академиясе Казан татарларының килеп чыгышы турында Мәскәүдә конференция оештыра. Анда катнашучылар Казан татарларын татар-монголлар белән бердәйләштерүне тулаем дөрес түгел дип саныйлар һәм, марризм йогынтысы нигезендә, Казан татарларының килеп чыгышында автохтонлык-җирлелек элементлары булуы фикерендә нык торалар. Бу очракта хәлиткеч этник компонентны тәшкил итүче Идел болгарлары истә тотыла. Моннан соңгы фикер алышуларда конференциянең «татар милләтчелеген туздыруына» басым ясала һәм бу, әлбәттә, дөрес күзәтү була.

Әлеге конференциядә археолог буларак катнашкан А. П. Смирнов фикеренчә, Казан татарларының бик тә катлаулы этногенезы фин-угыр, сармат, кыпчак һәм Идел болгарлары кабиләләре йогынтысына дучар була. Ул монгол басып алуларының әһәмиятен тулысынча кире кага һәм болгар мәдәниятенең Казан татарлары аша бүгенге көнгә килеп житүе юнәлешен тагын алга чыгарудан бүтән фикер әйтми. Т. А. Трофимова Казан татарларын антропологик яктан дүрт төргә бүлә. Понтия-Европа төре иң киң таралган булып санала, алар Казан татарларының өчтән бер өлешен тәшкил итә. Бу төр мордва-мукшылар арасында да шул ук дәрәҗәдә очрый. Ул Иранның күчмә халкы һәм шулай ук Идел болгарлары арасында җәелгән була. Мордва-эрзяга туры килә торган европача якты-ак йөзле төрнең, шулай ук удмуртларда һәм мариларда очрый торган сублапаноид төрнең һәркайсы Казан татарларының дүрттән бер өлешен тәшкил итә. Т. А. Трофимова Казан татарларының сигездән бер өлеше генә монгол тибына керүен әйтә, моны Көньяк Себер йогынтысы дип аңлата. Шуннан чыгып ул, Казан татарлары чынлыкта европеоид раса һәм алар монголлар нәселеннән була алмый, дигән ахыргы нәтиҗәсен ясый. Этнограф Н. И. Воробьев, докладында Казан татарлары мәдәниятендә урман һәм дала элементларын тикшереп, автохтон булмаган факторларны чикләргә тырыша. Л. Җәләй, киресенчә, лингвистик яктан тикшереп, татар телендә кыпчак элементларының өстенлеге күзгә бәрелеп торуын әйтә. Бу хәл, аныңча, болгар теориясенең дәвамы булып тора. Дискуссиядә С. Е. Малов бу фикергә каршы чыга, ул чуваш телен Идел-болгар теленең варисы итеп күрә. Башка яктан караганда, Ә. Булатов фикеренчә, чуваш теле төрки булмаган борынгы билгесез телдән килә һәм бары тик Казан татарлары теленең генә турыдан-туры болгарлардан чыга алуын мөмкин саный.

Унсигезенче гасырдан башлап, чувашларның килеп чыгышы турында очраклы теорияләр мәйданга чыгарыла. Әйе, чуваш теле төрки телле халыклар гаиләсендә аерым урын алып тора. Унтугызынчы йөз уртасына чаклы өстенлек иткән фин-угыр теориясе белән беррәттән, чувашларның славяннардан, хазарлардан һәм бортаслардан чыгуы фаразлары кабул ителә. Шул гасыр уртасына бу халыкның Идел болгарлары дәвамы булуы фикере күбрәк тарала, ул исә Идел буендагы кабер ташларындагы язуларны танып укуга нигезләнә. 1902 елда лингвист Н. И. Ашмарин, бу язуларны һәм шулай ук телнең башка чыганакларын җентекле тикшереп, ахыр чиктә Идел болгарлары теленең чувашлар теле белән бердәйлеге турындагы теорияне көчәйтә. Егерменче елларда барлыкка килгән чуваш милләтчелеге хәрәкәте бу фаразны яклый. Мондый яклауны чуваш милләтчеләре, аны тәнкыйтьләүчеләр фикеренчә, «милли чуваш-болгар дәүләтенең алтын гасыры»н идеаллаштырып, Чуваш республикасын «Болгар республикасы» итеп үзгәртү өчен саллы дәлил сыйфатында файдаланмакчы була. 1930 елда тарихчы И. Д. Кузнецов чувашларның килеп чыгышы турындагы әлеге артык гадиләштерелгән милләтчелек теориясенә каршы чыга һәм Идел болгарларының варислыгы мәсьәләсендә чуваш һәм татар тикшеренүчеләре бәхәсләренең нәтиҗәсезлеген билгели.

Чуваш тарихчысы М. Петров 1925 елда Чабаксарда урта кул милләтчелек рухында ясаган хисабында чуваш телен беренчел алтай теле белән якынайта. Шул елда Н. Я. Марр конференция җыя һәм, бик тә очраклы фараз итүләргә нигезләнеп, чувашлар тарихкача халыкларның — Көнчыгыш Европа яфетидларының исән калган нәселләренең соңгылары, дип белдерә, галимнәрне бу мәсьәләләрне тирәнтен өйрәнергә чакыра. Шулай да чувашларның этногенезы буенча тикшеренүләр, башка совет халыкларының килеп чыгышларын өйрәнүләр кебек үк, элеккечә жансыз хәлендә — маррчылык вакытындагыча кала.

Маррчылык чоры ахырына житкәч, 1950 елның гыйнварында, ягъни Казан татарларының килеп чыгышы турындагы конференциядән соң дүрт ел үткәч, Фәннәр академиясе чувашлар этногенезы буенча конгресс оештыра. Дөрес, аның «Советская этнография» журналында шул чакта ук басылган материалларына Сталинның тел белеме буенча хезмәтләре искә алына, ләкин нәтиҗәләрдә маррчылык концепцияләре тагын чагылыш таба. Чувашларның болгарлардан чыгуы турындагы «чуваш милләтчеләре һәм пантөркистлар» тарафыннан якланган артык гадиләштерелгән тезис каты тәнкыйтьләнә. Киресенчә, жирле фин кабиләләре роле уңай бәяләнә. Моңардан тыш, галимнәр 1946 елгы конференциянең кайбер карашларын, бигрәк тә кайбер татар тикшеренүчеләренең болгар варислыгын татарлар файдасына дәгъва итүен кире кагалар. Бу варислык исә, Третьяков фикеренчә, Киев Русе мәдәнияте урыслар, украиннар һәм белоруслар өчен нигез булган кебек, чувашларга да, татарларга да карый. Третьяковча, татарларга кыпчаклар йогынтысы зуррак, һәм шушы йогынты татарларны чувашлардан анык аерып тора. Икенче яктан, ул чувашларның бүленешенә басым ясый, ягъни һәр төркемнең үз чыгышы бар: «югары яктагы» чувашлар нигездә автохтон, «түбәнге яктагы» чувашлар исә далалар белән чиктәш көньякта формалашкан һәм беренче мең еллыкның уртасына чаклы төркиләшкәннәр.

Тән төзелеше күзлегеннән карап, Т. А. Трофимова игътибарны чувашларны искә алучы монголоведлар хезмәтенә юнәлдерә. Ул чувашларны, гәрчә алар фин-угыр аборигеннары арасында шул ук саннарда очраса да, Көньяк Урал тибы буенча беренче урынга куя. Үзәк Азиянең татарларда булмаган монгол элементларына килгәндә исә, болар сөн-болгар йогынтысы белән аңлатыла. Н. И. Воробьев, мәсьәләне үзенчә бәяләп, чувашлар мәдәниятенә тау мариларының автохтон элементлары көчле тәэсир итүенә басым ясый — болары алдында дала болгарлары да куркып торган икән. Ул бу фикерне 1856 елда басылган «Чувашларның гомуми этнографиясе» китабының беренче томында да кабатлый. В. Т. Егоровча, чуваш телен өйрәнү анда болгар элементлары күпчелек тәшкил итүенең бәхәссез икәнлеген күрсәтә. Ләкин Идел буенда элгәреге төрки кабиләләр булуы бу төбәктәге халыкны болгар күчмәннәре тарафыннан төркиләштерүне җиңеләйтергә тиеш иде.

Идел буеның борынгы тарихы буенча күренекле белгеч, археолог А. П. Смирновның Идел буе төркиләренең килеп чыгышы турындагы хезмәтләре игътибарга лаеклы. Аның Идел болгарлары турында 1948—1957 елларда язылган хезмәтләре совет тарих белеменең тулаем үсеш-үзгәреш кичерүен дә чагылдыра. Идел төркиләре этногенезында А. П. Смирнов жирле гонсерләрне 1949 елда аерып күрсәтсә дә, 1957 елда инде ул кырыгынчы еллар теориясен өлешчә яңадан карауны таләп итә һәм бу мәсьәләдә Алтын Урдага зуррак урын бирелергә тиешлеген билгели.

А. П. Смирнов хезмәтләре 1947 һәм 1950 еллардагы конференцияләр нәтиҗәләрен кабат карауны яңартуда бердәнбер түгел. Бу нәтиҗәләрне тәнкыйтьләү, марризмны хөкем итеп, Сталин тарафыннан якланды. М. Г. Сәфәргалиев 1951 елда «Вопросы истории» журналында басылган мәкаләсендә болгар варислыгына мөнәсәбәттә татар һәм чуваш тарихчыларын капма-каршы куйган бәхәсне мыскыл итеп бәяли. Ул бу ике этнос арасындагы тел аерымлыкларын күрсәтә, Казан татарларының болгарлардан килеп чыгуы теориясенә каршы килеп аларга кыпчакларның һәм Алтын Урданың йогынтысы әһәмиятенә басым ясый. Х. Г. Гыймади шул ук журналда, тарихи һәм тел ягыннан дәлилләрне яклап, Казан татарларының болгарлардан чыгуы тезисын алга куя.

Чуваш фәнни-тикшеренү институты, 1950 елгы конгресска җавап буларак, чувашларның килеп чыгышы буенча 1956 елның маенда яңа конференция оештыра. Анда төп урын күбрәк фин-угырларга түгел, ә болгарларга, аеруча көньяк төркемгә — суварларга һәм сувазларга бирелә.

Б. А. Серебренников моның чуваш теле хәленең үзенчәлегенә, бу халык мәнфәгатьләренә бәйле рәвештә кирәк булуын урынлы билгеләп үтә. Ул шулай ук чуваш телен Идел болгарлары сөйләшкән тел белән бердәй карый, татарларны чынлыкта кыпчаклардан килеп чыккан, дип саный. Борынгы чуваш тарихы буенча күренекле белгеч В. Д. Дмитриевнең фикеренчә, чувашлар X—XV гасырларда беренче фин-угыр кешеләренең һәм игенчелек белән шөгыльләнүче мәҗүси болгар-сувазларның охшашлану җимеше.

Идел буендагы бу халыкның этногенезы буенча В. Ф. Каховскийның «Чуваш халкының килеп чыгышы» исемле хезмәте бүгенгәчә тулы мәгълүматлы бердәнбер монография булып тора. Ул чувашлар этногенезында болгарларга төп рольне бирүче чуваш мәктәбе традицияләрендә язылган һәм биш йөз битле бу

хезмәт 1965 елда басылып чыга. Автор беренче тапкыр үзенең тикшеренүен Урта Идел буендагы бу халыкның килеп чыгышы белән генә чикләми, бәлки аның этник тарихының элекке дәверләрен башка төбәкләр тарихы белән тигез рәвештә бәйли. Хезмәттә күрсәтелгәнчә, беренче чор Байкал күле буенда уза. Монда безнең эрага чаклы беренче мең ел дәвамында чувашларның тәүге бабалары төрки-монгол берлекләреннән аерылганнар, безнең эраның беренче гасырларында Көнчыгыш Европа далаларында сувар-савир һәм болгар исемнәре белән таралганнар. Икенче чорда, икенче гасырдан башлап җиденче гасырга чаклы, төрки телле кабиләләр, элгәреге сөннәр белән тыгыз бәйләнештә торалар; соң, болгар һәм хазар империяләрендә алар, Идел-Кама буена килеп урнашачак болгарлар җиденче гасырның җитмешенче елларында Азов буен, ә суварлар сигезенче гасырның утызынчы елларында Каспий диңгезе тирәсен ташлап киткәнче, күп төрле мәдәниятләр йогынтысына дучар булалар. Өченче чорда, тугызынчы гасырдан башлап унөченче гасырга чаклы, «чуваш» дигән халыкның этник билгеләмәләре Идел Болгары дәүләте эчендә үсә. Тугызынчы-унынчы гасырларда болгарлар урманлы киңлекләргә урнаша һәм марилар белән бортасларны төркиләштерә, алардан «югарыгы» чувашлар килеп чыга. Сувар-сувазлар, монголлар изүенә чыдый алмыйча, унөченче гасырда Иделнең сул ярын ташлап китәләр һәм, елганың уң ярында тупланеп, чувашларның «түбәнге» төркемен барлыкка китерәләр. Нәкъ менә XIV—XVI гасырларда «чуваш» дигән халык шушы ике төркемнән оеша.

Кайчакта В. Ф Каховскийның фаразлары зәгыйфь тоелса да, алар күпсанлы археологик, тарихи, лингвистик һәм этнографик чыганакларга нигезләнгән. Библиографиядә күрсәтелгән биш йөз исем СССРда этногенетик фәннең байлыгын чагылдыра. 1970 елда чыккан «Чуваш этнографиясе»нең икенче томында В. Ф. Каховскийга халыкның килеп чыгышы автохтон булуы турындагы тезисны үзгәртергә туры килә. Бу тезис исә беренче томда Н. И. Воробьев тарафыннан әйтелә. Димәк, В. Ф. Каховский үзгәртүе чуваш галимнәре тарафыннан кабул ителгән, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин.

Татар тикшеренүчеләре, киресенчә, соңгы унбиш елда Идел буе төрки халыкларының килеп чыгышы турында башка теорияләр дә тәкъдим итәләр. Академиянең Казан филиалы институты күптән түгел уздырган казу эшләре нәтиҗәләренә таянып, алар Болгар чорында Идел буенда төркиләштерүнең читтән булуы фаразын алга куялар. Мондый фараз исә Н. Ф. Калинин, П. Н. Третьяков, В. Г. Егоров, В. Ф. Генинг кебек танылган галимнәр тарафыннан тәгъбирләнә.

Күренекле татар археологы А. Халиков төркиләрнең Идел буена беренче тапкыр безнең эраның икенче гасырында килгән булуларын фараз итә, бу хәлнең сөннәр һөҗүмен тизләтүен искәртә. Кайбер галимнәр, сөннәрнең һәм төркиләрнең, бигрәк тә чувашларның формалашуына тәэсир иткән йогынты Имәнкискә мәдәниятендә чагыла, дип саныйлар. Һәм әлеге мәсьәлә аеруча П. Н. Старостин тарафыннан өйрәнелә. Өченче баскычта — VI һәм VII гасырларда көнбатыш төрки каганлыгының яңа буын кешеләре Идел буена бәреп керәләр. А. Халиков фикеренчә, аларның мәдәнияте татарлар өчен, аннары Идел болгарлары өчен тигез дәрәҗәдә нигез була. Шулай итеп, Идел буендагы төрки телле ике халыкның килеп чыгышы болгаргача ике этник гомумилеккә-уртаклыкка кайтып кала. Шул ук җыентыкта Р. Фәхретдинев, А. П. Смирнов, В. Ф. Каховский тезисы һәм 1956 елгы конференциядә әйтелгән тезисны бәхәсле дип саный. Әлеге тезисын, Чуваш АССРның хәзерге бөтен җирендә болгарлар яшәгән, дигән фикергә нигезләнгән Р. Фәхретдинев болгар мәдәнияте эзләре чувашлар белән чиктәге зоналардан бүтән бер төштә дә табылмавын әйтә. Ул шулай ук суварлар белән чувашларны гади этнонимик бутауга каршы төшә. Бу җыентыкка кергән башка мәкаләләрдә болгар варислыгының Казан татарлары файдасына булуын тулысынча тану таләп ителә.

Шактый ук бәхәсле бу җыентык, гәрчә аның нәтиҗәсе рәсми кабул ителгән булса да, А. П. Смирновның чувашча басылган бик тә тулы хезмәтендә кискен тәнкыйтьләнә. Ул А. Халиковның мәдәниятнең этник кемнеке булуын тирәнтен өйрәнмичә генә ясаган «арбитраж нәтиҗәләр»ен кире кага. А. Смирнов төрки телле кабиләләрнең түгел, ә фин-угыр кабиләләренең һәм сарматларның ролен басым ясый. Ул аеруча Р. Фәхретдиневне «чуваш һәм татар тарихчыларының болгар варислыгына мөнәсәбәттә элекке бәхәсне кире кагуы өчен» шелтәли. А. Халиков һәм аның өч хезмәткәре мондый гаеп ташлауга җавап яздылар һәм «Советская археология» журналының 1974 елгы беренче санында бу мәсьәләләр буенча дискуссия оештыру фикерен әйттеләр. Журналның чираттагы санында А. Смирнов үз фикерен соңгы тапкыр яклап чыкты — шуннан соң озак та үтмичә

ул вафат булды. Галим Болгар чорына чаклы Урта Идел буена төрки элементлар кермәвенә үзенең ышануын кабатлый һәм төрки халыклар этногенезында фин-угыр элементлары булуын исәпкә алмаска ярамавын әйтә.

«Казан мәктәбе» теориясе уңаеннан дискуссиядән тыш (ул әле хәзер дә тәмамланмаган), соңгы елларда басылган мәкаләләрдә һәм монографияләрдә Идел төркиләренең килеп чыгышы турында башка фикерләр дә бар. Анропόлог Карин Марк Казан татарларын һәм чувашларны чагыштырып өйрәнгән һәм Т. А. Трофимованың монгол элементы роленә кагылышлы нәтиҗәләрен аеруча яклый. Казан татарларының зур күпчелеге, мордва-мукшылар һәм удмуртлар кебек, европеоидлар булып тора, ә чувашлар, марилар кебек, монголоид тибына күбрәк карый. Ләкин бүгенге көнгә чаклы бу нәтиҗәләрнең мәгънәсен ачып бирүче канәгатьләнерлек бер генә фикер дә әйтелгәне юк. Татар тарихчысы Ш. Мөхәммәдьяров 1968 елда Токиода этнология конгрессында Казан татарлары этногенезы турында чыгыш ясады. Ул Казан татарларының болгарлардан чыгуы фикерен кире кага, монда кыпчакларның хәлиткеч роль уйнавын күрсәтә — шушы ук фикерне М. Ф. Сәфәргалиев тә раслаган иде. А. Смирновның Болгар шәһәрендә монголоид типлы баш сөякләре һәм йорт төрләре табылуына ишарәсе Урта Иделгә монголларның килгән булуларына ышанырга, Казан татарлары этногенезы турында Икенче Бөтендөнья сугышына чаклы һәм сугыш вакытында өстенлекле саналган концепцияне яңадан карарга мөмкинлек бирә.

* * *

Идел буе татарларының иң зур төркемен Казан татарлары белән берлектә тәшкил итүче мишәрләрнең килеп чыгышы шактый сандагы хезмәтләрдә тикшерелә. Элек урыс галимнәре, мишәрләр фин-угыр кабиләләреннән чыгып татарлашканнар, дип санаган чакта күренекле «мишәрче» Г. Әхмәров 1903 елда, алар азияле, төрки чыгышлы, дигән теорияне күтәрә. 1959 елда Т. И. Алексеева һәм Б. А. Васильев «мишәр» исеменең топоним булуын һәм мишәрләрнең төркиләшкән мажарлардан (1960 елда Б. А. Васильев аларны бортаслар белән бердәй саный) чыгуын билгеләп үтәләр. М. Сәфәргалиев, үз чиратында, мишәрләрнең бабалары — төньякка барып чыккан Алтын Урда кыпчаклары, ди. Р. Мөхәммәтова татар-мишәрләрнең этнографиясе турындагы мөһим монографиясендә, мондый аңлатуларга каршы төшеп, бер фикерне алга сөрә. Аныңча, мишәрләр, күрәсең, Казан татарларына якын торган, аларның этногенезында Идел болгарлары һәм кыпчаклар хәлиткеч урын тоткан. Ул Казан татарлары һәм мишәрләр арасындагы аерманы соңгыларында барыннан да элек угыр элементы булу белән аңлата. Р. Мөхәммәтова, Б. А. Васильев кебек үк, бу элементны бортасларга һәм мордва-урыс йогынтысына (монысы мишәрләрдә көчлерәк) мөнәсәбәтле саный.

Чувашларның этник тарихы буенча яңа хезмәтләр күп, бу мәсьәлә галимнәрнең игътибарын туктаусыз җәлеп итә, аларны кыю фаразлар әйтергә этәрә. И. Д. Кузнецов, мәсәлән, чувашларны һәм кытайларны янәшә куюга барып җитә, ә бу халыкларның музыкасы, фольклоры һәм лексикасы арасындагы тиңдәшлекне басым ясап күрсәтә. Этнограф П. В. Денисовның 1969 елда чыккан монографиясендә Дунай болгарларының һәм чувашларның этник-мәдәни охшашлыгы турында сөйләнә. Бу ике халыкның матди һәм рухи мәдәниятендә ул, үзе әйтүенчә, төрки-болгар элементларын ача, бу элементлар исә ике халыкның генетик туганлыгы, чувашларның болгарлардан чыгуы теориясен ныгыта. Ниһаять, 1974 елда археолог Ю. А. Краснов яңа фараз әйтә. Ул А. Халиковның чувашларның болгарчага формалашуы фикерен, А. Смирновның хәзерге Чувашстан мәйданында борынгы заманда болгарлар яшәгән дип раславын бәхәсле саный. Аныңча, төрки телле болгарлар монда унөченче гасырда гына килгәннәр, уналтынчы гасырга чаклы — «чуваш» этнонимы чыганакларда беренче тапкыр телгә алынганчы — фин телле җирле халык белән кушылганнар. Шулай итеп, ул чуваш халкы формалашуын болай күз алдына китерә: болгарларның бу этник «суперстрат»ы тел биргән, ә фин «субстрат»ы физик тип, шулай ук күп кенә мәдәни кыйммәтләр биргән.

* * *

Күргәнебезчә, Урта Идел буе төрки телле халыкларының килеп чыгышы мәсьәләсе буенча бәхәсләр туктамый. Капма-каршы ике фикер арасында — А. Халиков яклый торган чувашларның һәм Казан татарларының

болгаргача төрекләшүе теориясе һәм бу ике халыкның Алтын Урда чорында гына болгар-суварлар яки хәзерге Чувашстан республикасы мәйданына килеп урнашкан кыпчаклар белән элемтәдә формалашуын раслаучы теория — аларның болгардан чыгулары теориясе дә бар. Соңгысы болгар варислыгына мөнәсәбәттә чуваш һәм татар тарихчылары арасында күптән баручы бәхәс белән бәйле. Бу теорияләрнең кайсын да булса берсен уңай бәяләве кыен. Аларны тиешенчә бәяләү өчен, югарыда әйтелгән милләтчелек карашын һәр очракта истә тотарга кирәк.

Төрле этногенетик мәктәпләр арасындагы бәхәсләр фән өчен һичшиксез файдалы. Һәм бу фәндә, аеруча археология тармагында (бу өлкәдәге нәтиҗәләр коры фикерләүгә генә корылган иде), яңа ачышларны кызыксынып көтәргә мөмкин. Хәзерге вакытта маррчылык йогынтысыннан арынган тарихи тел белеме һәм антропология, бигрәк тә палеоантропология галимнәре чувашлар белән татарлар һәм аларның аерымлыклары (раса аерымлыгына караганда, тел аерымлыкларына күбрәк игътибар биреп) турында эзләнүләрен күңел күтәренкелеге белән дәвам итәргә тиешләр. Безнең уйлавыбызча, моңардан тыш, дәүләтчелек традициясе, бәяләр системасы һәм дин кебек этник элементларны мөмкин кадәр ныграк исәпкә алырга кирәк. Этногенетик фәнне башка юнәлешләрдә — әйтик, тел, матди мәдәният һәм кардәш-ырулык юнәлешләрендә киңәйтү, һичшиксез, яңа нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙ — ХӘЛФӘ



Танылган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тәрҗемәи хәле турында сүз барганда әлегә кадәр әдипнең әдәби һәм сәяси эшчәнлегенә күбрәк игътибар ителде. Әмма әлеге шәхеснең татар мохитендә иң әүвәл «хәлфә» буларак танылуын билгеләү кирәк.

Гаязның «ысулы җәдид» тарафдары булуы аның гомуми караш-ышануларыннан килә. Халык бәхетен аның мәгърифәте, әхлак-тәрбиясе аша аңлату булачак язучыны бик иртә уку-укыту эшенә керешергә мәҗбүр итә. Моңа тагын Чистайдан Казанга, «Күл буе» мәдрәсәсенә күченеп килгән яшь егетнең «ысулы җәдид»нең ялкынлы тарафдары, яңача укытуны яклап, шул юнәлештә эшләүче Һади Максуди кулына барып керүе дә зур этәргеч бирә. Хәлфәсе артыннан яшь шәкертнең Әмирхановлар мәдрәсәсенә күченеп чыгуы да үзеннән 11 яшькә өлкән булган мөгаллименең көчле йогынтысы булу турында сөйли.

Инде «Күл буе» мәдрәсәсендә укыган вакытта ук Гаяз Бакчасарай шәһәрендә Исмәгыйль бәй Гаспиринский чыгарган «Тәрҗеман»ны җентекләп укып бара. Әлеге гәҗит һәм аның мөхәррире турында Исхакыйның әдәби әсәрләрендә, мәкаләләрендә җылы сүзләр еш очрый. Бу факт гаҗәп түгел. Чөнки бөтен татар дөньясында киң таралган «ысулы җәдид» исемен алган яңа укыту методының башлаучысы нәкъ менә Исмәгыйль бәй Гаспралы була һәм ул үз караш-фикерләрен тарату өчен «Тәрҗеман» гәҗитен киң файдалана. «Башларында Гаспринский торган хәлдә Фатих Кәримиләр бу хәрәкәткә тон биреп бара башлыйлар. Боларга Һади Максудыйлар, учительская школа мөгаллимнәреннән Шакирҗан Таһири кебекләр, шул ук мәктәпнең шәкертләреннән Гаяз Исхакыйлар килеп кушылып, булышырга тотыналар»,— дип яза Г. Сәгъди «ысулы җәдид» хәрәкәте турында. *(Татар әдәбияты тарихы.— Казан, 1926, 72—73 бб.)*

1913 елның көз аенда Исмәгыйль Гаспринский авырып урынга егылгач, татар дөньясы өчен хәвефле бу көннәрдә Гаяз җитәкләгән «Ил» гәҗите редакциясеннән Бакчасарайга атаклы шәхеснең хәле турында төгәл мәгълүматлар үтенгән телеграммалар китә. Гәҗит битләрендә «Тәрҗеман» мөхәррире «бабамыз» дип атала. Имзасы куелмаган, әмма стиле Гаязныкы икәнен күрсәтеп торган мәкаләдә түбәндәге юллар бар: «Хәзер ул ялгыз түгел. Бөтен Русия аның шәкертләре белән тулган, бөтен Русия мөселманнарының аңлы кыйсеме аның фикри идеясе белән ашланган... Һәр туган көн татар тарихына аның исемен тирәнәйткәннән тирәнәйтә бара». *(«Ил», № 39, 2 сентябрь, 1913.)* Ә инде Исмәгыйль бәйнең вафаты турында кайгылы хәбәр алынгач, Исхакый үзе һәм аның фикердәшләре

«Ил»дә мәкаләләр бастыралар: Н. Гасрый — «Алтын багана егылды», М. Фоат — «Нәүмизлек», Гаяз — «Бөек остаз Исмәгыйль бәк». Язмаларның исемнәреннән үк Гаспралының әлеге яшьләр төркеме алдында кадерле, бәясе чиксез зур булуы аңлашыла.

Югарыда саналганнардан кала Гаязның татарны агарту, белем-мәгърифәтле итү юлына аяк басуына тагын бер җитди сәбәп бар. Ул да булса әтисе Гыйлаҗ хәзрәт үрнәге. «Кызыл Армия» гәҗитенең 1919 ел, 10 июль санында бу кешенең үлеме турында басылган кыска гына хәбәрдә түбәндәге юллар бәян ителә: «Мәрхүм заманында Чистай һәм Казан әтрафында атаклы хәзрәтләрдән саналып, уку-укыту эшләрендә татар дөньясына күп хезмәт иткән кеше. Чистай шәһәрендә мәшһүр Закир ишан мәдрәсәсендә гыйлем тәхсыйль кылып, шул ук өяздә Яуширмә авылында 45 еллар мулла булып торган. Үзенең 45 ел мулла булып торган бер заманында тирә-як авылларда бик күп мәдрәсәләр ачып, татарларны укырга өндәгән».

Гаяз Исхакый хәлфәлек эшен 1897 елда башлап җибәрә. Әмирхановлар мәдрәсәсендә уку белән беррәттән, үзе дә дәресләр бирә. Яшь һәм талантлы егетне тиз күреп алалар. 1898 елда ул Яңа бистәгә мөгаллимлек итәргә чакырыла, аның исемен татар җәмгыятенең алдынгы катлауларында еш-еш телгә ала башлыйлар. Гаязның эшчәнлеге белән «ысулы саутия»ның (авазга бәйләнешле метод, аваз методы) Оренбургтагы ялкынлы тарафдары, татарны белемле, мәгърифәтле итәргә җаны-тәне һәм малы белән тырышучы Гани бай Хөсәенов тә кызыксынып тора. Казанга агасы Әхмәт байга язган хатында ул Гаяз турында: «Казанга барып безнең хәлфә шөһрәт чыгарды»,— дип яза. *(«Гани бай». Борһан Шәрәф редакциясендә.— Оренбург, 1913. 47 б.)* Гани байның «безнең хәлфә» дигән сүзләре билгеле бер фикергә этәрә. «1897 елның җәендә Мөхәммәдсадыйк хәзрәт мәдрәсәсендә (Каргалы авылы) яңа ысул белән укытырга өйрәтү буенча җәйге курслар ачыла. Өч ай дәвам иткән бу курсларга Россиянең төрле почмакларындагы билгеле мәдрәсәләрдән икешәр шәкерт чакырылган була. Барысы 70 тән артык кеше җыела»,— дип яза М. Гайнетдинов. *(«Народное просвещение у татар в дооктябрьский период».— Казань, 1992, 134 б.)* Күрәсең, бу курсларда Гаяз да катнашкандыр, Гани байның аны «безнең хәлфә» дип атавы да шуның белән бәйле булса кирәк.

Г. Сәгъди Исхакыйны «Казан бае Габдрахман Галикәевләрнең мөгаллиме» диеп атый. Галикәев — Гани байның кодасы һәм алар арасында янача укыту, җәдид мәдрәсәләр турында фикер алышкан хатлар йөреп торган. Хөсәеновның 1898 ел, 14 гыйнварда язган хатында мондый юллар бар: «Мәдрәсәләр бик яхшы бара, Гаяз хәлфә бик тырыша, дип язгансың. Гаяздан өмидемез күп иде. Инша алла, шулай булыр, дип торамыз. Сәлам әйт. Иҗтиһад кыла күрсен.»

1898 ел, 31 гыйнвар көне белән Оренбурдан Казанга агасы Әхмәт байга юлланган хатта да Гани бай Гаязны җылы сүзләр белән искә ала: «Садыйк кодаң куйган Гаяз хәлфә шикелле хәлфәләр кирәк. Алар шикелле булса, шөһрәт таптыра. Начар хәлфә белән эш йөртеп булмый...»

Шушы ук хатта, балалар укудан туктагач, Исхакыйны хәлфәләр укытырга кушу турындагы күрсәтмә-киңәшләр дә бар. Матди чыгымнарсыз эш бармасын Гани бай яхшы аңлый. Гаязның хәлфәләр укытуына бәйле рәвештә ул түбәндәгечә яза: «Укыган вакытта расходын бирсәң, укыгач, укыганнарына вазыйфа (хезмәт хакы) бирсәң, шунда гына эшең йөрер».

Әлбәттә, бу эшләрдә Гани бай Хөсәеновларның шәхси файдасын бөтенләй дә күздә тотмаган дисәк, бераз ялгышырбыз. Шушы ук хатта агасына үпкә белдергән сүзләр дә шактый. Ул Әхмәт байны Гаязга илтифатсыз булуда, «шөһрәт таптыручы хәлфәне» таныи ала белмәүдә шелтәли. «Садыйк кода... Гаязны куеп, бик яхшы шөһрәт чыгарган дип ишетелә. Сез безне күтәрәсенез килмәсә дә, кода күтәрде, әлхәмде лилля. Казанга барып, безнең хәлфә шөһрәт чыгарды. Син бу эшне эшләсәң, һәммәсе Хөсәеновныкы *(ягъни, Хөсәеновларныкы дип аңларга кирәк.*— **Х.Р.** буладыр иде»).

Гани бай янача укытучы мөгаллимнәренең, «ысулы җәдид»кә багъланышлы уку йортларының эшчәнлеген һәрвакыт күз уңында тота һәм кирәк чакта киңәш бирүдән дә тайчынмый. Г. Сәгъди: «Хәтта Һ. Максудый, Г. Исхакый кебек ысулы җәдидче алдынгы мөгаллимнәргә дә Гани бай җәдидчелек юлында тәрбияви киңәшләр бирә»,— дип яза. *(«Татар әдәбияты тарихы». Казан, 1926. 75 б.)*

М. Гайнетдинов мәкаләсендә түбәндәге юллар бар: «Бер-беремезгә барышу» исә Гани Хөсәеновның педагогик системасында нигез принципларыннан берсе. Үзара тикшерү, тәҗрибә алмашу яңа системадагы котылгысыз ким-

челекләрне тизрәк бетерү эшенә ярдәм итәргә тиеш».

Бу юлларның хаклыгы Гани байның хатларында раслау таба. Мисал өчен 1898 ел, 29 мартта Гаязга язган хатыннан бер өзек китерик: «Галимҗан хәзрәтнең мәктәбен күргәнең бармы? Шуны да барып карарга кирәк. Ул әүвәлрәк укыта башлаган кеше, бездә юк нәрсәләр бардыр. Кирәген аннан да алырга ярый. Тиеш булганын үзең арттырырга да ярый». *(99 б.)*

Һади Максудыйга язган хатыннан: «Үзеңез Гаязга барып карап йөри торгансыз дип торамыз. Барганыгызның хәбәре бер дә чыкмый. Сезләрдән тиеш иде, үзеңезгә якын дуст вә әшнә агай-эне муллаларны, шәкертләрне алып барып күрсәтергә сездән тиеш иде. Бер адәм барасы килсә дә кыймый. Сезнең үз мөгаллимегез, үз шәкердеңез, үз мәдрәсәңез. Мондагы мәдрәсәләргә нисбәт артыкмы, кимрәкме? Шөһрәтләре яхшы чыгып тора». *(100 б.)*

Гани бай үзе дә мәдрәсәләр эшен тикшерү, өйрәнү максаты белән төрле шәһәрләрдә, авылларда еш була. *(М. Гайнетдинов. Күрсәтелгән мәкаләдә. 137 б.)* Күрәсең, шундый бер тикшерүдән соң аның Гаязга карашы берникадәр үзгәргән. Галимҗан хәзрәт Барудига 1898 ел, 2 мартта язган хатыннан:

«Мөгаллимлеккә егет табуы кыен. Садыйк коданың Яңа бистәгә куйганы Гаяз мөгаллим бик үткен, бик зирәк егет, сөйләгәндә авызыннан утлар чыга. Шул егетнең дә ярар-ярамасына күз җитми... Гаязны бик яхшы дип әйтәләр. Яхшы юк. Яхшыны күрмәгәндә бар да яхшы була. Безнең өлкән мәдрәсәне үзеңез күрдеңез. Ибтидаи 1 нче, 2 нче, 3 нче сыйныф дәрәҗәсендәге укыткан хәлфәләр шул мәдрәсәдән узганнары бар. Безнең читтәге хәлфәләремез дәрдле егетләр, үзләре дә кушалар икән. Үзеңез Гаязның укытканын кереп күрсәңез, аңлар идеңез. Безнең мондагы өлкән мәдрәсәдән арткан кай җире бар икән? Үз белгәнегезне язып җибәрер идеңез». *(88 б.)*

Татар укытучылар мәктәбендә белем һәм тәрбия алуы «үткен, авызыннан утлар чәчә торган» Гаязның тынгысыз, туктаусыз үзгәреп тора торган холкын тагын да кискенләштерә, дөньяга күзен ача төшә.

Кайнар канлы, ялкынлы, кызу табигатьле Гаяз урталыкны сөйми, дөньяны тиз һәм кинәт үзгәртү юлын хуп күрә. Тора-бара күптән түгелге мәсләктәшләре, фикердәшләренең эшчәнлеген инкарь итүгә кадәр барып җитә. 1902 елда язылган «Инкыйраз»да татар дөньясы үсешендә Хөсәеновларның эшчәнлегенә бик тыйнак бәя бирә. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китик: бу бәя Гаязның үз күргәннәренә нигезләнеп бирелә. Чөнки 1902 елда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлагач, ул «Хөсәения»гә мөгаллимлек итәргә чакырыла, бер ел дәвамында шунда урыс теле һәм табигать белеме укытучысы булып эшли. Мәдрәсәдәге уку-укыту, тәртип-тәрбия торышы белән ризалашмыйча, 1903 елда Казанга — университетка керү теләге белән кайтып китә. Әмма бу теләге тормышка ашмый кала, чөнки Гаязга Яуширмәгә кайтып, мулла булырга туры килә. Мөгаллимлек эшен ул биредә дә дәвам итә.

1916 елда мөгаллиме, остазы, күптән түгелге мәсләктәше Һ. Максуди белән дә аралары бөтенләй диярлек бозыла. Һ. Максуди чыгарган «Йолдыз» гәҗитенең 10 еллык юбилее мөнәсәбәте белән Г. Исхакый «Сүз» гәҗитендә шактый күңелсез, ямьсез сүзләр язып чыга. Һ. Максуди да җавапсыз калмый. Ике мөхәррирнең бәрелешүен матбугат аша укучылар шактый вакыт күзәтәләр.

Артык озынга киткән бу «бәрелеш»кә Ф. Әмирхан да катнаша. «Йолдыз» һәм Гаяз Исхакый» дигән мәкаләсендә ул җәмәгатьчелекнең симпатиясен тулысынча Гаяз ягына аударырлык фикерләр, дәлилләр китерә. «Гаяз бер нәрсәгә ышандымы — ул инде аны башка һичбер нәрсә белән хисаплашмыйча әйтә дә бирә; Гаяз бер нәрсәне игътикад иттеме (күңеленә беркеттеме), ул инде шунын юлында һәммә нәрсәне, һәммә кызыксызлыкларны илтизам итә (өстенә йөкли) ала». *(Ф. Әмирхан. Әсәрләр. Дүрт томда. Казан, 1989, 3 т., 300 б.)* Күренекле язучының кеше күңелен дөрес аңлап, оста бәяли белүенең ачык мисалы бу юллар. Гаязның холкын тасвирлаганда Әмирхан әйткәннәрдән артык сүзләр эзләп тору кирәкмәс. Исхакыйның фикерләре, ышанулары, караш-мәсләкләре еш алышынуга карамастан, бер нәрсә үзгәрешсез кала: үзе аңлапмы, аңламыйчамы, Гаяз һәрвакыт «милләтче» булуында дәвам итә, ди мәкалә авторы. Һәм гомеренең соңына кадәр дәвам иткән шушы «милләтче»леге, милләтпарвәрлеге, милләткә хезмәт итүе Гаязның нәкъ менә хәлфәлегеннән башланып китә. Шуңа да күренекле язучының бу өлкәдәге эшчәнлеге, безнең карашка, аерым игътибар сорый.

**Руфия ХӘМИДУЛЛИНА,**
**педагогия институты аспиранты.**

# ХӘСӘН ТУФАН
# ҺӘМ
# СӘЙФИ КУДАШ ХАТЛАРЫ

**Хәсән Туфан мирасында аның иҗатының югары ноктасы дип бәяләнерлек һәм моңа кадәр укучы игътибарыннан читтә калып килгән тагын бер тармак бар. Бу — аның хатлары. Аларда конкрет кеше тормышында, көнкүрешендә була торган аерым очраклар, әдәбият һәм ил тормышындагы хәлләргә бәя-мөнәсәбәтләр, шулардан туган көчле эчке кичерешләр бик тә тәэсирле, үтемле, төгәл — димәк ки гомумиләштерүле, образлы чагылыш тапканнар. Ә бу хәл, үз чиратында, ул хатларның сәнгать әсәре, әдәби иҗат итеп эшләнүен искәртә. Аларда шагыйрь тормышы һәм яшәү рәвеше турында бай мәгълүмат тупланган. Хатлардагы һәр сүздә, һәр гыйбарәдә тезмә әсәрләргә хас шигърият бар.**

**Сәйфи Кудашның дусты Хәсән Туфанга язган хатларында да шул ук стихия өермәләнеп, кайнап, шундый ук төгәл сәнгатьлелек югарылыгына күтәрелә. Шулай итеп, Хәсән Туфан һәм Сәйфи Кудаш — татар тормышындагы хат-хәбәрләшүләрне чын сәнгать югарылыгына күтәргән һәм бу өлкәдә күзгә күренерлек өлге, үрнәк була алырлык саллы мирас калдырган әдипләр.**

**Журналның бу санында без укучыларга алар иҗатының шушы өлкәсеннән кайбер үрнәкләрне тәкъдим итәбез.**

Мәсгут **ГАЙНЕТДИНОВ.**

*9 нчы март 1964 ел*

Сәйфи! Кабатланмас туганым Сәйфи!

Ах, күп тә соң сиңа әйтәсе, сөйлисе килгән уйлар, сәламнәр... Сөенәм дә мена, бераз көенәм дә. Сөенәм: дөньяда син бар, иң якын иткән кадерле туганым. Үткәнебез, яшьлегебез, киләчәгебез белән дә иң якын туганым булган кешем — син бар. Көенәм:

Өйне шигырь белән тутырып
Бер сайрашыр идек утырып, —

диеп сагынышып яшибез үзебез. Ә күрешүләр, очрашулар нинди сирәк, сайрашып, серләшеп утыру сәгатьләре нинди кыска. Безнең күрешү кичәләре таңнарга тоташтырган сөйләшүләр, еллар буена йөрәккә тупланган өметләрне уртаклашырга дигән темаларның прологлары гына булып тоела, Сәйфи, прологлары гына. Без беркайчан да сайрашасы дигән өметләребезнең эпилогына барып житмәбездер: безнең туганлык ил эшендә бергә януның эчтәлеге торган саен киңәя, тулылана, зурая бара; тормыш аңа сәхифәләр — яңа битләр өстәп баста да баста гына. Син үзең сизмисеңдер, Сәйфи, ә миңа ачык күренә: иҗади канатың

ныгый да ныгый, рухи байлыгың балкый да балкый гына. Синең шулай яктырып, балкып яшәвеңә окланам һәм дулкынланам. Димәк, минем учакка да нур өстисең, яна-яна яшәргә илһамландырасың. Мин бары бер нәрсәгә, Сәйфи, кулыңнан каләм төшмәгәненә, авыруларга бирешмәвеңә ышанам: синең рух, бер яктан, давылларда чыныккан ветеран; икенче яктан, һаман алгы сафта барган азамат. Бу рухның тормышка, яшәүгә, халыкка мәхәббәте чиксез. Һичбер авыруга ишек ачмаячак. Тегендә, «җәһәннәмдә» [1] тормыш миңа үзенең бер серен әйтте: «һәлакәт ул кешенең, адәм баласының өмете сүрелгәнен, яшәүгә ышанычы беткәнен сагалый. Өметең сүрелдеме, димәк беттең». Шулай икәнен күрдем мин аның, тормышның. Ул безнең җаннарны аралый-аралый эндәште, боексак: «Ярамый, ярамый: өмете беткәнне һәлакәт сагалый!» Яшәүгә мәхәббәт сүрелсә әгәр дә, торалмас идек без кырыкка кадәр дә, Какса да ничә кат йөрәкне һәлакәт, ачмады ишекне аңарга мәхәббәт». Син дә үзеңнең бөтен гомереңбелән, олы гомерең белән «ишекне» ачмауның, бирешмәүнең җанлы мисалы бит. «Диссертация»н [2] римләрнең Херроннарын [3] искә төшерде, логикасының көче белән бәхәскә урын калдырмаслык хакыйкатьләре белән, үткен стиле белән, раслаган мәсьәләнең бөеклеге белән тарихи әсәр ул. Соклангыч гыйльми хезмәт ул. Мин аны алгач та барлык эшләрне читкә ташлап, бер утыруда укып чыктым. Искиткеч оста, акыллы язылган: җәдит турында бер нәрсә дә сүз юк кебек, ләкин ул мәсьәләдә: «кул җылытканнарның суны болгатып балык тотарга маташканнарның ясалма нигезләрен», «гыйльми» корамаларын ничек тар-мар итеп ташлый. Асылда алай гына түгел, аларга үзләренең кылган хаталарын аңлата һәм әгәр дә аңлый алырлык сәләтләре булса, тарихны фальцификацияләүләреннән котылырга ярдәм итә ала. Син бездәге ата җәдитченең [4] кем икәнен беләсең, билгеле. Гомәрдән [5] соң «диссертация»не шуңа илтеп укытып, кылган эшләренә күз салырга ярдәм итсән, ничек булыр, дип уйлаган идем. Гомәр белән киңәштек тә, файдасы булмас, иртәрәк диеп, без фикердән кайттык. Мирсәй [6] шактый озак тотты: союздагы ыгы-зыгылардан бушый алмады бугай. Аңарда да яхшы, тирән эз калдырган: «Бу мәсьәләдә тулы бер курс үткән кебек, ныгыдым мин хәзер. Бик аз белгәнмен икән, гаҗәп көчле дәлилләре алдагы эшләрдә безгә дә терәк була ала», ди ул.

Аннан соң Әмирхан [7] укыды. Хатип [8] исә өйгә килеп, бик кызыксынып танышып чыкты. Бездә яшьләр арасында да антиҗәдитчелекнең аңа «теркәтаповчылыкта» [9] икәнен яхшы аңлаган егетләр бар. Шундыйларның бер-икесен «диссертация» белән таныштыру кирәк булды. Алар сиңа сәлам белән бергә рәхмәт белдерделәр.

Безнең чын мәгънәсендә яктылык симптомы булган мәгърифәтче Зыя[10] буынын Романовлар охранкасына сатып яткан карагруһларның юньсез, хәерсез токымы вәрисе[11] рәвешендәге Алтайлар[12] бездә дә бар. Шуларның берсе Бадамшин дигән бер «Унтер Пришибеев» 1961 елда «Соц. Татарстан»да (№ 165) «Тел мәсьәләләрендә буталчыкка каршы» янәсе мәкалә белән чыккан иде. Үткән ел син аларны күздән үткәргәнсеңдер. «Телебезнең дөрес үсүе өчен» мәкаләсе белән балык тотып маташты. («Соц. Татарстан», 25.8) Бадамшин дигән исем бездә «унтер» мәгънәсендә йөргәненә күрә, ул мәкалә имзасыз бирелгән иде. Язучыларның киңәйтелгән гомуми җыелышы искиткеч ердәм рәвештә бу мәкаләдәге нәҗес ялаларны кире каккан иде. Менә шундый кабахәт Алтайлар, Вадамшиннар — үзләренең доноска ошаган, донос исе аңкыган язмалары белән кабахәт кулларын алдынгы төп язучыларның намусына сузылулары белән иҗат эшләребезгә аяк чалалар, борчыйлар, илһамлап иҗат итүне суытырга, игътибарны читкә юнәлдерергә, үзләре белән бәхәсләшүгә тартырга маташалар. Сиңа менә «Бар ул, бар!» дигән шигыремне җибәрәм. Бу шигырь сиңа татар язучыларының

---

[1] Төрмәдә, сөргендә.

[2] С. Кудашның Казахстан Өлкә партия оешмасы секретаре ип. Кунаевка язган хаты күз алдында тотыла.

[3] Херон — гарәпчә язудан ялгыш укылган күрәсең. Цицероннарын булса кирәк.

[4] кем икәне билгесез.

[5] Язучы Гомәр Бәширов.

[6] Язучы Мирсәй Әмир.

[7] Язучы Әмирхан Еники.

[8] Галим Хатип Госман.

[9] Теркәтаповчылык —

[10] Зыя Камали — Уфадагы «Галия» мәдрәсәсенең мөдире.

[11] Вәрис — мирас алырга хокуклы кешеләр.

[12] Алтайлар — дингә каршы көрәшүчеләр.

ниндиборчулар эчендә яшәүләрен, яна «Пришибеевларнын» ни рәвештә тенкәгә тиюләрен ачык итеп сөйләп бирә аладыр. Уфадагы унтер алтайлар мина да «кул суза», ягъни мине дә борчылырга мәҗбүр итә. Зыябыз турында шигырь языла башланды. Язмыйча, дәшмичә калырга мөмкин түгел, Сәйфи, мөмкин түгел. Бу турыда киңәшербез әле. Менә бер-ике строфасы:

Шырпыга да мохтаҗ заманнарда
Өйдән өйгә күчкән ут кебек,
Забойларга килеп керде исмен,
Йөрәкләргә безнең нур бирел...

Партадагы урыныбыздан барысы
Бер аршинда, ике аршинда
Утырдык без якты киләчәкне
Үтә күргән йөзең каршында...

диясем килә минем! Ул бөек остазыбыз Зыя ага, бәлки үзе дә сизмәгән хәлдә, материализмга юнәлдерде безне. Минем хәтердә моның бик күп фактлары бар. Ул безне Тукайча янып яшәргә, обыватель булмаска, фидакарьләрчә яшәргә сокландырды. Без олы буыннар бер-беребезне яхшы беләбез. Без иҗтимагый киң колачлылар, без тыныч кына, мыштым гына, битараф кына обывательчә яши белмибез. Бездә, аллага шөкер, андый «сәләт» юк, ләкин, Сәйфи, уйлыйсың да, әйләнәсең дә, карыйсың да, йөрәк жуу итеп куя. Ах, аз ла яна белүчеләр, ах, сай җанлылар да безне алмаштырачак яшьләр! Йөрәкләренә обывательлек, ниндидер әрсез мещанлык оялаган. Төп мәсьәләләрдә шундый сүренкелекләре «арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит» дигәндәй...

Әдәбиятка килеп кергәндә, тумыштан дигәндәй, таланты, янып яшәячәге күренеп торган яшьләр дә бар. Ләкин халтурада обывательнең дә үзенә «алтын чор» тудырылган заминга (җирлеккә) ясалма иҗат белән чын иҗат бергә буталып яшәгән мәйданга килеп керү белән яхшы сыйфатларын югалта башлыйлар, талантлы яшьләр керләнә баралар. Дөньяны пакьлый алырлык яклары югала бара.

«Диссертация»не җибәрәбез. Казанга килгәндә аны да алуың яхшы булыр: Нәкый[1] һәм Хәким[2] дә укыр иде, бәлки. Казанга үзеңне көтәбез. Димәк, алда очрашу, сайрашу көннәре. Гомернең язы килә кебек, күңелле миңа хәзер. Мәгъфүрәгә, үзеңә туганлык сәламнәре белән — ***Хәсән.***

*9.3.1964.*

Менә шунда кадәре өлешен авырый башлавың турындагы хатны алу белән яза башлаган идем. Аннары тагын бүлендем, җан ыгы-зыгы эчендә яшәде. Миңа бер вакытта да салкын тия алмый иде. Ни эшләгәнмендер, авырып та алдым. Телефонда сөйләшкәндә сиңа әйтергә онытканмын: безнең Мөнир Тутаев Тукай залында чыгыш ясаган иде. Шунда сине, «Хәтердә калган минутлар»ны бик матур бәяләп, телгә алып киткән иде. Бәлки Өлкә комитетлар үзара киңәшеп, сөйләшеп эш итәләрдер дигән яхшы уй туган иде миндә, шулай булсын!

Хатның дәвамы: шигырь.

## Бар ул, бар!

Кем беләндер залга килеп керде
Пришибеев кебек исәнеп,
Дивардагы Тукай, хәтта Горький
Куйган кебек булды сискәнеп.
Сатамшинмы, әллә Саламшинмы,
Исме-нисе истә калмады,
Җаныбызны таптагандай итеп
Карап торды бераз,
Аннары
Әйтеп куйды ымлап-пышылдап кына:
— Болар бар да узкий патриот!
То-есть, монда
Киң карашлы кеше
Почти юк!
Пантюркистлар болар... Нәкъ Такташ кук,
Беспартийный болар һәммәсе:
Шикле, то-есть, телче кешеләр болар,

[1] Язучы Нәкый Исәнбәт.
[2] Шагыйрь Сибгат Хәким.

Безгә болар ишме!? янәсе.
Бу унтерга, әйе, иш түгел без,
Бу турыда бәхәс юк безнең.
Ә ул безне —
Партиясезләр,— ди,
Төп максаты ни соң бу сүзнең!?

.................................................................

Сатамшинмы, әллә Саламшинмы?
Исме-нисе истә калмады,
Истә бары
Безне «төрткәләргә»
Күнегеп беткән керле бармагы
Менә шундый
Ярым космополит,
Ярым нигилист булган бәндәгә
Ленин васыятьләрен «төзәтергә»
Ирек бирә калсак әгәр дә,
Катып беткән догма бүкәнендә
Тамга салып
Безнең колакка,
Тезеп куяр иде һәммәбезне
Я «сул» якка,
Яки «уң» якка...
Гадәте шул
Аның — бичараның:
Шыпырт кына суны болгата.
Ялгыш эләккән билет ышыгында
Балык тотып ята ул пока;
Аса пока
Безнең муеныбызга
Яла исе килгән язмасын,
Сала пока
Безнең ап-ак йөзгә
«Шикле кеше» дигән тамгасын,
цитат итеп кенә «аңлап» бара
Партиябезнең программасын.
Иш түгел без һичбер Сатамшинга,
Бу турыда бәхәс юк безнең.
Ә ул безне партиясезләр ди,
Төп максаты ни соң бу сүзнең?
Бар ул, бар ул
Безнең партиябез!
Менә монда, безнең
Җанда ул.
Юк, Сатамшин,
Тыгыла алмый аңда
Һичбер нәҗес керле
Кара кул!
Бу үрдәк тә — Саламшин да бәлки
Ап-ак юлда яралгандыр да...
Ил күленнән күлдәвеккә күчеп,
Сазда яшәп каралгандыр ла.
Болдырың да, илем, ап-ак синең,
Һәрбер өең күңелең кебек пакь.
Кайда туып, кайда үсте икән
Менә шундый битсез, нәҗес зат?

*1.8.1964 ел.*

Сине озаткач, Кудаш, Гомәр аэропорттан туры «Аккош»ка (бакча) китте. Ә мин өйгә. Нигәдер, әллә нинди моңсулык басты үземне. Нишләп син шундый гаҗәп матур форсаттан файдалана белмәдең әле? — дип үз-үземне шелтәләргә керештем. Әгәр сине Уфага, өеңә кадәр озатып китеп баруым булган булса, икебез өчен дә нинди күңелле, кабатланмас кызык булачак иде. Өйгә кайтып,

күңелсезләнебрәк утыруымны күргәч, Мөнҗия дә «Озата барырга кирәк иде Сәйфи абыйны» дип нәкъ шул минем күңелдәге фикерне әйтеп куйды. Бүген менә хатыңны алып, исән-сау кайтып җитүеңне белдем. Син дә шулай ук: «Нигә бергә китмәдек-кайтмадык икән соң?» — дип уйлагансың икән. Хәерле булсын инде, бусында булмады. Давай, Кудаш, тагын кил Казанга.

Киләштән, Акманайдан син бөтенләй киткәнгәмедер, ягъни аны Тукайча әйткәндә, Сәйфи, ягыңны укучыларга тапшырганга (син бөтенләй Юматауга күчкәнгәчә) кадәр күрәсе килә. Гомереңнең байтак өлеше шунда үткән кадерле изге урын бит ул.

Киләш «Галия»дә чакта ук минем күңелгә кереп утырган иде инде. Ә «Акманай» сүзе күңелне били бара, мөкатдәс сүз булып тоела.

Рафаэлебез[1] Мәскәүдән яңа хәбәр алып кайтты безнең. Безнең поэзия атналыгы беренче октябрьдән башлана икән. Минем анда барасым килми. Җан да, аяк та тартмый инде. С. Евсееваның[2] «Когда придут татарские собаки»,— дип, татар халкының янагына суккан эзе әле һаман бетмәгән бит... Бу оятсызлык, «шовинистик дуңгызлык» бу дип чыккан булса да («Лит. Россия»), бу кызның, дөресе ялангачлык шагыйрәсенең сүзләрен абыйлары ишетмәмешкә салышалар бит. Димәк, безне «сабаки» дип атау белән килешәләр что ли алар? Атналыкның вакыты әлегә кадәр ачык билгеле түгел иде. Рафаэльнең бу хәбәре әйбәт. Минем октябрь башында Уфага, безнең өчен чиксез кадерле шигырь бәйрәменә барасым бар бит.

«Русча-башкортча сүзлек»не таптым, Казанга да килгән икән ул. Анда «сөрән» белән «оран»ны бер мәгънәдәге сүз итеп биргәннәр. Бу сүзләрнең аермалары бар бугай бит? Инде татар әдәбиятында да кулланыла торган «тәү» сүзе «беренче» мәгънәсендә генә түгел бугай. Башкорт телен яратам мин. Син миңа аның нечкәлекләрен төшендергәләүдә булышырсың әле. Кичә Вәсим абый Солтановтан[3] хат һәм шигырь килде. Кыскача гына үзенең терекчелеге (автобиографияне шулай атый ул) турында да язган. Галимҗан абый шәригы икән. 1909 елда «Галия»дән бергә сөрелдек» дип язган ул. Шул турыда тәфсилләрәк итеп язуын үтендем. Беренче җыентыгы «Канау буе» 1906 елда басылып таралды, дигән сүзе кызыклы.

Димәк, ул Тукай белән бер вакытта яза башлаган диярге була. Бу бик кызыклы хәл булып тоела миңа. Җибәргән шигырьләре болай төгәл язылган назым (көйле, рифмалы — С.К.) булудан узмаса да, ветеран булуын искә алганда, ихтирамга лаеклы әсәрләр.

Гомәргә сәламеңне тапшырдым. Тынычланды. «Ул ничек кайтып җитте икән? Хәле-саулыгы әйбәт микән?» — дип, борчылып йөри иде. «Җолдыз» — казакъ телендә әдәби журнал өчен рәхмәт. Шәригыбыз Баембәт Майлин турындагы истәлегең киң, тулы икән. Үткәннәрне яңарта-яңарта рәхәтләнеп укыйм. Ну хәтереңсинең, Сәйфи, магнитофон да, кинокадр да, энциклопедия да ул! Безнең тарихи бәхет ул! Сине, «Җолдыз»ны да уку казакъ телен үзләштерергә, төшенергә ярдәм итә.

Хәзер бездә иртәнге алты инде (тагын биш минуттан алты тула). Мин ятмадым әле. Төн буе шигырь яздым. Яктыра башлаганда гына бу хатны язуга күчтем. Сездә ничектер, бездә көн тын, уйчан. Явыйм микән, ачылыйм микән дигән сымак уйга калган бездәге бу иртә. Җил кайдадыр киткән, күрәсең. Агачлар — аяк очларына гына басып, нәрсә булыр икән дигән кебек, нидер көтеп-тынып тыңлагандай торалар.

Хәерле иртә сиңа! Икегезгә дә сәлам белән — ***Хәсән.***

P. S. Ятар алдыннан гына чәчкәләр янына чыккан идем. Иң яраткан чәчәгем — кыңгырау чәчкә — зәңгәр гүзәллеге белән көлемсерәп тора, мин аны урманнан алып кайтып утырткан идем. Игътибар итү ошады бугай үзенә: менә икенче мәртәбә чәчкә ата, 20 кыңгыравы бар, ә урмандагы туганнары икенче мәртәбә чәчкәләнмәделәр. Без дә шулай бит, Кудаш: яхшы җирлектә икенче, өченче тапкыр да чәчәк аталабыз.

Менә кыңгыравын хат эченә салам, барып җитә алса, сиңа сәлам әйтсен!

---

[1] Рафаэль Мостафин — язучы.
[2] С. Евсеева — рус шагыйрәсе.
[3] Вәсим Солтанов — «Галия» мәдрәсәсенең беренче шәкертләреннән, язучы, берничә китап авторы.

*17.4.1965 ел. Казан, урман.*

Моны, Сәйфи, «Аккош күле»ннән, теге кыңгырау чәчәкләр иленнән язам: табигатьнең ничек уяна башлавын күрик, тагы бер күрик дип бу якка килеп чыга торган гадәт бар безнең. Безнең дигәнем — Бәшир, Хәким дә мин. Аякларыбызда резин итекләр. Кулда көрәк. Гөрләвек кырына басып, уйга калып, аның җырларын тыңлап торабыз, ә ул — без китәбез, сез каласыз... дигәндәй, кайдадыр ашыккан сымак йөгерә дә йөгерә... Бу су дигән нәрсә мәңге хәрәкәттә. Чиксез мәңгелек эчендә кайларда гына булмагандыр инде ул. Никадәр илләрне, җирләрне күргәндер. Тамчыларның кайсыларыдыр буга-томанга әверелеп, күккә менәр, кайсылары җиргә сеңәр. Күктә булганым бар, анда көндез йолдызлар күренмәгәндә шыксыз шыр бушлык. Ә җир эчендә балчыклар арасында караңгы, үле тынлык. Җирдә, кояш нурлары эчендә кеше хәлендә яшәүгә ни җитә! Ах, җансыз материя — матдә булып яшәү, акылдан язарлык күңелсездер. Шулай уйланып басып торганда, гөрләвек ярны шыпырт кына астан уеп алган икән... Яр кинәт ишелде дә, төштем дә киттем суга. Ярый әле билгә генә чаклы баттым... Бәширләр кулына тотынып ярга чыктым. Итекләргә тулган суны бушаттым. Тау кырында кардан ачылган төштә көлдә бәрәңге пешербез дип яккан учак бар да, аның җылысында гына киптерерлек түгел минем хәл. Өйгә кереп киемнәрне алыштырып чыктым. Балалар кебек мавыгып гөрләвеккә юл ерышабыз, аны үзебезнең күлгә агызабыз. Күл эчендә каеннар, куаклар үскән утрау бар. Күлгә су аккан саен, утрау каеннары-ниләре белән бергә күтәрелә бара.

Урманда, безнең өйләр тирәсендә — язгы кошчыклар чыр-чуы... Нәселләрен дәвам иттерү мәсьәләләре турында киңәшләр, бәхәсләшәләр күрәсең. Миндә, ничектер, үз кошым да булсын иде, дигән хосусый милекчелек хисе туган иде. Үз кулым белән сыерчык оясы ясап куйган идем. Алар кабул итү комиссиясе кебек, бик эре генә, ашыкмыйча гына шул ояның сыйфатын тикшерәләр. Бәлки үтәр дип уйлыйм. «Фән һәм тормыш» журналындагы проект буенча төзегән идем сыерчыкларга дигән өйчекне. Бәширнең хәле-кәефе яхшырак: аныкы былтыр ук кабул ителгән оя. «Минекеләр кайттылар инде, теге илләрдә ниләр күрүләре турында хисап бирәләр әнә»,— ди ул. Менә шулай, Сәйфи, өеңдәге гомуми эшләрне онытып торырга, бераз хәл алырга телисең дә бит, ләкин булмый, булмый. «Совет әдәбияты»ның исемен көчкә-көчкә генә алыштыра алдык, ул «Казан утлары» булачак. Инде аңа яңа шул исеменә лаек редактор табу мәсьәләсе турында баш ватабыз. Иң лаек кеше Бәшир дә бит, риза булмый, алынмый, димләп кенә түгел, сүгеп тә карадым, юк, күндереп булмас ахры.

Икегезгә дә бәхетле яз һәм җәй теләп — ***Хәсән.***



**Рәсемдә:** Нури Арслан, Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким *(сулдан уңга). Җитмешенче еллар ахыры.*

*27.4.1965.*

Әй таркау да соң мин, туганым Сәйфи!

Башлаган хатым өстәлдә очына чыкканын көтеп, ятып калды! Мәгъфүрәне дә, үзеңне дә яз белән! Бәйрәм белән!

Теге бәндә (Наум)[1] безгә килде. Казанда андый Дон-Кихотка замин (җир-

[1] Наум — Хәнәф Наум — тәнкыйтьче.

лек — С. К.) юк: Галимҗан[1] абыйга кизәнергә маташкан кулны өзеп ташлаячак Казан. Үзем нәкъ егерменче еллардагыча янып, канатланып, җыелышлар, очрашулар укучылар белән давылында бөтерелеп яшим. Китабың турында төрле яшьтәшләребез сиңа рәхмәт укыйлар. Алар бөтен тирәнлеге белән төшенәләр кебек күренә. Кичә Тел, әдәбият һәм тарих филиалында борынгы әдәбият турында киңәшмә булган иде. Тәнәфес вакытында синең китап турында бербереңә шатлануларын белдерештеләр.

Сиңа беразын җибәрәм. Кирәк булса, яз, тагын җибәрермен.

Сәлам-сәлам — ***Хәсәнең.***

Аэропорт 27.4.1965.

*Казан 3.02.1966 ел.*

Кадерле туганым, Сәйфи!

Сезнең Мәгъфүрә белән икегезне күздә тотып әйтүем — улларыгыз, кызларыгыз, зурлары һәм нәниләре миндә гаҗәп матур эзләр, онытылмас истәлекләр калдырдылар. Җәйнең синең белән бергә үткәрелгән өлеше әле һаман йөрәкне җылытып тора. Яңадан күрешәсе килә. Әллә ничек үтә лә, узып тора ла бу тормыш. Көз көнө дә, ничектер, күрешә алмадык. Барып кайтыйм, йә үзеңне китерим дип торганда больницага керергә туры килде. Быелгы язның беренче чәчәкләрен, аларның хуш исле сәламнәрен бергә каршылыйсы иде. Бу үтәлми калуы мөмкин булган теләк булып тоела миңа.

Аңа кадәр күрешербез, бәлки: Сине Җәлил бәйрәменә дә көтәбез. (Чакыруны алгансыңдыр. Союз сине, Нажарны, Сәгыйтьне чакыра.)

Киевтан арып-талып кайткандыр ди Гомәр. Мин аңа: Сәйфи гипноз белән дә яши ала ул дим, алда берәр зур эш торганда арулана, авыруларны үзеннән алып ташлый ала ул дим. Мин савыгып киттем. Авыру чорларымдагы хатларың, киңәшләрең, кайгыртуларың миңа мәгънәви дару булды. Күз элекке хәленә кайтканнан соң, грипп кебек вак-төяк авырулар бәйләнгәләделәр. Аларны аяк өстендә генә үткәрдем. Әпсәләм (язучы Габдрахман Әпсәләмов) белән Пермь өлкәсе татарлары арасына мин дә барасы идем. Врачлар мине җибәрмәделәр, Казаннан чыкмаска киңәш бирделәр. Әпсәләм хәлен ишеткәнсеңдер инде. Ул анда авылда сәхнәдә ауган. Параличның бер төре инде. Казанга кайтарылды. Больницада, әкренләп исән калу ягына таба бара. Бүген Оренбургка, Мостафага (М. Җәлилнең туган авылы) китәбез. Минский, Хузанган һ. б. Мәскәүдән — Френкель, М. Львов, тагын үзбәкләрдән кемдер бара бугай. Казандагы бәйрәмгә кайтып җитәргә тиешбез. Бәйрәм Казанда башлана. Мәскәү, барлык союздашларның вәкилләрен җыйнап, 18 ндә Казанга килә. Мәскәү алып килергә тиешле кунаклар исемлегендә 80 кеше. Бәйрәм 20 нче февральдә Мәскәүгә күчә. Мәскәүдән килгән кунаклар бездә өч көнә көн була. Бездән аларга кушылып 10 кеше китәргә тиеш. Минем анда барасым килми: Җәлилне хөрмәтләү бик матур, күңелле, кирәкле эш тә, шуңа кушылган ыгы-зыгылары арыта. Ленинградтагы әдәбият атнасына да шуңа күрә бармаска булган идем. Бармауны сангa санамау дип аңларга теләүчеләр табылуы мөмкин булганга күрә, Гомәргә мин: «Булмаса авырырга кирәк миңа» дигән идем. Шаяру төсендә генә әйтелгән иде бу. Гомәр: «Ничек инде ул, андый эш мөмкин мени?» — дигәч, мин аңа әйтә куйдым: «Мин бит үземне — авырмаска! — дигән әмерем, карарым белән генә сау яшәтеп киләм. Әгәр шул карарны нәфи (юкка чыгарып) кылып, киеренкелекне вакытлыча гына йомшартсам да, нервалар пружинкаларын бушатсам, шундук авыруларым мөмкин дигән идем». Юри генә әйтелгән иде бу. Ә нервалар чынга алганнар күрәсең аны. Шуннан икенче көнне үк авырый башладым. Йөрәккә бәреләсе катастрофаның күзгә китереп бәрүе. Сәфәргә чыгу көне җиткәндә, мин больницада идем инде. Мин моны, Сәйфи, сиңа әйтәсе, сөйлисе, язасы сүзләрнең, серләрнең тезислары рәвешендә генә әйтәм. Врачлар: борчылудан бу, диделәр. Язучыларыбыздагы мещанлык, нафталинлы обывателлекләр, Тукайларча гомуми эшләребез өчен янып яши алачаклар дип күрүләр мине бик-бик нык борчыган иде. Бу газап барыбер әле дә бар. Сүнмәде, сүрелмәде дә. Зур шатлыклар да бар: халык үз әдәбиятын ябырылып укый. Газета-журналларның тиражлары (беркайчан да болай булганы юк иде) искиткеч арта. Ләкин кайгылар болардан да зуррак: мәктәпләребездәге хәлләр, телебез язмышы һ. б. шундый аяныч яклар, авырттырган яклар бар, хет тот та сөрән сал. Борчылмаска!.. дигән әмер белән, тешне ныграк кысу белән генә бирешми яшисең. Безнең бер төркем язучылар Түбән тарафларына әдәбият атналыгы үткәрергә барган иде (мин анда да бармадым).

[1] Галимҗан — Галимҗан Ибраһимов.

Мәктәпләр беренче класстан ук икенче телгә күчерелгәннәр. Ә балалар аны белми әле. Өлгереш начар. Бу хәл укытучыларны борчый, билгеле. Кайберләре балалар икенче телне үзләштерсен өчен, ана теле белән араны өзәргә кирәктер дип, туган тел китапларын җыеп яндырганнар. Ужас бит бу, ужас. XXIII съездны көтәбез. Бик зур өметләр, ышанычлар белән көтәбез. Бәлки Ильич васыятьләренең ничек үтәлүе мәсьәләләренә дә күз салыныр. Тарас агай иленнән, Тычинабыз өеннән язган шигъри хатың кәефең яхшы булуны раслый. Шигырь яза алу хәлендә булу күңелле факт ул. Әйбәт истәлекләр, матур уйлар-тойгылар белән канатланып кайткансыңдыр, бәлки. Павло миндә беренче күрүдә үк чын шагыйрь бу дигән тәэсир калдырган иде. Ул һаман шулайдыр кебек, Әхнәфнең (Ә. Харисов) «мирасы» турындагы мәкаләнне («Кызыл таң»да) укыган идем. «Мирас» турында Казанда төрле фикер бар. Тулысынча күздән үткәрергә өлгермәдем әле. Ләкин ул мәсьәләдә сиңенчәрәк караштa торам әлегә.

Үзеңә, Мәгъфүрәгә һәм сокланглыч семьяңа сәлам белән ***Хәсән.***

Сәфәргә җыена-җыена язам, бераздан юлга чыгабыз. Хәер-доганнан ташлама. Хатның башында мин сиңа башы шигырьләрдән, иҗади миләрдән ял итеп алсын дип, бер табышмак (**Җ — Б — С — В** куйдым, таба алмасаң үзем булышырмын, уңнан язылышы — **Җ — Б — С — В**). Бездән соңгы яшь буын безнең хатларга күз салганда, нәрсә икән бу дип кызыксынырлык булсын, янәсе.

*Казан*
*12.05.1966 ел.*

«Кадерле» дип башланса да, Сәйфи, гадәт буенча бездә хатлар, ләкин син миңа кадерле генә түгел, бу сүздәге гадәти мәгънәдән бик күп мәртәбәләр киң һәм бөек минем сиңа юнәлгән тойгыларым, хисләрем.

«Кадерле» дигән сүз урынына башка сүз күңелдәге хисләрне тулысынча әйтерлек бүтән сүз эзләп карадым. Юк, табылмый, бары иң өлкән туганнар хәлендә син һәм Нәкый (Исәнбәт) күз алдына килеп басалар. Нәкый дигәннән, үткән көннәрнең «азмы какканын вә сукканын күтәргән «буын өчен» — «авыру җанның бишмәтен-тәнне дәваның төрлесе белән һәр көнне ямау...» (Тукай сүзләре — С. К.) кебек хәлләр артык искитәрлек нәрсә түгел, безнең ул бит гади вакыйга, Нәкый Шамов яткан шифаханәдә дәвалана. Мин дә Нәкый һәм синең кебек үк «бишмәтнең иртән тагын ертык» булмавына ышанган хәлдә больницага керәм. Моны шунда барырга чыгып китәр алдыннан язам. Доктор «апалар» һәм «сеңелләр» яхшылап, җентекләп җитди тикшерү үткәрү кирәк дип табалар. Мин анда күп булмам. Майның 20 ләрендә чыгармын дип уйлыйм. Малеевкага барасы бар иде, Рувим Моран белән русчага китап әзерлисе бар. Күңел тыныч дияргә була, тик борчылмый яшәргә мөмкин булмаган нәрсәләр аз түгел инде алар. Барыннан битәр безнең әдәбиятларның — татар-башкорт әдәбиятының кайбер күңелсез яклары, үзара тиргәштереп, гаугалаштырып яшәтергә теләгән кәсепчеләр карамагына эләккәләве рәвешендәге күңелсезлекләр шактый борчый мине. Төп мәсьәлә булмаган ваклыклар белән мавыгу заманы мени, суны болгатучыларга битараф булып калу заманымы хәзерге көннәребез... Харисның (профессор) Әхнәф Харисов) «мирас»ы Казанда да төрлечәрәк фикер тудырды. Каш төзәтәм дип, күз чагырырга юл куймау ягында мин, яман балалар сыман , мирас өчен ызгышмау ягында мин. Үткән ел без синең белән бер сүзгә килгән һәм Мостай әйткән мәсьәләне мин монда беркемгә дә әйткәнем юк әле. Мостайның монда чагында, ничектер, ул турыда сөйләшергә онытканмын. Киткәндә, аэропортта искә алган идем дә, аягүрә ашыгыч кына сөйләшүнең мәгънәсе булмады. Бу бик мөһим мәсьәлә һаман да шул урында тора бирә икән дигән фикергә килдем мин. Гомумән, Башкортстанда туып үскән татарларның башкортларга аерата якынлыклары турында бер әйбәт шигырь темасы үсеп килә минем йөрәктә. Менә шуны язасы килә. Вак-төяк кәсепчеләрнең, бизнесчыларның күзләренә бәреп төшерерлек шигырь язасым килә.

Өстәлеңдә, язуларың янында, менә шундый уйлар эчендә яшисең Ә баш күтәреп тышка күз салсаң, анда яз, табигать. Синең «кешенең» һәрбер төрле аһ-ваһларына исе китмичә генә үз эшен башкара. Дөньяны яшәртә, җирне яшеллекләр белән төрә... Тагын яз килде, Сәйфи, тагын килде. Табигатькә якынрак йөрергә кирәктер безгә, аңардан гыйбрәт алырга кирәктер, салкын канлырак булырга, борчылмаска өйрәтә бугай ул безне.

Мәгъфүрәнең, үзеңнең хәлләрең ничек? Бирешмәгез, туганнар. Бик күп, бик күп язларны, җәйләрне бергә каршылыйсы һәм кәгазьдә аларның гаҗәп гүзәл эзләрен калдырасы бар әле безнең.

Егетләргә — Рөстәмгә, Раилгә, Искәндәргә, кызларга — Сөембикәгә, Чулпанга, Наиләгә һәм барча нәниләргә һәм үзегезгә сагыну сәламе белән

*Хәсәнегез.*

P. S. «Кызыл таң»ыбызның Татарстандагы әдәбият дөньясы хәлләренә игътибар биреп житкермәве бераз гажәпләндерә мине. Нигә ул шундый «битараф» икән? «Башкортстанны» ничектер яздырмаганмын. Анарда июньгә кадәр нинди әдәби вакыйгалар, әсәрләр булганын белми яшәргә туры килде.

*Казан*
*3.03.1967 ел*

Безнең егетләр, Сәйфи, Уфадан шактый ук, алай гына да түгел, бик күтәренке күңел белән кайттылар. Уфа сәламнәрен, бигрәк тә синең сәламнәрне, сиңа аерата ихтирам итүләрен чагылдырган хәлдә тапшырдылар. Беренче карлыгач буларак Фатих килеп керде. Уфадан алып кайткан барлык тәэсирәтләрен — синең белән жыелышта, өеңдә һәм Мәргәндә (язучы һәм галим Кирәй Мәргән) очрашуларының гүзәллеген, шигъриятен түкми-чәчми сөйләп бирде. Фатихта да, Әмирханда да (язучы Әмирхан Еники) тормышның һәм аның күренешләренең шигъри якларын күрә ала торган күз бар. Аларның миңа бу сәфәрләре турында «хисап бирүләре» кызыклы хикәяләр булып тоелды. Фатих минем хатны «аманәт жан саклый» дип, барып житкәч тә тапшырырга булып, алып киткән иде, мин аңа синең телефонны бирергә онытканмын, ә ул юньсез, барып житү белән үзен биләп алган шигъриятка чумып, югалып калган, ләкин аны бәхилләргә кирәк, гадәте шулай аның. Моңа Уфадагы искиткеч шигъри, жылы, әдәби һава гаепле... Безнең Татарстан язучыларының иң матур бәйрәме Уфада татар-башкорт туганнарыбыз арасында, аларның ничектер бердәм, күтәренке, илһамлы һәм талантлы әдәби тормышлары, самими кунакчыллыклары эчендә үткәрелгән көннәргә кайтып кала. Без югалткан матур гадәтләребезне, гүзәл үзенчәлекләрне сездән өйрәнәбез, Сәйфи, аңлатырга тырышабыз. Ләкин бу тырышу сокланудан узмый. Кыскасы, без Башкортстаннан һәр баруда яңарып, яшәреп кайтабыз. Рәхмәт сезгә, башкортстанлы туганнарыбызга, чын күңелдән рәхмәт! Анда ашлык кибәксез булмый, билгеле, саф орлык арасында кибәкләр дә бардыр. Ләкин алар Уфаның асыл әдәби тормышында типик күренеш түгел. Асыл юнәлешкә очраклы рәвештә генә эләккән вирус кынадыр алар. Алдагы хатта искә алырга онытканмын, «Лит. газета»дагы Келәш турындагы очеркны сокланып укыган идем. Ул бик акыллы, талантлы очерк язган егетнең кем икәнен белми идем. Халык еш әйткәнчә икән: Арысланнан куй тумый! Миндә «егет бераз шаян бугай» дигән сыманрак уй бар иде. Шаян булса да, димәк, наян түгел. Безнең дә шаян чаклар булгандыр, ләкин еллар төзәтте бит. Сабыр төбе — сары алтын, дибез инде.

Әгәр дә, Сәйфи туган, Мәгъжанны, талантлы Мәгъжанны терелтә алсаң, ә син терелтә аласың, Казан халкының иң күпчелеген чиксез шатландырган вакыйга булыр иде ул. Мәрхүм Мәгъжан өчен әлбәгъсе бәгъдәлмәүет (үлгәннән соң терелү — С. К.) булыр иде. Исеңдәдер, Казахстанда булган чагыбызда, казахның яшь галимнәре бу мәсьәләгә чын күңелдән теләктәш булуларын белдергән иделәр. Аларның үзләренә жайсыздыр. Синең бу инициатива Әуэзовның Галимжан абыйны (Ибраһимов) һәм Жәлилне (Муса) тергезергә катнашуы кебек булыр иде. Заман сиңа саулыклар гына бирә күрсен! Бөтенлеккә «амин» диючеләр берничә генә түгел, берничә миллионнар бит алар. Мин Галимжан абыйның берәүгә бүләк иткән «Безнең көннәр»нең беренче басмасына — гарәп шрифтындагысына очрадым. Гарәп хәрефе гажәп рәхәт укыла, тагын бер кат укып, хәтерне яңарттым. Яңалифтә басылганы белән бусы арасында шактый аерма бар. Мине төп вакыйгаларның урыны-географиясе һәм прототипларның кемнәр булулары кызыксындыра. Мин аларны ачык белмим. Сиңа минем «Безнең көннәр» һ. б. буенча байтак сорауларым бар иде. Синең ярдәм кирәк иде. Тик аларны хәзергә калдырып торам: үзең килгәч, рәхәтләнеп сөйләшербез, серләшербез әле. Афзал (Шамов) миннән мартның 13 ндә музейда булачак утырышка Галимжан абыйны күреп белүчеләр киңәшмәсенә килергә вәгъдә алды. Сәйфи дә була ул утырышта диде ул. Сәламәтлек анарчы рәтләнер әле. Барам дидем. Син дә анда булгач, ничек бармый калыйм. Димәк, озакламый бездә булачаксың. Кил, Сәйфи, кил, үлеп сагындым. Күрәсе килә. Безнең әдәби тормышта күңелле яңалыклар, жиңешләр дә, шактый борчыган хәлләр дә бар. Бары турында да үзең килгәч сөйләшербез. Мостайны да, «Сау булыгызны» бик сагындым. Аның турында сорашасым, синең аша хәлен беләсем килә. Яңа елда Малеевкадан хатын алган идем дә, больницага китеп бардым, жавапны яза алмадым. Кичә Мәскәү «Ай

тотылганда»ны тапшырды. Тәрҗемәсе дә нәкъ оригиналы кебек. Вот это да! — диярлек әйбәт. Үзеңне котәбез, Сәйфи, үзеңне. Мәгъфүрәгә, егетләргә һәм кызларга иң җылы сәлам.

Киләсе көнеңне алдан белдерә алсаң, күңеллерәк булыр иде. ***Хәсәнең.***

Менә сиңа, Сәйфи, күптән вәгъдә иткән «Могикан». Укып кара әле. Бәлки киңәшләрең булыр (моны һәм башка шигырьләрне «Казан утлары»на, 70 елның беренче яки икенче саннарында бирергә уйлыйм). Димәк, әгәр кирәк булса, үзгәртүләр кертүгә вакыт бар әле бераз.

Икенче шигырьнең тере могикан турында исемен «Гомер эзләре буйлап» дип куюю яхшырак булыр кебек: синең «Яшьлек эзләре буйлап»ка бераз аваздаш булуы кызыклырак шикелле тоела. Бу шигырьдә асылда «тик рухыңны талап китәргә» һәм талап яшәргә маташучыларга шигъри җавап та, аларны шигъри инкарь итү дә истә тотылды. (Киңәшең булса, тартынып торма, тиз арада миңа хәбәр ит. Бу шигырь синең шигырь белән бергә 12 нче санга керә. «Казан утлары»на җибәргән шигырьләрне өйгә алып кайтып, күздән кичердем. Эчтәлекләре белән гүзәл лирик шигырьләр. Ритмик яктан кайбер үзгәрешләр, бик аз гына үзгәрешләр керттем. Шулай итү мәгънәләрнең, фикерләрнең, хисләреңнең ачыла төшүенә ярдәм итә. «Казан утлары»ннан алган төп нөсхәләрне үземдә калдырып редакциягә яңадан машинкада басылган нөсхәләрне бирдем. Урнашу тәртибе менә шулай булса яхшырак була бугай: «Көнләшәм», «Барыбыз да хәзер», «Җыр алып чыксаң иде», «Исемем хакында», «Әгәр дә», «Ни кылырсың?», «Тик яткырмас», «Тик шулай да», «Гөлләрнең дә телләре бар икән», «Агыйделдә», «Урман юлында», «Алып китә» һәм «Каләмем югалды», «Кызыл таңнан», «Килми алар»ны өстәдем.

Сиңа ике мәртәбә телефон тоташтырырга теләп карадым, ләкин автомат-телефон нигәдер тоташтыра алмады. Гомумән, сөйләшер сүзләр бик күп. Теге шигырьдән Акмулла һәм Җангилде турындагы һәм үзеңнең казах халкына мәгърифәт ярдәме күрсәтүең турындагы строфаларны гына сайлап алганда да әйбәт шигырь килеп чыга, теге сатлык җан «минем турыда бу», дип әйтә алмаслык шигырь була ала. Шулай итеп аны да бу шигырьләргә өстәргә дип уйлаган идем. Ләкин бу шактый четерекле, житди мәсьәлә булганга күрә, үзең белән киңәшмичә, аны гамәлгә ашыру ярамый, билгеле. Тәртибе болай: (һәр строфаның юлларын күрсәтәм. Шуннан кайсы строфалар икәнен чамаларсың.)

1. Ак теләкле Акмулланың эзләре...
2. Акмулланы абактыга (төрмәгә — С. К.) салдырган...
3. Алматаның (бу сүзне Казахстанга хас булган башка исем белән алмаштырырга кирәктер) Ак атаның тулпарларын аксаткан...
4. Бик күпләрнең учакларын сүндергән...
5. Кичәр еллар кичүләрдән кичтеләр...
6. Булса да ул күпме генә мәкерле...
7. Бу законны саклый торган закон бар...*
8. Ике башлы бөркет җәеп канатын...**
9. Сары аркадан (дала — С. К.) гарәсәтләр (давыллар мәгънәсендә — С. К.) узганда...
10. Бу буранда күпме ирләр адашкан...
11. Кичәр еллар кичүләрдән кичтеләр...

(бу строфаны тагын бер кабатлап, шигырьне тәмамлаттырырга мөмкин). Шул рәвештә генә матбугатка чыкса да, Казахстанда моның нинди шигырь икәнен аңларлар иде. (Бу шигырьнең тулы хәлендәгесен алар беләләр иде бит инде.) Бәлки ашыкмаска, сабыр итәргә кирәктер.

Мостайның бәйрәме кайчанрак була? Син үзең юбилеяңа каршы булсаң да, хөкүмәт һәм партия барыбер юбилей ясамау белән килешмәс. Бу турыда яз. Безгә алдан белеп тору кирәк.

Балалар һәм икегезгә дә сәлам белән ***Хәсән.***

*Аккош. 25.9.69.*

---

* Бу строфаның ахыргы юлын «үзгәртә алмый барыбер сатлыклар» дип («Сабитлар»ны алмаштырып) алырга була.

** Бу строфадан шигырь үзең турындагы сүзләргә күчә.

*6.11.69.*
*Казан*

Бүген бәйрәм киче, Сәйфи. Ләкин тиздән Уфада синең белән күрешү — минем иң кадерле бәйрәмем булыр кебек тоела. Күңел үзенең шундый хисләрен шигырь итеп әйтергә тели:

Бу дөнья шундый бәйрәмгә
Даталар бирә торсын:
Бердәнбер бәйрәм түгел ул,
Меңнән бер бәйрәм булсын!

Димәк, фәрештәләрнең «амин» дигән чакларына туры килә күрсен. Сине бу «Язучы трагедиясе турында»гы гыйльми әсәрең дә диссертация булып чыккан, Сәйфи. Алгач та төн буе утырып, туктала-туктала, уйлана-уйлана укып, яратып укып чыктым.

Дәлилләрең шул кадәр көчле ки, алар янында гүя Ленин үзе басып тора. Гомумән, безнең әдәбиятлар, өчен, совет илендәге байтак халыкларның әдәби мәйданнары өчен таяныч, терәк, аргумент булган (һәм булачак) фактларга нигезләнеп иҗат иткәнсең. Моның өчен һәрбер әдәбият рәхмәт әйтергә тиеш сиңа, Сәйфи.

Гомәр бу хезмәтеңне укыганчы ук, хатларың аша чамалап та: «Кайбер урыннарын җаен табып безнең «Казан утлары»нда да биреп булмасмы икән»,— дигән иде. Үзем укып чыккач та, Гомәргә (больницага) илттем. Телефон аша сөйләшкән идек, укыган, ул да шулай ук иҗади фикердә, аерата сөйләшергә булдык. Иртәгә аның янына барам. Аның тәэсиратләрен күңелгә салып, сиңа алып барачакмын.

Үзебездәге әдәбият мәйданы вакыйгаларын язып тормыйм: баргач телдән сөйләрмен. Гомумән, хәлебез, ягъни Язучылар союзының хәле борчылмаслык түгел. Димәк, әгәр борчылабыз икән, тыныч түгелбез икән, бу да яман хәл түгел: тыныч булырлык, борчылмаслык чаралар күрергә сәбәп булыр. Синең белән тагын элекке очрашулардагы кебек үк сайрашырбыздыр дип уйлыйм. Ләкин Мәгъфүрә больницададыр бит әле, ул да өйдә булса, табын түгәрәк булыр иде.

Синең киңәшләреңне барын да исәпкә алып, «Могикан»ны яңадан редакцияләп чыктым. «Гөнаһсызрак» хәлгә килә язды бугай. Мостаебыз бәйрәменә дип бер шигырь язган идем. Укып карадым да, бер шигырьдән ике шигырь килеп чыкты:

...Менә шундый монсу көннәремдә
Казаннарга килеп чыгасың да,
Аккош күлендәге ак каенга
Пегасыңны бәйләп куясың да,
Тик күршедән кергән кебек кенә
Торагыма килеп керәсең...
Сагынуларым, димәк, сиңа, Мостай,
Барып житә, житә күрәсең.—

рәвешендәге лирик өлешен

Син россиян, импорт исемнәргә
Мохтаҗ түгел синең осталык —

рәвешендәге фикерләрдән аерып, ике шигырь төзедем. Казанга Нәҗибәк (Хафизов) килеп чыккан иде. Берсен «Кызыл таң»га, икенчесен «Башкортстан»га дип, аңа биреп җибәрдем. Гомәрнең дә барырга нияте бар иде. (Аңа да чакыру килде), ләкин бара алмый: врачлар шактый тырышсалар да, төзәтеп җиткерә алмадылар, ремонтлары озаккарак сузылды. Сибгат тә юллама алып куйган булган икән, Ессентукига «ремонтка» китеп барды. Бүген бездә көн аяз, әлегәчә Казанны атна буена болытлар томалап торды, самолетлар йөрмәде. Шуны искә алып, Ахун (Г. Ахунов — язучы) белән без поездда барабыз дип тора идек. Һәрхәлдә, 13 нче ноябрьдә, сиңа, Уфа телефонында «Әссәламәгаләйкем»не әйтеп, өенә йөгерермен дип өметләнеп торам.

Мәгъфүрәгә, балаларга минем сагыну сәламнәремне тапшыра тор. Һаман шулай, һәрвакыттагыча, янып яшәрлек саулык, тереклек теләп

***Хәсән.***

P. S. Иптәш Кунаевка адресланган хатыңны үзем белән алып барам. Киңәшербез әле: безнең кайбер акыллы, төпле яшьләргә укытасы иде аны.

*16.1.70.*
*Казан*

Кадерлебез Сәйфи!

Гасырыбызның җитмешенче елларына да, җиденче уннарына да килеп кердек. Бу унны иҗади тынгысызлар хәлдә бергәләшеп, яңгырап яшәп сигезенче унына керергә насыйп булсын!

«Казан утлары»ның 12 нче санын күргәнсеңдер инде. Яшьләр-шагыйрьләр тирән ихтирам белән яратып, сокланып укыйлар сине. Шигырьләр «Саумысыз, дим, әй киләчәк яшьләр!» рәвешендә үзләренә эндәшү белән башланып китүе, олы шагыйрьнең кечеләргә яхшы теләктә булуы — игътибар итүе аларны да дулкынландыра, билгеле. Сиңа язган идем дә. Аларны үзем белән Уфага алып барган идем. Ләкин туйганчы күрешеп, сөйләшә алмадык. Якында иркенләп күрешергә насыйп булсын. Уфага барып җиткәч, иртәдә үк синең яныңа алып баруларын үтенгән идем. Ләкин яшьләр, сине өзлектермәүне искә алып булса кирәк, баруны, синең белән күрешүне, яныңа кереп чыгу белән генә чикләделәр. Хәлеңне сорашып торам. Инде шаять шифаханәдән чыккансыңдыр. Сине дә, Мәгъфүрәне дә өегездә гөрләшеп яшәгәнегез хәлендә күрәсем килә минем.

Менә Исәнбәтнең дә бәйрәме үтеп китте. Үзе анда, Уфада... Бу хәл шактый уйландыра торган мәсьәлә. Очрашканда сөйләшүләргә калсын. Уфадан кайткач, Аккошка барып бикләндем дә җыентыкны тәмамладым һәм Татнәшергә тапшырдым. Ләкин бу гомеремдә бер тулырак күләмдә чыгарга тиешле китапны тынычландырганым юк: өстәү һәм кыскарту (кайбер шигырьләрне төшереп калдыру) рәвешендәге эшләрдән тыела алганым юк.

Февральдә Гомәр белән Малеевкага барырга җыенабыз. Шунда гына тынычлык табар ахыр бу җыентык.

Күрәсе килә, күрәсе, үзеңне күрәсе килә, Сәйфи.

Хат-диссертация турындагы үтенечеңне Гыйлемдар (Рамазанов) әйткән иде миңа. Ул турыда тыныч бул.

12 нче санда Бубилар турындагы мәкаләне күздән кичергәнсеңдер. Яшьләребез арасында әнә шундый зирәк галимнәребез бар. Казахстаннан (Исәнбәт бәйрәменә) Нортазин (галим — С. К.) килгән иде. Ул Мәгҗанны танучыларның берсе, акыллысы, төплесе икән. Кустанайда Майлин бәйрәмендә синең белән бергә булуларыбызны сагынып искә алдык.

Исән була күр, сау була күр, Сәйфи. Синең күпне күргән, кичергән йөрәкнең ныклыгына инанабыз без.

Үзеңә, Мәгъфүрәгә һәм балаларга самими сәламнәр белән ***Хәсәнегез.***

*28.2.70.*
*Малеевка*

Синең һәр хатың, Сәйфи, Тукай һәм Галимҗан абыйлар кебек гүзәл гамь эчендә яшәүеңне, безнең чорның, безнең әдәби-иҗтимагый тормышның тынгысыз кыңгыравы хәлендә гомер итүеңне хәтерләтә. Бу хатың да шундый.

Олы буынның бер өлешен шәхес культы гарасаты тезәлә, терелә алмаслык итеп имгәтеп үткән. Аларның иң кадерле идеалы — иң хәерсез обывательлек булып калган. Имансыз бәндәгә әверелгәннәр. Аларның җанына «денем өчен түгел, көнем өчен» дигән гамьсезлек шайтаны оялаган, күрәсең. Ләкин андыйларның бу халәте, имансызлыгы, Тукай әйтмешли, «коеп куйган» гына түгел, ә тоеп туган яшьләрдә реакция, яхшы мәгънәдәге реакция тудыра. Яшь галимнәр алардан йөз чөерәләр, имансызларны «көнә» өчен генә яшәргә юнәлгәннәрне алмаштырырга әзерләнәләр. Мондый яшьләрнең хәле җиңел түгел, әмма авырлыклар аларны чыныктырган гына. Имансызларның да һәм Генрих Гейнечә әйткәндә, аларга кәфен тукучыларның да исемнәрен әйтеп үтүнең кирәге юк. Син аларны күрәсең, беләсең. Без бу язда синең белән, әлбәттә, күрешәчәкбез бит. Фатих абый Кәримов турындагы борчылуларын һәм гамьсезләр турындагы борчулы кайнар сүзләрең бездә менә шундый кичерешләр тудыра. Без сине аңлыйбыз, Сәйфи: Әгәр дә син гүзәл гамьнәр накалыннан «азат» булсаң, яши дә алмас идең.

Пушкин «Яшәсен кояш, яшәсен акыл!» дисә, безнең «Яшәсен гүзәл гамь! Яшәсен гүзәл тынычлык!» диясе килә.

Алтайларның шалтай-балтайлары да ленинчыларда нәфрәт тудырырга тиеш. Егылганны — шифаханәдә яту хәлендә булганны кыйнау — гаҗәп оятсыз әдәпсезлек. Этикасызлык бит. Коммунистларның, чын ленинчыларның бу хәлне күрмәүләре гаҗәпләндерә.

Син монда, Малеевкада, 49 нчы елдан бирле булганың юк икән. 21 ел диган сүз бит ул. Минем хәл дә шулай. 1931 елда Муса Җәлил белән бергә ял итә-итә язып яткан идек. Уйлап карасаң, ана 40 ел инде. Гомәр белән съездга кадәр монда калырга уйлаган идек, урын да бар, алмадылар, Переделкинога күчерәләр. 5 нче мартта шунда китәбез. (Димәк, адресыбыз 22 нче мартка кадәр Переделкинода.)

Табигатьнең барлык күренешендә, кояшында, һавасында, урманнарында, сукмакларында ниндидер якты, җылы елмаю барлыгы сизелә, табигать зур хәрәкәт башлануны, уяну, терелү көннәрен көтә. Синә да бу нәкъ шундый хәлне алып килсен. Мәгъфүрә, тор инде, тор. Әкренләп йөри башла. Йоматаудагы бөреләр, кар астындагы чәчәк бөреләре — кар киткәч тә килер дип сине сагынып көтеп яталардыр. Безнең сезгә чәй эчәргә дә барасы бар бит әле. Тор әйдә, Мәгъфүрә, күтәрел, күтәрел.

Дачадагы Раилгә дә, башка балаларга да, үзегезгә дә сагыну сәламнәре белән

*Хәсәнегез.*

P. S. Гомәрдән дә сәлам: «Син — яза тор. 2—3 көннән мин дә хат язармын»,— диде ул.



**Рәсемдә** *(сулдан уңга)*: Сибгат Хәким, Сәйфи Кудаш, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан һәм Әмирхан Еники. *1964 ел.*

*29.3.70. Мәскәү, гост. Россия.*

Кадерлебез Сәйфи!

Съезд дигән тамашабыз да үтеп китте менә. Барлык ваклыклары һәм «эре»ләре алдан билгеләнеп куелган рәвештә формаль хәлдә узды. Съездның иң күңелле ягы бер-береңне күрү, фикер алышу, аралашу булыр дип уйлаган идем. Ул да булмады. Бу шәһәр кебек олы гостиницаның төрле катларына таралабыз, эзләп таба алмаслык ерак ителеп таралыштык. (Шулай урнаштырдылар.) Телефоннар аша гына аз-маз сөйләшкәләдек. Рәхәтләнеп кара-каршы утырып фикер алышулар булмады. Ыгы-зыгыга күмелеп яшәдек. Безнең ише олы яшьтәгеләр өчен съездларга йөрүнең кирәге юк дигән фикергә килдем. Безнең кордашлар моны күптән төшенгән булганнар күрәсең: Мәскәүдә генә яшәгәннәр дә съездга бөтенләй йөрмәделәр. Безнең өчен һәм гомуми чын язучы өчен иң мөһим, бердәнбер мөһим нәрсә иҗат, фәкать иҗат итеп яшәү дигән иман тагын да ныгый төште.

Безнең быелгы беренче «съезд» синең дачаңда булыр дип язны щатланып көтәм: өчәүләп (Гомәр, син һәм мин) сөйләшеп утырулар съездларга караганда күбрәк нәрсә бирәчәк безгә.

Миңа юлга чыгарга ун минут калды.

Икегезгә сәлам белән *Хәсәнегез.*

*17.I.1965. Уфа.*

Хәсән туган!

Менә син кайтып киткәнгә инде әллә ничә айлар үтеп бара да кебек тоела һәм сагындыра да башлады. Әгәр дә сине озатып җибәргәч мин өйгә ялгызым гына кайткан булсам, бик-бик юксынган һәм ятимсенгән дә булыр идем әле. Ләкин ул алай ук булмады. Мостай мине озатып куйды. Өйгә кереп Мәгъфүрә, Мостай һәм мин өчәүләп, бик шәп итеп, иртәнге чәйне эчтек. Шулкадәр самим һәм туганнарча сөйләшә торгач без, хәтта төшке ашның җиткәнен дә сизми калдык. Бер заман Мәгъфүрә чәй табынын җыеп аш табыны хәзерли башлагач кына белдек без бу хәлне. Ашны бик иркенләп, озак итеп ашаганбыздыр инде ахрысы. Мостайның аштан соң ятып алу гадәте бар икән. Ул йоклап торгач тагын да чәй эчәргә утырдык. Менә шул вакыт аны эзләп безгә Рауза килеп керде. Менә шул минутта без үзебезнең гафиллегебезне аңладык. Без әллә кайчан ук Раузаны чакырып алырга тиеш булганбыз икән шул. Ләкин, чынын әйтим, монда гаеп бездә түгел. Монда Мостай үзе гаепле. Чөнки аш ашап утырган чакта Рауза безгә шылтыратты. Мостай иртәнге чәйгә кайтмагач, ул аны эзләп төрле җиргә шылтыраткан икән. Сезне аэровокзалга илтеп куйган М. У. Гәрәев аңа: «алар Сәйфи ага белән кайтып киттеләр» дигәч, Рауза аны бездән тапкан иде һәм: «мине югалтма, мин озакламый кайтам» дип тынычландырган иде. Күрәсең, ул озаклап калган. Шуңа күрә тегесе тынычлана алмагандыр инде. Без бит әнә шул карчыкларыбызны һәрвакыт булмаса да, борчылырга мәҗбүр иткәлибез, туган. Әгәр дә без үзебез әз генә булса да, алданрак борчылган чакта, карчыкларыбызга алай тынычсызланырга да туры килмәс иде. Ләкин аны без эш үткәч кенә төшенәбез шул. Мостай иртәгесен Мәскәүгә китте. Ул инде анда озаграк булачак. Мин аны бик нык сагыначакмын. Чөнки ул минем иң ихлас һәм иң самим сөйләшә торган дусларымның берсе. Элек мин Хәбибулла мәрхүм Ибраһимов белән шулай сөйләшә идем. Хәзер Мостай белән. Сине озаткан көнне мин нишләптер тагын да салкын алдырганмын. Шуннан соң тагы да көненә әллә ничә тапкыр аспирин эчереп йөдәтте мине Мәгъфүрә. Әгәр дә ул булмаса, мин бер генә даруны төгәл эчә алмас идем.

Менә шул ятыштан өйдә ятып мин кичә генә башлап һавага чыктым. Башлап иртә белән чыгып репетиция ясадым. Ә кичкә инде үзәк китапханәгә, Шәехзадә Бабичның 70 еллыгына багышланган кичәгә бардым. Кичә ярыйсы гына үтте. Ә. Харисов кайткан икән, җыелыш белән ул җитәкчелек итәргә мәҗбүр булды. Чөнки Союз җитәкчеләреннән беркем дә вакытында килмәде. Назар Нәҗми ярты сәгать соңлап, җыелыш башлангач кына килде. Вакыт үтеп баргач, башлап җибәрергә мәҗбүр булдык. Баязит эчеп килгән, якын барып булмый, аракы исе аңкып тора иде. Сәгыйть белән Баязит берничә яшь язучыны ияртеп эчеп йөргәннәр һәм Сәгыйть — Баязитның әйткәнен язам, сәрхуш булып егылып калган икән. Менә без икебез дә карт кешеләр. Син дә, мин дә, хәзер алласызлар. Ә элек кешеләр мәчеткә исереп баралар идеме? Мин үз гомеремдә андый хәлне күрмәдем. Хәзерге театрлар, сәнгать сарайлары, китапханәләр безнең хәзерге иң саф, иң изге һәм хөрмәтле мәчетләребез. Мин бу урыннарга кешеләрнең исереп — сәрхуш булып килүләрен башыма сыйдыра алмыйм. Җитмәсә тагын Шәехзадә Бабич кебек шигырь пәйгамбәре булган бик аек бер шагыйрьнең хөрмәтле кичәсенә эчеп килүне намусым да, вөҗданым да кабул итми. Җитмәсә тагы үзеннең исереклеген кебек, яшь язучыларны да шундый түбән дәрәҗәгә төшереп тәрбияләр һәм аларга шунда әшәке үрнәк булуны мин, Бабич алдында да, совет җәмәгатьчелеге алдында да зур гөнаһ бер эш иттереп карыйм. Бу бер.

Икенче — кемнең доклад сөйләячәген һәм кемнәрнең истәлекләр сөйләячәкләрен мин китапханәгә баргач кына белдем. Бу хакта инде китапханә җитәкчеләре, әлбәттә Союз белән сөйләшкән булгандыр инде, алдан чара күргәндер, дип уйлыйм. Докладны университетта татар әдәбияты укытучысы Вазыйх Исхаков дигән кеше сөйләде. Ул акыллы гына, җитди генә бер егет. Ул үзенең докладында, әлбәттә, элек матбугатта игълан ителгән материалларга таянып, Бабичның казакъ шагыйре Абай тәрҗемәләре аркылы Пушкин һәм Лермонтовларны белүен әйтте. Бу, әлбәттә, дөрес. 15 яшьлек Бабич, әлбәттә, Пушкиннарны Тукай һәм Абайларның тәрҗемәләре аша гына белгән әле ул чакта (1910—1911 елларда). Ул Пушкин һәм башкалар турында, әлбәттә, «Галия»нең соңгы елларында гына, бигрәк тә анда Галимҗан Ибраһимов әдәбият укыта башлаган елларда гына яхшылап белә башлагандыр.

Докладчы соңгы сүзләрен әйтү белән үк, кызмача Баязит сикереп торды да Исхаковка отпор бирде. Менә Баязитнең шул звоногы, үзе белән эчеп йөргән яшь шагыйрьләргә бик тиз барып җитте. Шунда ук президиумга: «нишләп сез баш-

корт шагыйре турында татардан һәм татар телендә доклад ясатасыз?» дигән анонимка килде.

Әлбәттә, доклад башкорт телендә булса яхшырак булыр һәм милләтче элементларда укалар кузгатмауга да яхшы булган булыр иде. Исхаковның мәкаләләре башкорт телендә була. Хәтта Бабич турындагы хикәяләре дә башкорт телендә иде. Шулай булгач инде мин аның докладны да башкорт телендәдер дип уйлаган идем. Истәлек сөйләүчеләрдән элекке «Галия» шәкертләре Касыйм Гыйрфанов белән Мәгъдән Мәһдиевләр дә татарча сөйләделәр. Тик мин генә башкортча сөйләдем. Харисов башкортча ачты һәм алып барды. Гомумән кичә һәйбәт булды. Истәлекләр бик матур булдылар.

Тик менә шул югарыда әйтелгән хәлләр кичәгә һәм минем күңелемә күләгә төшерделәр. Чынын әйткән чакта Бабич бит гомер буе татарча язган бер шагыйрь. Хәтта ул бит әле башкорт милләтчеләре оясына барып кергәч, чеп-чи милләтчелек рухында һәм татарга дошманлык рухында язган шигырьләрен дә татар телендә язды. Аның соңгы китабы гына башкорт телендә басылган. Сәгыйть Агишның әйткәне чын булса, аны татарчадан башкортчага тәрҗемә итеп чыгарганнар икән. Ләкин мин аңа ышанмыйм. Башта ук ул Бабичның үзе тарафыннан шулай башкортча язылгандыр. Чөнки 1918 елның урталарында (июльдә) Чиләбе шәһәрендә чыга торган «Башкорт» гәзитәсендә Бабичның ураза бәйрәме уңае белән башкорт телендә басылган бер шигыре бар.

Менә син киткәннән бирле өйдә яткан бер кешенең беренче мәртәбә һавага чыккач алып кайткан тәэссоратлары шулар. Әхнәф Харисов белән кичә Урманче турында сөйләштек һәм иртәгә обкомга керергә сүз куештык. Анда кереп сөйләшү белән үк, нәтиҗәсен якын дус Урманчега язармын. Күрсәң шулай әйт. Телефоны булса шалтыратып сәламемне тапшыр.

Мәгъфүрәдән дә, үземнән дә туганлык сәламнәре белән:

***Сәйфи.***

Гомәргә, Фатихка, Габдрахманга сәлам әйт.

*26.VI.1965. Йоматау.*

Кадерле Хәсән туган!

Фрунзега — Туктагол Сатылганов юбилеенә китәр алдыннан язган хатыңны алган идем һәм сиңа күңелле һәм илһамлы сәфәр теләп калган идем инде.

Өченче көн врачка күренер өчен Уфага кайткан идем. Көтмәгәндә Әсгать Мирзаһитовны күрдем. Ул безгә килеп Кыргызстан хәбәрләрен сөйләп, алып кайткан күчтәнәчләрен тапшырып китте. Менә шул, мин, хатыңда язган планыңа карап: «Хәсән Фрунзеда калгандыр әле, чөнки Кыргызстанны күбрәк күрергә һәм белергә теләге бар иде аның», дигәч ул:

— Юк, бергә кайттык, ул хәзер Казанда,— дип болай кайтуның сәбәпләрен сөйләп алып китте. Булмаса, бу хатны мин сиңа июль башларындарак язармын дип тора идем әле.

Шуның өстенә кичә «Йолдыз» журналының (казакча) редакторы акын Сырбай Мауленовтан хат алдым. Ул Бәембәт Майлинның юбилее 5—10 июльләрдә Кустанайда булачагы турында хәбәр итә һәм безне дә чакырачакларын белдерә. Менә шул турыда да эшкәртеп куйыйм дидем үзенә. Кәефем начар түгел. Әгәр дә чакыра калсалар (хәтта чакырмасалар да) тәвәккәлләп барырга исәплләп торам. Чөнки моннан соң саулыкның һәм мөмкинлекләрнең ничек булачагын, алдан белеп булмый бит, туган. Мин гадәттә, гомер буена, зур өметләнеп, эшләрнең ал да гөл булуын алдан көтеп яшәргә өйрәнмәдем. Гадәттә эшләрнең күләгәле якларын элек уйлыйм. Шунлыктан, миңа килгән шатлыклар һәм бәхетләр көтелмәгәндә килеп чыккан кебек булалар. Шуңа күрә дә мин алар белән шашмыйм да, исермим дә. Хәзерге яшьтә һәм саулык белән шулай эшли һәм яши алгач зур бәхеткә саныйм. Бүген Мәгъфүрә белән дә шул хакта сөйләшеп алдык.

Әгәр дә бара алсам һәм бара калсам, Кустанайга инде синең белән икәүләшеп барырга, дип, бик нык ышанып торам. Чөнки минем өчен, Кустанайга барып, тагын да бер кабат яшьлек эзләре буенча атлап үтүгә, моннан да уңайлы очраклылык йә булыр да, йә юк.

Шуның өстенә безгә язмышы белән дә, иҗаты белән дә Бәембәт Майлиннан да якын кеше юк анда. Без бит ул оядан канат кагып, киләчәккә карап очкан һәм максатларга карый атлаган «туышкан»нарбыз.

Әгәр дә, ризык булып, Кустанайга бара калсак, жулдастар белән очрашкач та, үзебезнең теләкләребезне әйтеп куярбыз. Әгәр дә Сабит Муканов Кустанайга килә калса, аның белән бергә йөрербез. Чөнки ул үзе Кустанай тирәсендә йөрергә

теләге барлыгын язган иде. Ул мотлакан килер. Чөнки ул бит Бәембәт туенын комиссия председателе.

Бәембәтнең ике шәриге, ике кордашы һәм табакташы катнашу — аның тантанасы өчен бик-бик күңелле хәл булачак. Аннан соң Бәембәтнең карчыгы Гөлҗамалга да килергә вәгъдә биргән идем. Анда баргач нәрсә сөйләү һәм Бәембәтне ничек сагыну турында әйтәчәк нәрсәләр хакында очрашкач сөйләшербез.

Мостай белән Нажар минем дача күршеләрем булачаклар. Мостайга казык кактык инде.

Башка хәлләр, хәбәрләр һәм язарга теләгән нәрсәләр турында икенче хатларда язармын. Очрашкач сөйләнер. Теге милләтче карт татар работникларына яла ягып, тагы да әшәке рәвештә ЦК га хат язган. Күргәч сөйләрмен.

«Татар совет әдәбияты» рус телендә чыккан икән. Укып ятам. Гарәп классик әдәбияты турында бик кызыклы бер әсәр укыдым инде. «Русские поэты» дүрт томлыгының беренче томы килде. Шуны укый башладым. Ярый, хәзергә хуш. Гомәргә, Сибгаткә, Әпсәләмгә һәм Афзалга сәлам әйт. Икебездән сәлам белән, сагынып: ***Сәйфи.***

Кустанайга бару турында фикереңне көтәм.

Син яраткан ике чәчәк җибәрдем.

*25.VIII.1965. Уфа.*

Хәсән!

Мин инде син кайтып китү белән үк бер хат язган идем, алгансыңдыр. Үзем соңгы көннәрдә, һичбер көтмәгәндә, ангина һәм радикулит белән берьюлы җәфаланып яттым. Чөнки өзлексез яңгырлар үзәккә үтteләр.

Бер мәртәбә врачка килеп киткән идем инде, бүген менә Мәгъфүрә белән тагын да килеп җиттек. Әле менә врачым сәгать 2 дә генә кабул итә икән. Шул араны файдаланып, кайбер дусларга кыска гына булса да хат язарга утырдым.

Уфада артык хәбәрләр юк. Гафури көннәрен үткәреп җибәрдек. Мостай дача эшләре белән йөргән чакта дачага кереп хәл белеп чыкты. Мин түшәктә ята идем һәм сөйләшергә тамагым да бик авырта иде.

Бу арада авырудан башка бернәрсә дә эшләмәдем. Тютчевнең ике томын яңадан бер укып чыктым икән, шул.

Менә берничә фото җибәрәм. Искәндәр дә Кустанайда төшергән кайбер рәсемнәрне җибәрергә җыена. Өйрәнчек нәрсәләр генә инде, әлбәттә. Нишләтәсең, кулыннан килгәне шулкадәр генә булгач.

Синең үрмәле гөлләрең үсәләр. Аларны көзгә яки язга үзеңә бүләк итеп бирербез инде.

Агишның, миңа бик ачуланып, сүгеп йөрүен сөйләделәр.

— Туфан белән дус идек, Сәйфи Кудаш араны бозды,— дип әйтә, ди.

Белмим, без синең белән беркемнең дә гайбәтен сөйләмәдек. Агиш турында да сүз булмады. Чөнки үзең Уфага килгәч тә: «беркем белән дә очрашырга теләмим, мин килгәнне беркемгә дә әйтмәгез» дип Мостайга искәртү ясагач, мин беркем белән дә очрашу мәҗлесләрен ясамадым шул. Әгәр дә ул чын дуслык дигән нәрсә була икән, аны шайтан да, иблис тә бозарга мөмкин түгел бит. Шуңа күрә дә мин моңа Агишның гадәттәге бер ваклыгы, дип кенә карадым. Балигъ булыр өчен яшьнең 60 ка җитүе шарт булмый икән шул туганкай, диюдән башка нәрсә әйтә алмыйм.

Казанда нинди яңалыклар бар? Поэзия турында нинди әңгәмәгә хәзерләнәсез?

Мәгъфүрә сәлам язарга куша.

Гомәргә сәлам әйт.

Булмаса, көзгә Гомәр белән килеп китегез. Рәхәтләнеп, бер чеңгелдәшеп утырыр идек. Хәзергә шул. Күрәсең, хат болай гына языла.

Сагынып: ***Сәйфи.***

*12.XI.1965.*
*Уфа.*

Хәсән!

Синең авыруың турындагы хәбәр йөрәккә кереп утырды да, нәкъ, кечкенә генә, ләкин бик үткер тешле кара тычкан кебек, бертуктаусыз кытырдатып кыра да тора.

Әгәр дә син бер нәрсәне, бер хәлне, бер вакыйганы, ничек булганын ачык белмәсәң, ул сиңа тынычлык та, тынгылык та бирми, борчый да тора. Син, үз хыялың белән ул эшне үзеңчә фараз итәсең, үзенчә аны әллә нинди кыяфәтләргә кереп бетәсең. Менә синең авыруынны белгәннән бирле миңа яңа бер авыру өстәлде. Әнә шул авыру минем йөрәгемне һәрвакыт чеметеп, тырнап һәм әрнетеп кенә тора. Мин синең белән бергә авырыйм.

Мөнҗиянең әйтүенә караганда син хәзер өйдә булырга тиешсең. Шулаймы икән? Өйдә ятасыңмы икән? Өйдә син дәвалану тәртипләрен бозып, авыруны көчәйтә торган нәрсәләр эшләмисеңме? Күз белән шаярырга ярамый. Мин аның белән җәфаланган кеше түгел. Ләкин карамыйча, күрмичә һәм үз кулларың белән гәзитә һәм китап тотып укымыйча тору, әлбәттә, бик-бик авырдыр инде ул. Мин аны күз алдына китерәм дә, тоям да. Ләкин нишлисең бит, шундый хәл килеп туган һәм факт хәленә әйләнгән икән, аны җиңәргә, төзәтергә кирәк. Моның өчен үзеңне күп нәрсәләрдән вакытлыча мәхрүм итәргә дә мәҗбүр буласың. Менә да түзәргә һәм киләчәк өчен, чыдарга кирәк. Бигрәк тә дәвалануга зарарлы нәрсәләрдән саклана күр инде, туганкай. Врачларны тыңла һәм балаланма. Авыруны җиңәр өчен үзеңне дә кызганмаска кирәк. Вакытлы мәхрүмлекләрне җиңәргә көчең җитсә, авыруны җиңәсең, минемчә. Син бик зур бәхетсезлекләр вакытында үзеңне тота белгән кеше бит. Бу очракта да егет булып калырсың, дип ышанам.

Без шулай яшәп ятабыз. Авыргалап та алабыз. Тагын да торып китәбез. Көндәлек эшләрдән бушап булмый. Дачага барып кайтабыз. Укыйм. Хатлар язам.

Кустанайдан хатлар алам. Ике көнлесез хат килде. Теге, безне кунакка килеп алган элекке шәкертем Куйжыгул Туктауловның улы вафат булган. Соңра минем «Яшьлек эзләре буйлап» та исемсез генә язылган бер яшь акын бар иде. Шул фаҗигале рәвештә үлгән. Хатыныннан хат алдым. Яңа елдан Кустанайда казакъ теленда гәзитә чыга башлый. Теге облисполком секретаре Сәет Абдибиков яза.

Алма-Атада минем китабымны казакчага аударып беткәннәр һәм производствога тапшырганнар. Татарчасыннан да, башкортчасыннан да яхшырак-тулырак итеп чыгарабыз, дип язалар. Гөлсем ханымнан хат алдым. Аның Галимҗан абзый турындагы истәлеген «Дружба народов» журналында кабул иткәннәр. Ләкин Галимҗанның Тукайга карашы һәм яңалифкә карашы турында өстәп язарга кушып, үзенә кире кайтарганнар.

Үземнең Бабич турындагы истәлекләрне документаль хикәя итеп кабул итүләрен һәм яратуларын язган идем. Хәзер аны калган материаллар белән тулыландырып, аерым китап хәлендә чыгарыр өчен Казанга җибәрмәкче булып торам.

Уфа хәбәрләрен күп белмим. Мостай Италиядә йөреп кайтты. Килеп утырырга вәгъдә иткән иде. Һаман килеп чыкмый әле.

Икенче томны тапшырдым. Әгәр дә җәй көне булса, яшьлек эзләре буйлап тагы да Кустанайга китәр һәм «Тургай даласында» дигән китабымны язар идем. Чөнки эзләгән кешеләрнең адресларын таптым. Хәзер анда барасы гына калды инде.

Без сиңа, Бәхти Гайсинның синең сүзләреңә язган җырын җырлый-җырлый телеграмма да җибәргән идек, алгансыңдыр инде. Әле дә менә Фәридә радиода җырлый. Мин аны тыңлый-тыңлый хат язып утырам. Хәзергә менә шул. Мәгъфүрәдән дә, үземнән дә барчагызга да сагынычлы сәлам белән кочаклап: ***Сәйфи.***

Чынлап дәвалан һәм саклан!

*28/XII.1965.*

Хәсән!

Бүген менә бер китап җибәрәм. Аны син мотлакан укып чык. Үкенмәссең. Бүген Гомәрдән хат алдым. Ул синең күзләреңнең элеккегә караганда да яхшырак күрә башлавын язып бик шатландырды. Ләкин кара, күзем һәйбәтләнеп китте, дип күзне сукырайта торган нәрсәләргә бик төбәлеп карама һәм андый нәрсәләрдән тыел.

Безнең шигырь бәйрәме бик яхшы үтте. Күпчелектә яхшы шигырьләр яңгырады. Шуның белән бергә артта калган тыңлаучыларның зәвыкына карабрак сөйләнгән нәрсәләр һәм сөйләгән кешеләр дә булгалады. Үзенә сер итеп кенә әйтим, без ике китап хәзерләп ятабыз. 1) «Тукай Башкортстанда» дип атала. Ул Тукай турындагы мәкаләләрдән, шигырьләрдән һәм башка нәрсәләрдән тора. Юбилей көненә чыгарачакбыз. 2) «Г. Ибраһимов Башкортстанда» булачак. Аны да шулай ук 1967 елда Галимҗан абзыйның юбилеенә чыгарабыз.

Тиз көндә тагын бик мөһим бер китап җибәрермен. Ул китап чыкканы юк әле, мин аны укып ятам. Ләкин ул китап турында доносчылар югары урыннарга язганнар инде. Чөнки китап татар һәм башкорт халыкларының һәм башка төрле халыкларның үзара культура һәм әдәби мөнәсәбәтләре турында, бик нигезле һәм чын мәгънәсендә гыйльми итеп язылган. Әсәрдә татар культурасының һәм әдәбиятының башкорт әдәбиятын барлыкка китерү юлында иткән йогынтысы турында сүз бара. Бу халыкларның тарихи дуслыкларын данлыклый. Ә менә кайбер кешеләрнең шуңа эчләре поша, шуңа үтләре сытыла. Бу китап берәүнең докторлык диссертациясе. Мин шул китап турында гәзитә битләрендә берәр сүз әйтмәкче булам.

Хәзергә шул.

Тагын да Яңа ел белән! ***Сәйфи Кудаш.***

*12.02.66.*
*Уфа.*

Хәсәнем!

Бүгенге кичке почта синең 66 елның өченче февралендә язылган табышмаклы хатыңны китерде. Хатыңда аерым-аерым туктала торган мәсьәләләр бар. Мин әле сиңа үземнең Украинага Павлоның юбилеенә барып кайтуым турында бик озын хат язарга җыйнала идем. Менә бу табышмаклы хатың килеп төшкәч, ул хатыңны икенче нәүбәткә калдырып, шушы юлларны язарга кирәкле таптым. Табышмакны дөрес чишкәнменме? Киевтән кайткач мин сиңа һәм Гомәргә ике тапкыр шылтыраттым. Ләкин өйдә туры китерә алмадым. Соңгы шылтыратуымда инде Гомәрне өйдә таптым. Син инде Оренбургка киткән булып чыктың.

Мин Киевкә авырып, иреннәрем кутырлаган хәлдә чыгып киткән идем һәм шулай чабырткан иреннәр белән йөреп кайттым да. Мин дә, нәкъ синең кебек бит. Андый шау-шуларны бик дулкынланып каршы алам һәм бик арып, тәмам йончып, хәлдән таярдай булып үткәрәм. Киевкә мине, 27 нче январьда булачак юбилейгә 10 нчы январьда чакырганнар иде. Иң элек, нәкъ ун көн буенча, барыргамы-юкмы? дип борчылдым. Чөнки авырып өйдә ята идем һәм һәр көн укуллар ала идем. Шул ун көн буенча тәмам эштән чыктым. Ә Мәгъфүрә: теләсәң нинди язмышка очрасаң да бар. Бу бит инде дүртенче тапкыр рәсми рәвештә чакырулар. Әллә нәрсә уйларлар, Павло Григорьевич белән Лидия Петровнадан яхшы түгел, дип үгетләргә һәм юл нәрсәләре хәзерләргә керешге. Шуннан соң, ни булса булыр, тәвәккәл, дип 20 сендә барачагымны белдереп телеграмма бирдем. Ярар, бу хакта киләчәк хатта язармын. Менә әле дә кәефнең күге болытлы. Бик арып һәм йомшарып кайттым. Кайткач тагын да иреннәрем чабырып чыктылар. Температура булгандыр ахрысы. Чөнки мин температурамны үлчәмим.

Казаннан Муса юбилеенә чакыру кәгазе алдым. Чынын әйткән чакта, мин чакыру көтми идем. Чөнки Мусаның яшьтәшләре һәм җитәкче язучылар бар. Аларны чакырырлар дип тора идем. Кәгазь килгәч бераз аптырабрак калдым. Җитмәсә тагы Нажарны чакырмаганнар да икән әле. Сәгыйть инде ул Муса турында китап язган кеше, бергә укыганнар да. Шуңа күрә ул үзен барырга бик хаклы саный, диләр. Шәриф Камал юбилеенә ул бармыйча мин барган өчен, Союзга барып шаулап йөргән. Мин мондый нәрсәләрне бер дә яратмыйм һәм дәгъвәләшмим дә. Ә кайберәүләр шундый нәрсәләрне бик ямьсез интригаларга, гайбәтләргә корал итәләр. Мин гайбәт һәм интрига иҗат итә торган кеше түгеллекне үзең бик яхшы беләсең. Ач тамагым — тыныч колагым! Синең белән Кустанайга барып кайткач та бик нык гайбәт сөйләүче «дус»лар булдылар. Алла сакласын! Мин андый нәрсәләрне бик авыр күтәрәм. Саулыгыма зарар килә. Эшемә зыяны була.

Казанны да, дусларны да бик сагынган идем. Мусага инде мин болай да бик яхшы һәм туганнарча карыйм. Үземнең шигыремдә ул бик ачык әйтелгән. Мусаның миңа язган хатларын Газига тапшырдым. Алар эшкә бәйләнешле хатлар гына.

Боларны үзеңә генә язам. Гомер булса, саулык рөхсәт итсә Тукай бәйрәменә барырмын. Ә аңа кадәр бер күрешербез әле, беләсеңме? Без апрель башында ук дачага күчәбез — Мәгъфүрә белән. Син майда — Дим ташкыннары басылып, тугай яшәргәч, сандугачлар сайрый башлагач бер килеп кит безгә. Мин сине Бабич белән йөргән юллар белән йөретеп, күрсәтеп чыгармын, ярыймы?

Икебездән дә, балалардан да — барчабыздан да сиңа иң изге фатихалы теләкләр һәм туганлык сәламнәре белән: ***Сәйфи.***

Гомәргә сәлам әйт.

* * *

Бик чәнчешеп уткәч үзәгемә,
Сабырларым беткәч түзәремә,
Йөрәгемне ачып карадым —
Ышанмыйча торам күзләремә,
Чыгармадым санап исәбенә
Андагы ук, энә, яраның...

Нинди тешләр шулай талагандыр,
Кандай телләр энә кадагандыр,
Кемнәр агулы ук аткандыр?
Боз безләре ясап керфекләрен,
Бөркелдереп агулы үтләрен
Кемнәр шулай чәнчеп баккандыр?..

Усал куллар салган чаралары
Дәваларга таптым дәвалары:
Бик килеште халкым мәхәббәте,
Тик юк икән әле дару җирдә,
Һәм дәвалап булмый икән бер дә
Дуслар теле салган җәрәхәтне...

*1965.*

*14.VII.1968.*
*Уфа.*

Хәсәнем һәм Гомәрем!

Икегездән дә хат алгач байтак көннәр үтеп китте. Шигырьләрем басылган газетне җибәргән идем, әлбәттә, алгансыздыр инде, ышанам. Мостайга сездән хат алганлыгымны әйткән һәм сәламегезне тапшырган идем. Бер көнне хатларыгызны аңа да укып бирим әле, дип барган идем дә, булмады, алар Киләшкә киткәннәр икән. Берничә көннән соң, малай, минем барып йөргәнне сизгән кебек, үзе килеп җиткән һәм:

— Кая, тегеләрнең хатларын укыйк әле, дип ымсынып тора. Укыды. Сезнең хатларга кушып тагын Ташкенттан һәм Алма-Атадан килгән хатларны да укыды. Ул гына җитмәсә, язылып бетмәгән һәм язылып та, үзем дөньяга чыгармыйча каклатып, чыныктырып яткыра торган берничә (бик авыр) шигырьне дә укыдым. Алар турында Мостай:

— Боларны бездә басмаслар, ә Мәскәү басар,— диде.

Бу арада үзем аякка киез итекләр киеп булса да ихатада йөрим. Элек җәйге эссе көннәрдә аякларына киез итек кигән кешеләрне күрсәм:

— Эшлексез, ялкау һәм кышлыксыз, дип китә торган идем. Менә хәзер үзем җәй аягыма киез итек киеп тә җылыта алмыйм: «аякларга кан бармый, тамырларда спазма» диләр врачлар. Нәрсә тартынган инде ул канга, түбән таба гына агарга да минем аякларны җылытырга кирәк иде, ахмаклар!.. Шулай булса да моңа мин ышанмыйм. Ә менә аяк өстендә озак басып торганнан-йөргәннән соң, дөньяның асты-өскә килеп, башым әйләнеп китә. Бусына ышанам. Басып торган чакта йөрәк башка канны илтеп җиткерә алмый, ә килеп яткач, кан агышы үзе мигә кинәт бәреп керү белән, баш әйләнеп китә икән. Ләкин мин боларга гадәтләнгәнмен инде. Ә менә Мәгъфүрә белән 51 ел яшибез инде. Анарда булган бер хәлгә гадәтләнә һәм күнегә алмыйм. Һаман аның авырганын яратмыйм. Юк, алай түгел. Аны авыру итеп күрәсем килми. Минем ул һаман да йомгак кебек йомарланып, туп кебек тупылдап йөреп кенә торырга тиеш. Ул уфылдамасын да, сулкылдамасын да, йөзе якты, сүзе татлы, өстәле сыйлы, кочагы җылы гына булсын! Ә ул гел генә шулай булып тора алмый башлады хәзер. Еш, йөрәге чыгырыннан чыгып, ятып ала. Әллә нинди укуллар ала торгач, beләкләрен кара яндырып бетерделәр инде бичараның. Менә аның авыруын авыр кичерәм мин, туганнар. Үземнеке үзәгемә үтсә дә, өзелмим, йөгенмим, егылмыйм, сыгылмыйм, һаман кыймылдыйм да кыймылдыйм!

Гафу итегез. Бу хатны мин бит сезгә үзебезнең гаилә мәмләкәтенең дәхиле эчке хәлләрен сөйләр өчен түгел, бәлки шушы арада «Казан утлары» журналында укыган бер истәлекнең йөрәгемә салган җәрәхәтенә түзә алмыйча, җанымның сөрән салуын ишеттерер өчен яза башлаган идем бит мин.

Чынын әйтәм, мин ул истәлекләрне нәфрәтләнеп укыдым. Әле генә докторлык диссертациясе яклаган бер галимнең шундый җиңел караштан чыгып, өйрәнми, тикшерми, чагыштырмыйча Бәширинең баштанаяк, алдаудан һәм үзен зурайтып күрсәтергә тырышудан гыйбарәт булган тыйнаксыз язмаларын журнал редакциясенә басарга тәкъдим итүе гафу ителерлек түгел, туганкайлар! Хәзерге чорда, аерым авторның аерым әсәренә караганда, мемуар язмаларын чыгару эшенә ныграк игътибар итәргә кирәк. Чөнки аерым әсәр — ул бер авторга гына яки файда, яки зыян китәрәчәк. Ә мемуар әсәрләрдә җибәрелгән хаталар һәм бозулар алар бөтен милли әдәбиятның тарихына, аның зур кешеләренең биографияләренә зарар китерәләр. Неужели Казанда шуны гына аңлаучы галимнәр, редакторлар һәм рецензентлар юк икән? Бәширнең ул истәлекләре татар һәм башкорт халыкларының культуралары — әдәбиятлары өчен бик кадерле булган Тукай, Гафури, Галимҗан, Бабич һәм башкаларның тәрҗемәи хәлләрен бозып күрсәтә. Бәшири, әлбәттә, үз таланты, көче, хезмәте белән татар культурасына заманында үз өлешен керткән язучы. Ләкин ул татар әдәбиятының үзәк баганалары, матчалары булган Тукайлар, Гафурилар, Галимҗаннар, Әмирханнар түгел! Ул иҗаты белән дә, татар иҗтимагый хәрәкәтендә, иҗтимагый фикер-аң үстерү эшендә, көрәшендә дә югарыда әйтелгән мөхтәрәм затлар уйнаган актив рольне уйнамады, уйный алмады. Шуның белән бергә ул алар белән актив аралашып та яшәмәде һәм табакташ та, кабакташ та була алмады. Ә ул үзен менә шул кешеләр белән очраклы рәвештә генә, 10—15 елда бер килеп очрашуны, җан дусларга әйләндереп тасвирлый. Хәсән, син беләсең, аның шигырьләре Галимҗанның «Яңа әдәбият», Х. Искәндәревнең «Белек йорты» хрестоматияләрендә дә юк. Галимҗан аның шигырьләрен аһәңсезлеккә, кытыршылыкка мисал итеп кенә китерә иде бит. Аның бу истәлекләре безгә бик мәгълүм: кырыгынчы елларда мин аны үзем яздырта башладым. Азактан, үземә рецензиягә биргәч, (Гафури турындагы җыентыкка кертер өчен), мин аларның дүрттән... өлешенең ялган икәнлекләрен ачтым һәм дәлилләр белән беркетеп, нәшриятка бирдем. Шуннан соң аларны нәшрият кире какты һәм үзенә кайтарып бирде. Менә шуннан соң инде ул мөгезсез сыер кебек, Казанга барып интрига куертып йөрде-йөрде дә, без забраковать иткән кулъязмасын зур бәя белән анда эшкә ашырып кайтты.

Мин соңгы елларда Тукайлар, Гафурилар, Галимҗаннар, Бабичлар турында язылган бик күп хатирәләрне укыдым. Гәзитә-журнал редакцияләре өчен шуларга рецензияләр язып, бик күп ялганнарны — фашлап калдым. Булмаса, бездә хәзер Союзлар янында «мемуаристлар» секциясе төзергә була иде инде. Шул турыда мин зур мәкалә язарга җыенып килә идем. Һичбер көтмәгәндә менә, без Уфада ялганлыкларын ачып юкка чыгарган «истәлекләрне» журналда бастырып чыгардылар. Мин хәзер бөтен ачуларым, сабырсызлыкларым кайнап, «Казан утлары» журналы битләрендә басылган «көлҗәмнәр» турында комментарийлап, 40 битлек хат яздым. Хәзер инде мин элек җыйналган материалларны да туплап, гомуми бер мәкалә рәвешенә китермәкче булам. Ләкин мәкаләнең төп нигез материалы Бәширинең «Казан утлары»нда басылган ялган истәлекләре булачак.

Мин бу мәкалә-хатымда ваксынмыйм, шәхси мәсьәләләргә кагылмыйм. Бәлки, Бәширинең истәлекләрендә тыйнаксыз рәвештә бозылган фактларны конкрет дәлилләр белән беркетеп кенә язачакмын. Әгәр дә мәсьәләне шул көенчә калдырсак, әдәбиятчылар ул ялганнарны, бозуларны «саф алтын» итеп кабул кыйлачаклар. Чөнки гарәп хәрефе белән чыккан иске әдәбиятны, матбугатны укый алмаган яшьләр генә түгел, хәтта яшь галимнәр, революциягә кадәрге татар әдәбияты тормышын белмиләр. Аларга нәрсә сөйләсәләр, нәрсә язсалар, шуны кабул итәләр. Киләчәктә яшьләр өчен дөрес хәлне аңлау бигрәк тә мөшкелләнәчәк. Шуңа күрә дә безнең кебек шул дәверне үзе күреп, татып, укып, кичереп һәм җәфаланып белгән язучылар, хәзер ул дәвернең Галимҗан агалар үзләре язып калдырырга өлгермәгән әдәби тормыш процессларын бозып күрсәтүчеләргә каршы отпор бирмәсәк, ул ялганнар, хакыйкый хәл булып китәчәкләр.

Элек авылда тәлинкә юк иде. Ашны барыбыз да бер зур табактан бер табынга утырып ашый идек. Шул табынның түрендә баш булып безнең дәү әни Кайдәфә карчык утыра иде. Әгәр дә берәр комсызланып, кашыгы белән башка кешенең алдын капшалый башласа, дәү әни: «комсызланма, кеше ризыгына кул сузма! дип кашыгы белән теге кешенең кулына: «шак!» иттереп кундырып ала иде.

Минемчә, хәзер без үзебезнең әдәбиятыбызда комсызланып, кеше алдындагы ризыгына кашык сузучыларның кулларына сугучы әдәби дәү әниләр, дәү әтиләр булырга тиешбез!

Йә, әйтегез, шушы әдәби җинаятькә түзеп, дәшми калыргамы, яки ялганчыларның кашыкларына сугаргамы? Хат көтәбез.

Сагынычлы сәлам белән, икегезне дә кочаклап: ***Сәйфи.***

Мостай Мәскәүгә сессиягә китте. Аннан безгә киләчәк төрек язучысын каршылаячак.

*21.VII.1968.*
*Уфа.*

Хәсән!

Мин сезгә — Гомәр белән икегезгә бер хат язган идем. Алгансыздыр да — әллә бу Сәйфи акылдан шаша башлаган микән? дип куйгансыздыр инде. Ләкин мин акылдан шашарга җыенмыйм әле. Барлы-юклы акылымнан һаман да, культурабызның тарихын, әдәбиятларыбызның тарихларын һәм аларның бөек кешеләренең биографияләрен, тормышларын бозып күрсәтергә тырышкан ач күзләргә, ялганчыларга каршы көрәшергә багышлыйм. Ялган истәлекләрдән торган китапны әдәби эшкәртеп дөньяга чыгарырга юкка көч түккәнгә Гали Халитка 40 битлек хат язган идем. Мондагы егетләргә укыгач шаккаттылар һәм: «хат язма, кайтадан эшләү булса да мәкалә итеп яз, теләсәң журналда чыгартырбыз, дигәч, хатны архивка ташладым да, мәкалә яза башладым. Менә күрерсез әле кемнәр ничек үзләренең барлы-юклы хезмәтләрен Тукайлар, Гафурилар, Галимҗаннар һәм Бабичлар пьедесталенә мендерергә тырышканнар. Хәтта хәзер зур язучылар саналган кайберәүләр (Казанда һәм Уфада) Бабич һәм Гафури турында ялган «хатирәләр» язалар.

Хәсән, беләсеңме, синең җыр текстларыңны әлегә чаклы Фәридә белән Бәхтигә тапшыра алмый торганга бик борчыла идем. Алар өченче көн гастрольдән кайтты. 85 концерт биргәннәр, планны һәръяклап тутыргач филармониягә 10 мең саф файда алып кайтканнар. Кичә безгә дачага килделәр. Мин алар белән Уфага кайтып папкаңны аларга кочаклатып җибәрдем. Димәк, өстән бурыч төште. Кәефләре бик һәйбәт. Сиңа бик-бик күп сәлам язарга куштылар. Ләкин безнең күкләр тыныч һәм шат түгел. Мәгъфүрәнең саулыгы начарлана бара. Үзем бирешмәскә тырышам.

Менә шул. Кызларга, Гомәрләргә сәлам әйт.

Сагынып: ***Сәйфи.***

## Социализм һәм ислам

Француз лисанында нәшер иделмәктә булган «Һиндстан хәяты» исемле журналның соңгы номерында Мәшир Кодавиның «Социализм вә ислам» исемендә мөһим бер мәкаләсе басылып чыккан. Бу мәкаләсендә ул Коръәнне тәфтиш итеп, карап чыкканнан соң, Коръән кәримнең һәрбер социализм ислахчылары өчен мөрәҗәгать итәргә яраклы бер китап булганлыгын бәян кыйла.

«Коръәнне укып чыкканнан соң, Мөхәммәт пәйгамбәрнең беренче буларак, гамәли сурәттә социализм ислахлары ясаган кеше булган, дип ышанмау мөмкин түгел. Ул хәзерге заман гавамиятнең асыл нигезен салучы бер кеше булмыштыр» ди. Коръәннән беренчә аятьләрне дәлил буларак күрсәткәннән соң, мәзкүр мөхәррир ошбу нәтиҗәләрне чыгара: «Коръән бер аллага иман китергән кешеләргә нәҗит илә бәшарәт биргәннән соң инсаннар арасында һич тәфавет (аерма) юклыкны һәм инсаннарның һәркайсының бер-берсенә кардәш икәнлекләрен бәян кыйла.

Капиталның бер кеше кулына җыелуына юллар калдырмый».

Хәсән! 1911 ел 9 нчы август. «Йолдыз» гәзитәсе. № 717. Мәкалә өчен кирәк булгач, «Йолдыз»ны актардым. Менә шул вакыт бик кызыклы бер шул хәбәргә очрадым да, сиңа күчереп җибәрәм. Укып карагыз әле.

Сәлам белән: ***Сәйфи.***

# УЛ ЯШӘСӘ, БЕЗ БӘХЕТЛЕ

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТАТАР БҮЛЕГЕНӘ 50 ЕЛ

Кешелек тарихында эзе, хәзерге яшәештә, мең төрле халыклар арасында үз урыны, сихәтле җире булган милләт исемен йөрткән бүлеккә илле, аның мәрхәмәтле куенында аякка баскан факультетка биш яшь тулды.

Бүлек үткән юл — үзе бер олы дәрья. Бу юл табадай такыр, шома, тигез генә булмаган. Дәһшәтле 1944 елда кафедра һәм бүлек ачуга рөхсәт бирү бер хәл. Иң әүвәл укытучыларын табасы, аннан әзерлекле студентларын җыеп аласы, аларны язылмаган, басылмаган дәреслекләр буенча укытасы, университет дәрәҗәсенә тап төшермәслек итеп белем бирәсе бар. Киләчәге томанлы белгечлекне үзләштерергә ашкынып торучылар да күп булмый. Химия, авиация, техник белгечлекләр буенча китсәң, авызың балда-майда йөзәр, торган җирең шәһәр үзәгендә, кайнар сулы өйдә булыр.

1949 елгы беренче чыгарылышыбызның нибары җиде кешедән торуы гаҗәп түгел.

Хәзергәчә сакланган сугышчан рухны бүлеккә фронтовиклар буыны алып килә. Дары исе аңкып торган тозлы гимнастеркаларын да салырга өлгермәгән, дөресе, алмашка күлмәкләре дә булмаган Зыя Мансур, Рашат Гайнанов, Мәхмүт Хөсәен, Әбрар Кәримуллин, Ибраһим Нуруллин, Илбарис Надиров кебек милли пәрвәрләр буыны бүлекнең абруен күтәрә. Һәркайсы олы шәхес, язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе булып җитешә. Шул егетләр белән, оста дирижер сыман, Рабига апа Хәкимова җитәкчелек итә. Бик күпләр өчен ул туган аналары кебек якын һәм газиз кеше була. Әдәбият укытучысы Якуб ага Агишев та ихтирамга лаеклы затларның берсе. Ул сүзнең тәмен, әдәби әсәрнең ләззәтен тыңлаучыга ирештерү сәләтенә ия сәхнә кешесе дә иде.

Төп эш урыннары фәнни-тикшеренү институтында булса да, Мөхәммәт Гайнуллин, Латыйф Җәләй, Хәмит Ярми кебек изге җаннар яшьләрне үз итеп, алар белән аралашып, булган белемнәрен студент зиһененә сеңдерергә вакыт табалар.

Профессор Хатип Госман кафедра белән җитәкчелек иткән чорда бүлек яңа сыйфат югарылыгына күтәрелә. Шигырьгә гашыйк бу олы галим оста оештыручы, тәрбияче дә иде. Ул эшләгән дәвердә Диләрә Тумашева, Мирфатыйх Зәкиев, Нил Юзиев, Мансур Хәсәнов кебек фән докторлары оештыручы, җитәкче булып күтәрелә. Соңрак аларга кесәләрендә шул бүлек дипломын йөрткән Әбрар Кәримуллин, Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Азат Әхмәдуллин, Фоат Ганиев, Фәрит Хатипов, Рүзәл Йосыпов, Фәрит Йосыпов, Фирдәвес Гарипова, Хатип Миңнегулов, Резеда Ганиева кебек һәркайсы татар теле һәм әдәбият белемнәренең олы бер фәнни юнәлешен җитәкләгән галимнәр килеп кушыла. Аларның гыйльми ачышлары турында озын-озак итеп сөйләп булыр иде. Хезмәтләре, язылган китаплары күз алдында. Арабыздан иртә киткән Әнвәр Әфләтунов кебек фидакарьләрне, лаеклы ялдагы Зәет Мәҗитовны, Ибраһим Нуруллинны, һаман да татар теле өчен янып-көеп йөргән профессорлар Диләрә Тумашеваны, Вахит Хаковны, Мирфатыйх Зәкиевне хөрмәт белән искә алмый мөмкин түгел.

Бүлектә белем эстәп, илнең төрле почмакларында хезмәт иткән мәгариф һәм мәгърифәт алдынгылары факультетның терәге булган укытучы-галимнәр Флера Сафиуллина, Фәһимә Хисамова, Флера Ганиева, Сәгадәт Ибраһимов, Альберт Яхин, Марсель Бакиров, Шәйхелислам Садретдинов, Камил Биктаһировлар да җылы сүзләргә лаек. Әлеге мөхтәрәм укытучылар янына яшь көчләр өстәлә тора. Соңгы берничә елда Гафур Сөнгатов, Фәнүзә Нуриева, Дания Заһидуллина, Таһир Гыйлаҗев, Искәндәр Гыйлаҗев, Динә Мостафиналар фән кандидатлары булдылар.

Татар бүлегенең эшчәнлегe һәрьяктан бәрәкәтле булды. Шунда белем алган шәхесләр җөмһүриятебезнең әдәби, мәдәни, хәтта сәяси үсешендә, иҗтимагый тормышында мөһим урын тоталар. «Казан утлары», «Сөембикә», «Чаян», «Мирас», «Идел», «Ялкын», «Сабантуй», «Салават күпере» кебек газит-журналларның баш мөхәррирләре, күпчелек хезмәткәрләре — туган телгә, мең еллык тарихлы әдәбиятыбызга мәхәббәтне татар бүлегендә алган олы затлар. Татар халкының рухи-фәлсәфи үсеше көзгесе «Казан утлары» үзенең бүгенге сыйфаты белән Равил Фәйзуллин, Рашат Низамиев, Наис Гамбәров, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Мансур Вәлиев кебек татар бүлеге шинеленнән чыккан ир-егетләргә бурычлы.

1993 елда Татарстанның халык язучысы дигән исемне алган ике олуг әдипләребез — Гариф Ахунов белән Аяз Гыйләҗев бүлектә белем алсалар, өченчесе — Мөхәммәт Мәһдиев шунда аспирантура тәмамлап, утыз елга якын яшь буында татар әдәбиятына, Тукай шигыренә мәхәббәт тәрбияләгән.

Бүлекне тәмамлаган зыялылар күп өлкәдә тормыш сәхнәсенең үзәгендә кайныйлар. Район газитләре мөхәррирләренең, журналистларының зур күпчелеге безнең бүлектә укыган. Журналистика фәне факультеты башында торган Флорид Әгъзәмов, әлбәттә инде, сүзгә мәхәббәтне татар бүлегендә алган.

Татар бүлеге офыклары Татарстан белән генә чикләнми. Оренбург ягында туып-үскән Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәскәү өлкәсе егете Тәүфикъ Әйди, Түмән тарафының Вагай районы вәкиле Булат Сөләймановларны бүлек бик теләп үзенә кабул итте, белем бирде.

1994 елда Тукай бүләгенә лаек булган Нурихан Фәттах Башкортстаннан татар бүлеге һәм әдәбияты белгечлегенә юл ярган беренче дулкын вәкиле. Аннан соңгы елларда татар әдәбиты Әхсән Баянов, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, агалы-энеле Зөлкарнәевләрне, Госман Садәләрне үзенә чакырып алды.

Милләт язмышы өчен янып-көеп яшәгән фидакарь җитәкчеләр арасында бүлекне тәмамлаучылар җитәрлек. Казан педагогия институты ректоры Рүзәл Йосыпов кесәсендә шул белгечлекнең дипломын йөртә. Алабуга педагогия институты ректоры Наил Лаисов бүлектә диплом һәм кандидатлык диссертацияләре язып, Тукай лирикасы буенча белгеч булып бездә житешә.

Татарстан академиясен ачу, оештыру, аякка бастыру өчен безнең бүлекне тәмамлап, шунда укыткан, җитәкчелек иткән Мансур Хәсәнов, Мирфатыйх Зәкиевләр тырышып йөрде.

Татарстан язучылар оешмасы башында торучы Ринат Мөхәммәдиев, Зиннур Мансуровлар тәрбияне, заманча һәм итәгатьле фикерләү дәресләрен татар бүлегендә алганнар. Мәскәү университеты профессоры Роберт Бикмөхәммәтов, Уфа университеты дамелласы Әхәт Нигъмәтуллин, Ижауда татар бүлеген ачып йөрүче Дургали Мөхәммәтшин шулай ук безнең бүлек шәкертләре.

Безнекеләр халык хуҗалыгының башка өлкәләрендә дә сынатмый. Азнакайда эшләр һәр тармакта гөрләп бара, татар гимназияләре, мәктәпләре, мәчетләре ачылып тора дип тикмәгә генә әйтмиләр. Аның сере хакимиятнең башында безнең бүлекне тәмамлаган Әнәс Исхаков торуында.

Казан салым идарәсенә башлыкка намуслы, белемле, кыскасы, булган, житлеккән кеше кирәк икән, рәхим ит, андый житәкчене бүлекне тәмамлаган егетләр арасыннан сайлап алып була. Ул — 1968—73 елларда бүлектә укыган Равил Әхмәтшин.

Тарих-филология факультетында укыганда ук булачак профессорлар М. Зәкиев, И. Нуруллиннарны машина йөртергә өйрәткән Фалис Вәлиевне нинди эштә генә сынап карамадылар. Беркайда да сер бирмәде. Хәзер ул — Зәй районсоветы рәисе.

Казанда «Синдикат» исемле качакларга, мөһаҗирләргә ярдәм кулы сузучы, шәфкатьле оешма үсеп чыкты. Аны оештыручы, башында торучы кеше — татар теле һәм әдәбияты укытучысы дипломына ия Наил Мостафин. Бу төр мисаллар бихисап диярга мөмкин.

Бүлектә белем алган кешеләрнең иҗади, сәяси, мәдәни киңлеге, беркайда да югалып калмавы белгечлекнең асыл хасиятендә ята булса кирәк.

Татар теле — итагатьле, йомшак, нәфис җыр логате. Аның сүз байлыгында орышка, сүгенүгә, әдәпсезлеккә өйрәткән гыйбарәләр, җөмләләр бик аз.

Чал тарихлы татар әдәбияты — дөньяда иң фидакарь, намуслы, бары тик яхшылыкка, шәфкатьлелеккә, сабырлыкка өндәүче сүз сәнгатьләренең берсе. Башка халык дәүләтчелеге эчендә шулай гөрләп үскән, сәнгатьчә югарылыкка ирешкән олы әдәбиятлар күп түгел җир шарында. Бәлки юктыр да. Бу үсешкә этәргечне халык рухы бирсә, икенче сәбәп — милләтнең үткәне, төрле сәнгатьләр

үсешенә дәрт, көч биреп торган Бөек Болгар һәм Казан дәүләтләре, шул шаулы көннәрнең кайтуына, үз дәүләтчелеге торгызылачагына ышанычы иде. Матурлык көзгесе — әдәбият ышаныч вә өметтән, чынбарлык вә хыялдан башка яши дә, үсә дә алмый. Нәкъ менә шуңа күрә татар халкының бәхетле киләчәге, азатлыгы өчен көрәшчеләрнең беренче сафында үзебезнең шәкертләрне күрәбез. Шулар белән янәшәдә татар теле һәм әдәбияты дәреслеген кулына тоткан йөзләгән укытучылар да бар. Алар — туган телебезнең, әдәбиятыбызның каһарманнары, иң авыр, мактаулы хезмәтне җилкәләренә салган кешеләр — безнең төп байлыгыбыз, терәгебез, киләчәгебез. «Татарстан халык укытучысы» һәм башка мактаулы исемнәргә лаеклы педагоглар, авыл педагоглары, рус телле мәктәпләрдә эшләүче фидакарь җаннар алдында бүген баш иябез, аларга уңыш, исәнлек, бәхет телибез.

Татар теле һәм әдәбияты бүлеге илле еллык гомерендә төрлесен, туган халкы кебек үк, какканы да, сукканы да күрде, сөеннече дә, көенече дә, олы хуҗаларның ишеге төбендә салкын бозда аягын туңдырган дәверләре дә булды. Ләкин ул язгы үренте кебек гел яктыга, яңага ашкынды. Тыны кысылган, һава житмәгән чорларда Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, Ф. Миңнуллин, Ә. Рәшитов, В. Нуруллин, К. Тимбикова, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Н. Хисамов, К. Сибгатуллин, Зөлфәт, К. Булатова, С. Маннапов, Х. Әюпов, Р. Юныс, И. Гыйләжев, Г. Морат, А. Минһаҗева, Р. Зәйдулла кебек сәләтле егетләр-кызлар укырга кереп, аның яшәвенә җан өрә торган булды.

Милли телләрнең яшәеш даирәсе тарайган, татар мәктәпләре ябылган, матбугаты кысылган сиксәненче еллар башында белгечлеккә конкурс кими. Ата-аналар да, яшьләр үзләре дә почмак теле көненә кала барган лөгать белән киләчәкләрен бәйләргә теләмиләр. Элек бүлектә егетләр өстенлек итсә, торгынлык чорында анда кызлар күбәеп китә.

Бары тик хөррият җилләре исә башлагач, үзгәртеп кору чорында гына бүлегебез тормышы җанланып китте. Аның эшчәнлегенә яңалык рухы иңде. Әүвәл татар халкы тарихы дигән өстәмә белгечлек кертелде.



Рәсемдә: *Казан университетының татар бүлегеннән бер төркем галимнәр, язучылар һәм студентлар. Рәсем Фатих Әмирханның 90 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичә уңаеннан төшерелгән. 1976 ел.*

1989 елда шул чорда университетның уку-укыту эшләре буенча проректоры М. Госманов тәкъдиме белән гыйльми берлек татар бүлеге нигезендә татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетын булдыру турында карар кабул итте. Ике ел элек Татарстан хөкүмәте, татар факультетының фәнни-методик ярдәме белән, мәктәпләр өчен татар теле һәм әдәбияты, инглиз һәм көнчыгыш телләр укытучылары әзерләүгә чакырылган Татар дәүләт колледжын ачып җибәрде. Анда хәзер Татарстаннан ике йөзгә якын студент белем ала. Факультетның үзендә 700 дән артык кеше белем ала. Һәр елны көндезге бүлеккә 100 читтән торып уку бүлегенә 60—70 кеше кабул ителә. Шуннан да арттыру кирәк түгел дип саный факультетның гыйльми берлеге. Сыйфат дәрәҗәсен төшерү килешмәс.

Факультетка чын-чынлап аякка басу, һәр яңа белгечлек буенча бүгенге таләпләргә җавап бирерлек эшмәкәрләр әзерләү өчен бик нык тырышасы, эшлисе бар. Читтән ярдәмгә дә бик мохтаҗ безнең оешма.

Факультет элек бүлек биләгән уку-укыту мәйданнарында калды. Кысынкылык, тыгызлык, утырып укырга аудитория житешмәү, укытучы кадрларга кытлык — төп кыенлыкларыбыз.

Техник әсбаплары да, компьютер, лингафон кабинетлары да юк әлегә факультетның. Мәгълүм сәбәпләр аркасында ятимрәк хәлдә калдык. Ә бит бездә укучы талип-талибәгә, галим-голәмәгә мөнәсәбәтнең асыл нигезендә олы сәясәт — икенче дәүләт теленә караш, аның киләчәге мәсьәләләре ята.

Бүлекнең татар телен, сүз сәнгатен, димәк ки, халыкның үзаңын саклауга керткән өлеш бәяләп бетергесез.

1917 ел борылышына кадәр татар зыялылары «Галия», «Мөхәммәдия», «Хөсәения», «Күл Буе» кебек атаклы уку йортларында белем алганнар, хәлле-сәләтлеләре Каһирәнең 972 елда ачылган Әл-Әзһәр, Парижның Сорбонна университетларына чаклы барып житкәннәр.

Ил чикләренә тимер рәшәткәләр төшерелеп, әлифбалар алышынып, милли тел почмакка куып кертелгән, ул яклаучысыз, үги йорттагы ата-анасыз бала хәләтендә кала. Шул чорда татар бүлеге ачылып, шунда тел һәм әдәбият буенча белгечләр әзерләнмәсә, хәзер ана телебезнең ни хәлдә буласын күз алдына китерүе дә кыен.

Һәрхәлдә, тел байлыгының яртысы алынмалардан торыр, әдәби телебез гарип һәм күпкә зәгыйфь булыр иде. Тел саклаучы фидакарьләрне гыйльми оешма да, фәннәр академиясе дә үстерә алмый. Бу олы вазифаны, тарихи ихтыяҗны бары тик югары уку йорты гына үти ала. Җөмһүриятебезнең югары уку йортлары икенче дәүләт телендә укытуга күчмичә торып, татар теле тиешле дәрәҗәгә күтәрелә алмаячак.

Бүлекнең 50 еллык эшчәнлегенә гомуми бәя биреп шуны әйтәсе килә: ул татар халкын зыялы милләт буларак саклап калуга, телен, әдәбиятын, гомумән мәдәниятен, мәгърифәтен үстерүгә ифрат зур, бәяләп бетергесез өлеш керткән. Ул — татар халкының бәгыре, йөзек кашы, күзе, колагы, дине һәм дене булган үз чоры өчен...

Сүземнең ахырында, Фатих Әмирхан фикерен бераз үзгәртеп: «Китерегез аңа энже чәчәкләр, шул бәхетле көннәренең шигъри төсләрен исенә төшереп, киләчәк белән рухлансын! Мәңге яшә татар теле, татар әдәбияты! Син яшәсәң, без дә яшәрбез!» — дип кабатлыйсы килә.

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,**
**профессор, Казан университетының**
**татар филологиясе, тарихы**
**һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы.**

## РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК БӘЙРӘМЕ

30 август көнне Казанда Татарстан Республикасының Дәүләт суверенитеты турындагы Декларация кабул итүнең дүрт еллыгына багышланган спорт һәм сәнгать бәйрәме булып үтте. Республика бәйрәме быел Олимпия комитетының 100 еллыгына туры килде. Әлеге халыкара фестивальдә катнашу өчен күршеләребез Башкортстаннан, Чувашстаннан, Мари-Эльдән, шулай ук Киров, Краснодар, Кабарда-Балкар, Алтай якларыннан да кунаклар күп килгән иде.

Бәйрәм Казан ипподромында атлар чабыштырудан башланып китте һәм көннең икенче яртысында башкалабызның үзәк стадионында дәвам итте. Халыкны олуг бәйрәмнәр белән котларга һәм тамаша карарга Татарстан Президенты М. Шәймиев, Премьер-министр М. Сабиров, Вице-президент В. Лихачев, Җөмһүриятебезнең авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Ф. Сибагатуллин, физкультура һәм спорт комитеты рәисе Х. Мортазин һәм башка рәсми кешеләр белән бергә, Төркия авыл хуҗалыгы министры Рәфәхетдин бәй Шахин да килгән иде. Спорт ярышлары сәнгать осталарының чыгышлары белән аралашып барды. Җиңүче өч район (Чаллы, Балтач, Арча) командаларына Татарстан Президенты билгеләгән 25,15,10 миллион сум күләмендәге акчалата бүләк тапшырылды.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Җөмһүриятебез суверенитеты турында Декларация кабул ителүнең чираттагы еллыгына багышлап, 26 августта Татарстан Фәннәр Академиясе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты, Бөтентатар иҗтимагый үзәге «Татарстан мөстәкыйльлеге: бурычлар һәм проблемалар» дигән темага фәнни конференция үткәрде.

## КАҺАРМАННАРНЫ ИСКӘ АЛУ

25 августта, Казан Кремле алдындагы М. Җәлил һәйкәле янында, моннан 50 ел элек Алманиянең Плетцензее төрмәсендә фашист гильотинасы тарафыннан башлары киселгән 11 каһарманны — батыр йөрәкле милләттәшләребезне искә алу мәрасиме булды. «Хәтер җыены»на Мусаның бүгенге көндә исән көрәштәш дусларыннан — Казанда яшәүче Әмир Үтәшев, Үзбәкстанның Каршы шәһәреннән Фәрит Солтанбәков, Мәскәүдән шагыйрьнең хатыны Әминә ханым, кызы Чулпан, оныгы Таня, сугыш һәм хезмәт ветераннары, «Кызыл ромашка» берләшмәсе әгъзалары, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре килде.

Матәм җыенын Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин ачты. Җәлил белән бергә җәзалап үтерелгән 10 батырның — Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров барельефлары алдына (аларны атаклы скульптор — СССРның халык рәссамы, Муса һәйкәле авторы В. Цигаль иҗат иткән) Татарстан Президенты М. Шәймиев тере чәчәк бәйләмнәре салды.

Аннары Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев алып баруында митинг башланды. Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков, исән җәлилчеләр, Әминә ханым, язучылардан С. Баттал, Р. Мостафин, И. Юзеев, Р. Харис, нәфис сүз остасы А. Арсланов, җырчылардан У. Әлмиев, З. Сәхәбиева, Х. Бигичев, Р. Ибраһимов һ. б. үзләренең батырларга карата хисләрен кайнар сүз, шигырь һәм җыр белән белдерделәр.

Матәм җыеныннан соң, бер төркем кунаклар М. Җәлилнең Казанда чакта яшәгән йортында — шагыйрь музеенда булып, аның хакында, көрәштәшләре турында хатирәләрне яңарттылар.

* * *

М. Җәлилне һәм аның 10 көрәштәш дустын искә алу кичәсе Уфада да зурлап уздырылды. Аны Башкортстанның татар мәдәнияте үзәге (житәкчесе — Муса Сираҗи) оештырган иде.

Татарстан Югары Советы Президиумы җәлилчеләр истәлегенә багышланган әлеге кичәгә Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев, «Татарстан» журналы баш мөхәррире Р. Мостафин, «Татарстан хәбәрләре» газетасы баш мөхәррире, шагыйрь Р. Харис составында делегация җибәргән иде.

Татарстан делегациясен Башкортстан Республикасы Президенты Мортаза Рәхимов кабул итте.

* * *

Оренбурдагы татар театры һәм «Туган тел» җәмгыяте, шулай ук Санкт-Петербургтагы «Нур» татар җәмгыяте дә җәлилчеләрнең җәзалап үтерелүләренә ярты гасыр тулу көнен халык күңелендә калырлык итеп үткәрделәр.

## ВИЦЕ-ПРЕЗИДЕНТ ТӘКЪДИМЕ

Казагыстан Республикасы Президенты Н. Назарбаев инициативасы белән, 20 сен-

тябрьдә Алматы шәһәрендә «Евразия киңлеге: интеграция потенциалы һәм аны гамәлгә ашыру» дигән темага фәнни-гамәли конференция уздырылды. Аның эшендә, БДБ илләренең һәм чит илләрнең дәүләт эшлеклеләре, дипломатлар, галимнәр белән бергә, Татарстан Республикасының Вице-президенты В. Лихачев та катнашты. Ул Җөмһүриятебезнең Евразия интеграциясендә катнашу хокукын дәлилләп сөйләде. Евразия союзының җитәкче үзәкләренең берсен Казан шәһәрендә оештырырга, әлеге бердәмлекнең халыкара хокук институтын Татарстанда ачарга тәкъдим кертте.

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР КОНГРЕССЫ

Сентябрь аенда Төркиянең башкаласы Анкарада төрки халыклар тарихына багышланган фәнни конгресс үткәрелде. Аның эшендә Татарстан Фәннәр Академиясе Президенты М. Хәсәнов җитәкчелегендә җөмһүриятебезнең танылган галимнәреннән М. Зәкиев, Ә. Кәримуллин, С. Алишев, Ә. Мөхәммәдиев, Ф. Урманчеев катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## АРАЛАР ЯКЫНАЯ

Казанда чит дәүләтләрнең әдәбият һәм мәдәният көннәрен уздыру, төрле күргәзмәләр оештыру матур бер гадәткә әверелде. 5—12 сентябрь көннәрендә, мәсәлән, башкалабызда «Алмания көннәре: мәгълүмат һәм мәдәният атналыгы» зур уңыш белән үтте. 13—16 сентябрьдә исә Татарстан Рәссамнар берлегенең зур залында «Венгрия — сезнең партнер» дип исемләнгән күргәзмә эшләде. Анда әлеге республикада җитештерелгән күптөрле товар үрнәкләре күрсәтелде.

## НЕВА БУЕНДА — ЯҢА ВӘКИЛЛЕК

Татарстанның Санкт-Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсе белән узган елда төзелгән килешү нигезендә, Җөмһүриятебезнең Министрлар Кабинеты Нева каласында Татарстанның сәүдә-икътисад вәкиллеген ачу турында карар кабул итте. Аның җитәкчесе итеп хәрби фәннәр кандидаты Шамил Әхмәтшин билгеләнде. Элек ул тыл һәм транспорт академиясендә укыткан, хәзер берьюлы ике акционерлык җәмгыятьләре — «Самсон» һәм «Дәр-әл-Ислам» мөселман эшкуарлары президенты вазифаларын башкара.

## ЯПОНИЯ КУНАГЫ — ТАТАРСТАНДА

Җөмһүриятебездә Япония филологы, танылган профессор Тору Кавасаки булып китте. Төп һөнәре буенча рус әдәбияты белгече саналган әлеге галим, Казандагы һәм Татарстандагы милләттәшләребез белән якыннан танышып, «Россиядә татарлар» дигән яңа китабы өчен мәгълүматлар туплады. Моңарчы аның СССРдагы үзгәртеп кору чорын яктырткан китабы дөнья күргән иде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

15 сентябрьдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда, Язучылар берлеге оештырылуга 60 ел тулу уңаеннан, шушы елның 21 ноябрендә юбилей тантанасын үткәрүгә әзерлек мәсьәләләре каралды, «Шәһри Казан» газетасына кушымта рәвешендә «Әдәби җомга»ны чыгару турында эшлекле сөйләшү булды. Утырышта «Идел» журналының баш мөхәррире итеп янадан Фәиз Зөлкарнәй расланды. Аерым әдипләргә Татарстан Президенты фондыннан һәм эшмәкәр Рәшит Ахунов фондыннан акчалата ярдәм күрсәтелде.

* * *

Татарстан Язучылар берлеге каршындагы остаханәләр үз эшчәнлекләрен яңартып җибәрделәр. 31 августта балалар әдәбияты остаханәсе (җитәкчесе — Шәүкәт Галиев) «Мәктәпләрдә балаларга нинди әдәбият укытабыз?» дигән темага кызыклы сөйләшү үткәрде. «Мәгариф» нәшриятында әдәбият буенча байтак кына дәреслекләр чыгарган А. Яхин белән бергә, әлеге сөйләшүдә Л. Ихсанова, И. Юзеев, Р. Миңнуллин, Г. Садә, Р. Ягъфәров кебек язучылар, галимнәр, мөгаллимнәр дә катнашты.


* * *

19 сентябрьдә шагыйрьләр остаханәсе дә үзенең беренче утырышын үткәрде. Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев алып барган әлеге шигърият мәҗлесендә 90 яшен тутырып килүче Салих ага Баттал белән очрашу булды. Өлкән шагыйребез тыңлаучыларны үзенең иҗат тәҗрибәсе, әдәбият-сәнгать, сәясәт дөньясына кагылышлы күп кенә гыйбрәтле-кызыклы хәлләр белән таныштырды, күпсанлы сорауларга җаваплар бирде.

Шул ук утырышта остаханәнең 7 кешедән торган Шурасы (рәисе — Илдар Юзеев, урынбасары — Рәдиф Гаташ, сәркатибе — Шаһинур Әхмәтсафа, әгъзалары — Мөдәррис Әгъләм, Лена Шагыйрьҗан, Харрас Әюп, Газинур Морат) сайланды.

* * *

Әлки районында Алпар урта мәктәбе ачылуга 70 ел тулды. Шул уңайдан, биредә тантана булып узды. Кунаклар туган мәктәпләренә зур-зур бүләкләр (ике машина, төсле телевизор һ. б.) алып килгәннәр иде. Ә «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире, шагыйрь Шамил Маннапов белән композитор Луиза Батыр-Болгари, туган як гимны итеп, «Алпарым» дигән яңа җыр бүләк иттеләр. Аны, җыр авторлары кебек үк, шушы төбәктән чыккан танылган җырчы Мирсәет Сөнгатуллин башкарды.



# ИСЕМЛЕ ИМАШ ТУГАН

Рәшит Имаш, 1971 елның көзендә Мәскәүдәге Суриков исемендәге нәфис сәнгать уку йортын бетерүенә нәкъ бер ел дигәндә, Казанга, бу чорда шактый күкрәп-куәтләнеп киткән сынлы сәнгать мәйданына кайтып керде. Арысландай гайрәтле, көчле тавышлы, көләч йөзле һәм һәрвакыт күтәренке күңелле, калын гәүдәле егет, хөррият аланында печән чабучы гаярь ир кебек, бөтен көче-куәте белән селтәнеп җибәрде... Шулчак киндер тукымада бер-бер артлы гүзәл сыннар, сурәт-йөзләр, пейзаж һәм сюжетлы картиналар пәйда була башлады. «Хәбәрче», «Карчык», «Студент кыз», «Йорт буяучы» (маляр) Рафикова, «Солдат хаты» һ.б., һ.б. Тора-бара аны нәкыштан ташып чыккан графика (рәсемчелек) өлкәсе биләп алды һәм рәссамны төрле мөстәкыйль серияләр («КамАЗ төзүчеләр», «Татар язучылары», «Һиндстанга сәяхәт») тудыруга этәрде: биредә шулай ук дусларга, язучы-рәссамнарга багышланган шаржлар, «Социалистик Татарстан» газетасы, «Азат хатын», «Чаян» журналлары өчен башкарылган рәсемнәр, Мәскәүдәге «Балалар әдәбияты», Татарстан китап нәшрияты үтенече буенча эшләнгән иллюстрацияләр жанры туып чыкты (И. Нуруллин. «Кырлай авылы шагыйре», Г. Ахунов. «Артыш тавы артында»; Р. Мостафин. «Нәни Муса» повесте һ.б.) Шулай итеп, иҗатының беренче адымнарыннан ук, рәссам үзенең эчке җегәрен тоеп, берьюлы берничә жанрны эшкә җигеп, буразнаның һәркайсында уңай нәтиҗәләргә ирешеп, һәммәсеннән дә канәгатьләнү тапмыйча, ярсып-канатланып, алга ыргылды...

Аның дөнья, татар әдәбияты классикларына багышланган портретлары — үзе бер хәят...

Татарстан һәм Башкортстанда, Казан, Питрәч, Әлмәт төбәкләрендә ул башкарган дивар бизәм композицияләре — гипс рельефлар, Урал тауларыннан табылган вак ташлардан төзелгән төсле мозаикалар, фрескалар аның иҗат юлында бер сәхифә булды.

Тәүге эшләрендә беркадәр ялган пафослы героик аһәңнәр, хезмәт романтикасы кебек шаукымнар көйрәп алган иҗаты (КамАЗ, БАМ, Чирәм җирләр торгызу мотивлары), берзаман күзгә ташланырлык борылыш ясап, гади тормыш, табигатькә, халык мохитына, милли тоемнар дәрьясына юл тотты... Югары профессионал, нәкыш остасы Рәшит Имаш бу хисләрен җисемсез аморф лирика, мактау-мәдхия, риваятьнамәләр аша чишми — сынлы сәнгатьнең сыналган өлкәсе — портрет жанрында, тормышның умырткасын гыйбрәтләгән, «кургаш» сеңгән характерларда, табигать алхимиясен татып җыерчыкланган, гөлләнгән йөзләр, агач бура кебек тотнаклы, ышанычлы зур куллар аша тасвирлады («Карт кеше», «Төзүче А. Новолацкий», «Балта остасы», «Геодезистка» һ.б.) Колачлы, дуамал, бертуктаусыз алга омтылучы Рәшит Имаш иҗат сукмагыннан кызу барды.

Шулай итеп, Р. Имаш чамасыз потенциалын, зур сәләтен — күпкырлылык, төрлелеккә, сәнгать эчендәге туктаусыз эзләнүләргә багышлады. Бәлкем, шул олы илаһи сәнгать хисен төрле мәзхәб алымнарга бүлми, зур башлангычларын, киң мөмкинлекләрен бер максатка баглап, мыскаллап сарыф итсә — (мулрак) уңышка ирешкән булыр иде, кылганы тау кадәр булыр иде. Булуын булыр иде, ләкин татар рухлы, татар телле, бихисап омтылышлы, сөйләм остасы, мәзәкче, «артист» Р. Имаш дуслары һәм халык тарафыннан бу кадәр сөелгән, тау кадәр мәхәббәткә лаек шәхес була алмас иде, мөгаен.

Розалина ШАҺИЕВА,
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Рәшит Имашның «Балкар шагыйре Кайсын Кулиев портреты» картинасыннан фоторепродукция.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган шагыйрь, яшьләрнең Муса Җәлил бүләге лауреаты Зөлфәт (Дөлфәт Маликов).

М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР




ЯРУЛЛИН Фәнис. **Сайланма әсәрләр,** 3 томда: *Повестьлар, кереш сүз.*— Казан: Татарстан дәүләт «Мирас» китап нәшрияты, 1994 ел, 616 бит.

«Сайланма әсәрләр»нең беренче томына танылган әдипнең биш повесте кертелгән. Алар арасында «Җилкәннәр җилдә сынала», «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», «Язмышлар язылганда» әсәрләре үз вакытында аерым китаплар булып басылып, укучыларның мәхәббәтен казанган иде. «Кайту» һәм «Чәчәкләр моңы» повестьларында исә каршылыклы чорыбызның катлаулы күренешләре үзенчәлекле рәвештә тасвирлана.

Өчтомлыкка кереш сүзне тәнкыйтьче Әхмәт Сәхәпов язган.

ХАЛИКОВ Хәкимҗан. **Бәхет чишмәсе.** *Шигырьләр, табышмаклар, әкиятләр.* Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1994 ел, 144 бит.


Танылган шагыйрь Хәкимҗан Халиковның яңа китабы балалар өчен иҗат ителгән әсәрләрдән төзелгән. Ул «Матур буласым килә», «Кем тизрәк чаба?», «Табигатькә сәяхәт», «Борын-борын заманда» һәм «Җырларга да оста без» дигән бүлекләрдән тора.

Китап татар балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр һәм мәктәп укучылары өчен менә дигән бүләк булыр.



Бәясе 1100 сум

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог